# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 6*
*июнь*
*2015*
*(II өлеш)*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
СОВЕТЫ РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
2015

**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60х84 1/16. Тираж 32 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2015

## Эчтәлек

# I

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

521. «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....4

522. «2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү стратегиясен раслау турында» *Татарстан Республикасы Законы* ...255

523. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....334

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 521. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен әлеге Закон кушымтасы нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 17 июне
№ 40-ТРЗ

*Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.*



«2030 елга кадәр
Татарстан Республикасын
социаль-икътисадый үстерү
стратегиясен раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

### 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе

**Гомуми нигезләмәләр**

2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен (алга таба – Стратегия) эшләүнең норматив-хокукый нигезе – «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 172-ФЗ) һәм «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Стратегиядә төп стратегик максат куела: Татарстан-2030 – глобаль конкурентлыкка сәләтле тотрыклы регион, «Идел-Кама» үсеш полюсы драйверы (үсешнең төп чыганагы). Татарстан – кеше капиталының, институтларның, инфраструктураның, икътисадның, тышкы интеграциянең (Россиянең үзәк Евразия регионы) һәм эчке пространствоның үзара тыгыз бәйләнештә үсешенең сыйфаты буенча лидер; алда бара торган темплар белән үсә торган, халыкара эш бүленешенә югары дәрәҗәдә кушылган регион.

Стратегиянең үзәгендә – кеше, һәм аның тирәли Стратегиянең түбәндәге өч приоритеты төркемнәргә туплана: кеше капиталын булдыру һәм туплау; кеше капиталын үстерү өчен уңайлы пространство булдыру; икътисадта кеше капиталына ихтыяҗ булган һәм уңышлы эшли ала торган иҗтимагый институтлар булдыру. Икътисадый сәясәт, беренче чиратта, шартлар тудыру буларак карала, монда кеше талант иясе буларак ачылырга мөмкин. Бу инновация, инвестиция һәм кластер сәясәтләрендә дә мөһим акцент.

Стратегия, иң заманча тикшеренүләрне, теорияләрне һәм дөньякүләм тәҗрибәне исәпкә алып, алдынгы Россия һәм чит ил белгечләрен җәлеп итеп әзерләнде.

Татарстан Республикасында Стратегияне булдыруга кулланылган карашка түбәндәге үзенчәлекләр хас:

1) үз өлкәсендә иң яхшы компетенцияле оешмаларны берләштергән һәм махсус тикшеренүләр үткәрүне кертеп, Стратегияне һәрьяклап эшләүне тәэмин иткән халыкара консультантлар консорциумын оештыру;

2) эшче очрашулар, интервьюлар, киңәшмәләр, проект семинарлары һәм сессияләре аша бөтен кызыксынган катнашучыларны җәлеп итү мөмкинлеген биргән стейкхолдерларның (кызыксынган затларның һәм төркемнәрнең) ачык булуының һәм коммуникацияләрнең тиңдәшсез масштабы. Тармак, территориаль һәм конкуренция юнәлешләре буенча 13 проект мәйданчыгы эшләде. Http://tatarstan2030.ru махсус сайтында тиз арада хисаплар, проблемалы язмалар, документлар проектлары, эксперт фикерләре урнаштырылды. Әзерләү чорында ике ел вакыт дәвамында 40тан артык чара уздырылды, аларда 2,5 меңнән артык кеше катнашты;

3) концептуаль һәм операциональ дәрәҗәләрне берләштерү. База принципларын һәм үсеш идеяләрен эшләү һәм зур флагман проектларны формалаштыру белән беррәттән, предприятиеләргә тикшерү үткәреп, беренчел мәгълүматны җыю һәм анализлау буенча гаять зур эш башкарылды, бу Стратегияне гамәлгә ашыруның чаралар планына тәкъдимнәрне аныкларга мөмкинлек бирде;

4) үсешнең пространство аспектларын тирәнтен эшләү, бу социаль-икътисадый һәм территориаль планлаштыру документлары арасында концептуаль һәм вакыт өзеклеген киметергә мөмкинлек бирде;

5) республика киләчәген тасвирлау һәм аны дөньякүләм дәрәҗәдә тәкъдим итү өчен терминнарның яңа җыелмасын булдыру («Идел-Кама» үсеш полюсы, Идел-Кама метрополисы, Казан, Кама һәм Әлмәт икътисадый зоналары һәм агломерацияләре, «Идел-Кама ташкыны» экозонасы, Татарстан технологик инициативасы, кластер активлаштыру, «Татарстан 7+6+3» моделе һ.б.);

6) Стратегияне һәм аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган документларны әзерләүне бердәм процесска берләштерү. Әзерләү эшенә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын тыгыз интеграцияләү;

7) Стратегия әзерләүне һәм 2017 елның 1 гыйнварына кадәр күчмә чор билгеләгән 172-ФЗ нигезендә стратегик планлаштыруның яңа системасын булдыруны берләштерү. Россия Икътисадый үсеше министрлыгының әзерләнә торган методик тәкъдимнәрен исәпкә алып 2016 – 2017 елларда Стратегияне яңарту һәм үзгәртү ихтималлыгы;

8) Стратегияне гамәлгә ашыруга идарә итү мәсьәләләренә игътибар: республика үсеш институтлары системасын ныгыту, Стратегияне гамәлгә ашыруны мониторинглауның структурасын, шәһәр агломерацияләре кысаларында үсешне координацияләү органнарын билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Махсус эшләнгән интеграцияләү схемасын – «Татарстан 7+6+3» моделен куллануның методик үзенчәлеге стратегик анализның, регионның һәм аның предприятиеләренең конку-



рентлык сәләтен үстерүгә юнәлдерелгән идарә итү системасының максатларын билгеләү һәм аны төзү логикасыннан гыйбарәт. Модель төп идеяне – Татарстанның үсеш полюсларының дөньякүләм регионара конкуренциядә алдынгы урыннар өчен көрәштә катнашуын чагылдыра, аларда конкурентлыкка сәләтле икътисадый комплекслар һәм кластерлар үстерелә, капиталларны җәлеп итү һәм тотып калу өчен шартлар тудырыла (А рәсеме).

Модель регионны ике дәрәҗәдә карауны берләштерә: тышкы, ул, региональара конкуренциянең **җиде** юнәлешеннән чыгып, Татарстанның башка регионнарга карата конкурент позицияләрен чагылдыра, һәм эчке, ул, өч шәһәр агломерациясе тирәсендә булдырыла торган **өч** икътисадый зонадан чыгып, **алты** төп икътисадый комплекс структурасын (аларның һәрберсендә үсеш кластерларын һәм проектларын бүлеп) тасвирлый.

Конкуренциянең җиде юнәлеше бизнеска карата да (предприятиеләргә, хуҗалык комплексларына) һәм регионга карата да кулланылырга мөмкин, бу үзара бәйле процессларны – регионнарның һәм предприятиеләрнең конкуренциясен өйрәнгәндә һәм тасвирлаганда модельне уңайлы инструмент итә (А таблицасы).




**А рәсеме. Глобаль конкуренциядә Татарстан («Татарстан 7+6+3» моделе)**

Искәрмә. Модель регионара һәм глобаль конкуренция һәм территориаль үсеш теориясе классиклары Ф. Перру, М. Портер, Й. Шумпетер һ.б. карашларын үстерү нигезендә AV Group эшләгән «AV Region Galaxy Model»нең гомумиләшкән методикасын конкретлаштыру булып тора.

Регионара конкуренция юнәлешләре буенча регионнарны аерым билгеләү һәм чагыштыру еш кына авыр булганга күрә, предприятиеләр казанышлары регионда тудырылган гомуми шартларның нәтиҗәсе дигән гипотезадан чыгып, предприятиеләр (икътисадый комплекслар) эшчәнлегенең тиешле күрсәткечләре кулланыла.

**А таблицасы. Регионнар/предприятиеләр конкуренциясенең җиде юнәлешенең максатлары**

| Юнәлеш исеме (регион/предприятие) | Региональ дәрәҗә | Предприятие дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| **Продукция һәм хезмәт күрсәтүләр базарлары** | Специальләшүнең региональ тармакларының үз базарларында конкурентлык сәләте. Җирле предприятиеләр продукциясен тышкы базарларга чыгару өчен иң яхшы шартлар | Сатулар күләме һәм базар өлеше |
| **Институтлар/ Идарә итү** | Хосусый, дәүләт һәм дәүләт-хосусый институтларның һәм идарә итү механизмнарының сыйфаты. Эшкуарлыкны үстерүнең югары дәрәҗәсе. Административ ресурслардан файдалануның аңлаешлы булуы | Фирма эчендә нәтиҗәле идарә итү |
| **Кеше капиталы/ Персонал** | Кеше капиталына ия булучыларны җәлеп итү һәм тотып калу өчен иң яхшы шартлар. Социаль хезмәт күрсәтүләрнең югары сыйфаты | Мотивацияләнгән квалификацияле хезмәткәрләр |
| **Инновацияләр и мәгълүмат/ Технологияләр** | Инновацияләрнең иң яхшы экосистемасы. Телекоммуникация инфраструктурасының югары сыйфаты | Алдынгы технологияләр һәм яңа продуктлар эшләү һәм сатып алу |
| **Табигый ресурслар/ Чимал** | Табигый ресурслардан экологик иминлекне саклап файдалану өчен иң яхшы шартлар тәэмин итү | Чималдан һәм җир ресурсларыннан файдалану |
| **Реаль капитал/ Матди активлар** | Бизнесны һәм халыкны җәлеп итә торган физик инфраструктураның һәм пространствоның югары сыйфаты | Төп фондларның тәэмин ителеше һәм алардан нәтиҗәле файдалану |
| **Финанс капиталы** | Финанс институтларын үстерү шартлары. Тышкы инвестицияләрне җәлеп итүнең иң яхшы инструментлары. Федераль һәм региональ инвестицияләрне нәтиҗәле кертү | Финанс ресурсларының тәэмин ителеше һәм алардан нәтиҗәле файдалану |

Татарстан Республикасы социаль-икътисадый комплексының эчке структурасы «Татарстан 7+6+3» моделе белән тасвирлана һәм статистик күрсәткечләрнең тиешле җыелмасы булып түбәндәгечә чагылдырыла:

- тулаем республика;



- өч икътисадый зона: Казан, Кама һәм Әлмәт;
- алты төп икътисадый комплекс: дүрт җитештерү (нефтьгаз химиясе комплексы, энергетика комплексы, машиналар төзү һәм башка эшкәртү сәнәгате комплексы, агросәнәгать комплексы) һәм ике тәэмин итүче (инфраструктура комплексы һәм хезмәт күрсәтүләр комплексы), алар 17 һәм алга таба 60 ярдәмче комплексына һәм тармакка кадәр детальләштерелә (икътисадый комплекслар структурасы 1 кушымтада бирелде);
- тармакара кластерлар;
- куелган икътисадый һәм социаль максатларга ирешүне тәэмин итә торган чаралар һәм проектлар.

## 1. Стратегик анализ: төп нәтиҗәләр

### 1.1. Тышкы мохитнең үсеш тенденцияләре — стратегик мәсьәләләр

#### 1.1.1. Дөньякүләм үсешнең глобаль тенденцияләре

Без яңа дөнья алдында басып торабыз. Бу дөнья — технологияләрнең һәм кешеләр үзләре өчен өстенлекле итеп күргән нәрсәләрнең ашкынып үзгәрә торган дөньясы, зуррак волатильлек һәм икътисадтагы билгесезлек дөньясы, базарга өр-яңа катнашучылар килү сәбәпле конкуренция көчәю дөньясы, бизнесны җайга салуда таләпчәнлек арту һәм аның рентабельлелеге кимү дөньясы. Бу дөньяда кеше төп активка әйләнә. Конкуренциянең макродәрәҗәдән (дәүләтләр арасындагы конкуренция) мезодәрәҗәгә (үсеш полюслары арасында конкуренция) күчү дөньясы.

Хәзерге көндә дөньякүләм икътисад үсешенең түбәндәге төп глобаль тенденцияләре һәм факторлары бар, аларны озак сроклы үсеш стратегияләрен эшләгәндә исәпкә алырга кирәк (тенденцияләр конкуренциянең җиде юнәлеше буенча төркемләнә).

***Продукция һәм хезмәт күрсәтүләр базарлары***

- Тотрыклы үсеш моделенә (Sustainable Development) күчү, бу очракта бүгенге заман ихтыяҗларын канәгатьләндерү киләчәк буыннар ихтыяҗларына зыян китермичә башкарыла.
- Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләре халкының артуы исәбенә Җир шары халкының шактый артуы (фаразлар буенча 2030 елга 10 млрд. кешегә кадәр).
- Үсешләрендә алга киткән, күпчелек очракта «Егермелек төркеме»нә (G20) керүче илләрнең, шулай ук тиз үсә торган, BRICS+11 һәм Growth Markets керә торган илләрнең (Филиппины, Мисыр, Нигерия, Төркия, Вьетнам, Пакистан, Иран, Бангладеш, Малайзия, Сингапур, Гонконг, Тайвань) үсеш алдынгылары позицияләрен тотуы.

• Глобаль конкуренцияне көчәйтүне һәм халыкара кооперацияне актив үстерүне берләштерү исәбенә яңа регионнар — үсеш полюслары булдыру. Үсештә алдынгылыкның аерым дәүләтләрдән регионнарга — үсеш полюсларына күчүе, алар, кагыйдә буларак, шәһәр агломерацияләре тирәсендә булдырыла.

• Икътисадый активлык үзәгенең Азиягә күчүе: Азия Кытай һәм Һиндстан җитәкчелегендә җитештерүнең һәм куллануның дөньякүләм үзәге булачак. Фаразларга караганда, 2030 елга Кытай икътисад зурлыгы буенча дөньяда беренче булачак.

• Урта сыйныфның глобаль үсеше: үсә торган илләрдә урта сыйныфка караган халыкның саны артуы.

• Массакүләм куллану җәмгыяте идеологиясенең киң таралуы һәм бер кешегә исәпләнгән ресурсларны куллануның дәрәҗәсе артуы. Әмма монда үз ихтыяҗларын белә торып чикләүче «тотрыклы» кулланучылар катлавы да барлыкка килә.

• Хезмәт күрсәтүләр базарының алга таба үсеше (монда алдынгылар — үсешләрендә алга киткән илләр). Медицина хезмәт күрсәтүләре базарының халыкның глобаль картаюына бәйле үсеше. Яңа икътисадның югары квалификацияле белгечләргә ихтыяҗы артуга һәм белем бирүдә мәгълүмати-коммуникация технологияләр киң кулланылуга бәйле рәвештә белем бирү хезмәт күрсәтүләре базарының үсеше.

• Үсә торган эре икътисадлардагы халыкның тормышы яхшырганга күрә, үсә торган илләрнең эчке базарларының җитди үсеше.

• Товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне төп кулланучылар буларак хатын-кызларның һәм өлкәннәрнең өлеше артуы.

***Институтлар***

• Дөньяның үзгәрү темпларының тизләнүе, ул «иҗади таркалу» процессын — искергән һәм яшәүгә сәләтсез элементларны юкка чыгаруга һәм икътисадый структураларны яңартуга алып бара торган, яңа мәсьәләләр һәм мөмкинлекләр нигезендә үсеш юлларын эшкуарлар тарафыннан даими рәвештә яңадан аңлау процессын тизләтә.

• Региональ блокларны киңәйтү һәм дәүләтнеке булмаган субъектларның — трансмилли корпорацияләрнең, кланнарның, дини оешмаларның һ.б. чагыштырмача хакимиятенең артуы исәбенә глобаль күпкырлы системаның барлыкка килүе.

• Иң әһәмиятле сәяси, икътисадый һәм финанс мәсьәләләре буенча халыкара хезмәттәшлекнең әйдәүче форумы буларак «Егермелек төркеме» (G20) роленең көчәюе.

• БМО, Халыкара валюта фонды һәм Бөтендөнья банкы кебек халыкара хезмәттәшлекнең глобаль системаларында Көнбатышның өстен булу дәрәҗәсе кимүе, шулай ук әлеге институтларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны яңарту.



• Хакимиятнең ачык булуын арттыру — Ачык хөкүмәт булдыруга ирешү.

• Урта сыйныфның артуына һәм ярлылыкта яшәүче кешеләрнең саны кимүгә бәйле рәвештә гражданн җәмгыятенең йогынтысы көчәюе.

• Илләрнең һәм регионнарның конкурентлык сәләтенең иң әһәмиятле факторларының берсе буларак институтлар сыйфатының әһәмиятен тану.

• Идарә итүнең катгый системаларыннан гармонияле институциональ мохит нигезендә тышкы һәм эчке йогынтыларга динамик рәвештә җавап бирә торган «йомшак»ларына күчү. Конкурентлык сәләтен арттыру механизмнарын һәм үсешне финанс-икътисадый модельләштерү инструментларын үз эченә алган стратегик идарә итүнең яңа системаларына ихтыяҗ.

***Кеше капиталы***

• Киләчәк икътисадын үстерүнең озак сроклы факторлары арасында кеше капиталының беренче урынга чыгуы (табигыйресурс, реаль һәм финанс капиталы белән чагыштырганда).

• Индивидуаль мөмкинлекләрне үстерү темпларының тизләнүе. Кеше үз-үзен үстерүче мобиль актив буларак глобаль дөньяның субъектына әйләнә.

• Конкрет кешенең таланты тирәсендә эшли торган компанияләр саны артуы.

• Хезмәтнең техник яктан кораллануын көчәйтү һәм нәтиҗәлелекне арттыру алымнарын һәм технологияләрен үстерү исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру.

• Белем бирү сыйфатын үстерү, ул яңа технологияләрдән файдалануга һәм белем бирүдә мәгълүмати-коммуникация технологияләрен киң куллану мөмкинлекләренә бәйле рәвештә хезмәт шартларының үзгәрүенә бәйле.

• Кешеләрнең шәхси тормышы һәм эш арасындагы чикләрнең бетүе.

• Хезмәттәшлекне тоткарлый торган фактор буларак ераклык роленең кимүе.

• Дини кыйммәтләрнең һәм институтларның роле артуы.

• Балалар үлеменең кимүе.

• Авырлыгы артык булган кешеләр санының артуы.

• Хатын-кызларның хөкүмәттә һәм бизнеста менеджер функцияләрен акрынлап тартып алуы.

• Халыкның глобаль картаюы (бигрәк тә үсешләрендә алга киткән һәм тиз үсә торган илләрдә. «Яңа буынның өлкәнәюе акрынаюы» факторы («Питер Пен» синдромы). Олы яшьтәге кешеләргә эшләү өчен шартлар тудыру.

• Үсә торган илләрнең бай һәм белемле гражданнарының бер өлешенең ватанга кайтуы, бу үсә торган икътисадларның конкурентлык сәләтен арттырырга ярдәм итәчәк.

• Ярлы илләрдән (регионнардан) баерак илләргә халыкның хезмәт миграциясе көчәюе (шул исәптән, үсешләрендә алга киткән илләрдә чиста иммиграциянең еллык дәрәҗәсе артуы, бу хезмәткә сәләтле халык санының кимүен компенсацияли). Регион-донорлар: Африка, Азиянең үсә торган илләре, Латин Америкасы һәм БДБ; регион-реципиентлар: Төньяк Америка, Европа, азрак дәрәҗәдә – Якын Көнчыгыш һәм Азиянең үсешләрендә алга киткән илләре.

***Мәгълүмат һәм технологияләр***

• Күпсанлы традицион үсеш факторларының (индустриягә кадәрге тармакларга һәм җитештерү факторларын (эшче көчләр, ягулык, электр энергиясе) түбән бәяләүгә акцент ясауга нигезләнгән икътисадый үсешнең ресурс моделе потенциалы бетүе) йогынтысы кимегәндә икътисадый үсешнең төп инструментлары буларак инновацияләрнең һәм модернизацияләүнең әһәмияте артуы.

• Бишенче технологик торышны (аның нигезендә мәгълүмати технологияләр алдынгылыгы) алга таба нрыгытып, алтынчысын (нано- һәм биотехнологияләрнең алдынгылыгы), ә соңыннан җиденче технологик торышны (когнитив технологияләрнең алдынгылыгы) үстерүгә күчү.

• Алга киткән технологияләрнең актив үсеше:

• ясалма интеллект (үзара «интернет әйберләр» / «бөтен нәрсәне дә колачлый торган интернет» технологияләре нигезендә эшләүче интеллектуаль машиналар һәм компьютер программаларын булдыру фәнен һәм технологияләрен үстерү һәм аларның мөмкинлекләрен киңәйтү);

нанотехнологияләр;

биотехнологияләр;

мәгълүмати технологияләр;

когнитив технологияләр;

социогуманитар технологияләр;

аддитив технологияләр (3D-Printer).

• Хәзерге икътисадның үсешләрендә алга киткән илләрдә булдырылган технологик торышын үсә торган илләргә актив күчерү нәтиҗәсендә технологик үзәкнең Көнбатыштан акрынлап Көнчыгышка һәм Көньякка күчүе (АКШның алдынгы булуын саклап калып). АКШтагы реиндустриализацияләү, аның барышында Америка компанияләренең күбесе производстволарын үсә торган илләрдән кире кайтара.

• Тикшеренүләргә һәм эшләүләргә чыгымнарның артуы.

• Мәгълүмат күләменең берничә тапкырга артуы. Глобаль белемнәрнең портативлыгы.

• Глобаль социаль челтәрләрнең үсеше һәм җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә аларның роле көчәюе.

• Краудсорсингның үсә баручы роле.

• Мәгълүматны башка телләргә оператив автоматлаштырылган тәрҗемә итү чараларын үстерү, бу кешеләр арасындагы тел киртәләрен бетерәчәк һәм аралашу нәтиҗәлелеген сизелерлек арттырачак.

• Космос программаларын киңәйтү.

• Сәламәтлек саклау һәм геномика өлкәсендә яңа технологияләр үстерү, алар куркыныч авыруларның таралу дәрәҗәсен киметүне һәм гомер озынлыгын арттыруны тәэмин итәргә мөмкин.

• Икътисадны интеллектуальләштерү: «акыллы» һәм экологик чиста технологияләр үстерү, «акыллы» мохитләр, «акыллы» системалар һәм «акыллы» производстволар (транспорт системалары, энергия белән тәэмин итү системалары, җитештерү системалары, йортлар, кибетләр, шәһәрләр һ.б.) булдыру.

• Сәнәгатьнең алдынгы тармаклары өлкәсендә глобаль синхронлаштыру.

• Компьютер һәм мәгълүмати мохитләр һәм системалар эволюциясе, шулай ук менеджмент өлкәсендә ноу-хауларны камилләштерү нәтиҗәсендә кире инжиниринг тизлегенең артуы (базарга уңышлы чыккан продуктны анализлау, аның структурасын, дизайнын, аны җитештерү технологиясен һәм ысулларын өйрәнү). Базарда яңа продукт чыгу белән аны анализлауны һәм базар өлешен оту максатларында азрак чыгымнар белән аның аналогын чыгаруны күздә тоткан модельнең гамәлгә ашырылуын арттыру.

• «Яшел» икътисадны – ресурслардан нәтиҗәле файдалана торган һәм бөтен җәмгыять мәнфәгатьләренә җавап бирә торган, углерод кушылмаларын аз чыгара торган икътисадны үстерү (табигать мохитенә тискәре йогынтының масштабларын киметү, шулай ук углеводород чималына бәйлелекне һәм ахыргы продукт бәясендә аның өлешен киметү исәбенә үсешләрендә алга киткән икътисадларның конкурентлык сәләтен арттыру).

• Ресурслар һәм энергия саклауның нәтиҗәле технологияләрен детальле һәм системалы эшләү.

***Табигый ресурслар***

• Дөньякүләм икътисадның якындагы 30 — 50 елга төп сәнәгый минералларның расланган запаслары белән тәэмин ителеше.

• Халыкның гомуми артуы һәм урта сыйныфның үсеше белән берлектә икътисадый үсеш дәвам иткәнгә күрә, энергиясе булган әйберләрнең, азык-төлекнең һәм чиста төче суның кирәклеге артуы. Күрсәтелгән ресурслар кытлыгының көчәюе.

• Беренчел энергия чыганагы буларак казылма ягулыкның өстен булу әһәмияте саклануы (2030 елга энергия тотуның дүрттән өч өлешеннән артыгын тәэмин итү). Нефтьне куллану-дан акрынлап табигый газдан, күмердән һәм башка алмаштыргычлардан файдалануга күчү.

• Энергетикадагы «сланец революциясе» (сланец углеводородларын икътисадый яктан нәтиҗәле сәнәгый чыгару), бу якынча 2 — 3 унъеллыкка нефтьнең һәм газның икътисадый яктан акланган ресурсларын бетерү куркынычын чигерергә мөмкинлек бирде һәм дөньякүләм энергетиканың башлыча углеводород характерын озайтты. Дөньякүләм энергетик ландшафтын һәм энергия ресурсларының перспектив сәүдә ташкыннарын иң элек киметелгән табигый газ (СПГ) ташкыннарын яңадан бүлү өлешендә үзгәртү. Энергия ресурслары базарлары аз гына үзгәртелгәндә алдынгы катнашучылар көчләренең нисбәте сизелерлек дәрәҗәдә яңадан бүленәчәк, ә кайбер глобаль уенчылар йогынты ясауның өстәмә мөмкинлекләрен алырга мөмкин. Сланец углеводородларының иң күп запасларына ия Төньяк Америка илләре һәм (катгый экологик стандартлар белән кыенлаштырылган) Кытай тарафыннан аларны чыгару уңышлы үстерелгән очракта, Россия традицион энергетика базарларыннан өлешчә чыгарылырга мөмкин. Шуның белән бергә, сланец углеводородларын чыгару үсешенең перспективалары һәм аның дөньякүләм энергетика базарына тәэсире дәрәҗәсе фараз чорына нефтьнең дөньякүләм бәяләре динамикасына, шулай ук төп уенчыларның (АКШ, Кытай) сланец углеводородларының запасларын бәяләвен төгәлләштерүгә бәйле. Чикләүләр чыгаруның үзкыйммәте югары булуына, ресурслар чыгаруның түбән коэффициентына һәм зур экологик куркынычларга бәйле.

• Энергия җитештерүнең бәясе түбәнрәк булган, иминлек характеристикалары югары булган һәм атом төш калдыклары һәм атом төш материалларының таралу куркынычы ягыннан характеристикалары иң яхшы булган проектларга ия өченче һәм аннан соңгы буын конкурентлыкка сәләтле атом төш реакторларын куллану нигезендә электр энергиясен җитештерүне арттыру исәбенә атом энергетикасын үстерү.

• Климатның акрынлап глобаль үзгәрүе, бу кайбер ресурсларның (төче су, уңдырышлы туфраклар) кытлыгын көчәйтәчәк, әмма Россия һәм Канада төньягындагы, шулай ук Арктикада континенталь шельфтагы ягулык-энергетика ресурсларының шактый зур запасларыннан файдалануны арттырачак.

• Әйләнә-тирә мохиткә зарарлы чыгарулар күләменең үсеше һәм көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары күләменең артуы, болар табигатьтән рациональ файдалануны һәм калдыкларсыз, экологик чиста технологияләрне гамәлгә кертүне стимуллаштыра.

• Дөнья океаны ресурсларын үзләштерү темпларын арттыру.

***Реаль капитал***

Урбанизация: агымдагы тенденцияләр сакланганда 2030 елга дөнья халкының 60 процентка якыны шәһәрләрдә яшәячәк.

Яшәү, үстерү һәм инвестицияләү өчен регион сайлауга тулаем алганда инфраструктура һәм пространство сыйфаты йогынтысы үсеше.

Энергетика инфраструктурасын үзгәртеп кору (табигый газ, күмер һәм энергиянең альтернатив чыганакларын куллануга күчү максатларында).

«Өзлексез транспорт» (кулланучы фикеренчә, бердәм булып эшләү мөмкинлеген бирүче транспортның төрле төрләрен һәм типларын интеграцияләү) һәм нәтиҗәле логистика үсеше. Булган транспорт системаларының реинжиниринглы һәм мобильлек концепцияләрен үзгәртү нигезендә аларны системалы интеграцияләү. Индивидуаль мобильлекнең яңа сыйфатын тәэмин итә торган, күчүләрне һәм сәяхәтләрне интеллектуаль технологияләр белән интеграцияләү нигезендә мультимодаль транспорт системалары үсеше.

***Финанс капиталы***

• Илләр арасындагы һәм регионара конкуренцияне иң яхшы инвесторлар исәбенә, бизнес алып бару, яшәү һәм ял итү өчен максималь уңайлы шартлар тудыру юлы белән катгыйландыру.

• Белемнәр һәм технологияләр трансферының төп факторы буларак турыдан-туры инвестицияләрнең роле артуы. Акционер һәм бурыч капиталы базарының үсеше, кредит базарының үсеше.

• Дәүләт-хосусый партнерлык принципларында финанслау инструментларын куллануны киңәйтү.

• Үсешләрендә алга киткән илләрдә бурыч йөкләмәсенең үсеше һәм «глобаль дисбаланслар» проблемасы (суверен заем алучылар валютада бирелгән кредит валютасының эмитентлары булганда).

• Глобаль икътисадта җыйган акчалар кытлыгының артуы (озын акчаларга ихтыяҗ сакланганда озын пассивларның җитмәве), бу, шул исәптән, финанс кризисы вакытында активларны югалтуга бәйле рәвештә пенсия фондлары ресурслары кимүгә һәм бер пенсионерга исәпләнгән эшләүчеләр саны кимүгә бәйле.

• Дәүләт һәм тышкы инвесторлар исәбенә гамәлгә ашырыла торган инвестицияләр өлешенең артуы.

• Капиталның үсешләрендә алга киткән базарлардан үсә торганнарга хәрәкәте.

• Уникаль төп халыкара валюта буларак Америка доллары әһәмиятенең акрынлап кимүе.

### 1.1.2. Макроикътисадый фараз

Озак сроклы перспективага фараз төзү билгесезлекнең зур куркынычларына бәйле, алар озак чор дәвамында дөньякүләм базардагы хәлне тамырыннан үзгәртә торган сәяси һәм (яисә) икътисадый вакыйгалар булу ихтималы белән аңлатыла.

Алдынгы аналитик үзәкләр һәм халыкара оешмалар әзерләгән 2030 ел чорына кадәр дөньякүләм икътисад үсеше фаразлары дөньяның төп икътисадлары үсешен түбәндәгечә күзаллавын күздә тота:

• 2028 елга Кытай АКШны узып китәчәк һәм дөньяның иң эре икътисадына ия булачак, әмма бу 2022 елдан да иртәрәк булмаячак, чөнки АКШ икътисадны элеккечә үстерәчәк, ә Кытай икътисадының үсеш темплары акрынаячак.

• 2028 елга Һиндстан Японияне узып китеп, зурлыгы буенча дөньяның өченче икътисадына ия булачак. Һиндстанның тулаем эчке продукты 6,5 трлн. Америка долларыннан артачак, ә рейтингта дүртенче урында торачак Япония икътисадының күләме 6,4 трлн. Америка долларын тәшкил итәчәк.

• Бразилия Бөек Британияне һәм Германияне узачак һәм зурлыгы буенча дөньяның бишенче икътисадына ия булачак. Германия һәм Бөек Британия 2028 елга рейтингның алтынчы һәм җиденче урыннарын алачак. 2030 елга Бөек Британия Германияне узып китәчәк һәм Европаның иң эре икътисадына әйләнәчәк. Фараз нигезендә, 2028 елга Бөек Британиянең тулаем эчке продукты 4,3 трлн. Америка долларына, ә Германия икътисады 4,4 трлн. Америка долларына җитәчәк.



• Россия 2028 елга 4,1 трлн. Америка доллары күләмендәге тулаем эчке продукты белән иң эре икътисадлар рейтингында сигезенче урында калачак. 2018 елда Россия алтынчы урынга менә алачак, әмма аннары хәзер урнашкан сигезенче урынга төшәчәк.

• 2028 елга Төркия икътисады, Францияне һәм Италияне узып китеп, 3,4 трлн. Америка доллары күләмендәге тулаем эчке продукты белән Европаның иң эре икътисадларының берсенә әйләнергә мөмкин.

• Илләр һәм халыкара икътисадый оешмаларның макроикътисадый фаразлары нигезендә Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан әзерләнгән дөньякүләм икътисад үсешенең озак сроклы фаразына түбәндәге төп нигезләмәләр керә (1.1 нче таблица):

• 2014 – 2030 еллар чорында халык үсешенең көтелгән кимүе факторлары тәэсирендә дөньякүләм икътисадның динамикасы акрынаячак, ә хезмәт җитештерүчәнлегенең өлеше үсешне тоткарлау факторларын компенсацияләмәячәк. Нәтиҗәдә 2014 – 2030 еллар чорында дөньякүләм икътисадның үсеше уртача 3,4 процент тәшкил итәчәк, бу 1995 – 2010 еллардагы үсеш темпларыннан (4 процент дәрәҗәсендә) шактый түбән.

• 2030 елда дөньякүләм икътисадның күләме 2014 ел белән чагыштырганда 1,7 тапкырга артачак.

• Озак сроклы перспективада үсешнең демографик киртәсенең роле артачак. Бу икътисадый үсеш мөмкинлекләрен җитди тоткарлаячак.

• Төп сценарий буенча 2014 – 2030 елларда үсешләрендә алга киткән илләр икътисадының елына уртача 2,2 процентка артачагы күздә тотыла. Дөньякүләм икътисадның гомуми күләмендә Еврозона, АКШ һәм Япониянең чагыштырма авырлыгы 2013 елгы 33 проценттан 2030 елда 25 процентка кадәр кимиячәк.

• АКШ икътисадының үсеше шактый югары булып калачак. 2014 – 2030 елларда икътисад елына уртача 2,2 процентка артачак. XXI гасырның икенче унъеллыгы уртасыннан хезмәткә сәләтле яшьтәге халык саны артуының акрынаюы көтелә. АКШта хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеше фараз чорында инвестицияләр үсешенә һәм җыйган акча нормаларын арттыруга таяначак. 2030 елга җитештерү динамикасы үсеш траекториясенең ике процентына якынаячак.

• Еврозона халкының картаю тенденциясе белән аңлатыла торган көчлерәк демографик чикләүләр Европа икътисадының үсешен тоткарлаячак: 2014 – 2030 еллар чорында үсешнең уртача еллык темплары 1,5 процентка артмаячак. Икътисадый актив халык үсешенең уртача еллык темпы шактый кимиячәк:

1991 — 2010 еллар чорындагы уртача 0,8 процenттан алып 2014 — 2030 еллар чорында 0,1 процентка кадәр. Икътисад үсеше хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеше уртача 1,0 — 1,2 процентка тизләнүе белән тәэмин ителәчәк.

• Халыкның үсеше акрынаюы һәм аның картаюы икътисадый үсешне үсә торган илләрдә дә тоткарлап торачак.

• Кытай икътисадының үсеше 2030 елга кадәрге чорда акрынаячак һәм 1980 — 2010 еллардагы уртача еллык үсешенең 10 проценты белән чагыштырганда елына уртача 5,5 процент тәшкил итәчәк. Кытайның өстенлеге булып торган уникаль демографик хәл акрынлап үсешне тоткарлый торган факторга әйләнәчәк. Шул ук вакытта, төп дәрәҗәнең чагыштырмача югары булмавын исәпкә алып, хезмәт җитештерүчәнлеге үсешенең уртача еллык темплары үсешләрендә алга киткән илләрнекенә караганда шактый югары булачак: елына уртача 5 процент дәрәҗәсендә.

• Һиндстан һәм Бразилия 2030 елга кадәр эш белән тәэмин итү үсешенең яхшы потенциалын саклап калачаклар, аның темпы елына уртача 1,4 процентка якын булачак. 2030 елга Һиндстанда эш белән тәэмин итү Кытайдагы дәрәҗәгә якынаерга мөмкин. 2014 — 2030 еллар чорында Һиндстан икътисадының үсеше уртача 5,9 процент дәрәҗәсендә фаразлана, ә БРИК илләренең динамикасы тулаем алганда 5 процент темп белән фараз ителә.

• Икътисадый глобаль үсешкә башлыча үсә торган илләр, иң элек Кытай һәм Һиндстан исәбенә ирешеләчәк, 2013 — 2030 еллар чорына аларның өлешенә бөтен дөньякүләм үсешнең 40 проценты туры киләчәк. 2010 елда шушы ике илнең икътисадлары тулаем алганда дөньякүләм чыгаруның 20 процентын тәэмин иттеләр, 2020 елда аларның күләме дөньякүләм тулаем тышкы продуктның 25 процenттан артыгын тәшкил итәчәк, ә 2030 елга — 30 процenттан артачак.

• Үсә торган икътисадларның үсеше акрынаюга карамастан, алар һәм үсешләрендә алга киткән илләр арасында керемнәр дәрәҗәсендәге өзеклек кимиячәк. 2013 елда Кытайда һәм Һиндстанда сатып алу сәләте паритеты буенча бер кешегә исәпләнгән тулаем эчке продукт АКШ дәрәҗәсеннән тиешенчә 22 процент һәм 10 процент тәшкил иткән булса, 2020 елда бу күрсәткеч тиешенчә 30 процентка һәм 12 процентка кадәр артачак. 2030 елга Кытайда һәм Һиндстанда бер кешегә исәпләнгән тулаем эчке продукт АКШ дәрәҗәсеннән тиешенчә 40 процент һәм 18 процент тәшкил итәчәк.



**1.1 нче таблица. Дөньякүләм икътисадның үсеш темплары (Россия Федерациясе Икътисадый үсеше министрлыгы мәгълүматы буенча), процентларда**

| Регион /күрсәткеч | 2012 | 2011-2015 | 2016-2020 | 2021-2025 | 2026-2030 | 2030/2014, тапкыр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дөнья | 3,4 | 3,6 | 3,9 | 3,4 | 3,2 | 1,7 |
| АКШ | 2,3 | 2,2 | 2,5 | 2,0 | 2,1 | 1,4 |
| Дөньяда АКШның өлеше* | 16,6 | 16,3 | 14,5 | 14,4 | 13,5 | |
| Еврозона | -0,7 | 0,6 | 1,6 | 1,6 | 1,5 | 1,3 |
| Дөньяда Еврозонаның өлеше* | 12,7 | 12,3 | 10,9 | 9,9 | 9,0 | |
| Япония | 1,5 | 1,0 | 1,0 | 0,9 | 0,8 | 1,2 |
| Дөньяда Япониянең өлеше* | 4,7 | 4,6 | 4,0 | 3,5 | 3,1 | |
| Кытай | 7,7 | 7,8 | 6,4 | 5,1 | 4,2 | 2,3 |
| Дөньяда Кытайның өлеше* | 15,2 | 15,6 | 17,1 | 20,0 | 21,2 | |
| Искәрмә: *Сатып алу сәләте паритеты буенча. | | | | | | |

2030 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы 2014 — 2030 елларда икътисадый үсешнең 2,1 процент[1] дәрәҗәсендәге төп траекториясен күздә тота (1.2 нче таблица).

**1.2 нче таблица. 2011 — 2030 елларга Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше фаразының төп күрсәткечләре (үсешнең уртача еллык темплары, процентларда)**

| Күрсәткеч | 2011-2015 | 2016-2020 | 2021-2025 | 2026-2030 | 2014-2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| Тулаем эчке продукт | 2,1 | 2,6 | 2,4 | 1,9 | 2,1 |
| Сәнәгать | 2,4 | 2,1 | 1,9 | 1,9 | 2,0 |
| Төп капиталга инвестицияләр | 3,3 | 3,7 | 4,3 | 3,3 | 3,3 |
| Реаль хезмәт хакы | 3,6 | 3,3 | 3,1 | 2,6 | 2,8 |
| Ваклап сәүдә итү әйләнеше | 3,9 | 3,2 | 2,6 | 2,0 | 2,5 |

2014 елда Россия икътисадының «яңа нормаль» якларының озак сроклы перспективасына түбәндәге караш формалашты[2]: 3 процент дәрәҗәсендә үсеш (2,5 процenттан алып 3,5 процентка кадәр). Үсешнең зуррак темпларына ирешер өчен икътисадый модельне, икътисад һәм институтлар структурасын принципиаль рәвештә үзгәртергә кирәк. Икътисадны үстерүдә төп роль хосусый инвестицияләргә бирелә. Дәүләтнең бурычы, заем алучыны финанслауны тәэмин иткән продукт булдырып, хосусый инвесторга инвестицияләрен кертергә ярдәм итү (аерым алганда,

1 Россия Федерациясе Икътисадый үсеше министрлыгы мәгълүматы буенча.
2 Алексей Улюкаев, Россия Федерациясе Икътисадый үсеше министры.— Ведомостьлар. 2014. 25 июнь.

сүз инвестиция проектларына карата рефинанслау инструментын куллану турында бара). Икътисадый үсешне активлаштыру инструментлары буларак шулай ук кече бизнесны монополиягә каршы җайга салу өлкәсеннән чыгару һәм өстенлекле инвестиция проектларын Россиянең илкүләм байлыгы фондыннан финанслау карала.

Нефтькә дөньякүләм бәяләрнең кимүе, сумның көчсезләнүе һәм Украинадагы хәлләргә бәйле геосәяси кризисның тирәнәюе җирлегендә инфляция үсеше белән аңлатыла торган уртача сроклы фаразларның начараюы һәм Россия икътисадында икътисадый хәлнең катлаулануы ихтималы зур.

## 1.2. Татарстан Республикасының конкурент позицияләре

### 1.2.1. Татарстан Республикасының глобаль конкурентлык сәләтен бәяләү

Татарстан Республикасының 2030 елга төп бурычы — гел үзгәреп тора торган дөньяда региональ икътисадның глобаль конкурентлык сәләтен тәэмин итү. Конкурентлык сәләте индикаторларының берсе булып сатып алу сәләте паритеты буенча бер кешегә исәпләнгән тулаем региональ продукт тора (ППС буенча бер кешегә исәпләнгән ВРП).

Татарстан Республикасы инде 2008 елда ук Малайзиянең ППС буенча бер кешегә исәпләнгән ВРП дәрәҗәсен узды (1.1 нче рәсем) һәм шушы аерманы саклый, бу республиканың глобаль конкурентлык сәләтенең югары потенциалы турында сөйли, чөнки Малайзия Азиянең тиз үсә торган икътисадлары арасында икътисадый үсешнең иң югары темпларының берсенә ия.






**1.1 нче рәсем. Кайбер илләр – үсеш полюслары белән чагыштырганда Татарстан Республикасының ВРП динамикасы**

Шуңа да карамастан, алдынгы илләрнең — дөньякүләм үсеш полюсларының региональ икътисадларына тиңләшкәндә республика амбициялерәк бурычлар куярга тиеш.

Глобаль торыш Татарстанның һәм «дөньякүләм үсеш полюслары»ның ППС буенча бер кешегә исәпләнгән ВРП чагыштыру юлы белән билгеләнә. Нәтиҗәдә Дөньякүләм үсеш полюслары коридоры билгеләнде — 2013 елгы бәяләрдә 25 меңнән 45 мең АКШ долларына кадәр.

Татарстан Республикасының глобаль конкурентлык сәләтенә ирешүнең төп максатчан ориентиры — үсешнең барлык сценарийлары буенча да Дөньякүләм үсеш полюслары коридорына керү, шулай ук оптимистик сценарий буенча аның югары чигенә житү (1.2 нче рәсем).

Татарстан Республикасының Россиядәге конкурент позицияләре AV Regions Competition Index (RCI) методикасы[1] нигезендә билгеләнде. Шушы методика буенча Россия регионнары конкуренциясе рейтингы төзелде, анда Татарстан өченче урынны били, ул Россиянең социаль-икътисадый үсешенә иң зур өлеш кертә торган үсеш полюсларына (Мәскәү шәһәре, Мәскәү өлкәсе, Татарстан Республикасы, Санкт-Петербург шәһәре, Свердловск өлкәсе, Краснодар һәм Красноярск крайлары) керә (1.3 нче рәсем).

1 2012 елда регионара конкурентлык сәләтен анализлау өчен кулланыла торган 130 ачык статистик күрсәткечләр һәм рейтинг бәяләре буенча исәпләнгән AV Regions Competition Index рейтингы белешмәләре китерелә (барлык Россия регионнары буенча соңгы чыгарылган статистик күрсәткечләр). Методика һәм исәпләүләрнең тулы нәтиҗәләре «Татарстан-2030» http://tatarstan2030.ru/content1 сайтында бәян ителгән.




1.2 нче рәсем. Татарстан Республикасын дөньякүләм үсеш полюслары белән ВРП һәм ППС буенча бер кешегә исәпләнгән ВРП буенча чагыштыру

(1 позиция – факт, 2013 г., 2 позиция – 2030 елга 2013 ел бәяләрендә оптимистик сценарийның максатчан күрсәткечләре)




1.3 нче рәсем. Россия икътисадының регионнары – үсеш полюслары



**1.2.2. Татарстан Республикасының регионара конкурентлык сәләтен бәяләү**

Картадагы урынны исәпкә алып, конкуренция рейтингы буенча регионнарны төркемнәргә бүлү шулай дип атала торган үсеш коридорларын һәм үсеш полюсларын билгеләргә мөмкинлек бирә. Татарстан глобаль конкурентлык сәләте перспективаларына ия «Идел – Кама» Россия үсеш полюсының алдынгысы булып тора. «Идел – Кама» үсеш полюсына Татарстаннан тыш аның түбәндәге чиктәш регионнары керә: Башкортостан Республикасы, Оренбург өлкәсе, Самара өлкәсе, Ульяновск өлкәсе, Чуваш Республикасы, Марий Эл Республикасы, Киров өлкәсе, Удмурт Республикасы. Киләчәктә Татарстан өчен киңрәк чикләрдә, иң элек Идел бассейны кысаларындагы регионнар белән интеграцияләүне көчәйтү максатка ярашлы булып тора.

Татарстанның RCI югары урыны конкурентлык сәләтенең бәяләнә торган барлык җиде факторы буенча да чагыштырмача югары позицияләрдә торуы белән аңлатыла, аларның берсе буенча да республика унынчы урыннан да түбән төшми.

Татарстан соңгы елларда дәрәҗәле регионара рейтингларның күбесендә тотрыклы рәвештә югары урыннар били (1.3 нче таблица).

1.3 нче таблица. Татарстан Республикасының рейтингларда урыннары

| Рейтинг | Татарстан Республикасының урыны/урыннарның гомуми саны | | |
|---|---|---|---|
| | 2012 | 2013 | 2014 |
| RCI – регионнар конкуренциясе индексы | 3/83 | 3/83 | - |
| Эксперт РА – инвестицияләр җәлеп итү рейтингы | 1А | 1А | 2А |
| Регионнарның инвестицияләр җәлеп итүнең илкүләм рейтингы | - | - | I төркем |
| Doing Business (Казан шәһәрен бәяләү) | 5/30 | - | - |
| Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү («Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 21 августындагы 1199 номерлы Указы) | 1/83 | 1/83 | - |

Татарстан Республикасы үсешенең төп индикаторлары тотрыклы үсте, бу 2014 елда регионара чагыштыруда республиканың шактый югары урыннар алуын тәэмин итте:

• тулаем региональ продукт күләме буенча Россиядә 7 урын;

• авыл хуҗалыгы продукциясе күләме буенча Россиядә 3 урын;

• сәнәгать җитештерү күләме буенча Россиядә 5 урын;

• төп капиталга инвестицияләр күләме буенча Россиядә 5 урын;

• төзелеш эшләре күләме буенча Россиядә 6 урын;

• торак кертү күләме буенча Россиядә 8 урын;

• ваклап сатыла торган товарлар әйләнешенең күләме буенча Россиядә 8 урын.

### 1.3. Үсерүнең ирешелгән максатларын бәяләү һәм аның потенциалын анализлау

#### 1.3.1. Татарстан Республикасын үсерүнең ирешелгән максатларын бәяләү

Озак сроклы максатлар һәм максатчан параметрлар Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үсерү программасы белән билгеләнде. Максатчан параметрларга ирешүне бәяләү 1.4 нче таблицада бирелде.

Шуны әйтергә кирәк, Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында стратегик планлаштыруда программалы карашны кулланган субъектларның беренчеләреннән булды. 2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үсерү программасы – бу бишьеллык үсерү программасының инде бишенчесе, анда республиканы үсерүдәге комплекслы проблемаларны хәл итү буенча системалы чаралар салынды.

2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үсерү программасында принципиаль яңа институциональ караш кулланылды, бу системалы тармакара характерга ия янауларны һәм куркынычларны комплекслы исәпкә алырга мөмкинлек бирә.

Стратегия 2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үсерү программасын гамәлгә ашыруда салынган институциональ нигезләрне алга таба үсерүне күздә тота.

**1.4 нче таблица. Татарстан Республикасын үсерү максатларына ирешүне бәяләү**

| Күрсәткеч | 2015 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 |
|---|---|---|---|---|---|
| | максатчан күрсәткеч | хисап | хисап | хисап | хисап |
| ППС буенча бер кешегә исәпләнгән ВРП, мең АКШ долларында | 35,0 | 19,4 | 20,4 | 20,9[1] | 20,8* |
| Тулаем региональ продукт күләменә карата төп капиталга инвестицияләр күләме, % | 40,0 | 30,1 | 32,8 | 34,0 | 33,3* |
| Бер кешегә исәпләнгән турыдан-туры чит ил инвестицияләре күләме, АКШ долларларында | 1500,0 | 26,2 | 151,1 | 106,4 | 113,0 |
| Тулаем региональ продуктта эшкәртүче производстволар күләме, % | 25,0 | 17,0 | 18,3 | 18,1 | 18,5* |
| Сәнәгать җитештерү күләмендә эшкәртүче производстволар күләме, % | 75,0 | 64,2 | 67,8 | 68,5 | 70,3 |
| Уртача хезмәт хакы, мең сумнарда | 32,7[1] | 20,0 | 23,2 | 26,0 | 28,4 |
| Бер кешегә исәпләнгән торакның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш, кв. м. | 26,5 | 23,3 | 23,7 | 24,2 | 24,8 |
| Җитештерүнең гомуми күләменнән чимал булмаган продукциянең экспорт өлеше, % | 30,0 | 18,1 | 21,3 | 26,3 | 25,4 |
| Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә инновацияле продукция өлеше, % | 30,0 | 15,6 | 19,5 | 22,0 | 25,0* |
| Тулаем региональ продуктта кече һәм урта бизнес өлеше, % | 34,0 | 25,3 | 25,4 | 25,6 | 25,5* |
| Гомер озынлыгы, елларда | 74,1 | 71,3 | 71,8 | 72,1 | 72,2 |
| Гомуми файдаланудагы элемтә юллары челтәренә кадәр каты катламлы юллары булган торак пунктларның чагыштырма авырлыгы, % | 78,4[2] | 72,3 | 74,3 | 75,7 | 77,9 |

Искәрмә:[1] – бәяләү.

1 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 20 декабрендәге 2291-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә.



#### 1.3.2. Татарстан Республикасының конкурент өстенлекләре

Татарстан Республикасы–2015 – алдынгы Россия регионы, аңа түбәндәгеләр хас: амбицияләр, тәҗрибә һәм актив икътисадый сәясәт, базарлар һәм инфраструктура уңайлылыгы, балансы социаль-икътисадый система.

• Амбицияләр, тәҗрибә һәм актив икътисадый сәясәт – алдынгы регион репутациясе:

эшкуарлыкның югары дәрәҗәсе; урта сыйныфны булдыручы шәһәр халкының зур өлеше;

конкурент институциональ мохит; дәүләт хезмәткәрләренең яхшы квалификациясе; регион белән идарә итүнең югары дәрәҗәсе; булган реаль сектор белән идарә итәргә һәм «яңа икътисад» төзергә әзер булу; масштаблы халыкара һәм региональ проектларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе; федераль үзәк белән уңышлы хезмәттәшлек тәҗрибәсе;

1 «Республика башкарма хакимияте органнарына халыкның яшәү сыйфатын һәм аларның 2015 – 2017 елларга эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт заданиесен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә.

агросекторны һәм конкурент өстенлекләргә ия сәнәгатьнең эшкәртү тармакларын үстерүне стимуллаштыруның актив сәясәте, бюджетның һәм региональ компанияләрнең масштаблы инвестицияләре, аерым тармакларга глобаль инвесторлар җәлеп итү;

«милли үзәк» — хакимиятнең һәм бизнесның төрле төркемнәрендә амбицияләрнең һәм ышанычның югары дәрәҗәсе; дөньякүләм татар җәмәгатьчелегенең бердәйлеге; мөселман дөньясы белән элемтәләр, ислам финанслары белән эшләү тәҗрибәсе.

• Базарлар һәм инфраструктура уңайлылыгы:

Татарстан Республикасы өч транспорт коридоры киселешендә Россия Федерациясенең Европа өлеше уртасында, Идел-Кама бассейны үзәгендә урнашкан; 1 500 км радиуста урнашкан Россия регионнарында Россия халкының кимендә 70 проценты яши, бу шушы регионнарның Татарстан Республикасы белән уңайлы һәм тиз транспорт элемтәләрен оештыру мөмкинлеген тәэмин итә;

тамырлары әле «ефәк юлы»нда булган финанс-сәүдә-транспорт-логистик ташкыннарның киселеше;

алдынгы агломерацияләрне стимуллаштыру белән көчәйтелгән территориаль үсешнең күп үзәкле булуы; инфраструктура үстерүнең актив сәясәте;

үсеш өчен күп табигый ресурсларның һәм пространстволарның булуы.

• Икътисадый бәйсезлекнең югары дәрәҗәсенә ия балансы социаль-икътисадый система:

Татарстан Республикасының икътисадый бәйсезлеге һәм элемтәләрнең үзенчәлекле булуы: төп предприятиеләр региональ милектә; төп икътисадый комплекслар килешенгән икътисадый сәясәт алып бара; энергетика бәйсезлеге;

үсешендә алга киткән нефть-газ химиясе комплексы (углеводородларның эзләп табылган запаслары, республикада нефть-газ химиясе бизнесы бәясен булдыруның төзелгән чылбыры һәм бу бизнесның урнашуы);

үсешендә алга киткән машиналар төзү комплексы; «югары бүлү» дәрәҗәсе үсеше;

балансы агросәнәгать комплексы; авыл хуҗалыгы өчен чагыштырмача уңайлы табигать шартлары;

кеше капиталын үстерү системасы буларак социаль өлкәнең югары потенциалы;

инновацияле «акыллы» икътисад булдыруның алшартлары; үсешендә алга киткән мәгълүмати система; югары технологияле базар продуктларына һәм хезмәт күрсәтүләргә ярдәм итү проектлары (ИТ-Парк, Иннополис, СМАРТ Сити Казан).



Татарстан Республикасының аеруча конкурент өстенлекләре түбәндәгеләр:

• углеводородларның эзләп табылган запаслары, республикада нефть-газ химиясе бизнесы бәясен булдыруның төзелгән чылбыры һәм бу бизнесның урнашуы;

• Евразиянең үзәгендә урнашу, бу инфраструктура сыйфаты югары булган базарлар уңайлылыгын тәэмин итә;

• югары икътисадый бәйсезлеккә, «милли үзәк»кә һәм идарә ителүнең югары дәрәҗәсенә ия алдынгы регион репутациясе.

### 1.3.3. Төп проблемалар

Татарстан Республикасында түбәндәге берничә системалы проблема бар, аларның күпчелеге тулаем Россия Федерациясенә дә хас.

• «Голландия авыруы»ның алшартлары:

югары табышлы углеводород секторы булу аркасында инновацияләргә һәм нәтиҗәлелекне үстерүгә стимулларның түбән булуы;

федераль карарлардан һәм финанслаудан көчле бәйлелек.

• Кеше капиталының уртача сыйфаты һәм аның җитмәве:

чагыштырмача түбән хезмәт җитештерүчәнлеге; керемнәрнең югары дифференциациясе;

квалификацияле, шул исәптән эшче һәм инженерлык белгечлекләре буенча кадрлар кытлыгы; инновацияле икътисад өчен квалификацияле хезмәт ресурслары кытлыгы куркынычының җитди булуы;

меритократик критерийлар (компетентлык, квалификация, эшлекле сыйфатлар) буенча өскә таба карьер үсешнең кыенлашкан булуы, бу талантларның китүенә һәм профессиональ кадрлар кытлыгына китерә;

сәнәгать үзәкләренең бер профильле булу куркынычы;

менеджмент дәрәҗәсенең җитәрлек булмавы, хезмәткәрләр квалификациясенең башкара торган профессиональ эшчәнлекләренә туры килмәве.

• Конкурентлык сәләтенең системалы проблемалары:

эшкәртүче сәнәгатьнең глобаль конкурентлык сәләтенең җитәрлек булмавы;

нефть-газ химиясе өчен чимал җитмәү;

экологик проблемалар;

инвестиция портфеленең түбән сыйфаты; инвестицияләрнең түбән нәтиҗәлелеге;

финанс инфраструктурасы сыйфатының җитәрлек булмавы;

регионны үстерү яңа базарларга икътисадый экспансиянең үткәндә нәтиҗәле сәясәте булмаган һәм тышкы инвесторлар өчен регионга керү каналларын чикләгән ябык система принципларына корылды; күрше регионнар белән хезмәттәшлекнең көчсез булуы һәм продукция, хезмәт күрсәтүләр үсешенең җитәрлек дәрәҗәдә актив булмавы, шулай ук җитәрлек дәрәҗәдә үсмәгән инфраструктура белән материк эчендә урнашу сату базарларын киңәйтүне кыенлаштыра;

Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләренең заманча инфраструктурасын һәм шәһәр мохитен үстергән очракта ачыла торган потенциаль агломерация өстенлекләреннән җитәрлек файдаланмау.

**2. Татарстан Республикасының озак сроклы үсеше приоритетлары һәм максатлары**

**2.1 Кыйммәтләр һәм приоритетлар**

Республиканың үсеш Стратегиясе Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы һәм татар халкы ихтыярын чагылдыра торган Татарстан Республикасы Конституциясендә беркетелгән кыйммәтләргә һәм принципларга таяна.

Стратегия тиешенчә кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең өстенлеген тәэмин итә, халыкларның тигез хокуклылыгы принципларына нигезләнә, тарихи, милли һәм рухи традицияләрнең, мәдәниятләрнең, телләрнең сакланып калуына һәм үсешенә, гражданнар татулыгын һәм милләтара килешүне тәэмин итүгә ярдәм итә, демократиянең ныгуына һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен тизләтүгә юнәлдерелгән.

Кеше – үз ихтыяры белән эш итүнең үзе һәм әйләнә-тирәдәгеләр каршында гына түгел, киләчәк буыннар алдында да җаваплылыгын аңлаучы кабатланмас һәм иректе шәхес, кеше Стратегиядә үзәк кыйммәт булып тора.

Кеше – үзе кыйммәт; аны үстерү һәм камилләштерү өчен уңайлы шартлар булдыру – Стратегиянең иң югары максаты. Кеше капиталы – заманча икътисадның асылы, глобаль конкуренциядә уңышка ирешү нигезе. Регион үсешенең уңышы аның халкының яшәү сыйфатына, тупланган һәм уңышлы эшли торган кеше капиталының санына һәм сыйфатына карап бәяләнә.

Стратегия эчтәлеге түбәндәге өч үзара бәйле стратегик приоритет тирәли туплана:

1. кеше капиталын булдыру һәм туплау;



2. кеше капиталын үстерү өчен уңайлы пространство булдыру;
3. икътисадта кеше капиталына ихтыяҗ булган һәм уңышлы эшли ала торган икътисадый мөнәсәбәтләр һәм иҗтимагый институтлар булдыру.

Хәзерге глобальләшкән дөньяда глобальлек һәм үзенчәлекле булу арасында дөрес баланс таба торган, үзенең уникаль сыйфатларын югалтмыйча, киресенчә, регионара конкуренциядә аларга таянып дөньякүләм икътисадка оста туры килгән регионнар уңышка ирешә.

Уңышлы регионнарның дөньякүләм тәҗрибәсен гомумиләштерү уңышка ирешүгә ярдәм итә торган сыйфатлар җыелмасын билгеләргә мөмкинлек бирә, алар түбәндәгеләр:

- белемле, эшлекле, актив, сәләтле, креатив халык;
- дөньякүләм дәрәҗәдәге мәгариф системасы;
- миграция ташкыннары белән идарә итү системасы, талантларны җәлеп итү һәм тотып калу;
- карьера үсеше, эшкуарлык, инвестицияләр өчен киртәләрнең аз булуы;
- икътисадның диверсификациясе (кече бизнесның югары өлеше, тармаклар – үсеш драйверлары булуы);
- яшәү өчен уңайлы шартлар, сәламәт әйләнә-тирәле мохит, иминлек;
- төрле мохит (җирлекләрнең төрле типлары, шәһәрләрдәге иҗтимагый киңлекләр);
- региональ пространство элемтәсенең югары дәрәҗәдә булуы;
- ачыклык (актив халыкара һәм регионара элемтәләр);
- дөнья үзәкләренә бару мөмкинлеге булуы (халыкара аэропорт);
- бай мәдәни тормышлы танылган мәркәз;
- үзенчәлекле булу, үз йөзе булуы, танылганлык;
- региональ элиталар мәнфәгатьләре балансы, толерантлык;
- киләчәк белән идарә итүнең нәтиҗәле системасы.

Глобаль регионара конкуренциядә үз позицияләрен ныгытыр өчен Татарстанга түбәндәге юнәлешләрдә камилләшү стратегик яктан әһәмиятле булып тора.

1) *кеше капиталын туплау һәм иҗтимагый институтлар* өлешендә:

- идарә ителә торган модернизацияләү, патриархаль мөнәсәбәтләрдән акрынлап күчү;
- чит телләрне кертеп, массакүләм сыйфатлы белем бирү;

- талантлар белән идарә итү;
- сәләтләргә һәм компетентлыкка карап вертикаль һәм горизонталь мобильлеккә ярдәм итү;
- элиталарның укымышлы булуы;
- җәмгыятьтә ышаныч дәрәҗәсенең артуы;
- сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләре һәм сәламәтлек саклауның нәтиҗәле булуы;
- мәдәниятләр күплеге;
- конфессияләр тигезлеге;

*2) пространство* өлешендә:

- табигатькә ярашлы тотрыклы үсеш;
- киләчәк өчен ресурсларны резервлау;
- үсеш зоналарына акцент ясап, регионның Евразиянең үзәгендә урнашуын исәпкә ала торган күпүзәкле үсеш — транспортның тиз һәм бик тизйөрешле төрләрен үстерү исәбенә өч үзәге булган Идел-Кама метрополисын булдыру;
- республика эчендә җирлекләрнең барлык төрләренә транспортта бару мөмкинлеге булуы һәм күрше регионнар белән ышанычлы элемтәләр;
- аралашуга һәм ышаныч булуга ярдәм итә торган иҗтимагый киңлекләр булган уңайлы имин шәһәр мохите;
- эшчәнлекнең авыл хуҗалыгы булмаган төрләре исәбенә авыл җирлеген саклап калу;
- икътисадый нигезен югалтып баручы торак пунктларга карата сәясәтнең вариантларын булдыру;

*3) икътисадый мөнәсәбәтләр һәм идарә итү* өлешендә:

- икътисадый үсеш факторы буларак ышаныч дәрәҗәсенең артуы: кластер мөнәсәбәтләрен, коллектив идарә итүне үстерү, сотруенциягә (конкурентларның хезмәттәшлегенә) өйрәтү;
- ачык икътисад, конкурентлык сәләте стимулы буларак глобальләшү;
- ресурслардан файдалануны киңәйтү һәм тигезләү;
- инновацияләрнең тулы кыйммәтле экосистемасы;
- федераль үзәк белән үзара файдалы хезмәттәшлек;
- инфраструктура проектларында дәүләтнең нәтиҗәле катнашуы;
- коррупциягә бәйле мәсьәләләрне системалы хәл итү, «күләгә икътисады»ның җитди кимүе;
- дәүләт идарәсен үзәкләштерүне киметү, проектлы идарә итү, «нәтиҗә булу»га идарә итү һәм дәүләт-хосусый партнерлык принципларын гамәлгә керткәндә карарлар кабул итүне тизләтү мәнфәгатьләрендә вәкаләтләр бирү.



## Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше приоритетлары һәм максатлары белән килештерү

Татарстан Республикасы үсеше приоритетлары һәм максатлары Россия Федерациясе үсеше приоритетлары һәм максатлары белән килештерелгән, алар түбәндәге документларда тәгъбир ителгән: Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламалары, 2020 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеш концепциясе, 2020 елга кадәр Россия Федерациясенең милли иминлек стратегиясе, Россия Федерациясенең азык-төлек иминлеге доктринасы, 2025 ел чорына кадәр Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе, шулай ук федераль дәрәҗәдә кабул ителгән һәм расланган башка озак сроклы тармак стратегияләре, концепцияләре һәм доктриналары.

Россиянең стратегик приоритетларын берничә төркемгә тупларга була, алар Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең өч өстенлекле темасында чагылыш таба (2.1 нче таблица).

Татарстан Республикасы федераль приоритетларны гамәлгә ашыруда иң зур өлешне түбәндәге юнәлешләр буенча кертәчәк:

- инновацияле икътисад;
- азык-төлек иминлеге;
- транспорт-транзит системасы, халыкара транспорт коридорлары;
- кешенең байлык стандартларының, социаль иминлекнең һәм татулыкның югары булуын тәэмин итү.

**2.1 нче таблица. Татарстан Республикасы стратегиясендә Россиянең стратегик приоритетлары чагылышы**

| Россиянең стратегик приоритетлары | Татарстан Республикасы стратегиясенең өстенлекле темалары |
|---|---|
| • Кешенең байлык стандартларының, социаль иминлекнең һәм татулыкның югары булуын тәэмин итү.<br>• Гражданнарның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау, халыкның закон кушканча эшләү дәрәҗәсен арттыру, суд системасы эшен яхшырту, территориаль җәмәгать үзидарәсен активлаштыру. | **Кеше капиталы** |
| • Балансլы пространство-территориаль үсеш.<br>• Махсус икътисадый зоналар һәм алда барып үстерү зоналары үсеше, территориаль икътисадый кластерларга ярдәм күрсәтү, агломерация процессларына идарә итү системаларын булдыру<br>• Россиянең хуҗалык үзара элемтәләрен үстерүгә ярдәм итә торган транспорт-транзит системасын үстерү. | **Пространство** |

| | |
|---|---|
| • Белемнәргә нигезләнгән яңа нәтиҗәле икътисад булдыру, инновация эшчәнлеген, икътисадның югары технологияле секторларын, массакүләм инновацияләрне төп таратучы буларак кече эшкуарлыкны үстерү.<br>• Россиянең дөньякүләм базарларда конкурентлык сәләтен арттыру, Россия икътисадының традицион тармакларын үстерү.<br>• Норматив хокукый базаны камилләштерү, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыру, гражданлык җәмгыяте институтларының әһәмиятен көчәйтү.<br>• Дәүләт, гражданнар һәм җәмгыять иминлеге. | **Икътисад һәм идарә итү** |

## 2.2. Стратегияне гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Стратегия 15 елга (2016 – 2030 еллар) билгеләнде һәм дүрт (өч өчьеллык һәм бер алтыеллык) этапны күздә тота. Кирәк булганда Стратегия өч елга бер мәртәбә төзәтеләчәк, ә алты елга бер тапкыр – яңартылачак.

Гамәлгә ашыру этаплары социаль-икътисадый үсешнең шартлары, факторлары, куркынычлары һәм республиканың икътисадый сәясәте приоритетлары буенча аерыла.

**Беренче этап (2016 – 2018 еллар)** икътисадның нәтиҗәлелеген һәм аңа идарә итүне арттыру, кеше капиталы сыйфатын үстерү һәм конкурентлык сәләтен җитди үстерүнең алшартларын булдыру максатында республика икътисадының үзе ия булган конкурент өстенлекләрен гамәлгә ашыруга һәм киңәйтүгә нигезләнә. Әлеге этапта, төп икътисадый юнәлешләрнең үсеш программасын булдырып, дәүләт программалары системасын структурлаштырырга, региональ кластерлар портфеле кысаларында структурлаштырылган өстенлекле үсеш проектлары җыелмасын эшләргә кирәк булачак (кластер активлаштыру моделе җибәрелә һәм беренче нәтиҗәләрен бирә). Үсеш темплары берничә глобаль һәм Россия факторы аркасында түбән булачак. Импортны алмаштыру проектлары гамәлгә ашырылачак.

Стратегиянең беренче этабын дәвам итә торган геосәяси кризис, Россия гражданнарының, компанияләренең һәм банкларының кайберләренә карата халыкара санкцияләр саклану, нефтькә түбән бәя белән берлектә капиталның халыкара базарларында чикләүләр көчәю, шулай ук күрсәтелгән факторлар барлыкка китергән икътисадый хәлнең начараюы һәм Россия икътисадының акрынаюы дәвам иткән шартларда гамәлгә ашыру Стратегияне бу этапта башкару билгеләренең максатчан күрсәткечләренә ирешмәүнең җитди куркынычына һәм Татарстан Республикасының стратегик документлары системасын җитди төзәтүнең ихтималлыгына бәйле.



**Икенче этап (2019 – 2021 еллар)** конкурентлык сәләтенең үсеш моделенә нигезләнә. Үсешнең институциональ шартлары һәм технологик башламнары булдырылачак. Кластер активлаштыру кысаларында «заманча икътисад»ны модернизацияләү тизләнәчәк һәм «акыллы» икътисад башламнарын булдыру башланачак, регионара һәм халыкара интеграцияләү проектлары старт алачак. Тышкы конъюнктура яхшырачак, үсеш темплары артачак.

**Өченче этап (2022 – 2024 еллар)** – кластер активлаштыру республиканың яңа балансланган үсеш моделенә күчүе, кеше потенциалы һәм социаль пространство сыйфатын шактый яхшырту, «заманча икътисад»ның структур модернизацияләвен тирәнәйтү, яңа «акыллы» икътисадны җитди үстерү, инновацияләрне икътисадый үсешнең алдынгы факторына әйләндерү нигезендә Татарстан Республикасы икътисадының конкурентлык сәләтенең һәм социаль сферасының җитди үсешен тәэмин итәчәк.

**Дүртенче этап (2025 – 2030 еллар һәм алга таба)** – икътисадның конкурентлык сәләтен үстерүдә ыргылыш булачак, берничә төп юнәлеш кысаларында Татарстан Республикасының глобаль конкурентлык сәләтенә ирешү өчен шартлар булдырылачак. Татарстан Республикасы субъект-партнерларның һәм тулаем Россия Федерациясенең үсешен тәэмин итүче глобаль субъект – «Идел-Кама» үсеш полюсының алдынгысы позициясен алырга мөмкин.

Тышкы шартлар фаразының билгесезлеге Стратегияне гамәлгә ашыруның төрле вариантлардагы сценарийларын куллануга бәйле. Түбәндәге өч сценарий тәкъдим ителде:

• 1 сценарий – инерцияле (ресурс чикләүләренең кискен булуы сценарие);

• 2 сценарий – төп (ресурс чикләүләренең уртача булуы сценарие);

• 3 сценарий – оптимистик (ресурс чикләүләренең йомшак булуы сценарие).

**Инерцияле сценарий.** Әлеге сценарий икътисадый үсеш темпларының тизләнүен күздә тотмый (тышкы факторлар йогынтысына карап хәлнең вакытлыча начараюы мөмкин, бу шартларда инерцияле пессимистик сценарий каралачак), үсеш «стандарт» инерцияле трендлар буенча бара, ресурс чикләүләре үтелмәячәк. Ресурс чикләүләрен исәпкә алып иң өстенлекле һәм ресурс күләмнәре иң аз булган проектлар гына гамәлгә ашырыла (проектларны гамәлгә ашыруның сроклары соңрак вакытка күчерелергә мөмкин).

Сценарийның төп параметрлары:

• республика икътисады күпчелек тармакларының конкурентлык сәләтенең иң яхшы чит ил җитештерүчеләре дәрәҗәсеннән

аермасын аз гына киметүне тәэмин итү мөмкинлеген бирүче тотрыклы үсеш моделен булдыру максатында традицион өлкәләрдә конкурент өстенлекләрне ныгыту һәм киңәйтү, бу республиканың икътисадый структурасын аз гына модернизацияләүгә китерәчәк;

• кеше капиталының түбән үсеше;

• икътисадның һәм социаль өлкәнең чагыштырма өстенлекләрен гамәлгә ашыручы озак сроклы өстенлекле проектларның һәм программаларның чикләнгән санын башкару;

• инвестицияләр җәлеп итүнең түбән үсеше;

• пространство үсеше өчен шартлар тудыру;

• регионара һәм халыкара социаль-икътисадый киңлеккә интеграция процессларын киңәйтү;

• балансλы тотрыклы үсешкә ярдәм итә торган институциональ мохит үстерү;

• иминлекнең тотрыклы дәрәҗәсе.

Инерцияле сценарийга 2.2 нче таблицадагы индикаторларның минималь күрсәткечләре туры килә.

**Төп сценарий.** Әлеге сценарий ресурс чикләүләрен бетерүгә юнәлдерелгән кирәкле чараларның гамәлгә ашырылачагын күздә тота. Фаразланган срокларда гамәлгә ашырганда куркынычлар түбән булган проектлар һәм гамәлгә ашырганда куркынычлары югары булган берничә төп эре проект башкарыла.

Сценарийның төп параметрлары:

• республиканың үсеш потенциалын гамәлгә ашыруның югары дәрәҗәсе;

• традицион өлкәләрдә конкурент өстенлекләрне ныгыту һәм киңәйтү (шул исәптән технологик дәрәҗәне арттыру һәм икътисадның, социаль өлкәнең барлык тармакларында хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү нигезендә), үсешнең индустриаль һәм постиндустриаль факторлары балансын саклый торган кластер активлаштыру нигезендә тотрыклы балансλы үсеш моделен булдыру максатында яңа тармакларда конкурентлык сәләтен үстерүне стимуллаштыру;

• югары дәрәҗәдәге муллык, социаль тормышның җитешле булуы, татулык һәм иминлек нигезендә социаль өлкәне тирән модернизацияләү аша кеше потенциалын үстерү;

• икътисадның чагыштырма өстенлекләрен гамәлгә ашыручы озак сроклы өстенлекле проектларның һәм программаларның күбесен башкару;

• инвестиция климатын, шул исәптән чит ил инвесторлары өчен, шактый яхшырту;

• балансλы пространство үсеше (икътисадый үсешнең яңа үзәкләрен булдыру, пространство сыйфатын үстерү) һәм регионара һәм халыкара социаль-икътисадый киңлеккә сизелерлек интеграцияләнү;



• тотрыклы үсешкә ярдәм итә торган институциональ мохит булдыру.

Төп сценарийга 2.2 нче таблицадагы индикаторларның максатчан күрсәткечләре туры килә.

**Оптимистик сценарий.** Үсеш потенциалының тулысынча ачылуын, глобаль конкурентлык сәләтенә ирешүне күздә тота. Кластер активлаштыру уңышлы гамәлгә ашырыла: заманча икътисад (бигрәк тә бишенче технологик торыш элементлары булган дүртенче технологик торышлы) тулысынча яңартыла, акыллы икътисад (бишенче-алтынчы технологик торышлы, җиденче технологик торыш барлыкка килү мөмкинлеге белән) секторы булдырыла. Билгеләнгән проектларның күбесе план чорларында башкарыла.

Оптимистик сценарийга 2.2 нче таблицадагы индикаторларның максималь күрсәткечләре туры килә.

### 2.3. Максатчан күзаллау, максатларга ирешү күрсәткечләре, гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

Стратегия «Татарстан-2030» максатчан күзаллавына ирешүгә юнәлдерелгән, аңа түбәндәге характеристикалар кирә.

***Төп стратегик максат (ГСЦ) (2.1 нче рәсем)***

**ГСЦ** **Татарстан-2030 – глобаль конкурентлыкка сәләтле тотрыклы регион, «Идел-Кама» үсеш полюсы драйверы. Татарстан – кеше капиталының, институтларның, инфраструктураның, икътисадның, тышкы интеграциянең (Россиянең үзәк Евразия регионы) һәм эчке пространствоның үзара тыгыз бәйләнештә үсешенең сыйфаты буенча лидер; алда бара торган темплар белән үсә торган, халыкара эш бүленешенә югары дәрәҗәдә кушылган регион.**

Төп стратегик максат, өч стратегик приоритетны да (кеше капиталы, пространство, икътисад һәм идарә итү) исәпкә алып, регионара конкуренциянең җиде юнәлеше яссылыгында җиде стратегик максатка җәелдерелгән: конкуренциянең биш юнәлеше (өченчесеннән алып җиденчесенә кадәр) «икътисад һәм идарә итү» стратегик приоритетына берләшә.

***Стратегик максатлар (СЦ)***

**СЦ-1** **Кеше капиталы:** тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә. Республика яшәүнең югары сыйфатына ирешү өчен шартлар тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда алдынгы булып тора.

**СЦ-2** **Пространство, реаль капитал:** баланслы территориаль-пространство үсеше мохитнең югары конкурентлык сәләтен тәэмин итә; инфраструктура глобаль конкурентлылык сәләтенә ия. Җитештерү фондлары нәтиҗәле кулланыла.

**СЦ-3** **Базарлар:** Татарстан Республикасының махсуслаштыру тармаклары регионара һәм глобаль базарларда конкурентлыкка сәләтле.

**СЦ-4** **Институтлар:** дәүләт, хосусый һәм дәүләт-хосусый институтларның баланслы системасы конкурентлыкка сәләтле кластерларның, эшкуарлыкның (кече һәм урта бизнесның), эчке территориаль үсешнең һәм тышкы интеграциянең тотрыклы үсешен тәэмин итә.

**СЦ-5** **Инновацияләр һәм мәгълүмат:** республика «акыллы» икътисад үстерүдә, яңа материаллар, продуктлар һәм технологияләр булдыруда һәм аларны коммерцияләштерүдә алдынгы булып тора.

**СЦ-6** **Табигать ресурслары:** табигать ресурслары тотрыклы үсеш принциплары нигезендә нәтиҗәле кулланыла.

**СЦ-7** **Финанс капиталы:** республика дөньякүләм дәрәҗәдәге инвестицияләр өчен кызыклы булып тора. Финанс системасы югары нәтиҗәле.




Искәрмә. ГСЦ – төп стратегик максат, СЦ – стратегик максат, Ц – максат, З – бурыч.

**2.1 нче рәсем. Максатлар системасында төп стратегик максатның бүленеше**



Җиде юнәлеш буенча максатчан торыш индикаторлар (максатларга ирешү күрсәткечләре) җыелмасы белән билгеләнә, аларга өч сценарийга туры килә торган, план чорының контроль даталарына күрсәткечләрнең максатчан диапазоннары билгеләнде (2.2 нче таблица, 2.2-2.3 нче рәсемнәр). Төп сценарий максатчан була.

**2.2 нче таблица. Татарстан Республикасының максатчан торыш индикаторлары күрсәткечләре**

| Индикатор | 2013 | 2018 | 2021 | 2024 | 2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| **ГСЦ: Төп максат** | | | | | |
| ППС буенча бер кешегә исәпләнгән ВРП, АКШ долларлары (меңнәрдә), 2013 елгы бәяләрдә | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 20,9 | 22 | 23 | 24 | 26 |
| Төп сценарий буенча | 20,9 | 23 | 25 | 28 | 35 |
| Оптимистик сценарий буенча | 20,9 | 24 | 28 | 33 | 43 |
| ВРП үсешенең тупланган темпы (2015 елгы бәяләр белән бер чамада), % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | | 105 | 111 | 116 | 128 |
| Төп сценарий буенча | | 109 | 125 | 144 | 180 |
| Оптимистик сценарий буенча | | 115 | 139 | 170 | 236 |
| **СЦ-1: Кеше капиталы** | | | | | |
| Хезмәт җитештерүчәнлеге, млн. сумнарда/бер кешегә | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 0,85 | 1,12 | 1,33 | 1,53 | 1,98 |
| Төп сценарий буенча | 0,85 | 1,17 | 1,43 | 1,76 | 2,58 |
| Оптимистик сценарий буенча | 0,85 | 1,23 | 1,59 | 2,00 | 3,20 |
| Халыкның уртача еллык саны, мең кешедә | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 3 830 | 3 879 | 3 897 | 3 916 | 3 958 |
| Төп сценарий буенча | 3 830 | 3 897 | 3 956 | 4 069 | 4 182 |
| Оптимистик сценарий буенча | 3 830 | 3 923 | 4 018 | 4 186 | 4 385 |
| Көтелгән гомер озынлыгы, елларда | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 72,12 | 72,3 | 72,4 | 72,4 | 72,5 |
| Төп сценарий буенча | 72,12 | 73,4 | 74,2 | 74,6 | 75,3 |
| Оптимистик сценарий буенча | 72,12 | 74,4 | 75,9 | 76,8 | 78,0 |
| Эшсезлек дәрәҗәсе (МОТ методологиясе буенча), % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 4,0 | 3,9 | 3,9 | 3,8 | 3,8 |
| Төп сценарий буенча | 4,0 | 3,9 | 3,9 | 3,8 | 3,7 |
| Оптимистик сценарий буенча | 4,0 | 3,9 | 3,8 | 3,7 | 3,5 |
| Икътисадта эшләүчеләрнең уртача еллык саны, мең кешедә | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 1 817,7 | 1 818 | 1 818 | 1 817 | 1 819 |
| Төп сценарий буенча | 1 817,7 | 1 827 | 1 883 | 1 963 | 1 986 |
| Оптимистик сценарий буенча | 1 817,7 | 1 871 | 1 945 | 2 070 | 2 144 |
| Бер кешегә исәпләнгән торакның гомуми мәйданы белән тәэмин ителү, кв.м. | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 24,2 | 26,1 | 26,9 | 27,2 | 28,5 |
| Төп сценарий буенча | 24,2 | 26,5 | 27,6 | 28,1 | 30,0 |

| Индикатор | 2013 | 2018 | 2021 | 2024 | 2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| Оптимистик сценарий буенча | 24,2 | 27,3 | 29,1 | 30,9 | 34,3 |
| Югары уку йортларын тәмамлаучыларның укуны тәмамлаганнан соң беренче елда эшкә урнашкан өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 54,8 | 55,7 | 57,7 | 58,7 | 60,0 |
| Төп сценарий буенча | 54,8 | 56,7 | 59,7 | 61,7 | 65,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 54,8 | 70,0 | 73,5 | 76,0 | 80,0 |
| Һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның укуны тәмамлаганнан соң беренче елда эшкә урнашкан өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 44,1 | 55,6 | 64,0 | 67,5 | 70,0 |
| Төп сценарий буенча | 44,1 | 67,5 | 78,0 | 82,0 | 85,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 44,1 | 75,5 | 87,0 | 92,0 | 95,0 |
| Татарстан Республикасында югары белем мәгариф оешмаларындагы студентларның гомуми санынннан чит ил студентлары өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 2,6 | 5,0 | 5,3 | 5,5 | 6,0 |
| Төп сценарий буенча | 2,6 | 5,4 | 5,7 | 6,0 | 6,6 |
| Оптимистик сценарий буенча | 2,6 | 5,6 | 6,0 | 6,5 | 7,0 |
| Халыкның физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 31,0 | 35,0 | 37,0 | 39,0 | 43,0 |
| Төп сценарий буенча | 31,0 | 38,0 | 41,0 | 45,0 | 50,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 31,0 | 40,0 | 44,0 | 48,0 | 56,0 |
| Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме чараларын алучылар өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 2,3 | 4,7 | 6,2 | 7,7 | 10,7 |
| Төп сценарий буенча | 2,3 | 8,8 | 11,6 | 14,4 | 20,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 2,3 | 13,2 | 17,4 | 21,6 | 30,0 |
| Туристлар ташкыны күләме, мең кешедә | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 1 662 | 2 030 | 2 214 | 2 304 | 2 387 |
| Төп сценарий буенча | 1 662 | 2 004 | 2 454 | 2 965 | 3 617 |
| Оптимистик сценарий буенча | 1 662 | 2 435 | 3 153 | 4 095 | 5 534 |
| **СЦ-2: Пространство, реаль капитал** | | | | | |
| Магистраль тизйөрешле автомобиль юллары челтәренең (I и II техник категорияләрдәге автомобиль юллары) озынлыгы, км | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 250 | 505 | 633 | 888 | 1270 |
| Төп сценарий буенча | 250 | 612,4 | 793,6 | 1200 | 1700 |
| Оптимистик сценарий буенча | 250 | 810 | 1100 | 1650 | 2500 |
| Тизйөрешле һәм бик тизйөрешле тимер юл линияләре озынлыгы, км | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 0 | 0 | 0 | 0 | 43 |
| Төп сценарий буенча | 0 | 0 | 43 | 43 | 336 |
| Оптимистик сценарий буенча | 0 | 43 | 248 | 336 | 1031 |
| Аэропортларның пассажирлар әйләнеше, бер елга млн. кешедә | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 2,25 | 2,4 | 2,6 | 2,8 | 3,0 |



| Индикатор | 2013 | 2018 | 2021 | 2024 | 2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| Төп сценарий буенча | 2,25 | 3,7 | 4,3 | 5,5 | 7,3 |
| Оптимистик сценарий буенча | 2,25 | 4,5 | 5,4 | 7,3 | 10,0 |
| **СЦ-3: Базарлар** | | | | | |
| Россия Федерациясе экспортының гомуми күләменнән Татарстан Республикасы экспорты өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 4,2 | 2,4 | 2,7 | 2,4 | 2,3 |
| Төп сценарий буенча | 4,2 | 3,0 | 4,0 | 4,2 | 5,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 4,2 | 3,6 | 5,4 | 6,9 | 6,6 |
| Экспортның гомуми күләменнән чимал булмаган продукция экспорты өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 54,2 | 55 | 70 | 72 | 76 |
| Төп сценарий буенча | 54,2 | 57 | 75 | 78 | 85 |
| Оптимистик сценарий буенча | 54,2 | 60 | 80 | 83 | 90 |
| **СЦ-4: Институтлар** | | | | | |
| Өстәлгән бәядә кече һәм урта бизнес өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 25,6 | 26,9 | 27,4 | 28,0 | 29,0 |
| Төп сценарий буенча | 25,6 | 27,9 | 29,2 | 30,5 | 33,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 25,6 | 28,4 | 30,1 | 31,7 | 35,0 |
| Халыкның МСП секторында эшләүче өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 26,4 | 27,0 | 28,0 | 29,0 | 30,0 |
| Төп сценарий буенча | 26,4 | 28,0 | 30,0 | 31,0 | 32,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 26,4 | 28,5 | 31,0 | 32,0 | 34,0 |
| Кече предприятиеләр, шул исәптән микропредприятиеләр һәм индивидуаль эшкуарлар җитештерә торган продукция һәм хезмәт күрсәтүләр әйләнеше үсешенең тупланган темпы, 2015 елгы бәяләр белән бер чамада, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | | 110 | 128 | 148 | 198 |
| Төп сценарий буенча | | 119 | 147 | 182 | 278 |
| Оптимистик сценарий буенча | | 126 | 163 | 211 | 354 |
| **СЦ-5: Инновацияләр һәм мәгълүмат** | | | | | |
| Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләменнән инновацияле продукция өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 22,0 | 21,8 | 22,2 | 22,7 | 23,5 |
| Төп сценарий буенча | 22,0 | 25,2 | 27,6 | 30,1 | 35,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 22,0 | 27,5 | 31,4 | 35,3 | 43,0 |
| ВРПда НИОКРга чыгымнар өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 0,9 | 1,1 | 1,2 | 1,3 | 1,5 |
| Төп сценарий буенча | 0,9 | 1,5 | 1,9 | 2,3 | 3,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 0,9 | 2,1 | 2,8 | 3,6 | 5,0 |
| **СЦ-6: Табигать ресурслары** | | | | | |
| Җирлекләрне яшелләндерү дәрәҗәсе (яшел үсентеләргә бирелгән мәйданның җирлекнең гомуми мәйданына нисбәте), % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 25,0 | 27,0 | 30,0 | 32,0 | 35,0 |
| Төп сценарий буенча | 25,0 | 28,0 | 32,0 | 35,0 | 40,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 25,0 | 30,0 | 35,0 | 40,0 | 45,0 |

| Индикатор | 2013 | 2018 | 2021 | 2024 | 2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| Пычранган җирләрнең гомуми мәйданыннан яңадан торгызылган җирләрнең өлеше, % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 37,0 | 40,0 | 41,0 | 42,0 | 44,0 |
| Төп сценарий буенча | 37,0 | 41,0 | 42,5 | 45,0 | 50,0 |
| Оптимистик сценарий буенча | 37,0 | 50,0 | 60,0 | 70,0 | 80,0 |
| **СЦ-7: Финанс капиталы** | | | | | |
| Төп капиталга Россия инвестицияләренең тулаем санынннан Татарстан Республикасы өлеше , % | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | 3,8 | 3,7 | 3,7 | 3,7 | 3,8 |
| Төп сценарий буенча | 3,8 | 4,1 | 4,5 | 5,1 | 6,4 |
| Оптимистик сценарий буенча | 3,8 | 4,6 | 5,3 | 6,4 | 7,6 |
| Чит илләрнең турыдан-туры барлык тупланган инвестицияләре, АКШ долларларында (млн.) | | | | | |
| Инерцияле сценарий буенча | | 2 423 | 4 947 | 7 877 | 15 441 |
| Төп сценарий буенча | | 3 428 | 8 640 | 16 449 | 44 107 |
| Оптимистик сценарий буенча | | 4 616 | 13 438 | 30 430 | 94 022 |

Икътисадның максатчан торышының мөһим характеристикасы булып икътисадый комплекслардан чыгып структур алга китешләр тора (2.3 таблица). Оптимистик сценарий нефть-газ химиясе һәм машиналар төзү комплексларының әһәмияте артуын күздә тота.




2.2 нче рәсем. Татарстан Республикасы ВРП максатчан сценар фаразы




2.3 нче рәсем. ППС буенча бер кешегә исәпләнгән ВРП динамикасының максатчан сценар фаразы



2.3 нче таблица. Икътисадый комплекслардан чыгып, Татарстан Республикасы икътисады структурасы үзгәреше (төп сценарий)

| Тармак | Өстәлгән бәя, млрд. сумнарда | | | | Инвестицияләр, млрд. сумнарда | | | | Икътисадта эшләүчеләрнең уртача еллык саны, мең кешедә | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сумма 2013 ел | % | Сумма 2030 ел | % | Сумма 2013 ел | % | Сумма 2030 ел | % | Сумма 2013 ел | % | Сумма 2030 ел | % |
| **Татарстан Республикасы** | **1 547** | **100,0** | **5 132** | **100,0** | **526** | **100,0** | **1 657** | **100,0** | **1 818** | **100,0** | **1 986** | **100,0** |
| **Нефть-газ химиясе комплексы** | 453 | 29,3 | 1 595 | 31,1 | 181 | 34,5 | 639 | 38,5 | 117 | 6,5 | 126 | 6,4 |
| **Энергетика комплексы** | 38 | 2,5 | 87 | 1,7 | 26 | 5,0 | 36 | 2,2 | 31 | 1,7 | 37 | 1,9 |
| **Машиналар төзү һәм башка эшкәртүче сәнәгать комплексы** | **113** | **7,3** | **489** | **9,5** | **39** | **7,3** | **216** | **13,0** | **185** | **10,2** | **211** | **10,6** |
| Машиналар төзү | 98 | 6,3 | 390 | 7,6 | 35 | 6,6 | 188 | 11,4 | 165 | 9,1 | 189 | 9,5 |
| Җиңел, агач эшкәртү сәнәгатьләре һәм башка эшкәртүче производстволар | 14 | 0,9 | 98 | 1,9 | 4 | 0,7 | 26 | 1,6 | 20 | 1,1 | 23 | 1,1 |
| **Агросәнәгать комплексы** | **118** | **7,6** | **405** | **7,9** | **35** | **6,6** | **103** | **6,2** | **217** | **12,0** | **275** | **13,8** |
| Авыл хуҗалыгы | 83 | 5,3 | 233 | 4,5 | 19 | 3,7 | 40 | 2,4 | 173 | 9,5 | 219 | 11,0 |
| Азык-төлек продуктларын җитештерү | 35 | 2,2 | 170 | 3,3 | 15 | 2,9 | 63 | 3,8 | 41 | 2,2 | 53 | 2,7 |
| Балыкчылык, балык үрчетү | 0,1 | 0,0 | 0,5 | 0,0 | 0 | 0,0 | 0,1 | 0,0 | 0,5 | 0,0 | 1 | 0,0 |
| Урман хуҗалыгы | 0,5 | 0,0 | 3 | 0,1 | 0 | 0,0 | 0,3 | 0,0 | 3 | 0,2 | 2 | 0,1 |
| **Инфраструктура комплексы** | **549** | **35,5** | **1 699** | **33,1** | **162** | **30,9** | **360** | **21,7** | **702** | **38,6** | **748** | **37,7** |
| Сәүдә комплексы | 211 | 13,7 | 747 | 14,6 | 12 | 2,3 | 55 | 3,4 | 311 | 17,1 | 314 | 15,8 |
| Төзелеш һәм ТКХ комплексы | 245 | 15,8 | 689 | 13,4 | 84 | 15,9 | 182 | 11,0 | 276 | 15,2 | 285 | 14,4 |
| Торак-коммуналь хуҗалык комплексы | 67 | 4,3 | 174 | 3,4 | 59 | 11,3 | 108 | 6,5 | 65 | 3,6 | 65 | 3,2 |
| Төзелеш комплексы | 178 | 11,5 | 514 | 10,0 | 24 | 4,7 | 74 | 4,5 | 211 | 11,6 | 221 | 11,1 |
| Транспорт-логистика комплексы | 68 | 4,4 | 206 | 4,0 | 60 | 11,4 | 96 | 5,7 | 87 | 4,8 | 119 | 6,0 |
| Телекоммуникацияләр комплексы | 25 | 1,6 | 55 | 1,1 | 6 | 1,2 | 26 | 1,6 | 27 | 1,5 | 30 | 1,5 |
| **Хезмәт күрсәтүләр комплексы** | **276** | **17,8** | **856** | **16,7** | **83** | **15,7** | **305** | **18,4** | **565** | **31,1** | **589** | **29,6** |
| Фәнни-мәгариф комплексы | 56 | 3,6 | 194 | 3,8 | 11 | 2,1 | 81 | 4,9 | 173 | 9,5 | 167 | 8,4 |
| Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтүләр комплексы | 46 | 2,9 | 149 | 2,9 | 10 | 1,9 | 53 | 3,2 | 98 | 5,4 | 93 | 4,7 |

Стратегияне гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәсе булып, глобаль конкурентлык сәләтенә ирешүдән тыш, җәмгыятьнең бердәм булу дәрәҗәсенең, һәр кешенең республика үсешендә кызыксыну һәм аңа җәлеп ителү дәрәҗәсенең артуы торырга тиеш.

Стратегияне гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре югарыда бәян ителгән максатчан күзаллауга һәм индикаторларның максатчан күрсәткечләренә ирешү белән билгеләнә. Өч стратегик приоритеттан чыгып, Стратегияне **гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** – Татарстан Республикасы үсешенең максатчан торышы, ул түбәндәгечә билгеләнә:

1) **кеше капиталы**. Тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә:

Татарстан – туучылар саны югары һәм халыкның миграция килүе тотрыклы булган регион;

инновацияләр өлкәсендә кеше капиталы җитәрлек тупланган;

мәгариф системасы җәмгыять һәм икътисад ихтыяҗларына туры килә торган кеше капиталын булдыруны тәэмин итә;

сәламәтлекне саклау һәм озак яшәү – халыкның һәм сәламәтлек саклау системасының приоритетлары;

мәдәни тормышның сыйфаты һәм төрлелеге кеше капиталын җәлеп итүнең һәм туплауның реаль факторларына әйләнде;

социаль яклау һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү системалары яшәү дәрәҗәсен һәм сыйфатын арттыруга зур өлеш кертә;

2) **пространство**. Балансслы территориаль-пространство үсеше мохитнең конкурентлык сәләтенең югары булуын тәэмин итә:

пространство үсеше социаль-икътисадый факторларны һәм Татарстан Республикасының географик урынын – Евразия уртасында урнашуын күздә тота;

Татарстан территориясе – бердәй социомәдәни киңлек;

яңа социаль-икътисадый (технологик) торышларны алга чыгара торган алдынгы стандартлар нигезендә пространство ресурсы саклана һәм арта;

пассажирлар йөртү өчен таләп ителә торган уңайлылыкны тәэмин итә торган транспорт-коммуникация системасы сыйфатының югары күрсәткечләренә ирешелде;

интеллектуаль һәм экологик чиста технологияләр һәм карарлар нигезендә үсә торган өч агломерацияне (Казан, Кама һәм Әлмәт) берләштерүче челтәр төрендәге өч үзәкле Идел-Кама метрополисы төзелде;

Татарстан Республикасындагы барлык эчке, агломерацияара, регионара транспорт юнәлешләренең, шулай ук халыкара транспорт коридорларының югары синергиясе: «Идел-Кама» үсеш полюсының тотрыклы тизйөрешле транспорт кысасы төзелде;



3) **икътисад һәм идарә итү**. Кластер активлаштыру кысаларында «заманча икътисад» яңартылды һәм «акыллы» икътисад булдырылды, бу икътисадый комплексларның конкурентлык сәләтенең югары булуын тәэмин итә:

үстерү социаль-икътисадый үсеш драйверлары булган конкурентлыкка сәләтле кластерларда нигезләнә; үзәк кластер – нефть-газ химиясе комплексы кластеры;

«акыллы» икътисадның 10 инновацияле кластеры төзелде;

республикада үсешкә стратегик идарә итүнең «тере» системасы (киләчәккә идарә итү системасы эшли), тармак һәм территориаль ачык приоритетлар эшләнде, дәүләт хакимияте органнары структурасы оптимальләштерелде, карарлар кабул итүнең үзәкләштерү дәрәҗәсе киметелде;

бизнес хезмәттәшлек башлангычларында региональ стратегик планлаштыру процессына кертелде: үзгәртеп коруларга әзерлек һәм үз озак сроклы стратегияләре бар;

муниципальара хезмәттәшлек системасы җайга салынды, үз-үзен үстерүгә таянган муниципаль берәмлекләр стратегияләре эшләнде һәм гамәлгә ашырыла.

### 2.4. Стратегияне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ресурсларын бәяләү

2016 – 2030 еллар чорына төп сценарийны гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен төп капиталга инвестицияләр өчен юнәлдерелә торган финанс ресурсларының гомуми күләме 16 трлн. сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

- 2016 – 2018 елларда – 1,8 трлн. сум;
- 2019 – 2021 елларда – 2,4 трлн. сум;
- 2022 – 2024 елларда – 3,2 трлн. сум;
- 2025 – 2030 елларда – 8,6 трлн. сум.

Икътисадый комплекслардан чыгып, оптимистик сценарийның гамәлгә ашырылуын тәэмин итә торган төп капиталга инвестицияләрне финанслау күләме динамикасы 2.4 таблицада бирелгән.

2.4 нче таблица. Икътисадый комплекслардан чыгып, төп капиталга (млрд. сум) инвестицияләр динамикасы (төп сценарий)

| Тармак | 2016 – 2018 еллар | | 2019 – 2021 еллар | | 2022 – 2024 еллар | | 2025 – 2030 еллар | | БАРЛЫГЫ | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сумма | % | Сумма | % | Сумма | % | Сумма | % | Сумма | % |
| Татарстан Республикасы | 1 816 | 100,0 | 2 447 | 100,0 | 3 158 | 100,0 | 8 581 | 100,0 | 16 002 | 100,0 |
| **Нефть-газ химиясе комплексы** | 688 | 37,9 | 927 | 37,9 | 1 154 | 36,5 | 3 269 | 38,1 | 6 038 | 37,7 |
| **Энергетика комплексы** | 83 | 4,6 | 102 | 4,2 | 103 | 3,3 | 201 | 2,3 | 489 | 3,1 |
| **Машиналар төзү һәм башка эшкәртүче сәнәгать комплексы** | **181** | **10,0** | **259** | **10,6** | **358** | **11,3** | **1 084** | **12,6** | **1 883** | **11,8** |
| Машиналар төзү | 157 | 8,6 | 221 | 9,0 | 307 | 9,7 | 943 | 11,0 | 1 627 | 10,2 |
| Җиңел, агач эшкәртү сәнәгатьләре һәм башка эшкәртүче производстволар | 25 | 1,4 | 39 | 1,6 | 52 | 1,6 | 141 | 1,6 | 255 | 1,6 |
| **Агросәнәгать комплексы** | **116** | **6,4** | **146** | **6,0** | **186** | **5,9** | **529** | **6,2** | **976** | **6,1** |
| Авыл хуҗалыгы | 53 | 2,9 | 64 | 2,6 | 82 | 2,6 | 214 | 2,5 | 413 | 2,6 |
| Азык-төлек продуктларын җитештерү | 62 | 3,4 | 82 | 3,3 | 104 | 3,3 | 312 | 3,6 | 560 | 3,5 |
| Балыкчылык, балык үрчетү | 0 | 0,0 | 0 | 0,0 | 0 | 0,0 | 0 | 0,0 | 0 | 0,0 |
| Урман хуҗалыгы | 0 | 0,0 | 0 | 0,0 | 0 | 0,0 | 0,9 | 0,0 | 0,9 | 0,0 |
| **Инфраструктура комплексы** | **451** | **24,8** | **589** | **24,1** | **777** | **24,6** | **1 905** | **22,2** | **3 722** | **23,3** |
| Сәүдә комплексы | 64 | 3,5 | 81 | 3,3 | 108 | 3,4 | 293 | 3,4 | 546 | 3,4 |
| Төзелеш һәм ТКХ комплексы | 228 | 12,5 | 285 | 11,6 | 368 | 11,6 | 968 | 11,3 | 1 848 | 11,5 |
| Торак-коммуналь хуҗалык комплексы | 158 | 8,7 | 190 | 7,8 | 239 | 7,6 | 596 | 6,9 | 1 184 | 7,4 |
| Төзелеш комплексы | 68 | 3,8 | 95 | 3,9 | 129 | 4,1 | 373 | 4,4 | 666 | 4,2 |
| Транспорт-логистика комплексы | 119 | 6,6 | 174 | 7,1 | 242 | 7,7 | 496 | 5,8 | 1 031 | 6,4 |
| Телекоммуникацияләр комплексы | 40 | 2,2 | 49 | 2,0 | 60 | 1,9 | 148 | 1,7 | 297 | 1,9 |
| **Хезмәт күрсәтүләр комплексы** | **299** | **16,4** | **424** | **17,3** | **579** | **18,3** | **1 593** | **18,6** | **2 895** | **18,1** |
| Фәнни-мәгариф комплексы | 64 | 3,5 | 100 | 4,1 | 145 | 4,6 | 416 | 4,8 | 725 | 4,5 |
| Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтүләр комплексы | 40 | 2,2 | 66 | 2,7 | 96 | 3,0 | 272 | 3,2 | 474 | 3,0 |
| Туристлык-рекреация комплексы | 30 | 1,7 | 40 | 1,7 | 57 | 1,8 | 157 | 1,8 | 285 | 1,8 |
| Мәгълүмати-технологик комплекс | 5 | 0,3 | 20 | 0,8 | 35 | 1,1 | 119 | 1,4 | 179 | 1,1 |
| Дәүләт һәм хосусый хезмәт күрсәтүләр комплексы | 160 | 8,8 | 196 | 8,0 | 248 | 7,8 | 628 | 7,3 | 1 232 | 7,7 |
| ***Инерциале сценарий белән чагыштырганда төп сценарийны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган өстәмә инвестицияләр күләме*** | **62** | | **260** | | **519** | | **2 026** | | **2 867** | |
| ***Инерциале сценарий белән чагыштырганда оптимистик сценарийны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган өстәмә инвестицияләр күләме*** | **126** | | **405** | | **965** | | **5 195** | | **6 691** | |



## 3. Социаль-икътисадый сәясәтнең өстенлекле юнәлешләре һәм бурычлары

### 3.1. Кеше капиталын туплау стратегиясе: яхшылар өчен магнит

Кеше капиталы – территориянең икътисадый үсешенең мөһим ресурсы. Постиндустриаль икътисад үзенчәлекләре бу ресурсны беренче дәрәҗәдәге рангка күтәреп аның әһәмиятен арттыра. Кеше капиталы дигәндә, кешеләрдә гәүдәләнгән сәләтләр, белемнәр, күнекмәләр һәм осталык аңлашыла, алар кешеләргә шәхси, социаль һәм икътисадый байлыкларын булдырырга мөмкинлек бирә. Кеше капиталын булдыра торган төп факторлар булып белем бирү һәм һөнәри әзерлек тора. Киңрәк караганда, аларга шулай ук куллану дәрәҗәсен, яшәү сыйфатын, медицина хезмәт күрсәтүе дәрәҗәсен кертәләр. Кеше капиталын аңлауның киңәйтелгән карашыннан чыгып, ул тулаем социаль өлкә тарафыннан барлыкка килә һәм кеше капиталының сыйфаты әлеге өлкәнең сыйфатына бәйле дип әйтергә була.

Әлеге карашка таянып, Кеше капиталын туплау стратегиясе берничә социаль юнәлешне берләштерә. Шуларның икесе төп: миграция һәм демография сәясәте; белем бирүнең барлык дәрәҗәләре (мәктәпкәчә, урта гомуми, башлангыч һәм урта һөнәри, югары). Бу өлкәләр кеше капиталының төгәл төшенчәсенә, аны булдыру процессларына турыдан-туры бәйле. Башка кайбер юнәлешләр – сәламәтлек саклау, мәдәният, хезмәт базары, эш белән тәэмин итү сәясәте һәм социаль яклау – регионда кеше капиталын тотып калуга өстәмә шартлар тудыра.

Шул рәвешле Татарстан Республикасында Кеше капиталын туплау стратегиясенә тармак стратегияләренең ике блогы керә: кеше капиталын **булдыру факторлары** стратегияләре, аларга демографик үсеш (миграцияне кертеп) һәм мәгариф керә, шулай ук кеше капиталын **туплау һәм куллану шартларын** яхшырту стратегияләре (сәламәтлек саклау, мәдәният, хезмәт базары һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү, социаль яклау).

Карала торган барлык юнәлешләрдә үстерүнең локаль максатлары куелган, әмма алар үзара бәйле һәм Кеше капиталын туплау стратегиясенең төп максатына ирешүгә бергәләп эшлиләр (3.1 рәсем)[1]:

<u>СЦ-1</u> **Тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә. Республика яшәүнең югары сыйфатына ирешү өчен шартлар тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда алдынгы булып тора.**

1 Мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү бу бүлектә күбесенчә кеше капиталын булдыру һәм туплау факторлары яисә шартлары буларак карала. 3.3 бүлектә алар хезмәт күрсәтүләр икътисадының үсә торган тармаклары буларак карала.

Кеше капиталын туплау стратегиясе юнәлешләренең һәрберсе буенча агымдагы хәлгә үткәрелгән анализ нәтиҗәләре, төп мәсьәләләр һәм мөмкинлекләр, максатчан күзаллау һәм үсешнең алдагы бурычлары, шулай ук берничә чара — программалар һәм проектлар төзелде. Комплекслы характерга ия флагман проектларга аерым әһәмият бирелә. Кеше капиталын туплау стратегиясендә алты флагман проектны гамәлгә ашыру каралды, аларның һәрберсе социаль үсешнең берничә юнәлеше буенча алга баруны тәэмин итә (3.2 рәсем).






Максатлар системасы (максатчан күзаллау 2030)




3.1 рәсем. Кеше капиталын туплау стратегиясенең структурасы һәм максатлар системасы




**3.2 рәсем. Флагман проектларның һәм Кеше капиталын туплау стратегиясе юнәлешләренең үзара бәйләнеше**

### 3.1.1. Халык динамикасы

***Хәзерге торыш***

Татарстан Республикасы халкы саны арта: 1990 – 2014 елларда үсеш 182 мең кеше тәшкил итте. Халык саны артуы миграция исәбенә башкарылды, чөнки республикада туучылар саны үлүчеләр санын 2011 елдан гына узып китте.

Туучылар саны артуы тууларның интенсивлыгы үсешенә дә, иң актив репродуктив яшьтәге хатын-кызлар саны артуына да бәйле. Татарстанда шәһәр халкында да, авыл халкында да туулар интенсивлыгының кызу чагы элек булган кебек 20 – 24 яшькә түгел, ә 25 – 29 яшькә туры килә. Туулар календаре өлкән



яшьтәгеләргә күчә, бу икътисадый яктан үсешләрендә алга киткән илләрдә күзәтелә торган тенденциягә туры килә. Тууларның тулаем коэффициенты (СКР) 1,8дән артып китте, бу Европа илләре өчен югары күрсәткеч булып тора, авыл халкында СКР 2012 елда 2,09ны тәшкил итте, ягъни халыкны яңадан торгызу өчен кирәкле дәрәҗәгә якынайды. Әмма авыл халкының өлеше республикада зур түгел, шуңа күрә әлеге күрсәткеч республика буенча тулаем алганда халыкны яңадан торгызу күрсәткечләренә җитди тәэсир ясый алмый.

Татарстанда үлүчеләр саны һәм алдагы гомернең көтелгән озынлыгы (ОПЖ) күрсәткечләре буенча хәл Идел буе федераль округының башка регионнарына караганда уңайлырак. Үлем сәбәпләренең барлык төп класслары буенча коэффициентлар соңгы еллар дәвамында тулаем ил һәм Идел буе белән чагыштырганда түбәнрәк. ОПЖ, 2002 елдан алып ирләрдә 61 яшьтән 66 кадәр һәм хатын-кызларда 74,5 яшьтән 77,5 кадәр артып, өзлексез үсте. Әмма бу үсеш тулысынча торгызу үсеше булды: 1990 ел белән чагыштырганда күрсәткечләр үзгәрмәде диярлек. Иң җитди проблема, бу бөтен ил буенча да шулай, хезмәткә сәләтле яшьтәге ирләрнең үлеме югары дәрәҗәдә булуы. 20 – 59 яшьләрдә барлык сәбәпләр буенча ирләр арасында үлүчеләр саны хатын-кызлар үлеменә караганда өч тапкырдан да артык.

Татарстанда демографик хәлне алга таба яхшыртуны халыкның яшь структурасы үзгәрүдәге тискәре тенденцияләр тотып тора, бу структура гомумроссиянекеннән аерылып тормый диярлек. Бу тенденцияләр иң актив репродуктив яшьтәге хатын-кызлар саны кимүенә һәм өлкән яшьтәге халыкның саны һәм өлеше артуына бәйле. Халыкның хезмәткә сәләтле яшьтәге өлеше 2008 елдан алып кими, аңа өлкәннәр һәм балалар тарафыннан йөкләнеш арта. Яшьләр саны кими: якындагы елларда хезмәт базарына чыгучы яшь белгечләрнең саны демографик сәбәпләр буенча якынча 40 процентка кимиячәк. Халыкның күпсанлы когорталарының аз санлылар белән алмаштырылуы демографик һәм социаль сәясәт үткәрүне шактый авырайта, социаль хезмәтләр (мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль тәэмин итү) күрсәтү күләмнәрен даими төзәтү кирәклегенә китерә.

Бу шартларда аерым әһәмият миграция сәясәтенә бирелә. Татарстан, Самара һәм Түбән Новгород өлкәләре белән беррәттән Россиядә читтән килгән мигрантларны да, башка регионнардан килгәннәрен дә җәлеп итүче аз санлы эре үзәкләрнең берсе. Халыкның максималь миграция үсеше 1990 еллар уртасында күзәтелде. Соңгы елларда миграция үсеше 10 – 12 мең кеше дәрәҗәсендә сакланды, әмма 2014 елда ул 7,2 меңнән артмады.

Халыкара миграциядә төп үсешне Урта Азия илләре тәэмин итә, 1990 еллар башыннан алып бу ташкында этник татарлар да аз түгел. 2000 елларда репатриация миграциясе вакытлы хезмәт миграциясенә урын бирде, бу исә ташкынның аерым сыйфатлы билгеләренә тәэсир итте: чыгышы белән зур шәһәрләрдән булган кешеләр саны кимеде, килүчеләрнең белем дәрәҗәсе түбәнәйде. Мигрантлар агымы Татарстанда дөрес җайга салу һәм толерантлы яшәү традицияләре нәтиҗәсендә моноэтник регионнардагы кебек кабул итүче социумның килешмәвен китереп чыгармады.

Россия эчендәге миграциядә Татарстан халыкны башкала регионына (Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе) бирә, әмма аны Идел буе, Урал регионнарыннан һәм илнең көнчыгышыннан җәлеп итә. Халыкны җәлеп итүне регионның үсә барган икътисады, шулай ук иң зур һәм динамик үзәк — Казанның булуы тәэмин итә.

Россия эчендәге хезмәт миграциясенең балансы тискәре: Росстат мәгълүматлары буенча, 34,7 мең кеше республикадан читтә (Мәскәү, Төмән өлкәсе, ХМАО һәм ЯНАО) эшләде, Татарстанда бу вакытта башка регионнарда яшәүче 21,6 мең кеше генә хезмәт итте. Шул ук вакытта 2014 елда Татарстанда 11 мең чит ил гражданы эшкә рөхсәтләр рәсмиләштерде, физик затларда эшләүчеләр өчен 30 мең патент сатылды. Татарстанда тулаем алганда вакытлы хезмәт миграциясе балансы тәэмин ителә: республика кешеләре икътисадый яктан уңышлырак регионнарда яхшы түләүле урыннарда эшли, ә икътисадның аерым секторларында хезмәт базарындагы буш урыннарны чит ил хезмәткәрләре ала.

Республика чикләрендә халык Казанга тартыла, монда берничә зур югары уку йорты эшли һәм хезмәт базары төрле, шуңа күрә башкалага килүчеләр арасында яшьләр өстенлек тота. Авыл районнары, кече һәм урта шәһәрләр яшьләрне зур темплар белән югалта, районнарның кайберләрендә бу югалтулар урта мәктәпне тәмамлаучыларның 30 процентан артыгын тәшкил итә.

Киләчәктә Татарстанга күршеләр белән дә, халыкны җәлеп итүнең төп Россия үзәкләре белән дә халык өчен уңышлы ярышып, мигрантлар җәлеп итә торган регион урынын саклап калырга кирәк. Соңгы елларда табигый үсеш халык саны динамикасының төп компоненты булып тора, әмма киләчәктә миграциянең роле тискәре демографик динамика аркасында яңадан артырга мөмкин.

***Төп мәсьәләләр:***

• «демографик дулкыннар»ның тискәре чорлары шартларында демографик үсешкә ярдәм итү кирәклеге. Социаль хезмәт күрсәтүләр системасын «дулкыннар»га көйләү;



• якындагы елларда яшьләр санының тиз кимүе — инновацияле икътисадый үсеш өчен хәл ителәсе мәсьәлә;

• халыкның картаюының һәм хезмәткә сәләтле халыкка йөкләнешнең тиз артуының котылгысызлыгы;

• халыкны җәлеп итү үзәге позицияләрен саклап калу;

• республикада халыкны тотып калу омтылышы һәм кеше потенциалын мөмкин булган кадәр тулырак гамәлгә ашыру максатларында халыкның мобильлеген көчәйтүнең объектив кирәклеге арасында каршылык;

• халыкны регион эчендәге периферияда тотып калу бурычы һәм шәһәр агломерацияләрен үстерү арасында каршылык.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

**Ц-1.1**[1] **Татарстан — туучылар саны югары һәм халыкның миграция агымы тотрыклы булган үсә торган регион.**

*З-1.1.0.1*[2] **Ике һәм өч балалы гаиләләрнең өлешен арттыру исәбенә туучылар санын алга таба арттырырга.**

*З-1.1.0.2* **Хатын-кызларга ата-ана бурычларын хезмәт мәшгульлеге белән бергә алып бару өчен шартлар тудырырга.**

*З-1.1.0.3* **Хезмәткә сәләтле яшьтә үлүчеләр санын һәм идарә ителә торган сәбәпләрдән үлемнәрне киметү исәбенә көтелгән гомер озынлыгын озайтуны тәэмин итәргә.**

*З-1.1.0.4* **Регионның социаль-икътисадый үсешенә халыкның картаюы йогынтысының тискәре нәтиҗәләрен җиңеләйтергә.**

*З-1.1.0.5* **Халыкның һәм хезмәт мигрантларының агымын җайга салу өчен шартлар булдырырга.**

*З-1.1.0.6* **Республикадан яшь буынның, квалификацияле белгечләрнең читкә китүен киметү өчен шартлар тудырырга.**

*З-1.1.0.7* **Республикада мигрантларның адаптацияләнүенә һәм интеграцияләнүенә ярдәм итү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга.**

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) туучылар санының уңайлы динамикасын саклау (гаиләләргә максималь тулы дәрәҗәдә балаларга ихтыяҗны гамәлгә ашыру мөмкинлеген бирү шартларын тудыру):

• балалы гаиләләргә акчалата бирелә торган социаль ярдәм чараларының адреслылыгын арттыру;

• социаль ярдәм чараларын гаиләләрнең яшәү циклының

1 Ц — монда һәм алга таба Стратегия максатлары.
2 З — монда һәм алга таба Стратегия бурычлары.

төп стадияләре буенча нәтиҗәлерәк булу (хәзер күбесенчә бала 1,5 яшькә җиткәнче);

• балаларның үсеп җитүенә һәм аларны тәрбияләүгә ярдәм итә торган инфраструктура булдыру һәм үстерү;

• ата-аналарга балалар карауны икътисадый активлык белән бергә алып бару мөмкинлекләрен тәэмин итү;

• 2) үлүчеләр санын киметү һәм гомер озынлыгын арттыру:

• булдырмый калдыра ала торган үлемнәрне һәм иртә үлемнәрне киметү өлешендә сәламәтлек саклау системасын камилләштерү;

• үз-үзеңне саклау тәртибен үстерү һәм сәламәт, актив гомер озынлыгы өчен шартлар тудыру;

• 3) халыкның миграция үсешен тәэмин итү (төрле категориядәге мигрантлар өчен регионның мигрантлар җәлеп итүчәнлеген арттыра торган икътисадый шартлар булдыру):

• сыйфатлы эш урыннары булдыру;

• инфраструктураны (торак, транспорт һ.б.ш.) үстерү, аренда торагы базарына ярдәм итү, шәһәр мохите сыйфатын яхшырту, кече бизнес өчен шартларны яхшырту;

• ике яклы хөкүмәтара килешүләр төзү һәм аларны гамәлгә ашыру;

• мигрантларның кабул итүче социумга интеграцияләнүен тәэмин итү (мигрантларның өстенлекле категорияләре өчен ярдәм итү режимын булдырырга).

*Татарстан Республикасында туучылар санын арттыруга юнәлдерелгән өстәмә чаралар буенча Комплекслы план һәм «Татарстан Республикасында гаиләләрнең социаль-икътисадый хәлен яхшырту» программасы проекты.*

Якындагы 10 – 15 елда Россиядә һәм Татарстан Республикасында халыкның яшь структурасындагы тискәре үзгәрешләрнең нәтиҗәсе буларак (актив репродуктив яшьтәге хатын-кызлар саны кимүе) республикада туучылар саны кимиячәк. «1990 еллар кайтавазы»ның тискәре йогынтысын 2000 елларның икенче яртысыннан башланган, шул исәптән 2006 елда кабул ителгән актив демографик сәясәт чаралары белән стимуллаштырылган туучылар саны күрсәткечләрен арттыруның уңайлы тенденцияләрен дәвам итү җиңеләйтергә мөмкин. Дөньякүләм тәҗрибә шуны күрсәтә, тууларга ярдәм итү чараларын алга таба үстермәгәндә һәм камилләштермәгәндә аларның тәэсире бетә. Болай булмасын өчен, балалы гаиләләргә ярдәм итү чаралары аларның адреслылыгын арттыру, социаль ярдәм чараларын яшәү циклының төп стадияләре буенча нәтиҗәлерәк булу, шулай ук балалар тәрбияләүгә ярдәм итә



торган инфраструктура булдыру һәм үстерү, ата-аналарга балалар карау бурычларын икътисадый активлык белән бергә алып бару мөмкинлекләрен тәэмин итү исәбенә оптимальләштерелергә тиеш.

*Нәтиҗә*: туучылар саны күрсәткечләренең алдагы үсеше (2030 елга туучылар санының тулаем коэффициенты күрсәткеченең 1,838 дәрәҗәсенә кадәр үсеше), балалы гаиләләр арасында ярлылыкның радикаль рәвештә кимүе, уңайлы график шартларында һәм тулы булмаган эш көне режимында, шулай ук ерактан торып эшләү шартларында хезмәт итү мөмкинлеге булган, балалар тәрбияләүче хатын-кызларның өлеше артуы.

***«Татарстан – Идел буена халыкны җәлеп итү үзәге» флагман проекты (3.1.6.1 кара)***[1]

### 3.1.2. Мәгариф – Татарстанның үсеш нигезе

Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе түбәндәге төп принципларга һәм мәгариф системасына карата таләпләргә нигезләнде:

1) мәктәпкәчә һәм мәктәптә белем бирү сыйфаты Татарстанда яшәү сыйфатының һәм анда яшәүнең кызыклы булуның югары стандартлары фикеренә җавап бирергә тиеш;

2) кеше капиталына нигез сала торган мәктәптә белем бирү XXI гасыр компетенцияләренә юнәлеш тотарга, фикерләүнең инновацияле төрен булдыруны һәм патриотизм тәрбияләүне тәэмин итәргә тиеш;

3) һөнәри белем бирү сыйфаты һәм масштабы Татарстан икътисадының конкурентлык сәләтен тәэмин итәргә тиеш;

4) республика югары белем бирү системасы аша башка регионнардан һәм илләрдән талантлар җәлеп итү урынына әйләнергә тиеш;

5) мәгариф системасы Татарстанның күпмәдәни бердәйлегенең үсешен тәэмин итәргә тиеш.

Бюджет ресурслары чиклелеге шартларында система үсешенең төп ресурслары булып түбәндәгеләр торырга тиеш: инновацияләр; укыту процессына мәктәп балаларының һәм студентларның җәлеп ителүе; укыту процессында ата-аналарның катнашуы; кире элемтәгә нигезләнгән нәтиҗәле идарә итү.

**Ц-1.2 Мәгариф системасы Татарстан җәмгыятенең һәм икътисадының ихтыяҗларына туры килә торган кеше капиталын булдыруны тәэмин итә.**

---

1 Иң әһәмиятле булган флагман проектларның барысын тасвирлау аерым параграфта бирелә.

3.1.2.1. Мәктәпкәчә белем бирү

***Хәзерге торыш***

Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген, балаларны карап торуны һәм карауны гамәлгә ашыручы 2 029 оешма (ДОО) эшли, аларның яртысыннан артыгы (1 101) авыл җирендә урнашкан (2014 елгы мәгълүматлар). Аларда 179,7 мең урын бар, ә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гомуми саны 285 мең кешене тәшкил итә. Туучылар саны шактый арту сәбәпле ДООда урыннарның билгеле кытлыгы күзәтелә, моны бетерү өчен тиешле юл картасы эшләнде.

Мәктәпкәчә белем бирүнең мөмкин булуын гына түгел, ә аның сыйфатын да арттыру тулаем Россия өчен мөһим бурыч булып тора. Әмма Татарстанда моңа өстәп күпмәдәни белем бирү мохитен булдыру кирәклеге дә бар.

***Төп мәсьәләләр:***

• инфраструктура үстерү проектларын гамәлгә ашыруга бирелгән бюджетларны кыскарту куркынычына бәйле макроикътисадый тотрыксызлык;

• демографик тирбәлешләр (2010 еллар башында контингент артуы һәм «1990 елларның демографик кайтавазы»на бәйле 2010 еллар ахырында һәм 2020 елларның беренче яртысында көтелгән кимү);

• мәгарифнең глобальләшүе һәм милли мәдәниятне саклап калу кирәклеге арасында конфликт;

• балаларның иртә үсүен (өч яшькә кадәр) тәэмин итеп бару ихтыяҗының канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмавы;

• балалар белән эшләгәндә социаль, медицина һәм мәгариф хезмәтләре арасында ведомствоара кооперация булмавы.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

**Ц-1.2.1 Гаиләләр балаларны һәрьяклап үстерүдә һәм аларны мәктәптә укуга әзерләүдә нәтиҗәле ярдәм белән тәэмин ителде.**

*З-1.2.1.1* Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү торышын, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсеш дәрәҗәсен һәрьяклап тикшерергә.

*З-1.2.1.2* Уңайлы файдалану мөмкинлекләрен исәпкә алып, инфраструктураны яңартырга, заманча мультимедиа технологияләрен гамәлгә кертергә.

*З-1.2.1.3* Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган секторның өлешен арттырырга.

*З-1.2.1.4* Татарстан Республикасының күпмәдәни киңлеген һәм



заманча технологияләрне исәпкә алып, яңа Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә уку-укыту программаларын эшләргә.

*З-1.2.1.5* Гаиләләрдә һәм яслеләрдә балаларның иртә үсүен тәэмин итеп бару системасын булдырырга.

*З-1.2.1.6* Балаларның үсүен тәэмин итеп баруның ведомствоара координацияләү системасын эшләргә.

*З-1.2.1.7* Авырлыкларны иртә ачыклау һәм аларны хәл итүдә ярдәм итү өчен балаларның үсүен индивидуаль тәэмин итеп бару системасын булдырырга.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) мәктәпкәчә балачак өлкәсендә тикшеренүләр комплексы оештыру;

2) инфраструктура үстерүнең үзәкләштерелгән программасын гамәлгә ашыру;

3) мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә инновацияләргә ярдәм итүнең грант программаларын булдыру;

4) мәктәпкәчә белем бирүнең дәүләтнеке булмаган секторын стимуллаштыру, дәүләт-хосусый һәм социаль партнерлыкны үстерү;

5) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының мәктәпләр белән элемтәсен ныгыту, шул исәптән түбәндәге комплекслар рәвешендә: балалар бакчаларын мәктәпләр белән бергә комплекслар составына кертү, күпмаксатлы билгеләнештәге мәктәпкәчә белем бирү инфраструктурасын булдыру;

6) мәктәпкәчә баскычта икетеллелек культурасына һәм күпмилләтле мәгарифкә ярдәм күрсәтү: милли мәдәниятне саклап калуга һәм балаларны заманча мәктәптә белем алуга әзерләүгә юнәлдерелгән уку-укыту программаларын эшләү, педагогларны әзерләү һәм яңадан әзерләү;

7) муниципалитетлар дәрәҗәсендә мәктәпкәчә белем бирүдәге «балалар сервисларын» координацияләү: муниципаль дәрәҗәдә балалар мәнфәгатьләрендә социаль, мәдәни, медицина һәм мәгариф хезмәт күрсәтүләрне координацияләү механизмнарын булдыру; берничә «пилот» муниципалитетта ведомствоара кооперация механизмнарын һәм балалар үсешендәге авырлыкларны һәм үзенчәлекләрне исәпкә ала торган аларның үсүен индивидуаль тәэмин итеп бару механизмнарын эшләү; ведомствоара хезмәттәшлекнең актуаль системасын анализлау, мондый хезмәттәшлекне җайга сала торган норматив-хокукый база булдыру;

8) «Иртә үсеш» проектын гамәлгә ашыру, аңа түбәндәгеләр кирә:

• мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль үсешен бәяләү системасын булдыру;

• мәктәпкәчә белем бирү оешмалары нигезендә иртә үсеш клубларын оештыру, гаиләләргә һәм мәктәпкәчә белем бирүгә ярдәм итүнең уңайлы рәвешләре, авыр хәлдә калган балаларга, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларны кертеп, аеруча ярдәм итү;

• үсешләрендә авырлыклар булган балаларның үсүен тәэмин итеп баруның һәркем өчен мөмкин булган системасын булдыру.

### 3.1.2.2. Гомуми (мәктәп) белем бирү

***Хәзерге торыш***

Татарстан Республикасының гомуми белем бирү системасы күрсәткечләрнең күбесеннән Россия Федерациясе буенча уртача күрсәткечләрдән югары тора:

• укытучыларның хезмәт хакы 2012 – 2014 еллар дәвамында артты һәм республика буенча уртача хезмәт хакы күрсәткечен тотрыклы рәвештә узып бара;

• яшь укытучыларның өлеше 14 процент тәшкил итә, бу Россиядәге уртача дәрәҗәдән (13,2 процент) артыграк;

• мәҗбүри дисциплиналар буенча БДИның уртача тест баллының күрсәткече буенча да, «йөз баллчылар» өлеше буенча да чагыштырмача югары нәтиҗәләр. Шуның белән бергә, Россия Федерациясенең барлык регионнары кебек үк, Татарстан «XXI гасыр күнекмәләрен» бәяләүдә, тәнкыйди фикерләүне, академик белемнәр, мәгълүмати грамоталылык куллану сәләтен кертеп, югары нәтиҗәләр күрсәтми;

• Татарстан уку-укыту процессын һәм идарә итү системасын мәгълүматлаштыру дәрәҗәсе буенча Россиядә алдынгыларның берсе, әмма белем бирүне мәгълүматлаштыру дәрәҗәсе идарә итүне мәгълүматлаштырудан һәм хәзерге мөмкинлекләрдән артта кала.

2013/2014 уку елында Татарстан Республикасында 1 498 гомуми белем бирү оешмасында 368 691 кеше укыды, шулардан 31 484 кеше – икенче сменада. Татарстан икенче сменада шөгыльләнүче балалар саны буенча Россиядә 17 урында тора. Планлаштырылган чараларны һәм демографик фаразны исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмаларында берничә уң мең яңа урын булдыру таләп ителәчәк.

***Төп мәсьәләләр:***

• макроикътисадый тотрыксызлык, бюджетны кыскарту һәм чыгымнарны киметү куркынычы;



• укучылар саны артуы, бу яңа урыннар кертүне һәм штат арттыруны таләп итә;

• уку-укыту технологияләренең һәм укыту тәҗрибәләренең белем алучыларның ихтыяҗларыннан һәм мөмкинлекләреннән артта калуы;

• традицион педагогик карашлар өстен булу шартларында гомуми белем бирүнең яңа Федераль дәүләт белем бирү стандартларын кертү кирәклеге;

• белем бирүнең тигез булмавы көчәюенең куркынычлары;

• сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирүне тәэмин итү кирәклеге;

• мәктәп системасы аз куллана торган өстәмә формаль булмаган белем бирү мөмкинлекләрен киңәйтү: уку-укыту процессына өстәмә белем бирүне интеграцияләү.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

**Ц-1.2.2** **Гомуми белем бирү, индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, һәр мәктәп баласының социальләшүен һәм белем алуда югары казанышларга ирешүен, мәгълүмати технологияләр өлкәсендә күнекмәләр үсешен тәэмин итә.**

*З-1.2.2.1* Заманча архитектура, идарә итү, технологик һәм педагогик чишелешләрне берләштерә торган мохит булдырырга.

*З-1.2.2.2* Белем бирү ресурсларыннан файдалану тигезлеген тәэмин итә торган механизмнар эшләргә.

*З-1.2.2.3* Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирүне тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.4* Гаиләләрнең, урындагы җәмәгатьнең, бизнесның уку-укыту процессында, белем бирү сыйфатын бәяләүдә һәм мәктәпләр белән идарә итүдә катнашу мөмкинлекләрен киңәйтергә.

*З-1.2.2.5* Укытуның заманча рәвешләрен, профильле укытуны кертеп, үстерү исәбенә, гомуми һәм өстәмә белем бирүне интеграцияләү исәбенә белем алучыларның белем алу индивидуальлегенең һәм академик мобильлегенең югары дәрәҗәсен тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.6* Белем бирү сыйфатын бәяләүнең республика системасын булдырырга.

*З-1.2.2.7* Россия Федерациясендә алдынгылыкка ирешү өчен мәглүмат технологияләре һәм математика өлкәсендә белем бирүне үстерүгә өстенлек бирергә.

*З-1.2.2.8* Сәләтле балаларны һәм яшьләрне барларга һәм аларга ярдәм итәргә.

*З-1.2.2.9* Педагогик белем бирү системасын яңартырга.
*З-1.2.2.10* Иң яхшы яшь педагогик кадрлар килүен һәм аларның һөнәри үсешен тәэмин итәргә.
*З-1.2.2.11* Мәктәпләрне үз-үзен укыту оешмалары буларак үстерү стратегияләрен гамәлгә ашыручы алдынгы директорлар корпусын оештырырга.
*З-1.2.2.12* Балалар-үсмерләр оешмаларының республика системасын һәм хәйрия, граждан-патриотик, экологик һәм башка юнәлештәге хәрәкәтләрне үстерүне оештыру-методик алып баруны тәэмин итәргә.
*З-1.2.2.13* Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) яңа мәктәп биналарын төзү һәм реконструкцияләү программасы;
2) инновацияләргә ярдәм итүнең грант программалары;
3) сыйфатны бәяләү системасын үстерүнең республика программасы;
4) математика һәм мәгълүмати технологияләр өлкәсендә белем бирүдә алдынгылыкка ирешүнең республика программасы;
5) балаларга дәүләтнеке булмаган өстәмә белем бирүне үстерүдә норматив киртәләрне бетерү;
6) мәгариф оешмаларының мөстәкыйльлеген арттыруны норматив стимуллаштыру;
7) ата-аналарның уку-укыту процессында һәм мәгарифне үстерүдә катнашуын киңәйтүне норматив стимуллаштыру;
8) нәтиҗәле контрактны хуплау, аерым алганда, мәгариф оешмаларының менеджментын нәтиҗәле контракт нигезендә идарә итү методикаларына өйрәтү, контрактта нәтиҗәлелекне бәяләү критерийларын детальләштерү, нәтиҗәле контракт буенча хезмәт өчен түләү нормативларын оптимальләштерү;
9) сәләтле балаларны һәм яшьләрне барлау, үстерү һәм аларның үсешен тәэмин итеп бару программасы;
10) башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү дәрәҗәсендә икетеллелек культурасына һәм күпмилләтле мәгарифкә ярдәм күрсәтү.

***Чаралар исемлеге:***

1) мәктәп биналарын төзү һәм реконструкцияләү программасы төрле масштабта төрле ресурс мөмкинлекләре белән гамәлгә ашырыла. Беренче баскыч – башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны (1 – 4 класслар) бер сменалы режимда укыту өчен өстәмә урыннар булдыру.



Икенче баскыч – урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны (10 – 11 класслар) бер сменалы режимда укыту өчен өстәмә урыннар булдыру. Өченче баскыч – төп гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны (5 – 9 класслар) бер сменалы режимда укыту өчен өстәмә урыннар булдыру һәм мәгариф оешмаларында үсеш мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен уңайлы мохит булдыру;
2) «Гомуми белем бирү сыйфатын бәяләүнең республика системасы» проекты (бәяләү процедураларының бербөтен һәм balanslы системасын төзү чаралары);
3) колледжлар, бакалавриат һәм магистратура дәрәҗәсендә педагогик белем бирү системасын оптимальләштерү чаралары комплексын эшләү һәм гамәлгә кертү;
4) «Татарстанның яшь укытучысы» проекты. Яңа башлаучы укытучылар өчен икееллык интернатура кертү, яшь укытучылар әзерләүдә менторлар катнашуы, методик ярдәм күрсәтү, җәйге һәм кышкы мәктәпләр уздыру. Ресурслар булганда өстәмә рәвештә педагогик югары уку йортларын тәмамлаучыларның иң яхшылары арасында конкурс үткәреп алга таба вазыйфаны күтәрү һәм өстәмә түләү яисә магистратурага җибәрү;
5) технология һәм мәгълүмати технологияләр буенча гомуми белем бирү өчен уникаль уку-укыту программасын эшләү һәм гамәлгә кертү: яңа Федераль дәүләт белем бирү стандартларларын гамәлгә кертү (математикага һәм информатикага басым ясап), мәктәпләрнең һәм өстәмә белем бирүнең челтәр проектларын гамәлгә ашыру, мәктәп балаларының массакүләм конкурсларына, ярышларына һәм олимпиадаларына грант ярдәме;
6) гомуми белем бирү конкурслары системасын булдыру, аларда һәр бала үзенең мөмкинлекләрен күрсәтергә мөмкин;
7) директорлар корпусының кадрлар резервын булдыру һәм иң яхшы мәктәпләрдә, югары уку йортларында стажировкалар оештыру;
8) балалар-үсмерләр оешмаларының һәм хәрәкәтләренең тармакланган челтәрен булдыру;
9) милли мәгарифне үстерү концепциясен эшләү һәм гамәлгә ашыру;
10) татар теле һәм әдәбияты буенча укыту-методик комплектларны эшләү һәм гамәлгә кертү;
11) милли мәгариф буенча конкурслар һәм олимпиадалар системасын булдыру;
12) татар халкы компакт яшәгән Россия Федерациясе субъектларында татар телен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә ярдәм итү.

***«Мәгълүматлаштыру 3.0» проекты***

Проектка мәктәпләрне үстерүнең укучылар өчен дистанцион белем бирүне һәм белем бирү сервисларын куллануга юнәлдерелгән инновацияле программаларына ярдәм күрсәтү кирә.

Уку-укыту процессына заманча технологияләрне гамәлгә кертүдә ярдәм итә торган берничә чара каралды: кызыклы фәннең һәм эксплораториумнарның заманча үзәкләрен оештыру, комплекслы мәдәни, медия-социаль проектларга ярдәм, яңа технологик мохит булдыруның түбәндәге проектларына ярдәм: «цифрлы мәктәп», web 3.0, электрон гипертекстлы дәреслекләр, челтәрдәге ачык белем бирү сервислары, роботлар техникасы класслары.

Моннан тыш, проект белем бирү сыйфатын бәяләүнең республика системасы кысаларында Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә математика, рус, татар һәм инглиз телләре, табигый-фәнни цикл предметлары, мәгълүмати грамоталылык буенча уку нәтиҗәләрен мониторинглауны кертү ярдәмендә мәктәп балаларының белем алу нәтиҗәләрен бәяләвен камилләштерүгә ярдәм итәчәк.

***«Белем алудагы казанышлар траекториясе» проекты***

Гомуми һәм мәктәпкәчә белем бирү системасы өчен «Белем алудагы казанышлар траекториясе» проекты (укучыларның белем алуда казанышлары нәтиҗәләрен исәпкә алуның бердәй электрон персонификацияләнгән системасы) белем алудагы индивидуаль казанышларны мониторинглауның бердәй системасын булдыруны (электрон портфолио нигезендә) күздә тота. Бу белем бирү траекторияләрен тикшерергә, исәпкә алу кыен булган казанышларны (социаль әһәмияте булган эшчәнлектә катнашуны кертеп) исәпкә алырга, белем алучыларга һәм аларның гаиләләренә белем бирү хезмәт күрсәтүләрен сайлау өчен мәгълүмати база булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Индивидуаль дәрәҗәдә җыелган һәм регион дәрәҗәсендә тупланган казанышлар турындагы мәгълүмат укучыларның төрле яшьтәге, гендер, социаль төркемнәренә карата белем бирү сыйфатын анализлау мөмкинлеген бирәчәк, бу белем бирү сыйфатына идарә итү мөмкинлекләрен шактый киңәйтә.

Укучыларның индивидуаль белем алу траекторияләрен мониторинглау мөмкинлеге барлыкка килә, бу иң сәләтле һәм мотивацияләнгән мәктәп балаларын барларга һәм аларга укуның төрле этапларында белем алу потенциалын гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә мөмкинлек бирәчәк. Мондый система укучыларның укудагы казанышлары турындагы мәгълүматны, мәсәлән, төрле



диагностик чараларның белешмәләрен, дәүләт имтиханнары нәтиҗәләрен, шулай ук укучыларның өстәмә белем бирү системасындагы казанышлары хакындагы мәгълүматларны, олимпиадаларда һәм конкурсларда катнашу, спорттагы казанышлары турындагы белешмәләрне тупларга мөмкин.

***«Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» программасы***

«2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланды.

Программаның максаты – балаларның, яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерүнең күчә килгән системасын җәелдерүне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасының инновацияле үсеше мәнфәгатьләрендә талантлар белән стратегик идарә итү.

Программаның бурычлары түбәндәгеләр:

1) Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади үсеше мөмкинлекләрен популярлаштыру, яшьләр һәм ата-аналар аудиторияләре белән нәтиҗәле элемтәләр төзү;

2) берләшкән ресурс мәйданчыкларын булдыру һәм талантлар белән идарә итүдә ведомствоара хезмәттәшлекне үстерү;

13) конкурентлыкка сәләтле фәнни-тикшеренү юнәлешендә яшьләр бергәлекләре һәм проектлау-тикшеренү мәйданчыклары челтәрләрен үстерү;

4) балалар һәм яшьләр өчен алга китү компетенцияләренең иң яхшы үсеш модельләрен кертү, кыйммәтләргә мөнәсәбәт формалаштыру (формаль булмаган дуаль/проект/тренер өйрәтүе, остазлык һ.б.);

5) кадрлар менеджментының инновацион механизмнарын кертү, Программаны тәмамалаучыларга продюссер булу.

«Талантларның Казан ачык университеты 2.0» белем бирү платформасы, бу программаның төп элементы буларак, Татарстан Республикасында талантлы яшьләрне табуга, аларны үстерүгә һәм калдыруга ярдәм итәргә тиеш.

### 3.1.2.3. Урта һөнәри белем бирү

***Хәзерге торыш:***

Татарстан Республикасында 103 һөнәри белем бирү оешмасы эшли – бу Россиядә иң эре мәгариф челтәрләренең

берсе. 2014 – 2016 елларда республика икътисадына 440 төрле һөнәр һәм белгечлек буенча 98,2 мең яңа белгеч таләп ителәчәк. Бу ихтыяҗның 35 процентын – эшче һөнәрләре; 32,2 процентын 149 белгечлек буенча урта һөнәри белем алган белгечләр тәшкил итәчәк. Бу таләпнең арта баручы өлеше югары үсештәге компетенцияләргә бәйле булачак.

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү һәм югары уку йортыннан соң белем бирү системасы – Россиядә иң алга киткәннәрнең берсе. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән «2014 – 2020 елларга һөнәри белем бирүне үстерү һәм бу өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасы расланды. Анда билгеләнгәнчә, 2020 елга республика икътисадының әйдәп баручы тармаклары өчен эшче кадрлар әзерләү буенча яхшы җиһазландырылган заманча 25 кә якын ресурс үзәге оештырылачак. 2014 елның ахырына шундый 5 үзәк эшли башлады инде.

***Төп мәсьәләләр:***

• урта һөнәри белемнең дәрәҗәсе түбән булган шартларда югары дәрәҗәдәге һөнәри техник компетенцияләргә ихтыяҗ арту;

• урта һөнәри белем бирү системасын модернизацияләү өчен инвестиция ресурслары булмау;

• урта һөнәри белемне нигездә традицион «озын» программалар буенча укыту шартларында өзлексез һөнәри үсешкә ихтыяҗ булу.

*Максатчан күзаллау һәм бурычлар*

**Ц-1.2.3** **Һөнәри белем масштаблары һәм сыйфаты инновацион икътисад таләпләренә һәм халыкның социаль ихтыяҗларына туры килә, һөнәри белем бирү оешмалары белән эффектив системалы идарә итү җайга салынган.**

*З-1.2.3.1* Белем бирү программаларының яраклашучанлыгын арттырырга, халыкның төрле категорияләренә гомер буена һөнәри белем алу мөмкинлеген тудырырга.

*З-1.2.3.2* Һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимизацияләргә.

*З-1.2.3.3* Эш бирүчеләр белән, шул исәптән инновацион предприятиеләр белән нәтиҗәле партнерлык булдырырга.

*З-1.2.3.4* Һөнәри өйрәтү программаларын иҗтимагый-һөнәри аккредитацияләү системасын һәм һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның сертификация алу системасын оештырырга.



*З-1.2.3.5* Урта һөнәри белем бирү системасына ребрендинг үткәрергә.

*З-1.2.3.6* Урта һөнәри белем бирү системасы өчен кадрлар әзерләргә.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

Урта һөнәри белем бирү системасын үстерү гамәлләре икътисадый яктан актив халыкны яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү программаларына максималь җәлеп итүгә, шулай ук мәгариф инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән:

1) үзгәртеп корылган һөнәри белем бирү оешмалары базасында әзерлек юнәлешләре буенча ресурс үзәкләре оештыру;

2) икътисадның югары технологияле секторлары предприятиеләре өчен дуаль укыту системасын гамәлгә ашыру;

3) һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимизацияләү/кыскарту;

4) WorldSkills Russia региональ конкурслары системасын оештыру;

5) Татарстан Республикасы урта һөнәри белемнең яңа имиджын булдыру;

6) сыйфатны (мәгарифнең һәм компетенцияләрнең) бәяләү механизмнарын булдыру;

7) карьера үсеше системасын камилләштерү, урта һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның индивидуаль белем траекторияләре базасын оештыру;

8) урта һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләре өчен конкурентлылыкка сәләтле социаль пакет булдыру;

9) «Татарстан Республикасы Санлы көллияте» концепциясен гамәлгә ашыру;

10) Татарстан Республикасында өзлексез белем системасын булдыру;

11) урта һөнәри белем бирү системасы өчен кадрлар әзерләү (яңадан әзерләү) программасын гамәлгә ашыру.

***«Белем алучы регион: яңа икътисадка – яңа һөнәрләр һәм күнекмәләр» флагман проекты*** (к. 3.1.6.2).

### 3.1.2.4. Югары белем бирү

***Хәзерге торыш:***

Татарстан Республикасы югары белем бирү системасын үстерү һәм халыкны югары белемгә тарту дәрәҗәсе буенча Россия Федерациясе регионнары арасында алдынгы урыннарның берсендә тора. Республикада 71 югары уку йорты, шул исәптән югары белем бирүче 26 мөстәкыйль белем бирү оешмасы һәм югары уку йортларының 45 филиалы эшли. Гомумән, югары

белем бирүче мәгариф оешмлары саны буенча Татарстан Республикасы Россия субъектлары арасында 7 нче урында тора. Моннан тыш, югары уку йортлары карамагындагы акча күләме (2013 елда 22 млрд.сум) буенча Татарстан Республикасы беренче өчлеккә керә.

2014 елда студентларның гомуми саны 169 548 кешене тәшкил итте, шуның белән бергә аларның саны кимү тенденциясе дә күзәтелә: 2008 елда республиканың 10 000 кешесенә 594 студент туры килсә, 2014 ел ахырына аларның саны 441 гә кадәр кимеде. Бу гомумроссия трендына туры килә һәм 1990 нчы елларда туучылар санының түбән булуына бәйле. Югары белем бирү үзәге буларак лидерлыкны саклап калу өчен Татарстанга актив сәясәт үткәрергә һәм югары уку йортларына башка регионнардан һәм чит илләрдән яшьләрне җәлеп итү чаралары күрергә кирәк.

2014 елда мәгариф оешмалары эшчәнлеген мониторинглау күрсәткәнчә, элек (2013 елда) үткәрелгән мониторинг нәтиҗәләре буенча үзгәртеп кору стадиясендә булган ике дәүләт югары уку йортыннан, дәүләт югары уку йортларының өч филиалыннан һәм дәүләтнеке булмаган югары уку йортларының тугыз филиалыннан тыш, өстәмә рәвештә ике дәүләт югары уку йорты, дәүләтнеке булмаган өч югары уку йорты, дәүләт югары уку йортларының 20 филиалы, дәүләтнеке булмаган югары уку йортларының 5 филиалы Татарстанда эшчәнлекләре канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмаган югары уку оешмалары исемлегенә керә. Югары уку йортларының 40 процентында уртача эш хакы регион икътисады буенча уртача эш хакыннан кимрәк.

Татарстан Республикасында югары белем бирү системасының әзерлек структурасы белән регионның икътисадый ихтыяҗлары арасында дисбаланс күзәтелә. Күбесенчә социаль-икътисадый юнәлеш буенча белгечләр әзерләнә, гомуминженерлык әзерлеге булган кадрларга кытлык кимеми.

Базарның үзгәреп торучы конъюнктурасына җайлашырга сәләтле хезмәткәрләр әзерләүгә дәүләт югары уку йортларының кырыс структурасы һәм вакланган, тар белгечлек әзерләүгә нигезләнгән белем бирү программалары комачаулый. Кайбер белгечләр хезмәт базарында гомумән юк. Шулай ук бәя демпингына бәйле һәм дәүләт тарафыннан тикшерелми торган түләүле белем бирү (аеруча читтән торып уку) программаларының күбесе сыйфат ягыннан бик түбән дәрәҗәдә.

Мәгарифтәге проблемалар тәкъдим ителә торган белгечләрнең түбән сыйфатлы булуына гына түгел, мәгарифне үзенчәлекле кабул итүгә дә бәйле. Бер яктан, югары белемгә халык тарафыннан ихтыяҗ зур һәм ул шәхеснең үз урынын табуы, үсеше өчен мөһим таләп буларак субъектив кабул ителә. Икенче яктан, югары белем хезмәт базарында тулы күләмдә таләп ителә дип раслап булмый, бизнес әлегә мәгарифкә һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләүгә инвестиция салуның әһәмиятен тулысынча аңлап бетерми.

***Төп мәсьәләләр:***

• кеше капиталының югары дәрәҗәсен хуплау зарурлыгына карамастан, халыкның югары белем алу дәрәҗәсе кимү;

• түбән сыйфатлы югары белем бирү сегменты булу;

• әзерлек юнәлешләрендәге дисбаланс;

• яхшы студентлар һәм укытучылар өчен, тикшеренүләргә һәм эшләнмәләргә грантлар һәм килешүләр өчен регионнар һәм илләр арасында конкуренция арту;

• югары уку йортлары һәм регион үсеше стратегияләре арасында бәйләнешнең начар булуы;

• югары белем бирү системасының инновацион икътисад төзү максатларына туры килмәве: инновация компанияләренең яңа өлкәләрдә нетривиаль бурычларны хәл итәргә сәләтле яшь белгечләр җәлеп итүгә бәйле проблемалары булу.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

**Ц-1.2.4 Татарстан – югары белемнең конкурентлыкка сәләтле үзәге, талантлар җәлеп итүче лидер регион.**

*З-1.2.4.1* Әйдәп баручы тикшеренү һәм инновация университетларында җитди конкурентлыкка сәләтле булган белем бирүгә ирешергә.

*З-1.2.4.2* Массакүләм югары белемнең канәгатьләнерлек сыйфатын тәэмин итәргә.

*З-1.2.4.3* Россия Федерациясенең әйдәп баручы югары уку йортлары һәм чит ил университетлары белән партнерлыкны үстерергә.

*З-1.2.4.4* Татарстан икътисадының инновацион секторы белән партнерлыкны үстерергә.

*З-1.2.4.5* Юнәлешләр буенча югары уку йортлары төркемнәрен формалаштырырга: югары белем бирүнең федераль һәм халыкара базарларында конкурентлыкка сәләтле җитди федераль югары уку йортлары; регионның һәм макрорегионның икътисадый ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшли торган көчле бакалавриаты булган (шул исәптән урта һөнәри белем бирү белән берлектә) югары уку йортлары; халыкның сыйфатлы социаль-икътисадый һәм гуманитар белгечлекләргә ихтыяҗын тәэмин итә торган киң юнәлештәге югары уку йортлары (шул исәптән «аерымланган» территорияләрдә).

*З-1.2.4.6* Югары уку йортлары базасында өзлексез белем бирү системасын оештыру аркылы филиаллар челтәре сыйфатын яхшыртырга (шул исәптән хезмәт эшчәнлегенә актив кушылган халык өчен).

*З-1.2.4.7* Регионның һәм макрорегионның эш бирүчеләре, аеруча инновация компанияләре белән югары белем бирү системасын координацияләү һәм аның белән үзара хезмәттәшлек итү механизмнарын үстерергә.

*З-1.2.4.8* Югары уку йортларында идеяләрне һәм эшләнмәләрне коммерцияләштерү системасын җайга салырга.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

• югары уку йортлары инновацияләре өчен грант программалары;

• инновация компанияләрен уку-укыту планнарын һәм программаларын тикшерүгә һәм камилләштерүгә җәлеп итү; инновацион тармак компанияләрендә студентларның һәм уку йортын тәмамлаучыларның стажировка узу тәҗрибәсен арттыру;

• югары белем бирү оешмалары һәм инновация компанияләре тарафыннан фәнни-тикшеренү эшләренең/фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренең уртак проектларын гамәлгә ашыру;

• халыкара мәгариф һәм тикшеренү кооперациясен активлаштыру;

• республиканың һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының Татарстан Республикасында югары белем бирү системасын үстерүне координацияләү буенча килешүе;

• югары уку йортлары үзәге буларак Казан имиджын тарату буенча республика программасы;

• федераль структуралар, шул исәптән Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы белән югары уку йортлары инфраструктурасын үстерү буенча уртак чаралар.

***«Югары мәктәпнең конкурентлыкка сәләтен арттыру өчен партнерлык» флагман проекты (к. 3.1.6.3).***

### 3.1.3. Сәламәтлекне саклау һәм гомер озынлыгын арттыру

***Хәзерге торыш:***

Татарстан Республикасында югары үсеш алган медицина ярдәме күрсәтү челтәре һәм сәламәтлек саклауның югары фәнни-белем бирү потенциалы бар. Республика халкына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантиясе программасын ресурслар белән тәэмин итү уртача Россия нормативларыннан берничә тапкырга югары. 2014 елда халыкның табигый арту күрсәткечләре буенча регион лидерлар арасына керә (Россия



Федерациясендәге 0,2 процентка карата 2,6 процент) һәм фаразлана торган гомер озынлыгы күрсәткече буенча 13 нче урынны алып тора, бу күрсәткеч соңгы елларда туктаусыз үсә һәм 2013 елда ул 72,12 яшькә (Россиядә – 70,77 яшь, Идел буе федераль округында – 70,06 яшь) җитте. Шул ук вакытта Россия буенча уртача алганда Татарстанда табиб персоналы һәм койка фонды кимрәк: табиблар белән тәэмин ителеш – Татарстан Республикасында 10 000 халыкка 30,9 һәм Россия Федерациясендә – 44,7, койкалар саны – Татарстан Республикасында 10 000 халыкка 61,2 һәм Россия Федерациясендә – 81,5 (белешмәләр Татарстан Республикасы буенча 2014 ел өчен, Россия Федерациясе буенча 2013 ел өчен). 2011 – 2012 елларда республиканың сәламәтлек саклау өлкәсе халык үлеменең төп сәбәпләре булып торучы йөрәк-кан тамырлары авырулары, шешләр һәм тышкы сәбәпләр белән көрәшкә юнәлдерелгән «Сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү» программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә шактый нығыды. Татарстанстатның 2014 ел йомгаклары турында оператив мәгълүматлары буенча, сабыйлар үлеме дәрәҗәсе, Россия Федерациясе (7,6 процент) һәм Идел буе федераль округы (7,5 процент) буенча уртача күрсәткечләргә караганда түбәнрәк (6,5 процент). Күпьеллык максатчан эшчәнлек нәтиҗәсендә Татарстан педиатриянең һәм югары технологияле медицина ярдәменең кайбер юнәлешләрендә алдынгы урыннарны били. Республика субъект карамагындагы учреждениеләрдә югары технологияле дәвалау ысулларын куллану буенча лидер булып тора. Халыкара дәрәҗәдәге массакүләм спорт чаралары вакытында медицина ярдәме күрсәтүне оештыру буенча республикада уникаль тәҗрибә туплады.

Россия сәламәтлек саклау системасында күп очракта лидерлыкка ирешүгә карамастан, Татарстанда сәламәтлек саклау өлкәсенең интеграль күрсәткечләре – фаразлана торган гомер озынлыгы, дәвалап була торган сәбәпләрдән авыручылар һәм үлүчеләр саны икътисадый потенциалы алга киткән илләргә караганда бик түбән булып кала.

***Төп мәсьәләләр:***

• халыкның гомер озынлыгын арттыру һәм популяциянең олыгаюы, бу сәламәтлек саклау оешмасына куелган таләпләрне үзгәртергә һәм социаль системаларны ресурслар белән тәэмин итүне арттырырга мәҗбүр итә.

• дөньядагы технологик үзгәрешләрнең тизләнеше һәм медицина белән тәэмин итү системасын нанотехнологияләр, биотехнологияләр, мәгълүмат һәм коммуникация технологияләре нигезендә сыйфатлы яңартуга күчү. Конкурентлык өстенлеген

саклап калу өчен, Татарстан бу үзгәрешләрнең алга сафларында булырга һәм сәламәтлек саклау өлкәсенең киләчәген билгели торган төп технологик юнәлешләрне актив үстерергә тиеш.

• сәламәтлек саклау системасына стратегик инвестицияләр җәлеп итү һәм медицина туризмын үстерү өчен җитди конкурентлык көрәше көчәю. Татарстан ил инвесторлары өчен дә, чит ил инвесторлары өчен дә, шулай ук республикадан һәм башка регионнардан, илләрдән булган пациентлар өчен дә тармакның җәлеп итә торган булуына шартлар тудырырга тиеш.

• дөньяның барлык илләрендә диярлек сәламәтлек саклау системасында хезмәт ресурслары кимү һәм квалификацияле кадрларга кытлык булу. Бу хәл, бер үк вакытта персоналның регионда эшләү мотивациясен арттырып, медицина белеме бирүнең нәтиҗәле системасын оештыру кирәклеген таләп итә.

Республика алдында торучы бурычларны хәл итү өчен «2020 елга кадәр Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү буенча дәүләт программасы» эшләнде, ул региональ сәламәтлек саклау системасының нәтиҗәсез зоналарына җитди анализ ясау һәм максатчан бурычларны һәм чараларны билгеләү буенча җентекләп эшләнгән булуы белән аерылып тора. Әмма ресурсларга кытлык шактый зур булганга күрә, экстенсив үсеш сакланган очракта, билгеләнгән күрсәткечләргә ирешү авырлаша. Төп тотып торучы фактор федераль һәм регион стратегияләренең инфраструктураны һәм персоналны дәүләт балансында саклаган килеш, төп чаралар күләмен арттыруга юнәлдерелгән булуыннан гыйбарәт. Бу сәламәтлек саклау системасында конъюнктураның үзгәрүчәнлегенә җайлашу һәм инновацион технологияләрне тиз кертеп җибәрү мөмкинлеген киметә. Соңгысы, үз чиратында, медицина ярдәме күрсәтүнең дөньякүләм системасында республиканың конкурентлык сәләтен киметә һәм кешелек капиталының сыйфатын арттыру бурычын тулы күләмдә хәл итәргә мөмкинлек бирми.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

**Ц-1.3** **Татарстан Республикасы халкының һәм сәламәтлек саклау системасының мөһим бурычлары – сәламәтлекне саклау һәм озак яшәү.**

*З-1.3.0.1* Персоналның мотивациясен арттырырга һәм тармакның кадрлар потенциалын ныгытырга.

*З-1.3.0.2* Аерым авырулардан үлүчеләр санын киметергә (кан әйләнеше системасы авыруларыннан, юл-транспорт һәлакәтләре җәрәхәтләреннән, шеш авыруларыннан, туберкулездан һ.б.).



*З-1.3.0.3* Халыкта авыруларның көчәюен киметүгә һәм сәламәтлекне саклап калуга юнәлдерелгән тәртип модельләрен формалаштырырга.

*З-1.3.0.4* Сәламәтлек саклау системасын модернизацияләргә, бу аның нәтиҗәлелеген арттырачак.

*З-1.3.0.5* Эш бирүчеләрнең үз хезмәткәрләренең сәламәтлеген саклауга, һөнәри һәм һөнәргә бәйле авыруларның барлыкка килүен кисәтүгә юнәлдерелгән хезмәт шартларын тудыруга мотивациясен арттырырга.

*З-1.3.0.6* Сәламәтлек саклау өлкәсенең ресурс базасын киңәйтергә, медицинада икътисадның үсеш нокталарын булдырырга.

*З-1.3.0.7* Татарстан сәламәтлек саклау системасының җитди конкурентлык сәләтен арттырырга, республика халкының һәм башка регионнарда яшәүчеләрнең инновацион технологияләрдән файдалана алуын тәэмин итәргә, тармакның кадрлар потенциалын саклап калырга һәм арттырырга, Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итәргә.

*З-1.3.0.8* Ярдәм күрсәтүнең перспектив һәм заманча модельләрен кертү һәм, дәүләт заказын саклап калган килеш, медицина персоналын эзлекле рәвештә хосусый практикага күчерү исәбенә гамәлдәге сәламәтлек саклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрергә.

*З-1.3.0.9* Медицина иминияте һәм социаль иминият системаларын бүлү, иминләштерелгән затларның үз сәламәтлекләрен саклау буенча шәхси җаваплылыгын арттыру шартларында бәла-каза хәвефләреннән озак сроклы тупланма иминиятне кертү исәбенә халыкның медицина ярдәменә дифференциацияләнгән ихтыяҗларын канәгатьләндерергә.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

Куелган максатка ирешү медицина иминияте системасын, диагностиканы, дәвалауны, тернәкләндерүне, мониторингны һәм профилактиканы бергә туплый торган, нәтиҗәле ресурсларга ия булган, пациент теләген исәпкә алып ярдәм күрсәтүче сәламәтлек саклау системасын оештыруны күздә тота, аңа түбәндәгеләр керә:

• гражданнар сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән ресурсларның барлык чыганакларын (барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлар, предприятиеләрдә хезмәткәрләрне савыктыру чыгымнары, хәйрия, халыкның шәхси түләүләре, ведомстволар куәтләре, регионара һәм халыкара багланышларны файдалану мөмкинлеге һ.б.) инвентаризацияләү һәм файдалану;

• халыкның төрле категорияләренең дифференциацияләнгән ихтыяҗларын исәпкә алып, йөкләмәләр күләмен булган ресурсларга туры китерү;

• ведомствоара һәм территориальара хезмәттәшлек мөмкинлекләрен һәм ресурсларны файдалануның мөмкин булган альтернатив юнәлешләре нәтиҗәсен анализлау нигезендә оешмаларның һәм гражданнарның шәхси инициативаларын активлаштыруны исәпкә алып, ресурслардан файдалануны планлаштыру;

• телемедицина технологияләрен һәм заманча коммуникация чараларын үстерү исәбенә пациентның сәламәтлек саклау системасы белән үзара хезмәттәшлек итү модельләрен арттыру;

• медицина персоналы хезмәте өчен пациентларның ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән мотивацияле түләү системаларын кертү;

• сәламәтлекне иминләштерүнең төрле рәвешләрен үстерү, пациентның үз биологик потенциалын саклау өчен шәхси җаваплылык механизмын кертү.

*Әлеге юнәлешләр кысаларында түбәндәге гамәлләр планлаштырыла* :

• 2018 елга кече һәм урта медицина (фармацевтика) персоналының уртача эш хакын Татарстан Республикасындагы уртача эш хакыннан — 100 процента кадәр, медицина хезмәтләре күрсәтүче медицина оешмаларының югары медицина (фармацевтика) яки башка югары белеме хезмәткәрләренең уртача эш хакын 200 процентка кадәр арттыру;

• авыруларны киметүгә һәм халыкның сәламәтлеген саклауга китерә торган тәртип модельләрен формалаштыру максатында масштаблы мәгълүмати-агарту кампаниясен финанслау: сәламәт туклану культурасын популярлашу, спорт-савыктыру программалары, алкоголизмны һәм наркоманияне профилактикалау, тәмәке куллануга каршы көрәш.

• «нәтиҗәсез зоналар»ны эзлекле рәвештә бетерү исәбенә медицина ярдәме күрсәтүнең оештыру моделен оптимизацияләү: табиблар персоналының икътисадый мөстәкыйльлеген арттыру исәбенә мотивациясен арттыру, медицина-социаль ярдәм күрсәтү системасын үстерү, сәламәтлек саклауның социаль яклау системасы белән үзара хезмәттәшлеген координацияләү, өлкән яшьтәге затларга медицина ярдәме күрсәткәндә урта персоналның ролен күтәрү һәм функцияләрен арттыру.

• сәламәт яшәү рәвешен алып бару модельләрен формалаштыру, эш бирүченең үз хезмәткәрләренең сәламәтлеге өчен җаваплылыгын арттыру механизмнарын кертү һәм өлкән яшьтәге кешеләрнең сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыру:



диагностиканың һәм мониторингның мобиль системаларыннан файдалану практикасын арттыру; пропагандалауның нәтиҗәле формаларын үстерү; эш бирүчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең сәламәтлекне саклауда кызыксынучанлыгын арттыруның мотивация механизмнарын кертү; алкоголизмны, наркоманияне, тәмәке тартуны һәм хәвефнең башка факторларын, беренче чиратта, балалар һәм яшүсмерләр арасында профилактикалау буенча программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру; халыкның сәламәт туклану культурасын формалаштыру;

• башка регионнардан һәм илләрдән инвесторлар һәм пациентлар өчен Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының җәлеп итүчәнлеген арттыру: аерым юнәлешләр буенча югары технологияле ярдәм күрсәтү буенча дәүләти-хосусый партнерлык проектлары; эшләү; республиканың кайбер медицина оешмаларын дөньяви рейтинглар системасына кертү; регионара һәм халыкара хезмәттәшлекне арттыру; ана һәм бала сәламәтлеген саклау системасын үстерү; белем бирү учреждениеләрендә медицина ярдәме күрсәтүне камилләштерү;

• медицина ярдәме күрсәтүне оештыруның сервис моделенә күчү: диагностикалау һәм дәвалау җайланмасын эшләп чыгаручыдан сатып алуны интеграцияле хәл итүләр; төп чараларны бюджет исәбеннән карап тотудан, ремонтлаудан һәм сатып алудан аларны озак вакытлы арендага бирүгә күчү; әзер хезмәт күрсәтүләрне (сыйфатлы характеристикаларга ия билгеле бер медицина ярдәмен) теләсә кайсы провайдердан сатып алу.

• күпдәрәҗәле дифференциацияләнгән медицина иминияте моделенә күчү — медицина ярдәме күрсәтү системасын эзлекле рәвештә ике ярдәмче системага бүлү: социаль иминләштерүгә (мәҗбүри медицина иминиятенең хәвеф моделе кысаларында медицина ярдәме күрсәтүне түләүдә гражданнарның шәхси катнашуы) һәм социаль тәэмин итүгә (халыкның социаль якланмаган катламнары мәнфәгатьләрен җәмәгать чыганаклары исәбенә гамәлгә ашыру). Һәлакәт хәвефләреннән иминиятләштерүнең туплау системаларын кертү иминләштерелүченең үз сәламәтлеге өчен шәхси җаваплылыгы артуга һәм Татарстан Республикасында кеше капиталының сыйфаты яхшыруга китерәчәк.

### *«Медицина-тернәкләндерү кластеры» проекты*

Күпфункцияле территориальара интеграцияләнгән медицина-тернәкләндерү кластерын түбәндәге территорияләрдә оештыру:

1. Казан агломерациясе: югары технологияле ярдәм күрсәтү һәм дәвалауның инновацион ысуллары буенча махсуслашу;

2. Кама агломерациясе: эшкә сәләтлелекне торгызуның һәм

телемедицина ярдәме күрсәтүнең тернәкләндерү технологияләре буенча махсуслашу.

3. авыл җирлеге: геронтология һәм тернәкләндерү ярдәме мәсьәләләре буенча махсуслашу.

Кластер белән идарә итү пациент теләген исәпкә алып ярдәм күрсәтү системасының дөньякүләм алдынгы тәҗрибәсенә таяначак һәм заманча логистика һәм транспорт системалары белән тәэмин ителәчәк. Республиканың медицина оешмаларын дөньяви рейтинглар системасына кертү сәламәтлек саклауның сыйфатын арттырырга һәм башка регионнардан пациентлар җәлеп итәргә булышачак.

Диагностиканың, дәвалауның (шул исәптән югары технологияле), рекреациянең, геронтология хезмәтләре күрсәтүнең, туризмның мөмкинлекләрен берләштергән кластер Татарстанга башка регионнардан һәм илләрдән медицина ярдәменә мохтаҗ йә медицина белеме алу өчен гражданнарны җәлеп итү базасы булачак. Бу кунакханә һәм туризм хезмәтләре күрсәтү, көнкүреш хезмәтләре күрсәтү, сәламәт туклану индустриясе өлкәләрендә, агросәнәгать комплексында мультипликация эффектын барлыкка китерәчәк һәм медицина технологияләре өлкәсенә инновацияләр кертүгә этәрәчәк.

### 3.1.4. Һәркем файдалана алырлык мәдәният

***Хәзерге торыш:***

Республика территориясендә яшәүче халыкларның бай традицияләрен һәм рухи үзенчәлекләрен гәүдәләндерүче Татарстан мәдәнияте бер үк вакытта гомумкешелек кыйммәтләрен чагылдыра һәм дөньякүләм мәдәни мирасның бер өлеше булып тора.

ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирас исемлегенә Казан Кремле тарихи-мәдәни комплексын (2000 ел) һәм Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгын (2014 ел) кертү Татарстандагы мәдәни мирас объектларының уникаль булуын раслады. Мәдәни мирасның әһәмиятле объектларының тагын берсе – Свияжск тарих-архитектура һәм табигать-ландшафт комплексы, анда хәзерге вакытта федераль әһәмияттәге «Свияжск утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгын оештыру эше башкарыла. Казан дәүләт университеты (хәзерге Казан (Идел буе) федераль университеты) Россия Федерациясе халыкларының аеруча кыйммәтле мәдәни мирас объектларының дәүләт җыелмасына кертелде.

Халыкның борынгы традициясен күрсәтүче Сабантуй татар милли бәйрәме ЮНЕСКОның басма һәм матди булмаган мәдәни мирасы исемлегенә кертү өчен тәкъдим ителде. Сабантуй



мәйданы үз тирәсенә төрле милләт кешеләрен берләштереп, гомуми һәм интернациональ бәйрәмгә әйләнде. Татарстанда яшәүче халыкларның милли байлыгын һәм үзенчәлеген татарларның Сабануй бәйрәме белән беррәттән, русларның «Каравон», чувашларның «Уяв», мариларның «Семык», удмуртларның «Гырон быдтон» дәүләт гомумреспублика бәйрәмнәре ачык чагылдыра.

Җырчы Федор Шаляпин, язучылар Лев Толстой, Сергей Аксаков, Максим Горький, Василий Аксенов, шагыйрьләр Евгений Боратынский, Гавриил Державин, Марина Цветаева һәм Никита Заболоцкий, рәссамнар Иван Шишкин һәм Николай Фешин һәм башка бик күп күренекле мәдәният эшлеклеләренең язмышы Татарстан белән бәйләнгән. Татар поэзиясе классигы Габдулла Тукай, шагыйрь-герой Муса Җәлил, композиторлар Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, София Гобәйдуллина һәм башка бик күпләр татар мәдәниятен дөньяга таныттылар.

Татарстан Республикасында 7 иҗат берлеге, 14 дәүләт театры, йөзгә якын музей һәм алты музей-тыюлык, Дәүләт Эрмитажының Россиядәге бердәнбер филиалы, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе һәм С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы бар, алар базасында югары һөнәри дәрәҗәгә ирешкән иҗат коллективлары – Татарстан Республикасы Дәүләт симфония оркестры, Татарстан Республикасы Дәүләт халык уен кораллары оркестры, Татарстан Республикасы Дәүләт кыллы квартеты эшли.

Татарстанда үткәрелә торган Ф. Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале, Р. Нуриев исемендәге Халыкара классик балет фестивале, Казан халыкара мөселман киносы фестивале, төрки халыкларның «Нәүрүз» халыкара театр фестивале, «Европа – Азия» халыкара заманча музыка фестивале һ.б. мәдәният брендлары киң танылды.

Татарстанда мәдәният һәм сәнгать өлкәсенең булачак белгечләренә өзлексез һөнәри белем бирүче уку йортлары челтәре барлыкка килде. Алар арасында 104 балалар сәнгать мәктәбе, 8 урта махсус уку йорты, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты һәм В. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академик сәнгать институты филиалы бар.

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының мәдәниятка чыгымнар күләмен Россия Федерациясенең өч субъекты – Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Мәскәү өлкәсе бюджетлары белән генә чагыштырырга мөмкин. 2012 елдан башлап бу

өлкәдә чыгымнарның шактый артуы күзәтелә. Мәсәлән, 2014 елда мәдәниятккә тотылган чыгымнар өлеше 4,2 процентны тәшкил итте, шул вакытта 2012 елда ул Татарстанның берләштерелгән бюджетының — 3,3 проценты, ә 2013 елда 3,2 проценты иде.

Берләштерелгән бюджетның мәдәниятккә чыгымнары буенча Татарстан Республикасы, бер кешегә исәпләгәндә, Санкт-Петербург шәһәре белән тигезләште, ә 2013 елда уртача Россия дәрәҗәсен һәм Мәскәү өлкәсе күрсәткечләрен узып китте.

Шул ук вакытта мәдәният хезмәткәрләренең эш хакы дәрәҗәсе, уңай динамика булуга карамастан, регион икътисады буенча уртачадан түбәнрәк булуын дәвам итә һәм 2014 елда ул Татарстандагы уртача эш хакының 65,6 процентын тәшкил итте. Бу күрсәткеч Россия буенча уртача дәрәҗәдән түбән (2014 елда 73,2 процент) һәм берләштерелгән бюджетның мәдәниятккә чыгымнары Татарстан Республикасы белән бертөрле булган Россия Федерациясе субъектларының бу өлкәдәге күрсәткечләреннән арта кала. Эш хакының мондый дәрәҗәсе хезмәт базарында мәдәният өлкәсенең конкурентлылыгын тәэмин итә алмый, ул тармакка квалификацияле яшь белгечләрне җәлеп итәрлек түгел.

Әлеге мәсьәләләр мәдәният учреждениеләре челтәре торышына, тәэмин ителеш дәрәҗәсенә һәм халыкны мәдәният учреждениеләренә тартуга, аларны финанс белән тәэмин итүгә бәйле. Татарстанның мәдәният өлкәсендәге вәзгыятькә тигезсезлек хас. Мәдәният-ял итү учреждениеләре һәм китапханәләр саны, шулай ук алар белән халыкның тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча Татарстан Республикасы гомумроссия дәрәҗәсен һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәрәҗәсен узып китә. Шул ук вакытта концерт оешмалары һәм филармония коллективлары, театрлар, музейлар, парклар белән тәэмин ителеш буенча берләштерелгән бюджетларының мәдәниятккә чыгымнары шундый ук булган Россия Федерациясе субъектлары белән чагыштырганда, шулай ук гомумроссия дәрәҗәсеннән шактый артта кала.

Үсешнең гамәлдәге ысуллары саклангaнда мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм китапханәләрне финанс белән тәэмин итү мәсьәләләре шулай ук калачак, аларны заман таләпләренә туры китерү мөмкинлеге булмаячак. Мәсәлән, берләштерелгән бюджетларының мәдәниятккә чыгымнары шундый ук булган Россия Федерациясе субъектлары белән чагыштырганда, үсеш өчен бирелә торган бюджет акчалары өлеше, канәгатьләнерлек хәлдәге учреждениеләр, клублар һәм китапханәләр өлеше буенча, финанс тәэминатын бер учреждениегә исәпләгәндә, Татарстан Республикасы шактый калыша. Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм китапханәләрне бюджет белән җитәрлек тәэмин итмәү фонында бюджеттан тыш кертемнәр өлешенең дә шактый түбән булу күзәтелә.



***Төп мәсьәләләр:***

• югары белемле, мәдәни таләпләре һәм мәнфәгатьләре югары булган кешеләр өлеше арту;
• балаларының иҗади сәләтләрен үстерүгә омтылучы гаиләләр өлеше арту;
• мәгълүмати җәмгыятькә күчү;
• белемнәргә нигезләнгән инновацион икътисадка күчү;
• кеше капиталының үсешнең төп факторына әверелүе;
• хезмәткәрләрнең иҗади потенциалына таләпләр арту;
• креатив индустрияләрне һәм кластерларны алдан үстерү.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

| | |
|---|---|
| **Ц-1.4** | **Мәдәни тормышның сыйфаты һәм төрлелеге кеше капиталын җәлеп итүнең һәм туплауның реаль факторларына әйләнде.** |
| *З-1.4.0.1* | Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә Татарстан Республикасының югары казанышларына булышырга. |
| *З-1.4.0.2* | Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү системасын яхшырту, гомуми һәм өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары һәм мәдәният учреждениеләре кооперациясе һәм интеграциясе исәбенә иҗади кадрларны арттырып әзерләүне тәэмин итәргә. |
| *З-1.4.0.3* | Мәдәни туризм факторы буларак мәдәни мирасны сакларга һәм актуальләштерегә. |
| *З-1.4.0.4* | Иҗади индустрияләрнең интенсив үсеше һәм экспорт өчен эчке базарны һәм мөмкинлекләрне арттыру исәбенә аларның конкурентлык сәләтен арттыру өчен шартлар тудырырга. |
| *З-1.4.0.5* | Шәһәр агломерацияләрендә мәдәният инфраструктурасын алдан үстерүне тәэмин итәргә. |
| *З-1.4.0.6* | Күчмә мәдәният-мәгълүмат комплексларын һәм гастроль эшчәнлеген тарату аша авылда һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләрнең мәдәниятнең югары казанышларыннан файдалана алуын һәм мәдәният тормышында катнашуын тәэмин итәргә. |
| *З-1.4.0.7* | Аралашуның һәм үз-үзеңне тотуның гомуми культурасын арттырырга. |

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) Мәдәниятнең һәм сәнгатьнең дәүләт секторын ныгыту;
• дөньякүләм дәрәҗәдәге мәдәният эшлекләре һәм иҗат

коллективлары өчен грантлар системасын үстерү: Татарстан арт-брендлары;

• һөнәр алу алдыннан һәм һөнәри белем бирү системасын үстерү;

• торышы канәгатьләнерлек булмаган һәм заман таләпләренә җавап бирми торган мәдәният учреждениеләрен мәдәният эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларына туры килерлек итеп реконструкцияләү;

• заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, мәдәният өлкәсендә яңа төр хезмәтләр күрсәтүне популярлаштыру һәм тәкъдим итү;

• мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аларны төрлеләндерү өчен хокукый һәм икътисадый шартлар тәэмин итү;

2) мәдәният һәм туризм өлкәсе кооперациясен үстерү:

• гомуми һәм өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары, мәдәният һәм туризм учреждениеләре кооперациясе һәм интеграциясе өчен хокукый һәм икътисадый шартлар тәэмин итү;

• мәдәни туризм маршрутларының киң спектрын булдыру һәм тарату, мәгълүмат-туризм үзәкләре челтәрен, Татарстанның мәдәни мирасын һәм арт-брендларын капитализацияләү өчен нәтиҗәле маркетинг һәм логистика оештыру;

• визит-үзәкләр челтәрен арттыру;

• Татарстанның мәдәният урчреждениеләре буенча виртуаль турлар оештыру өчен мәгълүмат технологияләреннән файдалану;

• күчмә мәдәният-мәгълүмат комплекслары эшчәнлеген тәэмин итү, гастроль эшчәнлегенә финанс ярдәме күрсәтүне арттыру.

3) креатив кластер оештыру.

***«Татарстанның креатив индустирияләре» флагман проекты ( 3.1.6.5).***

Тәкъдим ителә торган гамәлләр мәдәниятне конкурентлыкка сәләтле иҗади кластер формалаштыруга, мирасны һәм традицияләрне саклау, яшәү урынына һәм керем дәрәҗәсенә карамастан, һәр кеше өчен мәдәни тормышта катнашу һәм иҗади яктан ачылу мөмкинлеген тәэмин итә торган кызыксындыручы мәдәни мохит булдыруга булышлык итә торган нисбәтле экосистемага әйләндерүне күздә тота. Тәкъдим ителә торган чаралар мәдәният, мәгариф һәм туризм партнерлыгын тәэмин итәчәк һәм социаль-мәдәни өлкә оешмаларының һәм учреждениеләренең үзара хезмәттәшлеге нигезендә гамәлгә ашырылачак, үзеннән-үзе арта торган иҗади ресурсларга һәм мәдәни инициативаларга таяначак. Финанс нигезе, бер яктан, мәдәният өчен Татарстан



Республикасының берләштерелгән бюджеты чыгымнарын арттыруны, икенче яктан, дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүне һәм меценатлыкны стимуллаштыруны тәэмин итә алачак.

### 3.1.5. Халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау

***Хәзерге торыш:***

Кеше капиталы республикада үзенә, иң беренче чиратта инновация өлкәсендә, нәтиҗәле кулланыш тапканда гына тупланачак. Бу хезмәт базарын җайга салуда, халыкны эш белән тәэмин итүдә һәм социаль яклауда җитди үзгәрешләр ясауны таләп итә.

Инновация продукциясен җитештерүнең глобаль характеры продукция сату базарының, җитештерү факторлары базарларының (шул исәптән кеше капиталының да) глобаль характеры белән тыгыз бәйләнгән. Квалификацияле белгечләрнең югары мобильлеге һәм компанияләрдән һәм илләрдән (регионнардан) аларга югары конкуренция булу моның нәтиҗәсе. Татарстан Республикасы алдында җитди мәсьәлә тора — инновациягә һәм, шул нисбәттән, кеше капиталына сорауны стимуллаштырырга, һәм бер үк вакытта, инновацион компанияләр эшчәнлеге, республика территориясендә кадрлар әзерләү һәм кеше потенциалы, кеше капиталы югары дәрәҗәдә булган затларның регионара һәм халыкара мобильлеге арасында үзара бәйләнешне исәпкә алып, кирәкле кеше капиталын җитәрлек күләмдә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасында хезмәт базарына турыдан-туры һәм читләтеп йогынты ясаучы берничә программ документ кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан эш бирүчеләрнең һәм гражданнарның гамәлдәге кадрлар агентлыгы турында мәгълүматларын арттыруга, халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар кабул ителә. Халыкны эш белән тәэмин итү буенча 15 шәһәр һәм 30 район үзәкләре эшли. Хезмәт базарындагы киеренкелек үсү фонында эш эзләү вакытының артуы регион дәрәҗәсендә хезмәт ресурсларын бүлү белән идарә итүнең сыйфатын яхшырту кирәклеген күрсәтә.

Татарстан Республикасы хезмәт базары күләмнәрен икътисадый эшчәнлек төрләре буенча озак вакытка планлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын әзерләү турында» карары кабул ителде.

Шулай итеп, Татарстанда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә шактый актив сәясәт алып барыла, әмма бу республи-

каны үстерү буенча куелган амбициоз максатлар өчен җитәрлек дәрәҗәдә түгел, аларга ирешү хезмәт базарындагы сорау һәм тәкъдим арасында барлыкка килгән аерманы тагын да арттырачак. Киләчәктәге 10 — 15 елда Татарстанда, илдәге кебек үк, демографик хәлнең начараюы һәм хезмәткә сәләтле яшьтәге халык санының кимүе көтелә.

Киләчәктә Татарстан Республикасына эш белән тәэмин итүне модернизацияләү буенча катлаулы мәсьәләләрне халыкның конкурентлыкка сәләтен арттыру, икътисадның инновацион секторына югары квалификацияле мигрантлар җәлеп итү, республика халкының мобильлеген арттыру һәм җирлекләрнең төрле типларында эре шәһәрләрне инновацион үстерү максаты белән эш белән тәэмин итүнең территориаль пропорцияләрен оптимизацияләү, сәнәгатьне үстерү өчен кадрлар белән тәэмин итү һәм авылның икътисадый яшәүгә сәләтен саклау юлы белән хәл итәргә туры киләчәк.

***Төп мәсьәләләр***

• Россия регионнарында кеше ресурсларына конкуренция үсү, бу Татарстан Республикасы хезмәт базарының җәлеп итүчәнлеген һәм аның конкурентлык сәләтен арттыруны таләп итә;

• яшәү дәверендә берничә һөнәр алмаштыру тенденциясе;

• республикада кеше капиталы сыйфатының түбән дәрәҗәдә булуы: белем бирү сыйфаты түбән булганда формаль «яңадан белем алу»;

• югары белем һәм тормыш шартлары өчен институциональ «тозак». Татарстан Республикасы, бер яктан, югары белемле белгечләр зур керемнәр алырга мөмкин булган регионнардан, икенче яктан, югары белемнән керем аз булганда да яхшы яшәү шартлары бирә торган регионнардан арта кала. Шуңа күрә югары эш хакы һәм хезмәт, яшәү шартлары яхшы булган башка регионнарга миграция барлыкка килә;

• хезмәт базарында структура дисбаланслары: квалификацияле сәнәгать эшчеләренә һәм техник белгечләргә, шулай ук Татарстан Республикасын үстерү буенча өстенлекле инновацион юнәлешләр өчен югары технологияләр өлкәсендәге белгечләргә кытлык;

• җирле хезмәт базарларында сорау һәм тәкъдим дисбалансларын кыскарту һәм эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен халыкның территориаль мобильлеге җитәрлек дәрәҗәдә булмау;

• «соры» хезмәт базарының шактый масштаблы, формаль булмаган керемнәрнең югары булуы;

• хезмәткә сәләтле халык өлеше кыскару;



• легаль булмаган хезмәт мигрантлары күп килү;

• эшсезлек дәрәҗәсе түбән, әмма аны бетерү өчен икътисадый активлыкның, аеруча хатын-кызлар арасында булмавы;

• инвестицияләргә һәм яңа эш урыннарына кертелми торган керемнәрне бүлүдә тигезсезлек (стагнация шартларында бу проблема кискенләшә);

• эш бирүчеләрнең үз предприятиеләре өчен хезмәткәрләр әзерләүгә һәм аларның квалификациясен күтәрүне инвестицияләүгә кызыксынучанлыгы җитәрлек дәрәҗәдә булмау;

• керемнәр структурасында социаль түләүләр өлеше арту;

• вакантлы эш урыннарына эшкә урнашуга теләми торган һәм эшләмәү өчен сәбәпләре булмаган гражданнарның керемнәрен исәпкә алу механизмы булмау;

• ярлылыкка нигездә балалар дучар ителгән булуга карамастан, социаль түләүләр системасының нигездә өлкәннәр өчен булуы.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

**Ц-1.5** **Үзгәрүчән хезмәт базары, халыкны эш белән тәэмин итүгә булышу һәм социаль яклау системасы эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәле булуын һәм кеше капиталын үстерүдән көнләшерлек керемнәр алуны тәэмин итә.**

*З-1.5.0.1* Инновацион икътисад өчен Татарстан Республикасына кадрлар җәлеп итәргә һәм аларны саклап калырга.

*З-1.5.0.2* Үзгәрүчәнлекне, яклангайлыкны һәм идарә ителүчәнлекне тәэмин итә торган хезмәт базары моделен кертергә.

*З-1.5.0.3* Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышуның актив чаралары өчен төгәл максатлар билгеләп, эш белән тәэмин итү хезмәтләренең эффективлыгын һәм нәтиҗәлелеген күтәрергә.

*З-1.5.0.4* Эшче көчләрне нәтиҗәлерәк файдалану өчен республика чикләрендә халыкның территориаль мобильлеген һәм хезмәт миграциясен җиңеләйтергә.

*З-1.5.0.5* Хезмәт базарына республиканың икътисадый актив булмаган халкын, аеруча балалы хатын-кызларны, башка регионнардан хезмәт мигрантларын җәлеп итәргә, пенсия яшендәге халыкның хезмәт активлыгын саклауны стимуллаштырырга.

*З-1.5.0.6* Мохтаҗлыкны бәяләү һәм социаль килешү принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла торган программалар ярдәмендә балалары булган ярлы гаиләләрнең социаль якланганлык дәрәҗәсен арттырырга.

*З-1.5.0.7* Озак яшәүгә ярдәм итү максатыннан өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшыртырга һәм алардан һәркемнең файдалана алуын арттырырга.

***Гамәлләр юнәлешләре***

*Хезмәт базарын җайга салу һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә булышу өлкәсендә:*

Хезмәт базарының үзгәрүчәнлегенә хезмәткәрләрне эшкә алуның һәм эштән азат итүнең гарантияләнгән ирege; эшкә яллаучының мохтаҗлыгыннан һәм хезмәткәрләрнең ихтыяҗларыннан чыгып, хезмәткәрләрнең эш вакытыннан файдалану мөмкинлеге (үзгәрүчән эш вакыты); эшкә яллаучының мохтаҗлыгыннан чыгып, хезмәткәрләрне күчерү мөмкинлеге (функциональ үзгәрүчәнлек); эшкә яллаучының мөмкинлекләреннән, бер яктан, һәм хезмәткәрләрнең өметләнүеннән, икенче яктан, чыгып, эш хакын билгеләү мөмкинлеге (үзгәрүчән эш хакы) белән ирешелә.

Үзгәрүчән хезмәт базары моделенә күчү «эш бирүче — һөнәри белем бирү оешмасы — хезмәткәр» элемтәсе буенча төзелгән алдан укыту системасын оештыру шартларында гына мөмкин, монда бәйләп торучы механизмнар һөнәр стандартлары системасыннан, хезмәт ресурсларына ихтыяҗның яңартыла торган фаразыннан, эш бирүче белән берлектә эшләнә торган һөнәри белем бирү программаларыннан гыйбарәт.

*Зарури гамәлләр:*

• эшче көчләрнең сыйфатын яхшырту һәм эш белән тәэмин ителгән затларның тармак һәм территориаль структурасын трансформацияләү, шулай ук эш белән тәэмин итүгә булышу чараларының өстенлекләрен билгеләү юлы белән, эш белән тәэмин итүне модернизацияләү һәм аның нәтиҗәлелеген күтәрү. Мондый сәясәт күчеп килүчеләрне урнаштыруга, шул исәптән, торак мәсьәләсен хәл итүгә өстәмә инвестицияләр таләп итә;

• Татарстан Республикасы брендын булдыру һәм аны Россия хезмәт базарына җәлеп итүчән эш бирүче буларак тарату;

• яшьләрне, шул исәптән республикадан читтән, җәлеп итеп һәм Татарстанда алга таба эшкә урнашу өчен шартлар тудырып, төрле дәрәҗәдәге һөнәри әзерләү программаларын үстерү;

• тармак белем бирү программаларын берләштерүче һәм ерактан ирекле файдалануны күздә тотучы бердәм мәгариф ресурсын оештыру;

• мәктәп укучылары, студентлар, регионның эшләүче гражданнары өчен тармак һәм гомумтармак карьера маршрутлары картасын төзү;

• эш табу мөмкинлеген гарантияләүче белем бирү программаларында катнашуга грант ярдәме күрсәтү системасын оештыру;



• формалаштырылган компетенцияләргә нигезләнгән һәм эш эзләүчеләр һәм вакансияләр турында дөрес мәгълүматны тупларга мөмкинлек бирә торган нәтиҗәле мәгълүмат-коммуникация платформасын оештыру;

• эш бирүчеләрне һәм белем бирү оешмаларын җәлеп итеп, компетенцияләрне объектив бәяләү механизмнарын эшләү (компетенцияләрнең республика системасы картасын булдыру);

• эшсезлектән һәм хезмәткә сәләтне югалтудан ирекле иминләштерү системасын оештыру;

• үз-үзен эш белән тәэмин итү программаларын арттыру һәм кече бизнесны үстерүне стимуллаштыру, аеруча авыл җирлегендә һәм зур булмаган шәһәрләрдә, шул исәптән икътисадый актив булмаган халык арасында;

• әлегә икътисадый актив булмаган, әмма киләчәктә хезмәт базарына чыгачак затларның (балалары булган эшсез хатын-кызлар, инвалидлар) икътисадый активлыгын стимуллаштыру һәм аларны һөнәри укыту, шулай ук пенсия яшендәге халыкның хезмәт активлыгын саклап калуны стимуллаштыру. Бу төркемнәрнең һәрберсе өчен аерым стимуллар бар: эш белән тәэмин итүнең үзгәрүчән рәвешләре, балалар өчен сыйфатлы һәм кыйммәт булмаган мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын арттыру, офистан тыш эшләү форматларын киңәйтү, инвалидлар хәрәкәте өчен уңайлы шәһәр мохитен тудыру, пенсия яшендә эшләвен дәвам итүчеләр өчен киләчәк пенсияләрен арттыру һ.б.

*Халыкны эш белән тәэмин итүнең территориаль программалары өчен финанслау проектын гамәлгә ашыру программасы*

Программа республика чикләрендә халыкның территориаль мобильлеген һәм хезмәт миграциясен стиммуллаштыру, хезмәт базарына икътисадый актив булмаган халыкны җәлеп итү исәбенә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең эффективлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән. Программалы алым халыкны эш белән тәэмин итүгә булышуның актив чараларын төгәл билгеләргә һәм халыкны эш белән тәэмин итүнең территориаль үзәкләрен һәм ресурсларын, җирле хезмәт базарлары мәсьәләләре үзенчәлеген исәпкә алып, Стратегия максатларына һәм бурычларына тупларга мөмкинлек бирәчәк. Проектны финанслауны гамәлгә кертү «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасының төп чараларына каршы килми, әмма максатчан төркемнәргә (балалы эшсез хатын-кызлар, эчке һәм тышкы мигрантлар, яшьләр) адресланган халыкны эш белән

тәэмин итү программалары өстенлекле булачак. Максатчан программалы алым халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү программаларының эффективлыгы һәм нәтиҗәлелеге мониторингын һәм ведомствоара хезмәттәшлекне таләп итәчәк. Программа кыскартылган вариантта «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы ресурслары кысаларында гамәлгә ашырылырга мөмкин. Өстәмә ресурслар бүлеп бирелгәндә яшьләрне һәм балалы хатын-кызларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү, мигрантларны яңадан әзерләү буенча нәтиҗәле программаларны гамәлгә ашыру, эш белән тәэмин итү хезмәтләре клиентларының кеше капиталы сыйфатын яхшыртуга һәм аларның хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга мөмкинлек бирә торган социаль килешү технологиясе кертелергә мөмкин.

*Социаль яклау өлкәсендә:*

• халыкның аз ресурслы төркемнәренә ярдәм күрсәтү һәм ярлылык күренешенең аерым рәвешләрен бетерү исәбенә тигезсезлекне киметү. Икътисадый үсеш темпларының түбән булуы һәм начар демографик тенденция шартларында социаль ярдәм күрсәтү түбәндәгеләргә юнәлдерелә: икътисадый активлыкка булышлык күрсәтүгә һәм халыкның аз ресурслы төркемнәреннән булган хезмәт ресурсларының сыйфатын яхшыртуга; социаль хезмәт күрсәтү хезмәтләрен үстерү исәбенә социаль яклауның икътисадый үсешкә өлеш кертүен арттыруга;

• НКО өчен дәүләт заказын, дәүләти-хосусый партнерлыкны һәм хәйриячелекне арттыру исәбенә социаль хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләрнең дәүләтнеке булмаган сегментын күбәйтү юлы белән актив озак яшәүгә ярдәм итү максатында өлкән кешеләр өчен социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру;

• халыкка социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы төрле оештыру-хокук рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге оешмалар челтәрен үстерү;

• халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы учреждениеләренең матди базасын ныгыту; социаль хезмәткәрләрнең уртача эш хакын Татарстан Республикасындагы уртача эш хакының 100 процентына кадәр арттыру; халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә конкуренцияне үстерү.

*«Аз керемле гаиләләрдән булган балалар өчен пособиеләр» проекты*

Проект «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының «Социаль түләүләр» ярдәмче программалары кысаларында гамәлгә ашырылырга мөмкин һәм дәүләт тарафыннан балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча гарантияләнгән чараларның берсе булып торучы, социаль контракт шартларында күләменең шактый артуыннан гыйбарәт булган балага айлык пособиене модернизацияләүне күздә тота. Социаль килешүнең предметы – балага айлык пособиене алучы эшсез яки аз түләнә торган эшләрдәге хезмәткә сәләтле гражданнар. Социаль килешүнең нәтиҗәсе – балалары булган аз керемле гаиләләрдән эшсез яки аз түләнелә торган эшләрдәге хезмәткә сәләтле гражданнарның икътисадый активлыгын арттыру.

Балалар арасында ярлылык куркынычы халык буенча уртача алганда 1,4 тапкыр югарырак булуга карамастан, балалары булган аз керемле гаиләләр социаль ярдәм алучыларның төп өлешен тәшкил итми. Балалы гаиләләр арасында ярлылыкның төп сәбәпләре түбәндәгеләр:

1) ата-ананың берсенең эше яки кереме булмау (яки ата-анасы булмау);

2) түбән эш хакы алу;

3) балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү түбән дәрәҗәдә булу. Шул ук вакытта нәкъ менә балалы гаиләләрдә формаль булмаган керемнәр туплау югары дәрәҗәдә, бу чынлыктагы ярлы гаиләләргә өстенлекле ярдәм күрсәтү процессын катлауландыра.

Балалары булган мохтаҗ гаиләләрнең иждивениечелек кәефләрен бетерү, социаль якланганлык дәрәҗәсен күтәрү өчен социаль килешү нигезендә аларга социаль ярдәм күрсәтүгә күчү тәкъдим ителә. Проектта катнашучылар мохтаҗ гаиләләр балалары өчен пособие алучы һәм гамәлгә ашырылмаган хезмәт потенциалы булган (эше һәм өстәмә рәвештә эшләп табылган акчасы булмау яки яшәү минимумының 150 процентыннан югары булмаган эш хакы белән тулы көн эшләмәү) балалы гаиләләр булырга мөмкин. Бәяләүләр буенча, мондый гаиләләр әлеге пособиене алучыларның 30% ын тәшкил итә.

*Көтелә торган нәтиҗәләр*: балалы гаиләләр арасында ярлылык кимү, балалары булган ярлы гаиләләрнең керемнәрен һәм икътисадый активлыгын арттыру.

***Флагман проектлары:***

1) ***«Инноваторларга социаль ярдәм күрсәтү» (к. 3.1.6.5);***
2) ***«Актив озак яшәү» (к. 3.1.6.6).***

**3.1.6. Кеше капиталын туплау өлкәсендә флагман проектлары**

**3.1.6.1. «Татарстан — Идел буенда халыкны җәлеп итү үзәге»**

Проект түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

• Татарстан Республикасы халкын миграция исәбенә, иң элек Россиянең башка регионнары мигрантлары исәбенә арттыруга;

• мигрантлар килү белән бергә регионның хезмәт базарында таләп ителә торган квалификацияле һәм югары квалификацияле белгечләрне арттыруга.

• Проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

• Россия Федерациясе һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге дәүләтләре арасында оешкан төстә чит ил хезмәткәрләрен җыю турында килешүләр төзү кысаларында, миграциягә кадәрге һөнәри әзерлекне арттырып, Россия укытучылары катнашында мигрантларнысайлап алу механизмнарын кертүне;

• Татарстан Республикасына чит ил студентлары килү агымын арттыруны, аларны эшкә урнаштыруны һәм республикада калдыруны;

• югары интеграция потенциалына ия булган мигрантларны иммиграцияләүгә һәм гражданлык хокукын бирүгә ярдәм итү.

Проектның нәтиҗәсе буенча, Татарстан Республикасы халкы еллык миграция исәбенә 2020 елга 10 — 15 мең кешегә, 2025 елга 20 — 25 мең кешегә артырга мөмкин. Татарстан Республикасының югары уку йортларында укучы чит ил студентларының саны 2025 елга 10 — 15 меңгә кадәр артуы көтелә, шулардан 50 процентының югары уку йортын тәмамлаганнан соң республикада калу һәм белгечлек буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булырга тиеш.

**3.1.6.2. «Белем алучы регион: яңа икътисадка — яңа һөнәрләр һәм күнекмәләр»**

Проектның максаты — Татарстан Республикасының кадрлар потенциалын арттыруны тәэмин итә торган төп фактор буларак өлкәннәрнең өзлексез белем алу системасын үстерү.

Проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

• республиканың югары технологияле тармаклары (нефть химиясе, авиа-, автомобиль төзелеше) хезмәткәрләре өчен өзлексез белем бирү инфраструктурасын үстерүне;

• инвалидлар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен формаль һәм формаль булмаган белем бирүнең төрле рәвешләреннән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне;



• пенсия яшенә җитеп килүче һәм пенсия яшендәге затлар өчен массакүләм белем бирү һәм укыту программаларын башлап җибәрүне («Татарстанның көмеш еллар университеты»);

• Казанны Learning Cities халыкара ассоциациясенә кертүне, ЮНЕСКО тарафыннан үткәрелә торган белем алучы шәһәрләрнең халыкара рейтингларында катнашу.

Көтелә торган нәтиҗә:

• регионның инвестицион җәлеп итүчәнлеген күтәрү, регионның инновацион икътисады өчен кеше капиталын алдан үстерү;

• республикадагы өлкәннәрнең функциональ (мәгълүмати, технологик, тел, финанс, медиа һәм башка төрләр) грамоталыгын яхшырту;

• республика халкының социаль җаваплылыгын арттыру һәм инвалидларны, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларны, пенсия яшенә җитеп килүче һәм пенсия яшендәге затларны белем алу һәм әзерләү аша социаль адаптацияләү.

**3.1.6.3. «Югары мәктәпнең конкурентлык сәләтен арттыру өчен партнерлык»**

Проектның максаты — Татарстанның федераль һәм халыкара югары белем бирү базарларында җәлеп итүчәнлеген көчәйтү өчен югары уку йортлары кооперациясен үстерү.

Ярдәм күрсәтү сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен югары белем бирү секторын түбәндәге сегментларга бүлү тәкъдим ителә:

• федераль һәм халыкара югары белем бирү базарларында конкуренциягә сәләтле глобаль-федераль югары уку йортлары (күбесенчә табигать фәннәре һәм техник юнәлешләр буенча);

• көчле бакалавриатлы (шул исәптән гамәли) югары уку йортлары — регион һәм макрорегионның икътисадый таләпләрен тәэмин итүгә (шул исәптән урта һөнәри белем бирү белән партнерлыкта) эшләүче «инфраструктура» югары уку йортлары;

• халыкның социаль-икътисадый һәм гуманитар белгечлекләргә ихтыяҗын тәэмин итә торган һәркем укый алырлык югары белем бирүче уку йортлары; мондый югары уку йортларының билгеле бер өлеше регион башкаласыннан читтә урнашырга тиеш.

Проект бүленгән сегментлар кысаларында университетлар кооперациясен үстерүне күздә тота:

1) федераль һәм глобаль дәрәҗәләрдә мәгариф һәм тикшеренүләр өлкәсендә үзара файдалы хезмәттәшлек итү өчен *җитди югары уку консорциумын (яки кооперациянең башка челтәр моделен) оештыру.*

Тормышка ашыру инструментлары, гамәлләр:

• уртак алдынгы белем бирү программаларын һәм методикаларын эшләүне һәм таратуны субсидияләү;

• университетара тикшеренүләрне субсидияләү;

• укытучылар алмашу рәвешләрен субсидияләү;

• консорциум эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү;

• финанс нәтиҗәлелеген күтәрү өчен әлеге югары уку йортларының максатчан капиталы фондлары эшчәнлеген (хокукый, финанс, мәгълүмати) үстерүне стимуллаштыру.

Моңа охшаш проектларны башка регионнарда гамәлгә ашыру (Том университетлары консорциумын оештыру, югары белем бирүче «Глобаль университетлар» белем бирү оешмалары ассоциацияләре, икътисад һәм менеджмент өлкәсендә алдынгы югары уку йортлары ассоциацияләре) аларның нәтиҗәлелеген күрсәтте.

2) *«Инфраструктура» югары уку йортларының үзара хезмәттәшлек итүенең челтәр рәвешләрен үстерү.*

«Инфраструктура» тибындагы югары уку йортлары хезмәттәшлеге регион икътисады таләпләре өчен тиешле компетенцияләрдәге кадрлар әзерләүнең нәтиҗәле системасын оештыруга юнәлдерелә. Югары уку йортларының үзара хезмәттәшлеге иң яхшы тәҗрибәләрне тарату исәбенә белем бирү программаларының нәтиҗәлелеген күтәрүгә мөмкинлек бирәчәк. Инфраструктурадан (мәсәлән, махсус лабораторияләр, станоклар, җайланма) уртак файдалану финанс чыгымнарын киметүгә мөмкинлек бирәчәк.

Тормышка ашыру инструментлары, гамәлләр:

• уртак алдынгы белем бирү программаларын һәм методикаларны эшләүне һәм таратуны субсидияләү;

• укытучылар алмашу программаларын субсидияләү;

• техник белгечләр әзерләү өчен бердәм ресурс үзәген оештыруга инфраструктура ярдәме һәм административ ярдәм күрсәтү;

• югары белем алу дәрәҗәсе түбән булган районнарда киң юнәлештәге (социаль-икътисадый һәм гуманитар белгечлекләр буенча) программаларны үстерү;

• кайбер һөнәри белем бирү оешмаларын, үз программаларын гамәли бакалавриат рәвешенә күчереп, профиле буенча һәм территориаль яктан якын университетларга кушу.

Проектны гамәлгә ашыру өчен югары һөнәри белем бирүне үстерү программасын һәм республика бюджеты акчасы исәбеннән аны финанслау күләмнәрен раслый торган регион дәрәҗәсендәге тиешле норматив документ әзерләргә кирәк.



**3.1.6.4. «Татарстанның креатив индустрияләре»**

Чимал икътисадыннан инновация икътисадына күчкәндә кадрларга һөнәри таләпләр, интеллектуаль үсеш һәм культура үсеше дәрәҗәсен дә кертеп, артуга бәйле рәвештә мәдәниятнең роле арта. Шул ук вакытта иҗади индустрияләр үзләре инновацион икътисадның аерылгысыз бер өлеше булып тора. Иҗади индустрияләрне тотрыклы үстерү Татарстанның инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруга, квалификацияле белгечләр килүне арттыруга, инновацияләрне һәм иҗатны мотивацияләүгә, конкурентлык сәләтен яхшыртуга булыша.

Проект Татарстан Республикасының иҗади индустрияләрен интенсив үстерү өчен шартлар тудыруга, эчке базарны зурайту һәм экспорт өчен мөмкинлекләрне арттыру исәбенә аларның конкурентлык сәләтен арттыруга юнәлдерелгән.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

• иҗади индустрияләр өчен, шул исәптән университетлар каршында бизнес-инкубаторлар челтәрен булдыру;

• кара-каршы финанслау шартларында консультация һәм грант ярдәме күрсәтү өчен венчур фонды һәм иҗади индустрияләр агентлыгын оештыру;

• иҗади индустрияләр продукциясен дөньяви базарларга чыгару һәм экспортны арттыру өчен Россия һәм чит ил партнерлары белән хезмәттәшлекне арттыру;

• креатив икътисад секторында бизнес-белем бирү программаларын арттыру;

• кластерда катнашучылар мониторингы һәм аларны мәгълүмат-аналитика белән тәэмин итү;

• дәүләти-хосусый партнерлыкка ярдәм күрсәтү, меценатлыкны стимуллаштыру;

• иҗади индустрияләр өчен чаралар пакеты, моңа салым ташламалары һәм башка преференцияләр дә керә.

Проектны гамәлгә ашыру Татарстанга 2025 елга алдынгы позицияләрне яуларга һәм халыкара дәрәҗәдәге иҗади индустрияләрне үстерү буенча конкурентлыкка сәләтле үзәк булырга мөмкинлек бирәчәк. Инновацион шәһәрләр индексы буенча (инновацион икътисадны үстерү өчен шәһәрләр тарафыннан барлыкка китерелүче потенциал һәм шартлар бәяләнә торган Innovation Cities™ Index) Казан Hub (Халыкара үзәк) категориясенә керергә мөмкин. Хәзерге көндә Казан 3Nod (Йогынты ясау чыганагы) категориясендә 222 нче урында тора, 2014 елда Россия шәһәрләреннән түбәндәге өч шәһәр Казанны узып китте: Мәскәү — 2Hub категориясе белән 63 нче урында, Санкт-

Петербург 3Hub категориясе белән 81 нче урында, Екатеринбург 3Nod категориясе белән 213 нче урында.

Проектны гамәлгә ашыру иҗади яшьләрнең Татарстан Республикасыннан китүен туктатырга, Татарстан Республикасы икътисадының креатив секторы өчен өстәмә рәвештә кимендә 25 мең квалификацияле иҗади белгеч җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр халыкның эш белән тәэмин ителгән өлешенең кимендә 15 процентын, мәдәният тормышында катнашучылар гомумән халыкның 60 процентын тәшкил итәчәк.

### 3.1.6.5. «Инноваторларга социаль ярдәм күрсәтү»

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) белгечләрнең үз урынын табуны стимуллаштыру системасын оештыру:

• квалификация күтәрү курсларын оештыру/финанслашу;

• чит телләрне өйрәтү курсларын финанслашу;

• төрле өлкәләрдәге белгечләрнең республика конкурсларын оештыру, лауреатларга премия бирү.

2) Татарстан территориясендә белгечләрне социальләштерү һәм республикада беркетү:

• рус, татар телләрен өйрәтүне оештыру/финанслашу;

• җәлеп ителгән белгечләр өчен торак арендалауны субсидияләү;

• өстәмә медицина иминияте өчен чыгымнарны финанслашу;

• балаларны мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына урнаштыруга һәм анда тәрбияләп тотуга булышлык күрсәтү;

• Татарстан Республикасы белән таныштыруга юнәлдерелгән махсус туристлык программаларын оештыру/финанслашу;

• талантлы яшьләр өчен җәйге мәктәпләр оештыру/финанслашу.

Проектны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасына югары белем өчен уртача премиядәге институциональ «тозак»тан чыгарга мөмкинлек бирәчәк, югары квалификацияле белгечләрне саклап калуны һәм башка регионнардан яшь белгечләр җәлеп итүне тәэмин итәчәк.

### 3.1.6.6. «Актив озак яшәү»

Проект актив озак яшәүгә булышлык күрсәтү максаты белән өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшыртуга һәм һәркемнең аннан файдалана алу мөмкинлеген арттыруга юнәлдерелгән. Ул гаиләнең өлкән әгъзаларын карау белән шөгыльләнүче туганнарны һөнәри эшчәнлек өчен азат итәргә



мөмкинлек бирәчәк. Хәзерге вакытта социаль хезмәт күрсәтү нигездә дәүләт секторы тарафыннан тәкъдим ителә. «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» федераль закон нигезендә бу өлкәдә дәүләтнеке булмаган секторны үстерү өчен шартлар тудырылды.

Проектта түбәндәгеләр күздә тотыла:

• халыкка социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы төрле оештыру-хокук рәвешләрендәге һәм милек рәвешләрендәге оешмалар челтәрен үстерү;

• социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эшенең сыйфатын тикшереп тору һәм бәяләү нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең барлык рәвешләрен (ярымстационар, стационар һәм ашыгыч) үстереп, социаль хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту;

• халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы учреждениеләренең матди базасын ныгыту;

• социаль хезмәткәрләрнең уртача эш хакын Татарстан Республикасындагы уртача эш хакының 100 процентына кадәр арттыру;

• халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә конкуренцияне үстерүне.

Үсеш драйверы — кече һәм урта бизнес, гаилә элемтәләре ныграк булган саен, аны үстерү өчен Татарстанда шанслар югарырак. Икътисадның әлеге сегменты эш белән тәэмин итүнең үзгәрүчән рәвешләрен киң куллана, формаль булмаган эш белән тәэмин итүне киметү буенча уңай эффект бирергә сәләтле, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә инновацион инициативаларны үстерүгә булышлык итәчәк. Өстәмә ресурслар дәүләтнеке булмаган учреждениеләргә грант ярдәме күрсәтү, тәэмин итү технологияләрен кертү һәм тернәкләндерү инфраструктурасын оештыру исәбенә хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту өчен таләп ителәчәк.

Катнашучыларның өстенлекле төркемнәре: өлкән яшьлекләр төркеме затлары, социаль өлкәдә хезмәтләр күрсәтүче дәүләт учреждениеләре, социаль өлкәдә хезмәтләр күрсәтүче дәүләтнеке булмаган учреждениеләр.

## 3.2. Пространство үсеше концепциясе: Идел — Кама метрополисы

### 3.2.1. Пространство үсешенең хәзерге торышы һәм тенденцияләре

***Ысулый алым***

Стратегиядә кабул ителгән кеше капиталы өстенлеге турында постулаттан чыгып, республика пространствосы беренче чиратта, кешенең яшәеш пространствосы буларак карала. Тер-

ритория һәм коммуникация системасы мондый очракта кешенең тормыш эшчәнлеген тәэмин итүче булып тора.

Кешенең тормыш эшчәнлеге пространствосы дүрткә бүленде:

• кешенең тормыш эшчәнлеген ресурслар белән тәэмин итү пространствосы – су, һава, файдалы казылмалар, урман һәм авыл хуҗалыгы җирләре пространствосы;

• шәхси тормыш пространствосы – һәр кешенең тормышы белән тыгыз бәйләнгән йорт, торак ячейкасының шәхси пространствосы;

• кешеләрнең үзара хезмәттәшлеген, мәгълүматлар һәм физик продуктлар алмашуны, гаилә дәрәҗәсеннән алып глобаль дәрәҗәгә кадәр барлык дәрәҗәләрдә социаль ячейкалар, бергәлекләр оештыруны һәм аларга булышлык күрсәтүне тәэмин итә торган транспорт-коммуникация пространствосы;

• коллектив эшчәнлек пространствосы – гаилә, тәрбия һәм белем бирү, җитештерү, ял итү эшчәнлеге алып барыла торган пространство; коллектив эшчәнлек пространствосы ячейкасы шулай ук коллектив эшчәнлек, әмма челтәр характерында алып барыла торган транспорт-коммуникация пространствосы белән тыгыз бәйләнгән.

Бара торган процессларны тасвирлау өчен технологик торышлар алмашу турындагы күзаллау файдаланыла: хәзерге вакытта мәгълүмат технологияләренә нигезләнгән дүртенче технологик торыш алдынгы булып тора, иң якындагы чорда (2030 елга кадәр) нано- һәм күзәнәк технологияләрен куллануга бәйле алтынчы торыш алдынгы булачак.

***Территория***

Татарстан Республикасы территориясе – 67,85 мең кв. км; 2014 ел башына халкы – 3 млн 838 мең кеше; торак пунктлар саны – 3 113.

Муниципаль-территориаль корылыш: 43 муниципаль район; 2 шәһәр округы (Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре); 39 шәһәр җирлеге; 872 авыл җирлеге (3.3 нче рәсем).

Татарстан Республикасы халкының тыгызлыгы – 1 кв. километрга 56,6 кеше, авыл халкының тыгызлыгы – 1 кв. километрга 13,6 кеше, шәһәр халкының өлеше – 76 процент. Төзелгән территорияләр – 4,2 процент, су өсләре – 5,7 процент, урманнар (тыюлыкларны кертеп) – 7,4 процент башка территорияләр (ачык ландшафтлар) 82,6 процент тәшкил итә.






3.3 нче рәсем. Территория, пространство, транспортның хәзерге хәле

*Транспорт-коммуникация каркасы*

Автомобиль юллары – 14 494,93 км, шул исәптән: федераль әһәмияттәге – 1 068,89 км, региональ әһәмияттәге – 13 425,9 км (шуларның 86 процентының камилләштерелгән өслеге бар). Җирле әһәмияттәге автомобильләр юлларының озынлыгы – 23 810,0 км, шул исәптән муниципаль районнар әһәмиятендә – 3 612,6 км; урамнарның озынлыгы (шәһәрләр һәм шәһәр тибындагы поселоклар) – 20 053,9 км.

Татарстан Республикасындагы тимер юл транспорты хезмәте «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиаллары Горький һәм Куйбышев тимер юллары тарафыннан күрсәтелә. Татарстан Республикасы территориясе буенча тимер юлларның гомуми озынлыгы 1 889 км тәшкил итә, шулардан 379,7 км электрлаштырылган; магистраль линияләр озынлыгы – кимендә 880 км, шулардан 30 проценты электрлаштырылган.

Авиация транспорты – 3 аэропорт: Казан, Бигеш, Бөгелмә (шулардан 2 се халыкара – Казан һәм Бигеш).

Татарстан Республикасының эчке суднолар йөри торган Идел һәм Кама елгалары буенча төп юлларының гомуми озынлыгы – 587 км.

Татарстанның пространство структурасы үзенчәлеге – Идел һәм Кама елгалары акваториясеннән гыйбарәт көчле табигый су коридоры, ул регион территориясен өч өлешкә: Каманың уң яры һәм сул яры территориясенә, Иделнең уң яры территориясенә бүлә һәм бүгенге көндә үзара түбәндәге өч күпер ярдәмендә тоташа:

• Казанның көнбатыш өлешендә Идел аша автомобиль юлы күпере-дамбасы (Займище күпере);

• Саескан Тавы авылы районында Кама аша автомобиль юлы күпере-дамбасы (Алексеевск күпере);

• автомобиль һәм тимер юл элемтәләре өчен Кама аша күпер сыйфатында файдаланыла торган Түбән Кама гидроэлектростанциясе буасы («Идел» М7 федераль магистрале).

Нефть транспортлау өчен үткәргеч торба челтәре – 6,5 мең км. Газ транспортлау өчен үткәргеч торба челтәре: магистраль газүткәргечләр һәм бүлеп бирелгән газ үткәргечләрнең озынлыгы – 5,6 мең км, бүлә торган газүткәргечләрнең озынлыгы – 39,8 мең км. Магистраль газүткәргечләр: Уренгой – Помары – Ужгород, Уренгой – Үзәк Россия; магистраль нефть үткәргечләр: «Дружба» (Әлмәт – Самара – Брест) нефть үткәргече, Усть-Балык – Курган – Уфа – Әлмәт; Әлмәт – Түбән Новгород – Рязань – Мәскәү, Пермь – Әлмәт, Әлмәт – Яр Чаллы.



Шәһәр җәмәгать транспорты системалары:

• Казан шәһәре метрополитены (1 линия, 10 станция, 15,8 км);
• трамвай: Казан, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләре;
• троллейбус – Казан һәм Әлмәт шәһәрләре;
• автобус транспорты – барлык эре торак пунктларда, шулай ук шәһәр яны һәм шәһәрара.

*Торак пространствосы*

2013 елга Татарстан Республикасы торак фонды 92,8 млн. кв.м тәшкил итте, шул исәптән 67,5 млн. кв.м шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда, 25,3 млн. кв.м авыл җирлекләрендә. Күпфатирлы йортлар 63 процент, индивидуаль йортлар 35,6 процент, махсус йортлар 1,4 процент тәшкил итә. 2014 елда торак белән уртача тәэмин ителеш – 24,8 кв.м/кеше.

*Технологик торышлар зоналары*

Татарстан территориясен алдынгы технологик торыш буенча зоналарга бүлү 3.4 нче рәсемдә күрсәтелгән. Территориянең шактый өлеше әлегә алдынгы булып торучы, нигездә индустриягә кадәрге җитештерүгә ия булган өченче технологик торышта. Дүртенче технологик торышның башлангыч этабына сусаклагыч зоналары (эре масштаблы түбән тыгызлы индустрия зоналары элементы буларак), нефть һәм газ чыгару зоналары тора. Алга киткән дүртенче торыш Кама агломерациясенә хас. Дүртенче технологик торыштан бишенчесенә әкренләп күчү зоналарына Казандагы фәнни-җитештерү берләшмәләре мәйданчыклары һәм «Алабуга» махсус икътисадый зонасының индустрия зонасы керә. Нигезендә мәгълүмат технологияләре булган заманча бишенче технологик торыштагы зоналар – Казанның (мәгариф оешмалары зоналарын кертеп), Чаллының, Әлмәтнең үзәк эшлекле районнары, проектлаштырыла торган «Иннополис», «Смарт-сити». Формалаша торган милли парклар, шулай ук шәһәрләрнең торгызыла торган тарихи төзелеш зоналары бишенче технологик торыш зоналары элементлары буларак билгеләнде.




3.4 нче рәсем. технологик торыш зоналарының бүгенге хәле



***Татарстан Республикасы пространствосын эре масштаблы үзгәртеп корулар***

XX гасырның уртасына кадәр Татарстан авыл хуҗалыгы җирләрен үзләштерү зонасы булды, аерым территорияләрдә сәүдә, индустрия һәм идарә үсеше алга киткән иде. Шулай ук мәдәният һәм мәгариф үзәге булган Казан һәрвакыт аерым роль уйнады. Тимер юлларның күпчелеге 1950 елларга кадәр төзелгәнлектән, алар соңрак барлыкка килгән икътисадый үзәкләрне тоташтыру өчен билгеләнмәгән иде. Төп тимер юллар Үзәк Россияне Урал һәм Себер белән тоташтыру өчен төзелде, Татарстан территориясен бары кыеклап кына үтте.

• 1940 нчы елларның икенче яртысыннан Татарстан Республикасы пространствосын җитди үзгәртеп кору башланды.

• 1940 нчы елларның икенче яртысында һәм 1950 нче елларда регионның көньяк-көнчыгышында эре нефть ятмасы үзләштерелә башлады, аның нигезендә яңа үсеш үзәге — Әлмәт шәһәре формалашты, Татарстанның көнбатыш өлешендә табигый һәм антропоген ландшафтларны үзгәрткән Куйбышев сусаклагычы барлыкка килде.

• 1960 нчы елларда Татарстан Республикасында төньяк-көнчыгыш үсеш үзәге формалаша башлады: Түбән Кама шәһәре, Түбән Кама гидроэлектр станциясе һәм Кама автомобиль заводы төзелә башлады, Чаллы шәһәре үсте.

• 1970 — 1980 нче елларда транспорт инфраструктурасы актив үсте: Татарстанның хәзерге автомобиль юлы челтәре формалашты, сәнәгать предприятиеләренә хезмәт күрсәтү өчен республиканың көнчыгышында тимер юл төзеде, икенче аэропорт барлыкка килде, «Казан» аэропортын Казан шәһәреннән читтәге яңа мәйданчыкка чыгару гамәлгә ашырылды, Түбән Кама сусаклагычы формалашты.

• 1990 нчы елларда экологик проектлар барлыкка килде: «Түбән Кама» милли паркы оештырылды, Казан шәһәре үзәге реконструкцияләнде.

• 2000 нче елдан соң Татарстан Республикасында транспорт үсешенең һәм икътисадый үсешнең яңа этабы башланды: автомобиль юллары реконструкцияләнде һәм кайбер яңалары төзелде, Казан үсте (метрополитен, автомобиль юллары төзелеше, аэроэкспресс, төньяк тимер юл вокзалы), «Алабуга» махсус икътисадый зонасын һәм регионның көнчыгыш өлешендә яңа индустрия паркларын формалаштыру, Иннополис һәм Смарт Сити Казан яңа шәһәрләрен төзү башланды.

Бу этапка түбәндәге гомумроссия тенденцияләре нигез булды:

• хәзерге Россиянең закон чыгару базасын алга таба эшләү — территорияләр һәм пространство үсешен билгели торган төп фе-

дераль законнар барлыкка килде: Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексы;

• телекоммуникация пространствосының һәр җирдә актив үсеше: кәрәзле элемтә, югары тизлекле интернет, санлы телевидение;

• автомобильләштерү, халыкның хәрәкәтчәнлеге арту;

• шәһәрләрдә яңа районнарны массакүләм типлаштырылган төзүгә кайту.

***Пространство үсеше перспективалары***

Мәгълүмат технологияләренә нигезләнгән бишенче технологик торышка күчкәндә җәмгыять үсешенең яңа этабында тормыш эшчәнлеге пространствосы җитди трансформалаша: коммуникация пространствосы телекоммуникацияләр үсү исәбенә киңәя (3.5 нче рәсем), әмма кешеләрнең шәхси аралашуына ихтыяҗ кимеми.




**3.5 нче рәсем. Татарстан Республикасының телекоммуникация пространствосы**

Гаилә пространствосы катлаулана, ул физик яктан бүленгән һәм төрле илләрдә урнашкан булырга мөмкин, әмма мәгълүмат һәм энергетика пространствосына бәйле рәвештә гаилә мөнәсәбәтләренең барлык билгеләре сакланып кала. Гадәттәге җитештерү пространстволары кешенең турыдан-туры катна-



шуын таләп итмичә роботлаша. Уку пространствосы виртуаль пространствоны куллана, аны кеше, киләчәкнең төрле вариантларын сайлап, интерактив режимда үзгәртә ала.

«Мәгънә пространстволары»ның — «урын рухы»на ия булган, кешеләрне тәрбияләгән, аларны үзара берләштергән, тормышны нәкъ менә бу урында мәгънәле итә торган, цивилизациянең тирән тамырларын саклап калуга булышлык күрсәтә торган һәм алга таба үсү өчен азык бирә торган урыннарның мәгънәсе арта.

Тормыш эшчәнлеге калдыклары җибәрелә торган пространство мәсьәләләре катлаулана.

Социаль-икътисадый үсеш стратегиясе җәмгыятьнең көчен тормышның барлык дәрәҗәләрендәге тормыш эшчәнлеге ресурсларыннан тагы да тулырак файдалануга, физик пространство һәм телекоммуникация пространствосы арасындагы, пространствоның глобаль һәм индивидуаль тасвирнамәләре арасындагы, үзгәрүчәнлек һәм тотрыклылык арасындагы балансны эзләүгә юнәлдерүне күздә тота. Шуның белән бергә технологик торыш алмашуга бәйле булган пространствоны яңадан үзгәртеп коруның җитди тенденцияләрен исәпкә алырга кирәк (3.6 нчы рәсем).

***Татарстан Республикасы пространствосының көчле һәм йомшак яклары***

Татарстанда үсеш өчен зур пространство потенциалы бар, экологик чиста зоналар һәм коридорлар сакланып калган, үсеш алган транспорт инфраструктурасы бар.

Регион үсешенең өч узелы булу, аларның һәрберсе аерым үзенчәлеккә ия, эчке һәм тышкы хезмәттәшлек һәм барлык дәрәҗәләрдәге инвестицияләр өчен уңайлы сәламәт конкуренция схемасын төзергә мөмкинлек бирә.

Регион территорияләр белән идарә итүнең җайга салынган системасы рәвешендәге яхшы институциональ фундаментка ия. Әмма кадрлар квалификациясен шактый күтәрүне, идарә итү технологияләрен яңартуны, үсешнең перспектив бурычларын алдан бару режимында хәл итү кирәк. Совет чорыннан соң барлыкка килгән пространствоны планлаштыру системасын югалту, аны территориаль планлаштыру һәм җир төзелеше белән алмаштыру — идарә итүнең барлык тормыш эшчәнлеге системасы үсешен тотып тора торган җитди җитешсезлекләрнең берсе.

Соңгы ун еллыкта төзелгән дүртенче технологик торышның пространство инфраструктурасы бишенче технологик торышка нәтиҗәле булышлык күрсәтү өчен үзгәртеп коруга шактый чыгымнар таләп итә. Яңа технологияләр «яшел карарлар» таләп итә һәм гамәлдәге экологик депрессив мәйданчыкларда урнаша алмый.



3.6 нчы рәсем. яңа технологик торышка күчкәндә пространствоны үзгәртеп корулар



Йомшак яклар һәм проблемалар:

• Ресурс пространствосы: яңа торак төзелеше өчен һәр җирдә дә территорияләр җитмәү; сусаклагыч һәм санитария-саклау зоналарын, авыл хуҗалыгы территорияләрен яңа төзелешләр өчен алу; торакның сыйфаты начараю, социаль инфраструктураның күмәк пространстволарын экономияләү исәбенә төзелеш тыгызлыгы арту; шактый пространстволарның нефть химиясе комплексы предприятиеләре калдыкларын урнаштыру зоналарында булуы; нефть һәм газ чыгарыла торган территорияләрнең бер өлеше киләчәктә бу территорияләр үсешен тоткарлап торачак бораулау скважиналары һәм үткәргеч торбалар белән җиһазландырылган булу.

• Индивидуаль һәм күмәк торак төзелеше: һәркем сатып алырлык бәяләргә сыйфатлы торак җитешмәү, бишенче технологик торышта эшләүче халык таләпләренә туры килми торган һәм арта калган торак төзелеше стандартлары; коммуналь инфраструктура начар нәтиҗәле һәм сүлпән; массакүләм төзелеш үзенчәлекләрен югалту; алтынчы технологик торыш стандартларына туры килә торган җирлекләрне үстерү идеяләре гомумән юк.

• Сәүдә һәм социаль өлкәнең күмәк пространствосы: мәгариф, мәдәният, ял итү объектлары җитешмәү, элегрәк төзелгән бик күп сандагы объектлар реконструкцияләүне таләп итә.

• Җитештерү пространствосы: дүртенче технологик этап предприятиесе (мәсәлән — «КАМАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте заводлары цехлары) өчен оештырылган пространстволар артык булу; кече һәм урта бизнес өчен пространстволар җитешмәү; экологик чиста пространстволар җитешмәү.

• Транспорт-коммуникация пространствосы: пространство сыйфаты белән идарә итүне югалту, төзекләндерүнең деградацияләнүе, җәяүлеләр юллары булмау, индивидуаль автомобиль пространствосының кирәгеннән артык күп булуы; коммуникацияләр урыннарының үзенчәлеген тәэмин итә торган «якорь пространстволары» җитешмәү; эчке һәм тышкы юлларда тизлекнең җитәрлек булмауы; иҗтимагый транспортның роле кимү.

### 3.2.2 Пространство үсешенең максатлары һәм бурычлары

Пространство үсеше өлкәсендә максатлар һәм бурычлар шәхес иреге, гаилә, мәдәният, ышаныч, тотрыклы үсеш кебек кыйммәтләрдән чыгып билгеләнде, бу гаилә мөнәсәбәтләренә һәм төрле социаль төркемнәр арасында аралашуга булыша торган пространстволарның өстенлеген аңлата. Мондый «үзара мөнәсәбәтләр» арасындагы бәйләнешне транспорт-коммуникация пространствосы тәэмин итә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне төзүдә мөһим рольне мәдәният алып тора. Җирле мәдәният тә,

гомумдөнья мәдәнияте дә бер-берсенә таныш булмаган кешеләргә пространствода үз урынын билгеләргә, хосусыйлыкның һәм иҗтимагыйлыкның менталь һәм физик чикләрен тәгаенләргә, ата-аналарга һәм балаларга, ир белән хатынга һәм күршеләргә уртак көнкүрешне оештырырга ярдәм итә.

***2030 елда Татарстанның пространство үсешен максатчан күзаллау***

**СЦ-2** **Нисбәтле территориаль-пространство үсеше мохитнең югары конкурентлык сәләтен тәэмин итә; инфраструктура җитди конкурентлыкка сәләтле була. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла.**

**Ц-2.1** **Пространство кеше ресурсларын саклап калу һәм җәлеп итү өчен, гомернең төрле этапларында һәм төрле тормыш рәвешләре контекстында шәхеснең тулы кыйммәтле үсеше өчен шартлар тудыра.**

**Ц-2.2** **Пространство үсеше Татарстан Республикасының социаль-икътисадый факторларына һәм география хәленә – Евразия үзәгендә урнашуга нигезләнеп бара.**

**Ц-2.3** **Пространство хәл итүләре дөньяви җәмгыятьтә Татарстан Республикасы статусын күтәрүгә, хезмәт һәм технологияләр бүленешенең дөньякүләм системасында уникаль урынын табуга булыша.**

**Ц-2.4** **Пространство алдынгы стандартларга туры килә һәм яңа технологик торышларны танытуга булыша (3.7 нче рәсем).**

**Ц-2.5** **Республика территориясендә бердәм социомәдәни пространство саклана.**

**Ц-2.6** **Интеллектуаль һәм экологик чиста технологияләр һәм хәл итүләр нигезендә үсә торган өч агломерацияне: Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләрен берләштерә торган челтәр тибындагы өчтөшле Идел-Кама метрополисы формалашты.**

**Ц-2.7** **Пассажирлар хәрәкәте өчен таләп ителә торган мөмкинлекләрне тәэмин итүче транспорт-коммуникация системасы сыйфатының югары күрсәткечләренә ирешелде.**

**Ц-2.8** **Татарстан Республикасында барлык эчке, агломерацияләр арасындагы, регионнар арасындагы транспорт юнәлешләренең, шулай ук халыкара транспорт коридорларының югары синергиясе: «Идел – Кама» үсеше полюсының тотрыклы тиз йөрешле транспорт каркасы формалашты.**

*З-2.0.0.1* Фаразлана торган саны 4 182 мең кеше[1] булачак (2013 ел белән чагыштырганда 350 мең кешегә артык) республика халкының тормыш эшчәнлеген сыйфатлы пространство, дүртенче технологик торышның булган ресурсларыннан файдаланып, һәм 2030 елга кадәр алтынчы торышка күчү перспективасы белән, 2020 елга бишенче торышта эшчәнлеккә актив күчүгә бәйле эшчәнлек өлкәләрендә эш белән тәэмин итәргә.

*З-2.0.0.2* Транспорт-коммуникация системасының сыйфатын арттырырга. Транспорт-коммуникация системасы пассажирларның күчеп йөри алуын тәэмин итәргә тиеш: торак һәм эшлекле районнар эчендә – 30 минут эчендә; агломерацияләрнең үзәк эшлекле районнарында (үзәкләрендә) – 0,5 – 1 сәгать эчендә; агломерациянең үзәк эшлекле районнары (үзәкләре) арасында – 1,5 – 2 сәгать эчендә; күрше регионнарның агломерацияләре үзәкләре белән – 3 – 4 сәгать эчендә; транспортның төрле төрләрендә Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре белән – 4 – 8 сәгать эчендә.

*З-2.0.0.3* Пространство белән идарә итүнең, перспектив мәгълүмат технологияләрен кулланып, яңа дәрәҗәсенә күчәргә. Идарәнең яңа системасында пространствоның барлык структур элементлары һәм барлык кызыксынучы затлар күрсәтелергә, коллектив идарә итү методлары кертелергә тиеш.




**3.7 нче рәсем. 2030 елга зоналарның яңа технологик торышларга күчеш зарурлыгы**

1 Стратегиянең база (максатчан) сценарие буенча

Пространство үсеше тотрыклы булырга тиеш. Тотрыклы (нисбәтле, табигый) үсеш кыйммәтләрен тану түбәндәгеләрне күздә тота:

• табигать ресурсларының сакланышын тәэмин итүне;

• агымдагы куллану һәм киләчәктә кулану нисбәтен;

• регион пространствосын гамәлдәге чикләрендә саклаганда структура-пространство нисбәтен (су, урманнар, кырлар, төзелгән территорияләр, иҗтимагый шартлар);

• нисбәтләрне саклау шарты белән халык, җирлекләр, берләшмәләр инициативаларын хуплауны;

• районнарның нисбәтле социаль һәм икътисадый үсеше аша территориаль килешүне һәм аларның конкурентлыкка сәләтен тәэмин итүне;

• халык урнашуының тотрыклы структурасын булдыруны һәм социаль гармония тәэмин итүне;

• транспорттан файдалана алуның нисбәтле шартларын булдыруны;

• яңа мәгълүмат чараларыннан файдалана алу мөмкинлеген үстерүне;

• иминлек, мәгариф һәм мәдәният программалары аша эчке гармониягә ирешүне;

• мәдәниятне алга җибәрүне, мәдәни мирасны тикшерү өчен һәм халыкара мәдәни үсеш өчен шартлар булдыруны;

• энергоресурсларны эшләп чыгаруның иминлеген арттыруны;

• тотрыклы эчке туризмны хуплауны;

• табигать бәла-казалары китергән зыяннарны киметүне.

Стратегик максат, тотрыклы үсеш һәм табигать ресурслары тармагындагы максатлар һәм бурычлар түбәндәгечә формалаша.

**СЦ-6** **Тотрыклы үсеш принциплары базасында табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану.**

**Ц-6.1** **Табигать ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеге.**

**Ц-6.2** **Үсешнең югары тотрыклылыгы (киләчәк буыннарның объектив ихтыяҗларыннан һәм гомумән табигатьтән чыгып, табигать ресурсларыннан нисбәтле файдалануны саклап калу).**

**Ц-6.3** **Җир ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеге.**

*З-6.0.0.1* Татарстан Республикасында табигать ресурсларыннан системалы һәм рациональ файдалануны тәэмин итәргә: булган табигать ресурслары җыелмасын ачыкларга һәм реестрны актуальләштерергә; предприятиеләрнең һәм проектларның ресурсларга ихтыяҗын ачыкларга; проектларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурсларның фаразлана торган балансын булдырырга; квартал саен ресурс базасыннан рациональ файдалану мониторингын үткәрергә.

*З-6.0.0.2* Тотрыклы үсеш системасын булдыруны һәм аның үсешен тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.3* Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметергә: табигать ресурслары белән эш итү өлкәсендә контрольлек системасын камилләштерергә; җитештерү технологияләренә экологик таләпләрнең нәтиҗәлелеген һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны арттырырга; экологик юнәлешле проектларга дәүләт ярдәмен гамәлгә ашырырга.

*З-6.0.0.4* Җирләрдән файдалануның югары нәтиҗәлелегенә ирешүне тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.5* Калдыклар белән эш итүнең комплекслы программасын эшләргә һәм аны гамәлгә ашырырга тәэмин итәргә (калдыкларны максималь дәрәҗәдә җыюны һәм тулысынча эшкәртүне оештырырга).

***Гамәлләр юнәлешләре***

1. Шәһәр агломерацияләре зонасында, кече шәһәрләрнең һәм авыл территорияләренең актив үсеш зоналарында, чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек зоналарында ресурларны һәм тырышлыкны туплау.

2. Татарстан Республикасының транспорт-коммуникация системасын үстерү:

• I һәм II техник категорияләрдәге (автотранспорт хәрәкәте өчен полосалар саны һәр якка кимендә икәү) тизйөрешле автомобиль юллары документациясен эшләү һәм шундый юлларны төзү яисә гамәлдәге автомобиль юлларын автотранспортның кимендә 100 км/сәг. тизлек белән хәрәкәт итүен тәэмин итәрлек техник категорияләргә туры китереп реконструкцияләү;

• тизйөрешле автомобиль юллары составында эре стратегик күперле кичүләр документациясен эшләү һәм аларны төзү;

• тизйөрешле һәм аеруча тизйөрешле тимер юллар документациясен эшләү һәм аларны төзү, пассажирларны тизләтелгән ташу максатыннан гамәлдәге тимер юлларны реконструкцияләү, транспортка күчеп утыру нокталарын оештыру;

• хезмәт күрсәтү мөмкинлекләрен арттыру максатыннан аэропортларны реконструкцияләү;

• җир өсте җәмәгать транспортын (шәһәр, шәһәр яны һәм шәһәр арасы) интенсив үстерү;

• барлык авыл торак пунктларын ел әйләнәсенә йөрерлек автомобиль юллары белән тоташтыру;

• транспортның альтернатив төрләрен үстерү;

3. Татарстан Республикасының логистика инфраструктурасын үстерү;

4. Калдыклар белән эш итү системасын булдыру;

5. Пространство үсеше өлкәсендә (проектлау, идарә, белем бирү һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеге) институциональ чараларны гамәлгә ашыру.

***Мөмкин булган сценарийлар***

Инерцион сценарийда кече шәһәрләрне һәм авыл торак пунктларын икътисадый яктан стимуллаштыруның өстәмә чаралары бик аз күләмдә кулланыла. Әлеге сценарийда халыкның урнашу системасындагы регресс – авыл җирлегенең дәвам итә торган депопуляциясе, эре шәһәрләрнең стихияле үсүе каралган. Агломерлашу процесслары дәвам итәчәк, ләкин, җайга салу һәм идарә булмау сәбәпле, производстволарның урнашуындагы җитешсезлекләр һәм башка функцияләр сакланып кала. Ресурсларның чикләнгән булуы торак пунктларның иҗтимагый зоналарын үстерүне, аларны төзекләндерүне һәм яшелләндерүне финанслау һәм стимуллаштыру кимегәнлектән хезмәт күрсәтүләр сыйфатының, яшәү мохите сыйфатының түбәнәю аркылы мохит сыйфаты күрсәткечләре динамикасына йогынты ясый.

База сценариенда пространствоны үсеш ноктасына беренче чиратта агломерациягә «тарту»ның дәвам итә торган процессларында республика территориясен гамәлдәге дәрәҗәсендә саклап калу мөмкинлеге карала. Муниципаль берәмлекләр сәясәте яшәү өчен әһәмиятле инфраструктураларны канәгатьләнерлек хәлдә саклап калуга һәм тотуга нигезләнә. Халыкның билгеле бер катламнарының тормыш дәрәҗәсен тигезләргә мөмкинлек бирә торган гамәлдәге программалар дәвам иттерелә.

Оптимистик сценарийда үсешне тизләтү, көчләрне һәм ресурсларны туплап, актив үсеш зоналарын аеру, муниципальара кооперация һәм күрше субъектлар белән чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек инициативаларын, сәясәтен стимуллаштыру каралган. Торак пунктлар һәм агломерацияләр арасындагы сыйфатлы тизйөрешле юллар регион чикләрендә дә, регионара дәрәҗәдә дә хезмәт миграциясенә һәм башка миграцияләргә вакытлыча чыгымнарны киметергә мөмкинлек бирә. Территория юлларында, шәһәр мохитендә актив үзгәртүләр, яңа үсеш территорияләре концепциясен булдыру һәм гамәлгә ашыру, иҗтимагый коммуникация пространстволарын арттыру һәм аларның редевелопменты (күчемсез мөлкәт объектларын



һәм территорияләрне тагын да нәтиҗәлерәк файдалану максатыннан реконструкцияләү, үзгәртеп кору) ярдәмендә республика Россиянең халыкны үзенә җәлеп итүче иң эре үзәкләренең берсе булып тора.

Татарстан Республикасы транспорт элемтәсен яхшыртуның сценар вариантлары:

• Инерцион сценарий: 2030 елга кадәрге чорда беренче чираттагы дип билгеләнгән чаралар гына гамәлгә ашырылырга мөмкин;

• База сценарие: Минимум планы чаралары гамәлгә ашырыла;

• Оптимистик сценарий: Максимум планы чаралары гамәлгә ашырыла яисә гамәлгә ашырыла башлый.

Пространство үсеше индикаторларының максатчан диапазоны 2.2 нче таблицада күрсәтелгән.

**3.2.3. Пространство үсеше чаралары**

**3.2.3.1. Икътисадый зоналар стратегиясе**

Үсеш стратегияләре өч икътисадый зона – Казан, Кама һәм Әлмәт зоналары буенча дифференциацияләшкән, бу зоналар махсуслаштырылган критерийлар нигезендә бүленгән (3.8 нче рәсем). Татарстан Республикасы икътисадый зонасы – республиканың башка зоналардан аерылган, социаль-икътисадый һәм пространство үзенчәлегенә ия булган табигый табигать һәм административ чикләрдә төзелгән өлеше. Зоналарның чикләре муниципаль берәмлекләр чикләренә туры килә. Һәр икътисадый зона составына шәһәр агломерацияләре (Казан, Кама һәм төзелеп килә торган Әлмәт агломерациясе) керә, алар үзәк муниципаль берәмлекләрдән, агломерация поясыннан һәм шәһәр агломерацияләренең барлыкка килә торган йогынты поясыннан (икътисадый зоналар пояслары) тора.




3.8 нче рәсем. Татарстан Республикасының икътисадый зоналары



Икътисадый әһәмиятләре ягыннан зоналар шактый аерылып тора (3.9 нчы рәсем).




**3.9 нчы рәсем. Икътисадый зоналар буенча Татарстан Республикасы үсеше күрсәткечләре**

***Казан икътисадый зонасы***

Казан икътисадый зонасының (КазИЗ) пространство структурасында Казан агломерациясе һәм өч ярдәмче зонадан — Кама алды, Кама аръягы һәм Идел алды ярдәмче зоналарыннан торучы Казан агломерациясенең барлыкка килә торган йогынты поясы аерылып тора. Казан икътисадый зонасына гамәлдәге һәм потенциаль актив үсеш территорияләре керә:

1) Казан шәһәр агломерациясенең актив үсеш зонасы, аңа Казан шәһәр округы һәм биш муниципаль район — Зеленодольск, Биектау, Питрәч, Лаеш һәм Югары Ослан районнары керә;

2) кече шәһәрләр һәм авыл территорияләре актив үсеш зоналары:

• Кама алды ярдәмче зонасы, аңа район үзәкләре — өченче чираттагы үсеш нокталары: Арча, Балтач, Кукмара, Байлар Сабасы һәм Теләче арасында урнашкан территория керә;

• Идел алды ярдәмче зонасы, аңа район үзәкләре — өченче чираттагы үсеш нокталары: Буа, Апас, Кама Тамагы һәм Тәтеш арасында урнашкан территория керә;

1) «Идел-Кама агымы» экозонасы кысаларында яр буе территорияләренең актив үсеш зонасы, аңа Идел елгасы буйлап урнашкан Казан агломерациясе территорияләре, шулай ук Спас, Алексеевск, Чистай, Тәтеш, Кама Тамагы, Лаеш һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары керә;

4) Казан икътисадый зонасының чик буе хезмәттәшлек итү территорияләре түбәндәгеләр:

• Көнбатышта: Марий Эл Республикасында урнашкан Волжск шәһәре белән үзара эш итә торган Казан шәһәр округы һәм Зеленодольск районы.

• Төньякта: Нократ Аланы һәм Малмыж шәһәрләре (Киров өлкәсе) белән үзара эш итә торган Кукмара һәм Балтач муниципаль районнары.

• Көньяк-көнбатышта: Чуваш Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе торак пунктлары белән үзара актив эш итүче Буа районы.

Казан икътисадый зонасының тармак структурасына химия сәнәгате (химия һәм нефть химиясе), электр энергетикасы, машина төзелеше (авиатөзелеш, судно төзелеше, электр җиһазлары эшләп чыгару), җиңел сәнәгать, авыл хуҗалыгы җитештерү комплексы, яңа төзелешләр һәм төзелеш материаллары җитештерү тармаклары керә. Югары белем бирү һәм хезмәтләр күрсәтү комплексы тупланган Казан һәм агломерация аеруча мөхим урын алып тора.

*Казан икътисадый зонасын перспектив күзаллау* — хуҗалык эшчәнлеген индустриализацияләү максат итеп куелган шәһәр агломерациясенең инновацион үсеш территорияләрен һәм барлыкка килә торган йогынты поясының авыл территорияләрен туплау пространствосы (3.10 нчы рәсем). Казан икътисадый зонасы — «акыллы» икътисадның үсеш территориясе. Пространство үсеше бишенче торышка һәм перспективада алтынчы торышка күчүне хуплауга юнәлдерелгән.





3.10 нчы рәсем. Казан икътисадый зонасының пространство үсеше

Казанның һәм аның яңа иярченнәре Иннополисның һәм СМАРТ Сити Казанның киләчәктәге функцияләре түбәндәгеләр:

• алдынгы университет үзәге һәм дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни-тикшеренү үзәге;

• глобаль конкурентлыкка сәләтле мәгълүмат-технология полюсы;

• «Идел — Кама» үсеш полюсының финанс үзәге;

• транспорт-логистика хабы.

Казан икътисадый зонасы районнары буенча тармак структурасы динамикасы перспективалары 3.11 нче рәсемдә күрсәтелгән.

| МО | Зона | НГХК | ЭК | МК | АПК | СК | ЖКХ | ТоргК | ФК | ТЛК | ИКК | НОК |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Казань | Центр Казанской агломерации | +++ | + | +++ | + | ++ | + | + | ++ | ++ | | |
| Зеленодольский | Пояс Казанской агломерации | | + | ++ | + | | | +++(2) | +(2) | +++(2) | | |
| Лаишевский | Пояс Казанской агломерации | | | +++(1,3) | | | ++(1,3) | ++(1,3) | ++(3) | ++(1,3) | +++(3) | 3 |
| Пестречинский | Пояс Казанской агломерации | | | | | | | | | | | |
| Верхнеуслонский | Пояс Казанской агломерации | | | ++(1) | | + | ++(1) | ++(1) | +(1) | +(1) | +++(1) | ++(1) |
| Высокогорский | Пояс Казанской агломерации | | | | + | | | | | | | |
| Апастовский | Предволжская подзона | | | | + | ++ | | | | | | |
| Буинский | Предволжская подзона | | | | | ++ | | | | | | |
| Дрожжановский | Предволжская подзона | | | | | | | | | | | |
| Кайбицкий | Предволжская подзона | | | | | | | | | | | |
| Камско-Устьинский | Предволжская подзона | | | | | ++ | | | | | | |
| Тетюшский | Предволжская подзона | | | | | ++ | | | | | | |
| Арский | Предкамская подзона | | | | + | | | | | | | |
| Атнинский | Предкамская подзона | | | | | | | | | | | |
| Балтасинский | Предкамская подзона | | | | | | | | | | | |
| Кукморский | Предкамская подзона | | | | + | ++ | | | | | | |
| Мамадышский | Предкамская подзона | | | | | + | | | | | | |
| Рыбно-Слободский | Предкамская подзона | | | | | | | | | | | |
| Сабинский | Предкамская подзона | | | | ++ | | | | | | | |
| Тюлячинский | Предкамская подзона | | | | | | | | | | | |
| Алексеевский | Закамская подзона | | | | | | | | | | | |
| Алькеевский | Закамская подзона | | | | | | | | | | | |
| Спасский | Закамская подзона | | | | | | | | | | | |
| Чистопольский | Закамская подзона | | | ++ | | + | | | | | | |

НГХК – Нефтегазохимический комплекс
ЭК – Энергетический комплекс
МК – Машиностроительный комплекс
АПК – Агропромышленный комплекс
СК – Строительный комплекс
ЖКХ – Комплекс жилищно-коммунального хозяйства

ТоргК – Торговый комплекс
ФК – Финансовый комплекс
ТЛК – Транспортно-логистический комплекс
ИКК – Информационно-коммуникационный комплекс
НОК – Научно-образовательный комплекс

Проекты развития:
+ - небольшие проекты развития
++ - крупные отраслевые проекты развития
+++ - глобальные проекты / интенсивный рост отраслей

(1) – влияние проекта «Иннополис»
(2) – влияние проекта «Свияжский межрегиональный мультимодальный логистический центр»
(3) – влияние проекта «СМАРТ Сити Казань»

Источник: Паспорта МО, Инвестиционный меморандум, аналитика AV

Текущий уровень развития и значимость комплекса для МО: Оч. низкий / Низкий / Средний / Высокий

**3.11 нче рәсем. Казан икътисадый зонасы үсешенең тармак өстенлекләре**

***Кама икътисадый зонасы***

Кама икътисадый зонасының (КамИЗ) пространство структурасы Кама агломерациясеннән һәм Кама агломерациясенең барлыкка килә торган йогынты поясыннан гыйбарәт.

Кама икътисадый зонасы өч актив үсеш зонасына бүленә:

• Кама шәһәр агломерациясенең актив үсеш зонасы, аңа Алабуга, Менделеевск, Тукай, Түбән Кама районнары һәм «Чаллы» шәһәр округы керә. Киләчәктә агломерация процессларында Минзәлә, Мамадыш шәһәрләре һәм Зәй муниципаль районнары катнашачак.



• «Идел-Кама агымы» экозонасы кысаларында яр буе территорияләренең актив үсеш зонасы, аңа Актаныш, Минзәлә, Әгерже, Алабуга, Менделеевск, Тукай, Түбән Кама районнары һәм «Чаллы» шәһәр округы территорияләре керә.

• Чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек зоналарына Удмурт Республикасының күрше районнары белән үзара актив эш итүче Әгерже муниципаль районы кертелгән.

Кама икътисадый зонасы түбәндәге тармаклар буенча махсуслаша: нефть химиясе һәм химия сәнәгате, автомобиль төзелеше, электр техникасы җитештерү, агросәнәгать комплексы.

*Кама икътисадый зонасын перспектив күзаллау* — «Идел — Кама» үсеш полюсының сәнәгать-технология үсеше лидеры, «яңа индустриализация» һәм югары технологияләр үсеше территориясе. (3.12 нче рәсем).



3.12 нче рәсем. Кама икътисадый зонасының пространство үсеше



Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры кысаларында үсеп килүче машина төзелеше һәм нефть химиясе сәнәгате базасында яңа индустриаль проектлар булдырылачак. Кама икътисадый зонасының пространство үсеше, күпкатлы корылмалар тыгызлыгын арттырып, тормыш эшчәнлеге мохитенең экологик характеристикаларын, төзелгән территорияләрне авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр исәбеннән киңәйтмичә, тамырдан яхшыртып, бишенче технологик торышка күчүгә юнәлдерелгән.

Кама икътисадый зонасы районнары буенча тармак структурасы динамикасы перспективалары 3.13 нче рәсемдә күрсәтелгән.

| МО | НГХК | ЭК | МК | АПК | СК | ЖКХ | ТоргК | ФК | ТЛК | ИКК | НОК |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Агрызский | | | | ↗ | | | ↗ | | | | |
| Актанышский | ◆ | | ◆ | ++ ↗ | ◆ | | ↗ | | | | |
| Елабужский | ++(1) ↗ | | +++(1) ↗ | ++(1) ↗ | +(1) ↗ | +(1) ↗ | +(1) ↗ | | +(1) ↗ | | |
| Заинский | ↗ | + ↗ | ↗ | + ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | | ↗ | | |
| Менделеевский | +++ ↗ | + ↗ | ◆ | ↗ | | ↗ | ↗ | | ↗ | | |
| Мензелинский | | | | ◆ | ◆ | | ↗ | | | | |
| Муслюмовский | | | ◆ | ↗ | | | ↗ | | | | |
| Нижнекамский | +++ ↗ | ++ ↗ | ↗ | ◆ | + ↗ | + ↗ | ↗ | | ↗ | ◆ | ↗ |
| Тукаевский | ◆ | | ↗ | ++ ↗ | | ↗ | ↗ | | ↗ | | |
| Набережные Челны | | ++ ↗ | +++ ↗ | ++ ◆ | ++ ↗ | + ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ↗ |

Пространство, занимаемое комплексом: ↗ - будет расти, ↘ - будет сокращаться, ◆ - останется стабильным

**Названия экономических комплексов:**
НГХК – Нефтегазохимический комплекс
ЭК – Энергетический комплекс
МК – Машиностроительный комплекс
АПК – Агропромышленный комплекс
СК – Строительный комплекс
ЖКХ – Комплекс жилищно-коммунального хозяйства
ТоргК – Торговый комплекс
ФК – Финансовый комплекс
ТЛК – Транспортно-логистический комплекс
ИКК – Информационно-коммуникационный комплекс
НОК – Научно-образовательный комплекс

**Проекты развития:**
+ - небольшие проекты развития
++ - крупные отраслевые проекты развития
+++ - глобальные проекты / интенсивный рост отраслей

(1) – влияние ОЭЗ ППТ «Алабуга»

Источник: Паспорта МО, Инвестиционный меморандум, аналитика AV

Текущий уровень развития и значимость комплекса для МО: Оч. низкий, Низкий, Средний, Высокий

3.13 нче рәсем. Кама икътисадый зонасы үсешенең тармак өстенлекләре

***Әлмәт икътисадый зонасы***

Әлмәт икътисадый зонасының (ӘлмИЗ) пространство структурасы Әлмәт агломерациясеннән һәм Әлмәт агломерациясенең барлыкка килә торган йогынты поясыннан гыйбарәт. Әлмәт шәһәр агломерациясен булдыру процессында бүгенге көндә өч чиктәш муниципаль район: Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә районнары, шулай ук бераз Азнакай районы катнаша.

Чирмешән, Нурлат, Аксубай, Яңа Чишмә муниципаль районнары һәм Сарман муниципаль районының зур өлеше башлыча

аграр индустрия үсеше территорияләре булып тора. Алар арасында потенциаль актив үсеш территориясе билгеләнгән («Кече шәһәрләрнең һәм авыл территорияләренең Кама аръягы актив үсеш зонасы»), аңа Нурлат шәһәре һәм Аксубай шәһәр тибындагы поселогы керә, аларны үзара күптәнге икътисадый элемтәләр бәйли.

Чик буенда урнашкан Ютазы һәм Баулы муниципаль районнары, территорияләреннән федераль транспорт юллары (Ульяновск – Уфа тимер юлы һәм федераль әһәмияттәге М-5, Р-239 автомобиль юллары) үткәнгә күрә, Татарстан Республикасы белән күрше регионнар – Башкортостан Республикасы һәм Оренбург өлкәсе арасында үзара актив эшчәнлек итү зонасы булып торалар. Мондый пространство урнашуы әлеге районнар өчен чик буе территорияләрендә социаль-икътисадый хезмәттәшлек өчен өстенлекләр тудыра. Санкт-Петербург – Татарстан – Казахстан – Көнбатыш Кытай юнәлешендә яңа халыкара автомобиль магистрален төзү планын исәпкә алып, Баулы һәм Ютазы районнары халыкара дәрәҗәдәге эре транспорт-логистика комплекслары һәм инвестицияләр, бизнес үсеше өчен стратегик мәйданчыклар урнаштыру өчен потенциаль претендентлар булып тора.

Самара өлкәсе белән шундый ук бурычны Нурлат шәһәре башкара, ул киләчәктә, өч регион арасында мөһим транспорт үзәге буларак, Татарстан Республикасы, Самара һәм Ульяновск өлкәләре арасында чик буе территорияләрендә хезмәттәшлек итү буенча актив агент булачак.

Әлмәт икътисадый зонасы түбәндәге тармаклар буенча махсуслаша: нефть чыгару һәм иярчен газ чыгару, нефть җайланмалары һәм башка җайланмалар җитештерү, агросәнәгать комплексы, төзелеш материаллар җитештерү.

*Әлмәт икътисадый зонасын перспектив күзаллау* – нефть чыгару һәм аны тулысынча эшкәртүгә күчү өлкәсендә югары технологияләрне үстерү, эшчәнлекнең авыл хуҗалыгы төрләрен индустриализацияләү нигезендә икътисадны диверсификацияләү, нефть, газ комплексын модернизацияләү территориясе (3.14 нче рәсем).






3.14 нче рәсем. Әлмәт икътисадый зонасының пространство үсеше

Әлмәт икътисадый зонасының пространство үсеше Әлмәт агломерациясен һәм чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек зоналарын үстерүгә, мохит сыйфатын үзгәртү һәм үзлектән үсеш потенциалын активлаштыру исәбеннән кече шәһәрләренең һәм авыл торак пунктларының җәлеп итүчәнлеген арттыруга басым ясап, әлеге территориянең Татарстанның «көнчыгыш капкасы» рәвешендә эшләвен тәэмин итәрлек күпторышлы диверсификацияләнгән икътисадка юнәлдерелгән.

Әлмәт икътисадый зонасы районнары буенча тармак структурасы динамикасы перспективалары 3.15 нче рәсемдә күрсәтелгән.

| МО | НГХК | ЭК | МК | АПК | СК | ЖКХ | ТоргК | ФК | ТЛК | ИКК | НОК |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Азнакаевский | ++(1) ↗ | + ↗ | ↗ | ++ ◆ | ↗ | + ↗ | ↗ | | | | |
| Альметьевский | ++(1) ↗ | + ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ◆ | ↗ |
| Бавлинский | ++(1) ↗ | | | + ↘ | | + ↗ | ↗ | | ↗ | | |
| Бугульминский | ++(1) ↗ | + ↗ | + ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | ↗ | | ↗ | | |
| Лениногорский | ++(1) ↗ | + ↗ | ++ ↗ | ↗ | ↗ | + ↗ | ↗ | | ↗ | | ↗ |
| Сармановский | ++(1) ↗ | | | ++ ↗ | | ↗ | ↗ | | | | ↗ |
| Черемшанский | ++(1) ↗ | | | ↗ | | ↗ | ↗ | | ↗ | | |
| Ютазинский | ++(1) ↗ | | ↗ | ↗ | | ↗ | ↗ | | | | |
| Аксубаевский | | | | | | | | | + | | |
| Новошешминский | | | | | | | | | | | |
| Нурлатский | ++(1) ↗ | | | | | | | | | | |

Пространство, занимаемое комплексом: ↗ - будет расти, ↘ - будет сокращаться, ◆ - останется стабильным

Названия экономических комплексов:
НГХК – Нефтегазохимический комплекс
ЭК – Энергетический комплекс
МК – Машиностроительный комплекс
АПК – Агропромышленный комплекс
СК – Строительный комплекс
ЖКХ – Комплекс жилищно-коммунального хозяйства
ТоргК – Торговый комплекс
ФК – Финансовый комплекс
ТЛК – Транспортно-логистический комплекс
ИКК – Информационно-коммуникационный комплекс
НОК – Научно-образовательный комплекс

Проекты развития:
+ - небольшие проекты развития
++ - крупные отраслевые проекты развития
+++ - глобальные проекты / интенсивный рост отраслей

(1) – освоение новых месторождений, необходима экспертиза

Источник: Паспорта МО, Инвестиционный меморандум, аналитика AV

Текущий уровень развития и значимость комплекса для МО: Оч. низкий | Низкий | Средний | Высокий

**3.15 нче рәсем. Әлмәт икътисадый зонасы үсешенең тармак өстенлекләре**

### 3.2.3.2. Агломерацияләрнең стратегияләре

***Казан агломерациясе***

Казан агломерациясе — Казан һәм Зеленодольск шәһәрләрен үз эченә алган бер үзәкле постиндустриаль агломерация. Агломерация процессларына төп коммуникация үзәге Казаннан транспорт белән бер сәгать эчендә барып җитү мөмкинлеге булган Зеленодольск, Биектау, Питрәч, Лаеш, Югары Ослан муниципаль районнары торак пунктлары, шулай ук Волжск шәһәре (Марий Эл Республикасы) җәлеп ителгән (3.16 нчы рәсем). 2014 елның



1 гыйнварына халыкның гомуми саны 1 478 мең кешене тәшкил итә. Халыкның урнашу тыгызлыгы — 177 кеше/га.

Агломерациянең төп проблемалары пространство үсешендәге һәм коммуникацион үзәкнең, шәһәр яны территорияләренең һәм периферияләге районнарның үзара урнашуындагы диспропорциягә бәйле:

• Казанның шәһәр яны территорияләре һәм агломерация процессларында катнаша торган районнар белән элемтәсен тәэмин итүче транспорт инфраструктурасының мөмкинлекләре арта баручы транспорт йөкләнешләренә туры килмәү;

• агломерациянең уң һәм сул ярлары арасында элемтә начар; Идел аша бары тик бер генә автомобиль күпере булу;

• гамәлдәге инженерлык инфрастуктурасы объектларының тузуы һәм аларга нагрузканың артык күп булуы;

• Казанның шәһәр яны территорияләре стихияле үсү, хуҗалык эшчәнлеге аз булу.



3.16 нчы рәсем. Казан агломерациясенең пространство үсеше



*Үзгәртеп кору юнәлешләре:*

• агломерациянең тизйөрешле юллар, Казан шәһәрен урап уза торган яңа автомобиль юлы һәм тимер юл төзүне, шулай ук Гребени авылы янында Идел аша стратегик күпер салуны үз эченә алучы тотрыклы структура барлыкка китерә торган транспорт каркасын булдыру (Казан шәһәреннән көньяктарак Идел аша күпер салу Лаеш районы үсешенә ярдәм итәчәк; Иделнең уң ярында урнашкан Югары Ослан муниципаль районы агломерация процессларына актив кушылып китәчәк; әлеге территорияне үзләштерүнең мөһим шарты аның экосистемасын саклап калудан гыйбарәт, бу – «яшел» технологияләр куллану, аз һәм уртача катлы торак төзү, рекреацион һәм ял итү функцияләрен үстерү дигән сүз);

• инженерлык инфраструктурасын үстерү һәм модернизацияләү;

• шәһәр яны зоналарында хуҗалык эшчәнлеген тәртипкә салу;

• сәнәгать зоналары редевелопменты;

• Иделнең һәм кечкенә елгаларның су буе территорияләрен саклап калу һәм төзекләндерү;

• Казан шәһәренең иярчен җирлекләре редевелопменты, селитеб төзелешне арттыру.

*Эшләү һәм гамәлгә ашыру күздә тотыла торган программалар*

• **«Урнашу реновациясе»**:

Казан шәһәренең иярчен җирлекләрендә гамәлдәге торак пунктларны модернизацияләү һәм инфраструктураның барлык төрләрен үстерү юлы белән торак төзелешен арттыру; Казан шәһәре чикләрен консервацияләү;

файдаланылмый торган сәнәгать территорияләрен һәм коммуналь территорияләрне (Казан шәһәренең Идел буе районы сәнәгать мәйданчыкларын, иске аэропорт районын, Республика клиник хастаханәсе районын, Урта Кабан яр буе зонасын) torакның яңа төрләре өчен реновацияләү;

төзелгән территорияләрне комплекслы тыгызлауның потенциаль зоналарын анализлау; «сирәк» торак төзелгән территорияләрне («Зур Крыловка», Калуга –Әмәт, Әмәт һ.б. районнары) тыгызлау;

Казан шәһәре үзәгеннән алып Юдино поселогына кадәр Идел елгасының яр буе территорияләрен – Дары заводы, Бишбалта территорияләрен үзләштерү;

торак белән тәэмин итү дәрәҗәсе бер кешегә 25 кв. м исәбеннән эконом класслы массакүләм төзелеш районнарын проектлау.

• **«Казан агломерациясенең инженерлык инфраструктурсын үстерү һәм модернизацияләү»**. Гамәлдәге нык тузган инженерлык инфраструктурасы объектларын реконструкцияләү, гамәлдәгеләрен модернизацияләү, шулай ук, фаразлана торган халык санын исәпкә алып, яңа коммуналь корылмалар өчен урын сайлау һәм аларны төзү. Инженерлык системаларының нәтиҗәлелеген арттыру: кулланучыларның артуына карамастан, энергия һәм су ресурсларын куллану дәрәҗәсе 2030 елга шул ук дәрәҗәдә калырга тиеш.

• **«Казанның шәһәр яны зонасы»**. Шәһәр яны территорияләрендә транспорт челтәрен киләчәктә халыкны Казан шәһәреннән көньяк һәм көнчыгыш юнәлешләрдә Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап күчерү челтәрен арттыруны исәпкә алып үстерү. Рекреацион поселоклар үсешен мониторинглау һәм, территорияләрне капитализацияләү процессларын сыйфатлырак җайга салу максатларында, аларга махсус статуслар бирү.

• **«Сәнәгать зоналары редевелопменты»**. Шәһәр төзелеше кыймммәте югары булган шәһәр территорияләрендә җитештерү зоналарыннан файдалануны үзгәртү. Мондый мәйданчыкларга инвентаризация үткәрү, милекчеләр белән үзара эш итү сәясәте, шәһәр төзелеше активларын яңадан бәяләү, барлыкка килгән шәһәр мохите контекстында бу мәйданчыкларны үстерү концепцияләренә конкурс эшләнмәләре.

• **«Казан яр буйлары»**. Идел елгасының һәм кече елгаларның яр буе территорияләрен саклап калу һәм төзекләндерү, халыкның тулысынча файдалана алуын тәэмин итеп, рекреация зоналары булдыру. Агломерациянең актив үзәгенең тоташ су-яшеллек каркасын булдыру мохитнең сыйфатын арттырырга, даими яшәүчеләр өчен һәм күбәя баручы күчеп килүчеләр өчен шәһәр территорияләренең җәлеп итүчәнлеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк. «Яшел артерияләр» эре шәһәрдә «якорь» эффекты тудыра һәм шәһәрләшкән территорияләрдә артып баручы экологик йөкләнешне киметергә мөмкинлек бирә. Елга буе ландшафтларын шәһәр пространстволары системасына актив кертү аралашу, ял итү һәм тернәкләнү өчен яңа мөмкинлекләр ача.

• транспорт системасын үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасына өстәмә — **«Казан агломерациясенең транспорт инфраструктурасын үстерү»** агломерациянең тизйөрешле элемтәләрен үстерүне, Казан шәһәрен урап уза торган яңа автомобиль юлы һәм йөк тимер юлы салуны, Гребени авылы янында Идел аша стратегик күпер салуны, метроны һәм җиңел рельслы транспортны актив арттырып, җәмәгать транспортын һәм тиешле инфраструктураны төрле чаралар ярдәмендә алга җибәрүне үз эченә алган тотрыклы структура барлыкка китерүче транспорт каркасын булдыру.



*Казан агломерациясенең пространство моделе*

Казан шәһәренең фән-белем, инновация һәм финанс үзәге буларак әйдәп баручы роле төп магистральләрнең радиаль элемтәләре белән ныгытыла. Төп үзәк поясында урнашкан иярчен җирлекләр агломерациянең күп функцияле структурасын формалаштыралар: бердәм функциональ бәйләнешле пространство барлыкка килә. Кайбер функцияләрне (җитештерү, күңел ачу, куллану) гамәлгә ашыру өлешчә үзәктән иярчен җирлекләргә күчерелә. Шәһәр яны районнары цивилизацияле үсәчәк, агломерациянең бердәм хезмәт базары барлыкка килә. Агломерация регион һәм дөнья икътисадының пространство структурасында мөһим үзәк булып тора.

***Кама агломерациясе***

Кама агломерациясе — күп үзәкле агломерация, ул дүрт урбанизация үзәгеннән: Чаллы, Түбән Кама, Алабуга һәм Менделеевск шәһәрләреннән барлыкка килә (3.17 нче рәсем). Агломерация процессларына Алабуга, Менделеевск, Тукай, Түбән Кама муниципаль районнарының бер-берсеннән транспорт белән бер сәгать эчендә барып җитү мөмкинлеге булган чикләрдә урнашкан торак пунктлары җәлеп ителә. 2014 елның 1 гыйнварына халыкның гомуми саны 944,3 мең кеше тәшкил итә. Халыкның урнашу тыгызлыгы — 165 кеше/га.

*Агломерациянең төп проблемалары*:

• шәһәрләрнең бер генә өлкәдә махсуслашкан булуы;

• агломерациянең транспорт каркасы тотрыксыз булу: Кама елгасының уң һәм сул ярларында урнашкан үзәкләр арасында элемтәнең начар булуы, транспорт инфраструктурасының үсеше җитештерү үсешеннән артта калу;

• Түбән Кама һәм Менделеевск шәһәрләрендә нефть эшкәртү һәм химия производстволары эшчәнлеге аркасында имин булмаган экологик хәл;

• агломерациянең үзәк шәһәрләре чикләрендә биләнмәгән җир ресурслары җитәрлек булмау, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә пространство экспансиясе;

• шәһәр мохитенең бертөрлелеге һәм көпшәк булуы, деформацияләнгән шәһәр пространстволары.




3.17 нче рәсем. Кама агломерациясенең пространство үсеше



*Үзгәртеп кору юнәлешләре*:

• агломерациянең үзәк шәһәрләре махсуслашуын трансформацияләү һәм диверсификацияләү, хезмәттәшлектән синергетик эффектны арттыру;

• агломерациянең үзәк шәһәрләре үзенчәлеген арттыру;

• агломерациянең тотрыклы структура барлыкка китерә торган транспорт каркасын булдыру, моңа тизйөрешле юлларны арттыру һәм Соколка авылы тирәсендә (озак сроклы перспективада) һәм Алабуга шәһәрендә стратегик күперләр төзү дә керә;

• агломерация шәһәрләрен гамәлдәге урбанизация территорияләре чикләрендә интенсив үстерү, табигать ландшафтларын һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне максималь саклап калу;

• сәнәгать предприятиеләренең санитар-саклык территорияләрендә тыгыз һәм бәйләнешле шәһәр мохите барлыкка китерүгә юнәлдерелгән девелопмент (территорияне үстерүгә һәм җирләрне, объектларны яңадан файдалану максатыннан әзерләүгә бәйле эшчәнлек).

*Эшләү һәм гамәлгә ашыру күздә тотыла торган программалар һәм проектлар*:

• **«Реновация / акыллы тыгызлык»**. Чаллы, Түбән Кама, шулай ук өлешчә Алабуга, Менделеевск шәһәрләренә һәм Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогына хас типовой микрорайоннарга бүленеп, 1970 – 1990 елларда торак йортлар төзелгән территорияләрне сыйфатлы үзгәртеп коруны башлап җибәрү.

• **«Шәһәр һәм ландшафтлар»**. Агломерациянең үзәк шәһәрләрендә шәһәр мохитен җирле ландшафтларның төп кыйммәтенә – Кама елгасы ярларына таба җәелдерү. Шәһәрнең актив һәм һәркем файдалана ала торган су фронтын булдыру, ул, бер яктан, Кама буенча су транспортында узучы пассажирларга шәһәрнең үзенчәлеген күрергә мөмкинлек тудырачак, икенче яктан, шәһәр җәмәгать траснпорты челтәренә кушылып, шәһәр мохитендә үз урынын алачак.

• **«Шәһәр һәм сәнәгать»**:

чистартылган җитештерү мәйданчыкларын яңадан файдалану;

кими баручы санитар-саклык зоналарын яңадан файдалану;

шәһәр халкын һәм эре предприятиеләрне үзара бәйләүче шәһәр мәдәни мәйданчыклары һәм программалары булдыру (шәһәр иҗтимагый пространстволары, өстәмә белем бирү функциясен, туристлар, яшьләр өчен заводларга экскурсияләрне үз эченә алган мәдәният үзәкләре һ.б.).

• **«Шәһәр һәм мирас».** Тарихи төзелеш объектларын мохитне күздә тотып саклап калу һәм капитализацияләү программасы. Тарихи шәһәр территориясендә урнашкан җир кишәрлекләреннән яисә йортлардан, милектәге яисә арендага алынган тарихи биналарга сакчыл карау шарты белән, хезмәт күрсәтү һәм сәүдә бизнесы өчен файдалана торган бу җир кишәрлекләренең һәм йортларның милекчеләренә ярдәм итү механизмын куллану. Идарәчеләрнең, архитекторларның һәм дизайнерларның тарихи контекс мохитендә эшләү культурасын арттыру чаралары.

• **«АлаБег»**[1]. «АлаБег» проекты – Кама агломерациясенең тизйөрешле транспорт каркасы структурасын барлыкка китерә торган элементы, ул шәһәрләр арасындагы элемтәләрне ныгытырга, хезмәт корреспонденциясе, эшлекле һәм мәдәни корреспонденцияләр агымын арттырырга, агломерация шәһәрләренең, «Алабуга» махсус икътисадый зонасының һәм «Бигеш» аэропортының турыдан-туры эшчәнлеген җиңеләйтергә мөмкинлек бирәчәк (3.18 нче рәсем). Проект киләчәктә Алабуга шәһәренең шәһәр ипподромы тирәсендә Кама елгасы аша күпер салуны күздә тота. «АлаБег» транспорт проекты гына түгел: аның базасында агломерация масштабларында һәм өлешчә региональ масштабта планлаштырыла торган ике яңа үсеш күчәре төзелергә мөмкин, аларда яңа эшлекле активлык тупланачак. Химия предприятиеләреннән бүленеп чыккан зарарлы матдәләрдән чистарту буенча «Идел-Кама агымы» программасында каралган чаралар белән беррәттән, «АлаБег» Түбән Кама һәм Чаллы арасында торак пунклар үсешенә һәм яңа торак төзелешенә этәргеч бирәчәк (Прости һәм Бәтке авыллары). «АлаБег» шулай ук Алабуга шәһәренең көнбатышында торак һәм сәнәгать районнарын активлаштырырга сәләтле булачак. Яңа девелопмент мәйданчыкларын урнаштыру зонасында проектның барлык үсеш үзәкләре арасында яшел коридорлар булдыру юлы белән табигать һәм шәһәр ландшафтлары арасындагы нисбәтне саклап калу мөһим. Яңа күпер районындагы ландшафтларны саклауга аеруча зур игътибар бирергә кирәк.





3.18 нче рәсем. «АлаБег» селитеб-җитештерү экокоридоры

*Кама агломерациясенең пространство моделе*

Агломерация моделе пространство каркасының нигезе булып торучы табигать күчәренә – Кама елгасына карата формалаштырыла. Кама елгасы аша күпер кичүләре булган транспорт коридорлары каркасның тотрыклылыгын тәэмин итәчәк. Транспорт системалары интеграциясе, үзәк шәһәрләр синергиясе агломерациянең пространство позициясен ныгыта, аларның һәрберсенең үз образы һәм хуҗалык үзенчәлеге бар. «Шәһәр – су» мөнәсәбәтләре Кама агломерациясе пространствосының җәлеп итүчәнлеген һәм пространство элемтәсен тәэмин итүче төп элемент булып тора.

***Әлмәт агломерациясе***

Әлмәт агломерациясе – өч үзәк: Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск шәһәрләре ярдәмендә формалаша торган күп үзәкле агломерация. (3.19 нчы рәсем). Агломерация процессларына Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск муниципаль районнарының бер-берсеннән транспорт белән бер сәгать эчендә барып җиту мөмкинлеге булган чикләрдә урнашкан торак пунктлары җәлеп ителә. 2014 елның 1 гыйнварына халыкның гомуми саны 337 мең кешене тәшкил итә. Халыкның урнашу тыгызлыгы – 71 кеше/га.

*Агломерациянең төп проблемалары*:

• чикләрне киңәйтү һәм агломерациянең үзәк шәһәрләрен үстерү мөмкинлегенең чикле булуы;

• гамәлдәге автомобиль юллары челтәренең мөмкинлекләре түбән булу;

• агломерациядә «масштаблы вакыйгаларның» аз булуы;

• ял итү һәм мәдәният объектларының агломерация шәһәрләре арасында тигез бүленмәве: төп объектларның Әлмәт шәһәрендә тупланулы;

• бурычлар билгеләү, программалар кабул итү һәм комплекслы инфраструктура проектларын гамәлгә ашыру өчен муниципальара кооперация механизмы булмау.

*Үзгәртеп кору юнәлешәре*:

• Әлмәт, Бөгелмә һәм Лениногорск шәһәрләренең иярчен җирлекләрендә территорияләр редевелопментын үз эченә алган селитеб төзелешне үстерү;

• Әлмәт агломерациясендә автомбуслар ярдәмендә бердәм транспорт системасын булдыру: җәмәгать транспортының агломерациянең үзәк шәһәрләрен, иярчен җирлекләрен һәм авыл торак пунктларын үз эченә ала торган бердәм челтәрен булдыру;

• агломерациянең төп шәһәрләрендә, муниципальара мәйданчыкларда коммуникация үзәкләре булдыру һәм аларны үстерү;

• спортның һәм туризмның комплекслы инфраструктурасын булдыру.






3.19 нчы рәсем. Әлмәт агломерациясенең пространство үсеше

*Эшләү һәм гамәлгә ашыру күздә тотыла торган программалар һәм проектлар:*

• **«Татарстанның көнчыгыш капкасы»**. Татарстан Республикасына көнчыгыштан киләчәктә «Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара автомобиль юлы белән килергә мөмкин булачак, Әлмәт агломерациясе халыкара дәрәҗәдәге транспорт-логистика үзәге буларак актив үсәчәк. Мондый функцияләрнең артуы яңа инвестицион мәйданчыклар оештырырга, эш урыннары булдырырга, халыкара хезмәттәшлекне интенсификацияләргә һәм сыйфатлы хезмәт ресурсларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

• **«Көнчыгыш меридиан»**. Транспорт, логистика, ял итү һәм сервис инфраструктурасы үстерелергә тиешле магистральләр буенда урнашкан торак пунктларны үз эченә алган янәшәдәге территорияләрне үстереп, Бөгелмә – Әлмәт – Чаллы юнәлеше буенча транспорт инфраструктурасын модернизацияләү. Кама һәм Әлмәт агломерацияләренең төп үзәкләре Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама һәм Бөгелмә шәһәрләренең йогынты зоналарын арттыру ерак киләчәктә халыкны күчертеп утыртуның яисә конурбациянең бердәй поясын барлыкка китерәчәк. Мондый бердәмлекне оештыруның нигезе Әлмәт һәм Чаллы шәһәрләре арасында транспорт-коммуникация элемтәсеннән һәм энергоҗитештерү циклы базасында үзара бәйләнешле технологияләрдән һәм социомәдәни коммуникацияләрдән гыйбарәт.

• **«Халыкны күчереп утырту реновациясе»**. Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск шәһәрләренең иярчен җирлекләрендә селитеб төзелешне үстерү, моңа кими баручы кече шәһәрләрне һәм авыл җирлекләрен алга таба яңартып, территорияләр редевелопменты да керә.

• **«Әлмәт агломерациясенең иҗтимагый пространствосы»**. Ял итү һәм мәдәният объектларының агломерация шәһәрләре арасында тигез бүленеше, агломерациянең төп шәһәрләрендә дә, муниципальара мәйданчыкларда да коммуникация үзәкләре булдыру һәм аларны үстерү. Ял һәм коммуникация пространстволарының территориаль диверсификациясе яшәү тирәлегенең күптөрлелеген һәм сыйфатын арттырырга ярдәм итәчәк, бу әлеге территорияләрдәге халыкның тормыш дәрәҗәсен әкренләп тигезләргә мөмкинлек бирәчәк, халыкның үз урынын табу өчен мөмкинлекләр, яшьләрнең уңайлырак инфраструктуралы шәһәрләргә күчеп китүенә каршылык тудырачак.

• **«Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгыш зонасында туристлык инфраструктурасы»**. Татарстан Республикасының бердәй туристлык-рекреацион системасының бер өлеше һәм Әлмәт икътисадый зонасының, агломерация икътисадының перспективалы юнәлешләренең берсе буларак карала торган региональ әһәмияттәге туристлык комплексын булган ресурслар базасында үстерү. Туризмның перспективалы төрләре – рекреацион-савыктыру, спорт, туган як тарихы, этнографик, экологик, сәнәгый һәм агротуризм – тиешле инфраструктураларга ихтыяҗ тудыра. Программа халыкка туристлык индустриясендә хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекнең яңа төрләрен булдырырга, традицион (милли) кәсепләр һәм һөнәрләр базасында кече эшкуарлыкны үстерергә ярдәм итәчәк.

• Транспорт системасын үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасына өстәмә – **«Автобус нигезендә Әлмәт агломерациясенең бердәй транспорт системасын булдыру»**.

*Әлмәт агломерациясенең пространство моделе*

Агломерация структурасына линия-үзәк сыйфатлар хас. Төзелеп килә торган Әлмәт агломерациясенең пространство каркасы «Европа – Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт коридорыннан һәм Пермь – Ижевск – Чаллы – Әлмәт – Көнбатыш Казахстан юнәлешендәге регионара транспорт коридорыннан гыйбарәт.

Шәһәрләрнең тармаклар буенча махсуслашуындагы бердәйлек һәм аларның күпкомпонентлы булуы үзәкләрнең функциональ яктан бертигез булуын һәм бер-берсен тулыландыруын билгели.

### *3.2.3.3. Авыл территорияләрен үстерү*

Авыл территорияләре дигәндә әлеге Стартегия максатларында авыл торак пунктларын һәм аларның әйләнә-тирәсендәге территорияләрне үз эченә алган, шәһәрләрдән читтәге территорияләр аңлашыла. Татарстан Республикасы халыкны күчерү системасын оптимизацияләү авыл территорияләрен саклап калуны һәм авыл халкының тормыш сыйфатын яхшыртуны күздә тота.

*Проблемалар:*

• урбанизация процессларын дәүләт тарафыннан җайга салу механизмнары булмау;

• авыл хуҗалыгын индустриальләштерү проектларын комплекссыз гамәлгә ашыру;

• муниципаль районнар арасында территориаль планлаштыру схемаларының җайга салынмавы һәм үзара ярашмавы;

• муниципаль-территориаль бүленешнең һәрвакытта да рациональ булмавы: Казан тирәсендә, Кама һәм Әлмәт агломерацияләрендә урнашкан авыл торак пунктлары еш кына шәһәрләрнең ерактагы районнары буларак кабул ителә; алар икътисадының 90 проценттан артыгы эре шәһәрләр икътисады тарафыннан «йотыла»;

• авыл яшьләрен социаль-мәдәни һәм ял хезмәтләре белән тәэмин итүдә җитди асимметрия булу (иң беренче чиратта, мондый хезмәтләр күрсәтелмәгәнгә күрә);

• эш урыннары җитмәү һәм транспортның начар йөрүе;

• торак төзелешенең авыл җирендә социаль-икътисадый проблемаларны тиешенчә чишәргә мөмкинлек бирми торган инертлылыгы.

*Тенденцияләр һәм мәсьәләләр:*

• Татарстан Республикасы халкын күчерү системасын ике бурыч – авыл территорияләрен саклап калу һәм халыкның тормышын яхшырту аша оптимизацияләү;

• авыл бергәлекләренең үз урыннарын таба алу мөмкинлеге, Татарстанның авылларда сакланып калган полиэтник үзенчәлегеннән файдалану;

• авылда кече бизнесның булырга мөмкин төрле вариантлары, шул исәптән экологик яктан чиста продукция җитештерү;

• төрле районнардагы күпторышлыкның республика өчен оптималь шартларын эзләү, эре, уртача һәм кече предприятиеләрнең ярашуы;

• күрше регионнар базарларына чыгу мөмкинлекләре һәм инвесторларны җәлеп итү юллары;

• авыл җирлеге икътисадын диверсификацияләү мөмкинлекләре һәм аларда эшчәнлекнең авыл хуҗалыгына карамаган төрләрен үстерү;

• эре шәһәрләрнең шәһәр яны зоналарында сезонлы һәм даими субурбанизация процесслары.

*Авыл территорияләрен үстерү концепциясе*

Урбанизацияләнмәгән төп территорияләр өч агломерациянең – Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләренең барлыкка килә торган йогынты поясларына туры килә. Авыл территорияләренең бер өлеше өч агломерация поясларына керә һәм акрынлап агломерация процессларына җәлеп ителә.

Кече шәһәрләрнең һәм авыл территорияләренең пространство үсеше «регенерация» буларак карала, бу территорияләрнең икътисадый, социаль һәм физик яктан бетүенә каршы юнәлдерелгән чаралар комплексын күздә тота. Җирле бергәлекләр кеше капиталын саклап калу һәм арттыру максатларында тормыш эшчәнлеге пространствосы сыйфатын яхшырту, аерым бер территориянең брендын булдыру һәм үз районнарының һәм тулаем регионның конкурентлыкка сәләтен ныгыту программаларын эшләүгә җәлеп ителәләр.



Авыл территорияләрен сыйфатлы пространство планлаштыруы территорияләрне үзгәртеп коруның җиде юнәлешен гамәлгә ашыру өчен база булдыруны күздә тота.

1. *Агросәнәгать комплексын индустриализацияләү һәм муниципаль индустриаль паркларны урнаштыру түбәндәгеләрне үз эченә ала*:

• җитештерү технологияләрен модернизацияләүне, авыл хуҗалыгы продукциясен чистартуны, саклауны һәм эшкәртүне, авыл хуҗалыгы предприятиеләре белән идарә итүнең заманча системасын, предприятиеләрнең җитештерү-хуҗалык комплексын камилләштерүне, кул хезмәтен механикалаштыруны, технологик процессларны автоматлаштыруны һәм роботлаштыруны;

• мәйданчыкларны Татарстан Республикасында индустриаль паркларны урнаштыру концепциясе кысаларында урнаштыру, бу чакта инженерлык һәм транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерүне һәм резидентлар җәлеп итүне күздә тота торган муниципальара кооперация һәм интеграция сәясәтен истә тоту. Татарстан Республикасында кыска вакыт эчендә барлыкка килә торган муниципаль индустриаль парклар кече һәм урта бизнес өчен якорь мәйданчыклары, шулай ук халыкның хезмәтен куллану урыннары булдыруны күздә тота.

2. *Җирләрдән файдалануның яңа концепциясе* – җир эшенең экологик нисбәтле системасы – түбәндәгеләрне үз эченә ала:

• авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге гамәлдәге җирләрдән, шул исәптән хосусый кырлардан файдалануны интенсификацияләү;

• авыл хуҗалыгы җирләрендә сәнәгать һәм инфраструктура объектларын рациональ урнаштыру: юл хуҗалыгының, энергия белән тәэмин итүнең, нефть чыгаруның линия объектларын төзү;

• инновацион технологияләр кертү;

• кыйммәтле ландшафтларны саклап калу;

• хосусый авыл хуҗалыгы җирләрендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм хуҗалык эшчәнлегенә булышу, продукцияне сатуны стимуллаштыру һәм аңа ярдәм итү, файдаланылмый торган җирләрне регион ихтыяҗлары өчен сатып алу.

3. *Муниципальара кооперация һәм чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек*. Кече шәһәрләрнең һәм авыл җирлекләренең актив үсеш территорияләре сәясәте кооперацияләр һәм институциональ платформалар булдыру аша муниципальара проектларны каршылыксыз гамәлгә ашыруны күздә тота. Чик буе территорияләрендә хезмәттәшлек сәясәтенең төп максаты – иң чик субъектларның янәшәдәге муниципалитетлары белән

нәтиҗәле һәм ике як өчен дә файдалы социаль-икътисадый хезмәттәшлек, бюджет барлыкка китерү базасын тотыру максатларында, регионның төп үсеш үзәкләреннән читтә урнашкан муниципалитетларның икътисадый мөстәкыйльлеген беркетү.

*4. Үзенчәлекне саклап калу һәм арттыру*. Территориянең үзенчәлеге тарихи яктан һәм традицияләрнең, мәдәни мирасның, хуҗалык эшчәнлегенең үзенчәлеге белән билгеләнә. Бу факторларга сакчыл мөнәсәбәт көчлерәк булган саен, регионның терәк пространство каркасында территориянең роле дә зуррак. Татарстан Республикасының этник төрлелеге территориянең һәм теге яки бу милләтләр күбрәк яшәгән торак пунктларның үзенчәлегендә чагыла. Үзенчәлекне саклап калуның төп юнәлешләре – мәдәният, туризм, шәһәр мохите.

*5. Нигезле эреләндерү*. Татарстанда, бөтен илдәге кебек үк, икътисадый яктан көчсез торак пунктларны тоту чыгымнарына кагылышлы проблемалар бар. Аерым авыл җирлекләрен, аларның территорияләрен бөтен ресурслары белән бергә көчлерәк башка муниципаль берәмлекләр чикләренә кертеп, муниципаль-территориаль бүленеш берәмлеге буларак бетерү, һичшиксез, җентекләп уйлаганнан соң башкарыла, бу эш, муниципаль берәмлекнең финанс ягыннан үз-үзен канәгатьләндерә алуы, аның үз ресурслары һәм идарә итү сыйфаты арасындагы бәйләнешне ныгытачак.

*6. Җирлек-спутникларны үстерү*. Төп шәһәрләрнең (Казан, Чаллы һәм Әлмәт) территориаль ресурслары чикләнгән булудан һәм якын тирәдәге, шулай ук уртада калган шәһәр яны территорияләрендә, аларны кече шәһәрләр һәм авыл торак пунктлары тәшкил итә, киң инфраструктура ресурсы булудан гыйбарәт ике фактор эре шәһәрләргә якын булган авыл торак пунктларын, аларның инфраструктурасын тамырдан үзгәртеп, җирлек-спутникларга үзгәртеп кору сәясәтен барлыкка китерә. Мондый торак пунктларда производстволар урнаштыру, хезмәтләр күрсәтү, торак төзелешен үстерү үзәкләрнең мөмкинлекләрен тулырак гамәлгә ашырырга җирлек тудыра, шул рәвешле аларның социаль-икътисадый һәм шәһәр төзелеше проблемаларын хәл итә, спутникларны үстерүгә импульс бирә.

*7. Шәһәр кешеләре өчен икенче торак*. Агломерациянең үзәк шәһәрләре әйләнә-тирәсендә урбанизация процессының көчәя баруы оешмаган рәвештәге сезонлы һәм даими субурбанизация процессларында ачык күренә. Әлеге процессны җайга салу түбәндәгеләрне күз алдында тота:

- үзәк шәһәргә тоташкан муниципаль районнарны территориаль планлаштыру схемаларының төп нигезләмәләрендә шәһәр яны территорияләрен үзләштерү тенденцияләрен исәпкә алуны;



- агломерацияләр инфраструктуралары схемаларында гамәлдәге шәһәр яны территорияләренең каркасын алдан уйлап куюны;
- җир кишәрлекләренең һәм аларда урнашкан капиталь объектларның чынбарлыкта файдаланылуына ясалган мониторингка нигезләнеп, гражданнар даими яши торган территорияләрдә җирләрне ДНП категориясеннән ИЖС категориясенә күчерү механизмын уйлап табуны;
- үзәк шәһәрләрнең шәһәр яны территорияләрендә хуҗалык эшчәнлеген килешүләр нигезендә муниципалитетара (агломерацион) югарылыкта планлаштыруны һәм җайга салуны.
- Кече шәһәрләрнең һәм авылларның үсешен планлаштырганда түбәндәге принципларны саклау мөһим:
- авыл территорияләрен яңартуның яңа идеологиясе;
- муниципаль киңлек сәясәте максатларын билгеләү өчен муниципаль һәм республика планлаштыру структуралары кооперациясен, квалификацияле кадрлар әзерләү, җирлекләрне саклап калу һәм үстерү буенча комплекслы программалар төзү;
- инфраструктура һәм тармак проектларын гамәлгә ашыру, җирләрдән файдалану, табигатьне саклау гамәлләрен тәэмин итү өлкәсендә муниципалитетара кооперация һәм уртак гамәлләр өчен институциональ платформа булдыру.

Җирле хакимият региональ хакимиятнең тулы хокуклы партнерлары булырга тиеш, ә кризис күренешләрен уңышлы җиңеп чыгу өчен муниципаль берәмлекләрнең финанс базасы һәм аларның финанс автономиясе ныгытылырга тиеш.

Актив үсеш территориясенә (3.20 нче һәм 3.21 нче рәсемнәр) керә торган авыл җирлекләре һәм кече шәһәрләр өчен махсуслаштырылган программалар һәм проектлар тәкъдим ителә. Яр буе территорияләрен үстерү программасы Татарстанның иң эре елгаларының яр буе территорияләрендә махсус экологик һәм пространство регламентлары булган зоналар төзү һәм аларны үстерүне күз алдында тота: «Идел-Кама агымы» экозонасы (кара: 3.2.4.1). Чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек зоналарын үстерү программасы Башкортостан Республикасы, Удмурт Республикасы, Марий Эл Республикасы, Самара, Киров һәм Ульяновск өлкәләре белән чиктәш алты зонаны үз эченә ала. Программада берничә юнәлеш ассызыклана: трансчикләрнең агломерация элементләрен ныгыту; бизнес өчен шартларны яхшырту һәм мәйданнар булдыру, җирле үзенчәлекләрне популярлаштыру.




3.20 нче рәсем. Актив үсеш зоналары һәм чик буе территорияләрендәге хезмәттәшлек зоналары




3.21 нче рәсем. Пространство үсеше комплексы программаларында катнаша торган муниципаль берәмлекләр

### 3.2.3.4. Идел-Кама метрополисын төзү концепциясе

Татарстан Республикасында өч урнашу үзәге аерылып тора: Казан, Чаллы һәм Әлмәт, алар үзләре тирәсендә бербөтен агломерация системаларын төзиләр. Әлеге системалар арасында начаррак үсеш алган һәм халык азрак яши торган, бу, шул исәптән, алардагы транспорт инфраструктурасының начар булуы белән аңлатыла, районнар бар. Югарыда күрсәтелгән үзәкләрнең һәркайсы үзенчә махсуслашкан, аларда икътисадый элемтәләр һәм Мәскәү белән турыдан-туры транспорт элемтәсе (аэропорт) урнашкан.

Татарстан Республикасы пространствосын аерым өч агломерация системасы рәвешендә үстерүгә алар арасында тыгыз хезмәттәшлек һәм кооперация булдыруны өстәргә кирәк, бу үз чиратында бердәм Идел-Кама метрополисын төзүгә китерәчәк. Өч агломерациянең мөмкинлекләреннән бергә һәм килештереп файдалану Татарстанның үсешен, синергетик йогынтыга нигезләнеп, сыйфат ягыннан алга җибәрүгә, аның конкурентлыкка сәләтен арттыруга китерәчәк, агломерацион нәтиҗәләрне арттырачак. Идел-Кама метрополисын үстерү Татарстан Республикасының үзәк өлеше муниципаль районнарын активрак үстерергә мөмкинлек бирәчәк.

Идел-Кама метрополисын төзү глобаль конкуренциядә һәм маркетингта Татарстан Республикасының уңышка ирешүе өчен мөһим, ә бәлки хәлиткеч алшарт булып тора. Бердәм метрополис Россия Федерациясе агломерацияләре арасында халык саны буенча өченче урынга менәчәк һәм глобаль масштабка чыгачак (рәс. 3.2.2).

Идел-Кама метрополисын төзү Татарстан Республикасы пространствосының үзара бәйләнешлелеген арттырган очракта, аеруча Казан, Чаллы һәм Әлмәт арасында икътисадый араны киметкәндә мөмкин булачак. Әлеге шәһәрләрне аерып торучы ераклыкны исәпкә алсак, бу мәсьәләне алар арасында тизйөрешле транспорт коммуникацияләрен төзү юлы белән уңай хәл итеп булачак (кара 3.2.3.5). Әлеге концепциягә Мәскәү – Казан – Екатеринбург югары тизлекле тимер юлын төзүнең тәкъдим ителгән варианты җайлы гына керешеп китә.






3.22 нче рәсем. Идел-Кама метрополисы

Ераграк перспективада Идел-Кама метрополисының йогынтысын алга таба киңәйтү буенча чаралар күрүне Татарстан агломерацияләре һәм хәзерге вакытта транспорт элемтәләре белән начар тоташкан әйләнә-тирәдәге эре үсеш үзәкләре арасында тизйөрешле транспорт элемтәләрен төзү юлы белән хәл итәргә кирәк булачак.

Глобаль конкурентлыкка сәләтле регион буларак Татарстанга тизйөрешле элемтәләр һәм җитәрлек санда күперле кичүләрне үз эченә алган тотрыклы каркас булдыру таләп ителә. Регионда Россиянең иң эре елгалары ага торган барлыгы өч күпернең генә булуы территориянең пространство тотрыклылыгы өчен җитми.

Татарстан территориясе бәйләнешлелегендәге актив үзгәрешләр тагы дүрт стратегик күпер проектлауны һәм төзүне күз алдында тота.

1. ***Гребени авылы тирәсендә күпер (Көньяк Казан күпере) төзү***, ул Казанның Көньяк транспорт әйләнгеч юлының бер өлеше булачак. Әлеге күпернең кирәклеге Казан шәһәрендә һәм аңа чиктәш муниципаль районнарда бара торган актив агломерацион процессларга бәйле. Иделнең уң ярында Иннополис һәм аэропорт янында СМАРТ Сити Казан шәһәр-спутникларның барлыкка килүе, халыкара аэропортның тоткан урыны арту, аның алга таба хабка әверелү ихтималы зур булу **Казан агломерациясе** территориясендә Идел аша икенче күпер төзү гамәлләрен башкаруны беренче чиратка куя. Әлеге проектны гамәлгә ашыру Югары Ослан һәм Лаеш районнарына тизрәк үсәргә мөмкинлек бирәчәк, уң ярга инвестицияләр килүне тәэмин итәчәк, Казан үзәге аша транзит йөкләнешен шактыйга киметәчәк.

2. ***Соколка авылы тирәсендә күпер (Соколка күпере) төзү*** – Татарстан Республикасының пландагы проекты. Әлеге күпернең төзелүе Түбән Кама ГЭС плотинасыннан транзит автотранспорт агымын киметәчәк.

3. ***Алабуга шәһәре районында күпер (АлаБег күпере)*** – **Кама агломерациясенең** тизйөрешле транспорт каркасы структурасының бер өлеше. Әлеге күпер, иң беренче чиратта, Түбән Кама һәм Алабуга шәһәрләре өчен Кама агломерациясенең хезмәт корреспонденцияләре һәм йөк ташулары өчен кирәк. Кама агломерациясендәге яңа күперләр икътисадны үстерү, халыкның мобильлеген, хезмәт һәм хезмәткә бәйле булмаган миграцияләрне активлаштыру өчен зур этәргеч булачак; республиканың стратегик объекты булып торучы һәм бүгенге көндәге торышы канәгатьләндерми торган Түбән Кама ГЭС плотинасын бушатачак.

4. ***Тәтеш шәһәре тирәсендә Идел аша күпер (Болгар күпере)*** – Татарстанның көньягы өчен, беренче чираттагы булмаса да, бик мөһим чара. Бүгенге көндә Кама аръягы, мобильлек һәм регион үзәкләренә транспорт белән барып җитү күзлегеннән чыгып караганда, пространство структурасының иң начар үсеш алган өлеше булып тора. Шулай ук туристлык тармагын, аерым алганда, Кама аръягы һәм Идел алды территорияләрендә актив үстерүне исәпкә алсак, күпер төзелешенең таләп ителүе шиксез. Болгар шәһәренең туризмны үстерү буенча федераль программаларга кертелүе мөмкин булган маршрутлар диапазонын киңәйтүгә ярдәм итү өчен алшартлар тудыра. Болгар һәм Биләргә бара торган туристлык тарихи-мәдәни маршрутларына («Көмеш дага») Иделнең уң ярындагы уникаль рекреацияләрне һәм тарихи урыннарны кертү әлеге юнәлешне баетачак һәм туристлар агымын шактый арттырачак. Әлеге юнәлешнең уңышы инфраструктура сыйфатына һәм әлеге җирләрдәге истәлекле урыннар буенча каршылыксыз сәяхәт итү мөмкинлегенә бәйле булачак.

**3.2.3.5. Тизйөрешле транспорт төрләрен булдыру концепциясе**

Татарстан Республикасының тизйөрешле транспорт төрләрен булдыру һәм юл хуҗалыгы концепциясе (алга таба бу параграфта – Концепция) төп өч төркем бурычны хәл итүне максат итеп куя:

1) Татарстан Республикасы эчке транспорт каркасының «тотрыклы өчпочмагын» төзи торган Татарстан Республикасының өч агломерациясендә агломерацияара транспорт элемтәләрен үстерү;

2) Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләренең Россия Федерациясенең иң эре шәһәрләре, шулай ук күрше регионнарның барлык үзәкләре белән регионара транспорт элемтәләрен яхшырту; мондый шәһәрләр исемлегенә түбәндәгеләр керә: Мәскәү, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Самара, Уфа, Пермь, Екатеринбург, Чиләбе, Чабаксар, Ульяновск, Ижевск, Йошкар-Ола, Киров һәм Оренбург;

3) һәркайсында катлаулы транспорт системасы булып регион агломерацияләренә республика тизйөрешле элемтәләр системасын кертеп җибәрү.

Концепция кысаларында гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган барлык чаралар ике зур төркемгә бүленде: Минимум планы һәм Максимум планы.

*Минимум планы* – хәзерге һәм киләчәктә ихтыяҗ арта барачак транспорт йөрешен канәгатьләндерү өчен билгеләнгән гамәлләр җыелмасы. Аны гамәлгә ашыру ике этапта башкарылачак дип уйланыла: гамәлләрнең бер өлеше беренче чиратта башкарылачак һәм 2020 елга кадәр тәгәлләнергә тиеш, икенче

этап исәпләнгән вакытка кадәрге чорда (2020 һәм 2030 еллар арасында) гамәлгә ашырылырга тиешле чараларны үз эченә ала.

*Максимум планы* – транспорт йөрешен канәгатьләндерү өчен генә түгел, ә аңа ихтыяҗны стимуллаштыру өчен билгеләнгән чараларның киңрәк җыелмасы ул, бу Татарстан Республикасы территорияләрен башкалардан алданрак үстерергә мөмкинлек бирәчәк. Аларны исәпләнгән вакыттан соң да (ягъни 2030 елдан соң), шулай ук, тиешле ихтыяҗ, сәяси ихтыяр һәм җитәрлек күләмдә финанс чаралары булган очракта, якын киләчәктә дә (оптимистик сценарий) гамәлгә ашырырга мөмкин.

Концепциядә тизйөрешле транспорт коммуникацияләрен булдыру дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

• I һәм II техник категорияләрдәге тизйөрешле автомобиль юлларын төзү (автотранспорт хәрәкәте өчен полосаларның саны һәр якка кимендә икешәр) яисә гамәлдәге автомобиль юлларын автотранспортның кимендә 100 км/сәг. тизлек белән хәрәкәт итүен тәэмин итә торган шундый ук техник категорияләргә кадәр реконструкцияләү;

• тизйөрешле автомобиль юллары составында эре күпер кичүләрен төзү;

• тизйөрешле һәм аеруча тизйөрешле тимер юллар төзү, тизләтелгән рәвештә пассажирлар йөртүне кертү максатыннан гамәлдәге тимер юлларны реконструкцияләү, транспортка күчеп утыру үзәкләрен төзү;

• аэропортларны аларның үткәрүчәнлеген арттыру максатыннан реконструкцияләү.

Концепциядә куелган бурычларның башкарылуын бәяләү өчен нигез критерий – Татарстан Республикасының кеше яши торган төп үзәкләре: Казан шәһәре, Кама һәм Әлмәт агломерацияләре шәһәрләре арасында җир өсте транспортының бару вакытын (1,5 – 2,5 сәгатькә кадәр), шулай ук әлеге үзәкләр белән Үзәк Россиянең һәм Уралның шундый ук үзәкләре арасында бару вакытын кыскарту.

Татарстан Республикасының географик урнашу урыны уңай булганга күрә, Үзәк Россия белән Уралны тоташтыручы буын булган бөтен Идел буе регионының тизйөрешле тотрыклы транспорт каркасын төзүдә иң төп рольне уйнаучы буларак кабул ителә.

Татарстан Республикасының агломерацияара һәм регионара элемтәләрен тәэмин итә торган барлык потенциаль тизйөрешле транспорт юнәлешләре регион аркылы уза торган халыкара һәм федераль транспорт коридорларына җиңел керешеп китә ( 3.1 нче таблица, 3.23 нче рәсем). Бу исә Татарстан Республикасында тизйөрешле транспорт проектларын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан финанс чараларын җәлеп итүне шактый җиңеләйтергә мөмкин.



3.2 нче һәм 3.3 нче таблицаларда, шулай ук 3.24 нче рәсемдә Татарстан Республикасында тизйөрешле элемтәләр төзү гамәлләренең тулы исемлеге бирелде.

**3.1 нче таблица. Татарстан Республикасының потенциаль тизйөрешле транспорт юнәлешләре белән федераль транспорт коридорларының керешүе**

| Агломерацияара / регионара транспорт юнәлешләре | Транспорт коридоры |
|---|---|
| Казан агломерациясе – Кама агломерациясе<br>(Төп юнәлеш)<br>Казан – Чабаксар – Түбән Новгород – Мәскәү<br>Чаллы – Екатеринбург<br>Чаллы – Уфа | Мәскәү – Татарстан – Урал – Себер («Транссиб» халыкара коридорының бер юнәлеше) |
| Казан агломерациясе – Әлмәт агломерациясе<br>(Көньяк-көнчыгыш юнәлеш)<br>Әлмәт – Оренбург – Казахстан | Санкт-Петербург – Татарстан – Казахстан – Кытай перспективалы коридоры |
| Кама агломерациясе – Әлмәт агломерациясе<br>(Көнчыгыш Татарстан юнәлеше)<br>Чаллы – Ижевск – Пермь<br>Әлмәт– Оренбург – Казахстан | Төньяк Урал – Ижевск – Татарстан – Көнбатыш Казахстан регионара коридоры |
| Казан агломерациясе – Самара | Санкт-Петербург – Кытай коридорының перспективалы тармагы, Россия Федерациясенең Төньяк-көнбатышын, Мәскәүне урап узып, Самара һәм Тольятти белән тоташтыруны тәэмин итәчәк |
| Казан – Йошкар-Ола – Киров<br>Казан – Ульяновск | Коми Республикасы – Киров – Йошкар-Ола – Казан – Ульяновск – аратов – Волгоград – Россия Көньягы регионара коридоры |
| Казан – Удмурт Республикасы – Пермь | Мәскәү – Урал коридорының перспективалы тармагы, Мәскәү белән Пермь арасында иң кыска юл булачак |




3.23 нче рәсем. Федераль һәм регионара транспорт коридорлары үсеше контекстында Татарстан Республикасы



**3.2 нче таблица. Татарстан Республикасында тизйөрешле элемтәләр системасын төзү гамәлләренең җыелма таблицасы — Минимум планы**

| Чират | Гамәл |
|---|---|
| Беренче чират — 2020 ел | Мәскәү — Казан ВСМын төзү |
| | Мәскәү — Казан ВСМын «Тихоново» станциясенә кадәр төзү (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле карары булганда) |
| | М-7 автомобиль юлын (барлык участокларын) реконструкцияләү |
| | Шәле — Баулы (Европа — Көнбатыш Кытай) автомобиль юлы, I чират |
| | Идел аша күпере булып, Казанны көньяктан әйләнеп узу юлы |
| | Соколка авылы янында Кама аша күпере булып, Кама агломерациясен ерактан әйләнеп узу юлы |
| | Әлмәт — Чаллы автомобиль юлын реконструкцияләү |
| | «Казан шәһәрендә божралы тимер юл хәрәкәтен оештыру» проектын гамәлгә ашыру |
| Исәпләнгән вакыт — 2020 — 2030 еллар | «Чиста юл» автомагистрале — 1 нче этап (гамәлдәге Казан — Сорочьи Горы, Түбән Кама — Кама Аланы автомобиль юлларын II категориягә кадәр реконструкцияләү, торак пунктларны әйләнеп узу юлларын төзү) |
| | Шәле — Баулы (Европа — Көнбатыш Кытай) автомобиль юлы — тулысынча эшләп бетерү |
| | Проект һәм әзерлек эшләре: Идел аша күпере булган Көньяк Татарстан магистрале, Казанны төньяктан әйләнеп узучы автомобиль юлы |
| | Сөйки Кичүе (Кама Тамагы муниципаль районы) — Болгар паром кичүе |

**3.3 нче таблица. Татарстан Республикасында тизйөрешле элемтәләр системасын төзү гамәлләренең җыелма таблицасы — Максимум планы**

| Чират | Гамәл |
|---|---|
| 2020 елдан башлап регионара юлларны үстерү (күрше регионнар һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы белән килештереп) — 2030 елга кадәр проектлау һәм төзи башлау, 2030 елдан соң төзелешне төгәлләү | Казан — Малмыж — Пермь автомобиль юлы |
| | Р-241 Казан — Ульяновск автомобиль юлы |
| | А-295 Казан — Йошкар-Ола автомобиль юлы |
| | Алексеевск — Высокий Колок — Самара автомобиль юлы |
| | Алнаши — Екатеринбург автомобиль юлы |

| Чират | Гамәл |
|---|---|
| Исәпләнгән вакыт тәмамлангач (2030 елдан соң) | «Чиста юл» автомагистрале – тулысынча төзеп бетерү (Сорочьи Горы – Кама Аланы автомобиль юлын реконструкцияләү) |
| | Казанны төньяктан әйләнеп узучы автомобиль юлы |
| | Буа – Тәтеш – Болгар – Әлмәт Көньяк Татарстан магистрале |
| | «АлаБег» проекты: Түбән Кама – Чаллы автомобиль юлы; «Бегишево» аэропорты – Алабуга – «Алабуга» МИЗ автомобиль юлы; Кама елгасы аша күпер |
| | «АлаБег» – ЛРТ тизйөрешле элемтәсе |
| | Р-239 автомобиль юлын реконструкцияләү |
| | Казанны әйләнеп узучы йөк тимер юлы |
| Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы, РЖД белән килештереп, 2020 елдан соң ВСМ системасын үстерү. Шул исәптән ВСМ линиясенә эре шәһәрләрне һәм күрше регионнарны (Марий Эл Республикасын һәм Удмурт Республикасын, Ульяновск өлкәсен) гамәлдәге тимер юл линияләрен реконструкцияләү юлы белән алар буенча «эре шәһәр / регион үзәге – ВСМ терминалы» арасында тизләтелгән регионара пассажир поездларын үткәрүне тәэмин итү өчен тоташтыру | Казан – Екатеринбург ВСМын төзү |
| | Волжск – Зеленодольск – Казан (ВСМ терминалы) – Арча тимер юл линиясен реконструкцияләү (Казан агломерациясе шәһәрләренең Казандагы ВСМ терминалы белән тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |
| | Зеленодольск – Йошкар-Ола тимер юлын реконструкцияләү (Марий Эл Республикасының Казандагы ВСМ терминалы белән тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |
| | Зеленодольск – Буа – Ульяновск тимер юлын реконструкцияләү (Ульяновск өлкәсенең Казандагы ВСМ терминалы белән тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |
| | Писмәнкә (Лениногорск шәһәре) – Әлмәт – Чаллы –Тихоново ВСМ терминалы – Әгерҗе – Ижевск тимер юлын реконструкцияләү (Удмурт Республикасы һәм Тихоноводагы ВСМ терминалы белән Әлмәт агломерациясе тизләтелгән тимер юл элемтәсен оештыру) |





3.24 нче рәсем. Татарстан Республикасында тизйөрешле элемтәләр системасын төзүнең чиратлылыкны исәпкә алган җыелма схемасы

Транспорт инфраструктурасы проектларын гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең норматив хокукый документлары нигезендә шәһәр төзелеше һәм экологик регламентларның төп таләпләрен үтәргә кирәк. Антропоген-табигый мохитнең, яшел массивлар һәм өске сулыклар табигый ландшафтларының экологик балансын саклап калу тәэмин ителергә тиеш. Һәр проектны эшләр алдыннан магистраль яны территорияләренең һава бассейны торышы, проектлана торган һәм аңа чиктәш булган территорияләрнең ландшафт характеристикалары, территориягә антропоген йогынты ясауның төп чыганаклары һәм факторлары тәэсире анализланырга һәм бәяләнергә тиеш.

Түбәндәге гамәлләрне эшләү әлеге проектларны тормышка ашыруның мәҗбүри шартларын тәшкил итәләр:

- тискәре инженер-геологик процесслардан саклау,
- туфракны саклау,
- урман массивларын һәм кыйммәтле ландшафтларны саклап калу һәм /яисә торгызу,
- су объектларын саклау,
- гамәлдәге һәм проектлана торган төзелешләргә акустик йогынтыны киметү.

### 3.2.3.6. Татарстан Республикасының логистик инфраструктурасын үстерү

Логистик инфраструктураның үзәк объектлары Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләрендә туплана.

**Казан агломерациясе**. Логистиканың үзәк объектлары Казанның үзендә яисә аның тирәсендә урнашкан – «Q-Park Казан» һәм «Тандер» логистика комплекслары, «Биек Тау» һәм «Константиновка» логопарклары, шулай ук «Эшлекле линияләр» күпфункцияле логистика комплексы. Санап үтелгән объектларның йөкләнеше тигез түгел, аларны файдалануны оптимальләштерү резервлары бар. Моннан тыш, якын киләчәктәге елларга «Свияжск регионара мультимодаль логистика үзәге» (алга таба – СРМЛҮ) проектын һәм СМАРТ Сити Казандагы логистика өлешен уңышлы гамәлгә ашыру бурычы куела.

Свияжск күпфункцияле мультимодаль логистика комплексы Идел буе регионында гамәлдә булган йөкләр хәрәкәтен бер урынга җыю һәм яңаларын төзү үзәге була ала. Моннан тыш, тимер юл йөк ташуларын, йөк портлары эшен Казан шәһәреннән СРМЛҮ территориясенә күчерү бушатыла торган шәһәр территориясен үстерү өчен шартлар тудырачак, шәһәр зонасындагы Идел елгасы ярларында туристлык-рекреация объектларын урнаштырырга мөмкинлек бирәчәк.



СРМЛҮ территориясенә һәм аның янәшәсендәге территориягә махсус икътисадый зона статусын бирү зур инвестицияләр җәлеп итәргә, «Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисадый зоналары үрнәгендә эшкуарлыкны үстерү өчен өстәмә импульс булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

**Кама агломерациясе**. «КИП «Мастер» индустриаль паркы һәм «Логикам» логистика-бүлү үзәге («Мастер» ЛҮ) кебек индустриаль парклар һәм логистика үзәкләре эре сәнәгать предприятиеләренең ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр һәм алар белән бергә үсәләр. Тиздән «Алабуга» МИЗ территориясендә Havi Logistics бүлү үзәге сафка кертеләчәк. Хәзерге вакытта урнашкан шартларда логистика объектларына ихтыяҗ, тулаем алганда, бар.

**Әлмәт агломерациясе**. Монда заманча күпфункцияле логистика үзәге бер дә юк. Шул ук вакытта республиканың көньяк-көнчыгыш зонасында федераль әһәмияттәге ике автомобиль юлы: М-5 «Урал» (Мәскәү – Самара – Уфа) һәм Р-239 (Казан – Оренбург) кисешә. 2020 елга кадәр «Европа – Көнбатыш Кытай» автомобиль юлы кулланылышка тапшырылачак, аның бер участогы шулай ук карала торган территория аша уза торган була. Гамәлдәге һәм проекттагы эре автомобиль юллары киселешенең уңай географик урынын, шулай ук сыйфатлы инфраструктурага ихтыяҗ булуны исәпкә алсак, төп игътибар Әлмәт агломерациясендәге логистиканы «Татарстанның көнчыгыш капкасы» проекты кысаларында үстерүгә бирелергә тиеш.

2020 елда «Европа – Көнбатыш Кытай» автомобиль юлын сафка кертүгә аерым игътибар бирү кирәк, ул бөтен юл буена транспорт, икътисадый һәм социаль глобаль коридоры булачак. Әлеге трасса буенча транспорт-логистика инфраструктурасын һәм юл буе сервисын үстерү регион икътисадын тәшкил итә торган мөһим өлешләрнең берсе булып тора һәм «Татарстан – глобаль хаб» стратегия максатына ирешергә ярдәм итәчәк.

«2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасының транспорт системасын үстерү» программасының «Татарстан Республикасында логистика үзәкләре челтәрен үстерү» ярдәмче программасын төзү буенча 2015 елда башланган эш төрле класслы логистика комплексларын урнаштыру өчен иң уңай урыннарны билгеләргә һәм регионның нык логистик каркасын булдырырга мөмкинлек бирәчәк, ул исә логистика һәм терминал-склад хезмәт күрсәтүләр базарын үстерүнең нигезен тәшкил итәчәк.

### 3.2.3.7. Калдыклар белән эш итү системасы

Татарстан Республикасында калдыклар белән эш итү өлкәсендәге төп проблемаларга түбәндәгеләр керә:

• эшкәртелми, ә күмелә торган калдыкларның проценты югары булу;

• калдыкларны системалы җыюның һәм алып китүнең барлык торак пунктларда да башкарылмавы;

• калдыкларны эшкәртү буенча югары нәтиҗәле производстволарның булмавы;

• экологик культураның түбән булуы;

• калдыклар барлыкка килүнең һәм аларның хәрәкәтенең тиешле исәбе алып барылмау һәм контроль булмау.

Төрле категориядәге калдыкларның барлыкка килү күләмнәре даими рәвештә арта барганга күрә, гамәлдәге полигоннарга туры килә торган йөкләнеш елдан-ел арта гына бара, һәм шуңа бәйле рәвештә полигоннарны тиешенчә файдаланмау сәбәпле әйләнә-тирә мохитнең пычрануына, аларның территорияләрен киңәйтү зарурлыгына һәм башкага бәйле проблемалар кискенләшә бара. Күп кенә авыл җирлекләрендә барлыкка килгән калдыкларны системалы рәвештә алып чыгу чынбарлыкта башкарылмый, бу рөхсәт ителмәгән чүплекләр барлыкка килүнең төп алшарты булып тора.

Хәзерге вакытта күмеп юкка чыгарыла торган калдыкларның күп өлешен эшкәртелүгә җибәрү мөмкин булган булыр иде, бу очракта полигоннарга да йөкләнешне күп тапкырлар киметергә һәм алга таба җитештерү процессына кертеп җибәрү өчен яраклы әзер чимал алырга мөмкинлек биргән булыр иде.

Республикада өч калдыклар белән идарә итү үзәген җитәрлек дәрәҗәдә производство куәтләрен туплый торган өч икътисадый зонада төзү дөрес булыр дип уйланыла.

Кама икътисадый зонасында калдыклар белән эш итү проекты пилот проект буларак сайлап алынды. Проектның максаты җитештерү һәм куллану калдыкларының әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын, проектның экологик һәм икътисадый аспектлары арасында тигезлеккә ирешеп (аерым алганда, калдыклар белән идарә итүнең масштабы һәм үзәкләштерелүе хисабына социаль риза булырлык тарифлар булдыру), идарә итүнең нәтиҗәле системасын төзү хисабына киметүдән гыйбарәт.

Проектның максатына ирешү түбәндәге бурычларның хәл ителүен таләп итә:

• проект территориясен җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, алып китү һәм сортларга бүлү эшчәнлеге белән колачлануын максимальләштерүне, аерым алганда, халыктан һәм предприятиеләрдән җыела торган каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларга туры килә торган өлешне калдыклар җыюның оештырылуын камилләштерү, бердәм тариф сәясәтен куллану, шулай ук калдыклар барлыкка килү факты буенча аларның исәбен алып барырга һәм аларны кабул итәргә мөмкинлек бирә торган заманча җиһазлар файдалану хисабына 100 процентка кадәр җиткерүне;



• барлыкка килә торган калдыкларның бөтен агымын бер урында (калдыклар белән идарә итүнең муниципалитетара үзәгендә) үзәкләштерүне, бу производство җиһазларына оптималь йөкләнешне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк;

• калдыкларны сортларга аеру, ваклау һәм эшкәртү буенча автоматлаштырылган производство куәтләрен эшләтеп җибәрүне;

• алга таба сату өчен яраклы әзер продукция алу максатыннан аерым категорияләрдәге калдыкларны эшкәртү җиһазларын сафка кертүне;

• проект территориясендәге барлык муниципаль районнарны территориаль яктан максималь нәтиҗәле колачлауны тәэмин итә торган, аерым районнарда һәм торак пунктларда калдыклар җыю һәм алып китүдә махсуслашкан предприятиеләрнең транспорт чыгымнарын киметә торган күчереп төяү станцияләре челтәрен төзүне;

• калдыклар эшкәртү өлкәсендә заманча технологияләрне калдыклар белән идарә итү үзәге каршында экологик технопарк булдыру хисабына кертүне, ул таләп ителә торган инфраструктура һәм эшкәртелә торган калдыкларга турыдан-туры керә алу мөмкинлеген бирү белән бергә чит оешмаларның производство куәтләрен урнаштыру өчен мәйдан булып тора;

• ресурслары беткән полигоннарны алга таба консервацияләп һәм /яисә ябып, проект территориясендә эшли торган полигоннарга йөкләнешне көйләүне;

• калдыклар җыюны, алып китүне һәм утильләштерүне, калдыкларны селектив җыюга һәм аларның барлыкка килүенең чынбарлыктагы күләмнәре буенча түләүгә шома гына күчүне тәэмин итү максатыннан, калдыкларны алып китү һәм эшкәртү өлкәсендә тарифлар сәясәтен камилләштерүнең мөһим аспекты сыйфатында бердәм комплекслы хезмәт күрсәтүләр буларак оештыруны;

• аерым категорияләрдәге калдыкларны утильләштерүне җайга салу өлкәсендә экологик сәясәтне сортларга аерыла һәм эшкәртелә алган калдыкларны күмүне чикләү максатыннан камилләштерү буенча гамәлләр уйлап табуны һәм тәкъдимнәр бирүне;

• проектны тормышка ашыруга гамәлдәге инфраструктураны проектны тормышка ашыруның бөтен срогы дәвамында эзлекле рәвештә заманчарак технологияләргә күчүне тәэмин итеп кертеп җибәрүне максимальләштерүне.

Проектны тормышка ашыру дәүләт-хосусый партнерлыгы механизмына – BOT (Build-Operate-Transfer) форматындагы концессиягә нигезләнер дип уйланыла.

#### 3.2.3.8. Пространстволы үсеш өлкәсендә институциональ чаралар

*Социаль-икътисадый һәм территориаль планлаштыруны үзара яраштыру*

Ресурсларны сак тоту һәм пространстволы үсешне билгели торган социаль-икътисадый һәм территориаль планлаштыру документларының килештерелү дәрәҗәсен арттыру максатларында, стратегик документларны эшләүдә билгеле бер эзлеклелекне саклау максатка ярашлы була.

*1 нче адым.* Кабул ителгән Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезендә муниципаль берәмлекләр стратегияләре эшләнә, алар түбәндәге сигез зонага төркемләнә (кара 3.2.1):

1) Казан агломерациясе;
2) Кама агломерациясе;
3) Әлмәт агломерациясе;
4) Кама алды авыл кече зонасы;
5) Кама аръягы авыл кече зонасы;
6) Идел алды авыл кече зонасы;
7) Кама агломерациясе поясының авыл территорияләре;
8) Әлмәт агломерациясе поясының авыл территорияләре.

Зонага керүче берничә муниципаль берәмлекнең стратегияләрен вакыт һәм эшләү методикасы ягыннан синхронлаштыру аларны эшләү сыйфатын яхшыртырга, эшләү бәясен һәм срокларын киметергә мөмкинлек бирә, кабул ителгән чараларны гамәлгә ашырганда муниципалитетара хезмәттәшлек өчен алшартлар тудыра. Бер үк вакытта аерым муниципаль берәмлекләрнең стратегияләре дә, тиешле зона стратегиясе дә эшләп бетереләчәк. Аерым зоналарны үстерү стратегияләре республика дәрәҗәсеннән аерым муниципаль берәмлек дәрәҗәсенә күчү буенча бик мөһим бурычны зона кысаларында үсешне координацияләүне тәэмин итеп хәл итәргә мөмкинлек бирә торган карау масштабын күздә тота. Мондый якын килүне йә муниципалитетара хезмәттәшлек механизмы ярдәмендә, йә «Татарстан-2030» проектының төзелгән проект мәйданнарыннан файдаланып республика дәрәҗәсендә тормышка ашырып була.

*2 нче адым.* Муниципаль берәмлекләрнең стратегияләре аерым муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документларына төзәтмәләр кертү, составында транспорт һәм инженер өлгеләре эшләнә торган, территорияләрнең аерым өлешләрендә социаль, производство, коммуналь һәм башка билгеләнештәге объектлар урнаштыру карала торган берләштерелгән инфраструктура схемаларын эшләү өчен нигез була.



Территориаль планлаштыру документларын эшләгәнче (төзәтмәләр керткәнче) тикшеренүләр (социологик, транспорт һәм башкалар) үткәрелә, аларга нигезләнеп, республика һәм муниципаль башкарма хакимият органнары дәрәҗәсендә килештерелергә тиешле техник йөкләмәләр төзелә.

*3 нче адым.* Территориаль планлаштыру документларының мониторингын алып бару һәм планлы рәвештә актуальләштерү Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен һәм Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын яңартуның чираттагы циклы өчен алшартлар тудырачак.

Күрсәтелгән процессларны мәгълүмат белән тәэмин итү өчен гамәлдәге Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасына (ИС ОГД) өстәмәләр кертелергә, детальләштерелергә тиеш, һәм ул Территорияләрнең шәһәр төзелеше үсешенә идарә итүнең мәгълүмат-аналитика системасына (ИАС УГРТ га) үзгәртелергә тиеш.

*Пространстволы үсешне координацияләү*

Бөтен Россиядәге кебек үк, республикадагы заманча идарә итү системасы, идарә бурычларына ведомстволы якын килеп, еш кына территориянең табигатен исәпкә алмый. Территориаль һәм тармак программаларын гамәлгә ашыру белән идарә итүгә гомуми яктан якын килүне булдыру тотрыклы үсеш өчен принципиаль әһәмияткә ия. Моңа «Татарстан-2030» проектының проект мәйданнары ярдәм итәр дип уйланыла.

Проект мәйданнары эшчәнлеге кысаларында һәм үзгәртеп төзелгән Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы ярдәме белән агломерацияләрне пространстволы үстерү буенча даими эшли торган координацияләү советлары һәм агломерациягә керми торган авыл районнарын пространстволы үстерү буенча даими эшли торган координацияләү советлары төзелә ала.

Координацияләү советлары, түбәндәге бурычларны хәл итеп, стратегик планлаштыру документларының күмәк заказчысы функцияләрен үти алалар: бердәм сәясәт уйлап табу, мәнфәгатьләрне килештерү, дәүләт хакимияте органнары белән эшләүне координацияләү, транспорт, инженер, социаль һәм башка инфраструктуралар өлкәсендә гомуми бурычлар һәм аларны

хәл итү юлларын булдыру, инвесторларга мәгълүмати-аналитик һәм проектта каралган хезмәтләрне күрсәтүдә булышлык күрсәтү.

*Пространстволы планлаштыру өлкәсендә белем һәм тикшеренүләр*

Профессионал кадрлар әзерләүне камилләштерү өлкәсендәге төп бурычлар территорияләрне үстерүгә һәм планлаштыруга багышланган тикшеренүләрне саклап калудан һәм алга таба үстерүдән, шәһәр төзү мәктәпләрен алга таба үстерүнең индивидуаль стратегиясен чит ил аналоглары тәҗрибәсен исәпкә алып эзләүдән гыйбарәт. Мәгариф системасы, «мохит булдыру» моделе эчендә белгечлекләрне һәм укыту юнәлешләрен үстерү, «идарә итү» моделе барлыкка килүнең платформаларын булдыру һәм шәһәр төзү белеменең башка (мәсәлән, «тикшеренү») модельләрен булдыру өлешендә җәмгыять ихтыяҗларына адекват сизгер булуы хисабына һөнәри белем бирүнең гомум дөньяви системасына җайлы гына керешеп китеп, үз илебезнең шәһәр төзү белемен бирүнең уникаль якларын саклап калырга тиеш (3.4 нче таблица).

**3.4 нче таблица. Татарстанда кадрларны һөнәри әзерләү системасын үстерү бурычлары һәм кораллары**

| Үстерү бурычлары | Үстерү кораллары |
|---|---|
| Пространстволы планлаштыру системасының илкүләм һәм региональ тәңгәллеген саклап калу | Татарстан Республикасының шәһәр төзү кадрларын һөнәри әзерләү системасын үстерүнең мөстәкыйль сценариесен эшләү |
| | Татарстан Республикасының шәһәр төзү кадрларын һөнәри әзерләү системасында югары, урта һәм дипломнан соңгы белем бирү оешмалары системасын бергә берләштереп үстерү |
| Пространстволы-территориаль планлаштыруның дөньяви системасы белән кушылу | Белем бирүнең планлаштыру эшчәнлегендә киләчәктә катнашучыларны төрле яктан әзерләүне тәэмин итә торган яңа шәһәр төзү белгечлекләрен һәм юнәлешләрен үстерүгә ярдәм итү һәм методик яктан тәэмин итү |
| | Болонья процессы таләпләре нигезендә уку дисциплиналарын һәм уку планнарын эшләү |
| Дөнья трендлары контекстында Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру системасын үстерү | Татарстан Республикасының тотрыклы мәгариф пространствосын булдыру һәм үстерү |
| | Халыкның өстәмә архитектура-шәһәр төзелеше белеме системасын үстерү |
| | Шәһәрне планлаштыру, төзекләндерү, территориаль планлаштыру өлкәсендә компромисс эзләү өчен проект бергәлеге, халык һәм хакимият вәкилләре арасында диалог булсын өчен шартлар тудыру |

Пространстволы планлаштыру өлкәсендә даими фәнни һәм проект тикшеренүләре механизмын, мәсәлән, Татарстан Республикасының Территориаль планлаштыру тикшеренү институты рәвешендә яңадан торгызырга һәм институтлаштырырга кирәк. Мондый институт эшчәнлеге өлкәсенә түбәндәгеләр керергә тиеш: нигез фәнни тикшеренүләр; пространстволы планлаштыруның төшенчәләр аппараты, пространстволы планлаштыру документларын эшләгәндә кулланыла торган принциплар һәм алымнар күрсәтелеп, пространстволы үзгәртеп корулар стратегиясе буенча фәнни-методик материаллар эшләү; шәһәр төзелешен планлаштыруның объектлар кырын киңәйтү. Институт шәһәр төзелешен планлаштыруның региональ норматив-хокукый базасын, үзгәрүчән социаль-икътисадый шартларга сизгер булып, даими актуальләштереп бара алачак.

Институт Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасына да, шулай ук Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең эшли торган фәнни-белем бирү структураларына да кертелергә мөмкин.

Фәнни тикшеренүләргә һәм һөнәри белем бирүгә ярдәм күрсәтә торган республика грант программалары кысаларында территориаль планлаштыруга ярдәм юнәлешен аерып күрсәтү, моңа тикшеренүләр башкаруга һәм эскизлар проектлауга грантлар, үсеш программасын проект рәвешендә эшләүгә субсидияләр кирә, максатка ярашлы булыр. Бу шәһәр төзелешен планлаштыручы дигән һөнәрне кире кайтару һәм үстерү өчен бик кирәк, чөнки киләчәк пространствосын проектлау билгеле бер дәрәҗәдә аның квалификациясенә бәйле булачак. Татарстан Республикасы, тиешле юнәлешне Россия базарында һәм халыкара базарларда махсуслашу өлкәсе буларак үстереп, әлеге бурычны хәл итүдә лидер ролен алырга мөмкин.

### 3.2.4. Пространстволы үсешнең флагман проектлары

#### 3.2.4.1. «Идел-Кама юнәлеше» экозонасы

Яр буе территорияләрен актив үстерү зонасы — «Идел-Кама юнәлеше» экозонасы — регион масштабындагы тармакара проект, ул Идел, Кама, Нократ һәм Агыйдел елгалары буенда урнашкан муниципаль районнарның су пространстволарын һәм яр буе ландшафтларын үстерүне комплекслы күзаллый (3.25 нче рәсем).



3.25 нче рәсем. «Идел-Кама юнәлеше» экозонасы

*Проектның максатлары:*

• республиканың су һәм яр буе ландшафтларына халыкның үтеп керә алуын тәэмин итү (җирдән файдалануны тәртипкә салу, туристлык-рекреация комплексларын, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын бетерү һәм эшкәртү системаларын, кулланган суны чыгару һәм, суга бару юлларын төзекләндереп, су юлларын чистарту системаларын булдыру, кечкенә судноларһәм туристлык флоты өчен причаллар төзү бурычларын хәл итү юлы белән);

• Татарстан Республикасының иң эре елгаларының су һәм яр буе ландшафтлары табигатеннән файдалану культурасын арттыру;

• яр буе территорияләрендә табигый һәм мәдәни кыйммәтләргә ярдәм күрсәтү һәм аларны капиталлаштыру;

• яр буе территорияләрен үстергәндә киләчәкне гомуми күзаллау аркылы синергетик нәтиҗәне тәэмин итү, идарә системасын камилләштерү һәм проектны тормышка ашыру нәтиҗәләренә мониторинг ясау.

*Проектның бурычлары:*

• региональ һәм җирле юллар челтәрен, шулай ук җәмәгать транспорты маршрутларын үстереп, яр буе ландшафтлары белән торак пунктларның тоташуын һәм аларга бара алуны тәэмин итү;

• инженерлык инфраструктурасын үстерү юлы белән кече шәһәрләрдә һәм экозона авылларында яшәү дәрәҗәсен күтәрү;

• сәнәгать предприятиеләре чыгарган зарарлы матдәләрне, сәнәгать һәм көнкүреш су юлларын чистарту системаларын кертү юлы белән һәм каты көнкүреш калдыкларын эшкәртүнең яңа технологияләрен кулланып, эре елгалар һәм яр буе территорияләре экосистемаларының куркынычсызлыгын тәэмин итү;

• туристлык һәм рекреация маршрутларын үстерү юлы белән җирле халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен, аның хезмәт күрсәтүләр өлкәсендәге икътисадый активлыгын арттыру, шулай ук яр буе җирлекләрендә шәһәр мохитенең сыйфатын яхшырту;

• яр буе торак пунктлары һәм аларның әйләнәсендәге территорияләр өчен пространство концепцияләрен һәм регламентларын төзеп, елга ярларында җирдән файдалану һәм төзелеш процессларын җайга салу;

• «чиста» производстволарны һәм «яшел сертификат»ы булган сервис компанияләрен стимуллаштырып, яр буе муниципаль районнары икътисадының үсешен һәм тотрыклылыгын тәэмин итү.

*Экозонаны үстерү принциплары*

Проект кысаларында гамәлгә ашырыла торган пространстволы үзгәртеп коруларның төп принциплары буларак экозонаның тотрыклы үсеше, халыкның бу процесста катнашуы, иң беренче чиратта гамәлдәге торак пунктлар һәм аларда яшәүче халык өчен социаль һәм икътисадый нәтиҗәлелек алынырга тиеш. Проектны планлаштырганда һәм тормышка ашырганда тарихи корылмаларга һәм ландшафтларга сак карау, җирле мәдәни институтларны үстерү аркылы җирле үзенчәлекләрне саклап калуга һәм арттыруга аерым игътибар бирергә кирәк.

***Гамәлләр юнәлешләре***

*Транспорт инфраструктурасы*

Экозона транспорт каркасының төп өлешен «Чиста юл» юлы (Казан – Алексеевск – Чистай – Кама Аланы – Түбән Кама) тәшкил итәчәк, ул регионның ике иң эре агломерациясен тоташтырачак һәм Кама һәм Идел елгалары су фронтының матур ландшафтларына һәм рекреация инфраструктурасына зур шәһәрләр халкының уңайлы килә алуын тәэмин итәчәк.

*Нигез (коммуналь) инфраструктура*

Нигез инфраструктураның (җылылык, су белән тәэмин итү, кулланган суны чыгару, электр энергиясе белән тәэмин итү, көнкүреш калдыкларын алып китү һәм утильләштерү) сыйфатын тигезләү республиканың эре шәһәрләре һәм авыл җирлеге халыклары арасындагы яшәү дәрәҗәсендәге аерманы киметү өчен кирәк. Проектның әлеге өлешен тормышка ашырганда сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гамәлгә ашырыла торган карарларның экологик характеристикалары һәм тотрыклылык дәрәҗәсе мөһим.

*Әйләнә-тирә мохитне саклау*

Чыгарыла торган зарарлы матдәләрне мониторинглау, чистарту һәм сәнәгать предприятиеләренең калдыкларын утильләштерү системасы экозонаның мәҗбүри бер өлеше булырга тиеш. Мондый системаны иң беренче чиратта Кама агломерациясендә кертергә кирәк (Түбән Кама һәм Менделеевск шәһәрләрендә нефть химиясе һәм химия предприятиеләре). Идел, Кама һәм Нократ елгаларына төшә торган су юлларын чистартуга аерым игътибар бирергә кирәк. Бу юнәлеш кысаларында Түбән Кама сусаклагычының перспективалы дәрәҗәсе турындагы мәсьәлә хәл ителергә тиеш.

*Туристлык маршрутлары*

Экозонаны үстерү драйверын туристлык-рекреация проектларын гамәлгә ашыру тәшкил итәргә мөмкин, алар экозона шәһәрләренең һәм авылларының тарихи үзәкләрендә дә, игътибарга лаек табигать урыннарында да тәүге үзгәрешләргә башлангыч бирәчәк. Бу проектларның җирле инициативаларга нигезләнеп төзелүе һәм базарга бердәй экозона бренды астында чыгуы мөһим. Нәтиҗә территориянең имиджы үзгәрүдә, аның Татарстан халкы арасында һәм аннан читтә популярлашуында күренәчәк. Бу эшкә җирле халыкны катнаштыру аларның үзләре яши торган мохиткә карашын үзгәртәчәк һәм җирле инициативаларны активлаштырачак.

*Яр буе территорияләренә килеп урнашу системасы һәм аларның яңа икътисады*

Проект бурычларының берсе яр буе территорияләренә килеп урнашу системасын әйләнә-тирә мохиткә зыян китермичә төзүдән гыйбарәт. Авыллар һәм бакчалар участоклары территорияләрен зур шәһәрләрдә яшәүчеләр икенче торак буларак актив үзләштереп баралар. Мондый территорияләр өчен яр линиясенә керүгә, энергия куллануга һәм эчке планлаштыруны оештыруга кагылышлы махсус таләпләр билгеләү максатка ярашлы була. Шулай ук экозонага керүче шәһәрләрнең яр буе зоналарына карата да билгеле бер планлаштыру тәкъдимнәре эшләнергә һәм кулланырга тиеш.

Туризм һәм рекреация эш башларга старт бирә торган төймә, үсешнең беренче драйверы ролен уйнаячак. Экозонада төп өстәлгән бәяне «яшел сертификат»лары булган яңа производстволар бирәчәк. Киләчәктә, шәһәр мохите һәм транспорт юллары дөрес үстерелгән очракта, яр буе территорияләренең тарихи шәһәрләре инновацион компанияләрне урнаштыруда эре агломерация үзәкләренә альтернатива була алачак.

*Җирле инициативаларны гамәлгә ашыруга идарә итү һәм координацияләү*

Проектны гамәлгә ашыру максатыннан муниципалитетара координацияләү советы төзеләчәк, ул сөйләшүләр алып бару һәм карарлар кабул итү өчен мәйдан булачак.

**3.2.4.2. «Чиста юл» проекты**

«Чиста юл» проекты, Татарстан Республикасында яңа өстәмә тизйөрешле элемтә булып, Казан шәһәрен, «Казан» халыкара аэропортын, Алексеевск шәһәр тибындагы поселогын, Чистай шәһәрен, Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогын, Түбән Кама шәһәрен, «Бегишево» аэропортын, Чаллы шәһәрен һәм, бәлки, Менделеевск шәһәрен үзара тоташтырачак (3.26 нчы рәсем).




3.26 нчы рәсем. «Чиста юл» проекты

Проектның асылы — Казан һәм Кама агломерацияләрен берләштерәчәк бердәм үсеш коридорын төзи торган яңа тизйөрешле транспорт элемтәсен булдыру «Идел — Кама юнәлеше» экозонасы проектын тормышка ашырырга ярдәм итәчәк. Проект Татарстан Республикасының үзәк өлешендә урнашкан халык саны аз булган, үсешнең рекреацион, тарихи-мәдәни, экологик югары потенциаллары, аеруча Кама елгасының су фронтына чыгу урыннары булган һәр муниципаль районның мөмкинлекләрен гамәлгә ашырырга этәргеч бирәчәк. Бу районнарда шулай ук кече шәһәрләр — индустриаль үзәкләр һәм агробизнесны үстерүгә юнәлеш алган үзәкләр бар, алар барысы да транспорт элемтәләрен яхшыртуга мохтаҗ.

Проект гамәлдәге автомобиль юлларын, барлык торак пунктларны әйләнеп узу юлларын төзеп, реконструкцияләүне күз алдында тота. Яңа тизйөрешле автомобиль юлы (хәрәкәт полосаларының саны һәр якка кимендә икешәр) Казан белән Сорочьи Горы авылы янындагы Кама елгасы аша күпер арасындагы транспорт элемтәсен күпкә яхшыртачак, бу шулай ук Казан — Әлмәт һәм Казан — Самара арасындагы элемтәгә уңай йогынты ясаячак. Түбән Кама шәһәре тирәсендә әлеге юл Кама агломерациясенең агломерация эчендәге юллар системасына тоташтырылачак. Бу магистральдә транспортны автоматлаштырылган рәвештә алып бару технологияләрен, мәсәлән, «акыллы» юл технологиясен, кулланып карау мөмкин булачак.



### 3.3. Икътисад: кластерлы активлашу стратегиясе

### 3.3.1. Икътисадый сәясәт: кеше капиталын нәтиҗәле файдалану шартлары

Икътисадның үсеше иң элек җәмгыятьтә продуктив эшчәнлеккә стимуллар булуга, шулай ук үз кулларына лидерлыкны алырга һәм тәвәкәллекләргә әзер кешеләрнең булуына бәйле. Кеше капиталын булдыру белән бергә эшкуарларга — табыш алу өчен тәвәкәллекләргә баруны таләп итә торган ирекле, инициативалы эшчәнлек белән шөгыльләнүче субъектларга Татарстан Республикасында бизнес алып бару өчен максималь уңай шартлар тудырырга кирәк. Бизнес лидерлары, инноваторлар һәм креатив класс белән беррәттән, — икътисадый үсешнең төп драйверлары. Аларның үз-үзләрен канәгатьләндерә алуы өчен уңай шартлар тудыру, аларны җәлеп итү һәм калдыру өчен башка регионнар белән конкуренциядә җиңеп чыгу — мөһим мәсьәлә.

Татарстан Республикасының глобаль конкурентлыкка сәләтле булуы — предприятиеләрнең глобаль конкуренциядәге уңышы. Татарстан Республикасы иң эре трансмилли корпорацияләр өчен, аларның партнеры булу һәм аларның бизнесын республика территориясендә алып баруны оештыру өчен ачык булырга, «Идел — Кама» үсеш полюсы кысаларында аларның кушылып китүе өчен мәйдан булып торырга тиеш. Глобаль конкуренциядә уңышка ирешүнең мөһим шарты Татарстан Республикасының бизнес мохитенә бизнес һәм технологик партнерлар сыйфатында иң эре дөньякүләм уенчыларын җәлеп итүдән гыйбарәт, бу исә Татарстан эшкуарларына халыкара хезмәт бүленешенә керергә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы дөньяның, Россиянең һәм Татарстанның иң эре компанияләре рейтингында иң югары баскычларга менү өчен регион предприятиеләренә һәм эшкуарларына стимул биреп торырга тиеш. Төп мөмкинлекләр хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә ачыла. Шулай итеп, дөньяның 100 иң эре компаниясе структурасында хезмәт күрсәтүләргә туры килә торган өлеш Россиянең һәм Татарстан Республикасының 100 иң эре компаниясе структурасындагы хезмәт күрсәтүләр өлкәсенә туры килә торган өлештән күпкә зуррак. Әйдәүче дөньякүләм компанияләрнең тармаклар буенча махсуслашуына анализ яңа базар юнәлешләре: финанс һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләр, телекоммуникацияләр, фармацевтика, мәгълүмат технологияләре, шулай ук электр җиһазларын җитештерү (бу тармакта яңа технологияләр, беренче чиратта нано- һәм биотехнологияләр кулланылуга бәйле рәвештә яңа мөмкинлекләр ачыла) барлыкка килүне күрсәтә (3.27 нче рәсем).

Конкурентлыкка сәләтле булуны арттыру буенча икътисадый сәясәтнең төп билгеләнеше бизнесның барлык төрләре өчен уңай шартлар, шулай ук аерым бер юнәлешләрдә һәм тармакларда үсеш өчен стимуллар булдырудан гыйбарәт. Либераль һәм дирижистик схемаларның бергә дөрес кулланылышы барлык төр (кече, урта һәм эре) эшкуарлар катнашканда гына, бөтен эшкуарлык бергәлеге мәнфәгатьләрен килештергәндә генә табыла ала.






Чыганак: Аналитика AV Group. Forbes Global 2000 Leading Companies, Эксперт-400, «Рейтинг крупнейших компаний Татарстана 2013» («Деловой Квартал» (DK)), «Топ-300 крупнейших компаний Татарстана» («БИЗНЕС ONLINE»)

**3.27 нче рәсем. Дөньяның, Россиянең һәм Татарстан Республикасының 100 иң эре предприятиесе структурасын (керем буенча) төп тармаклар буенча чагыштыру**

Икътисадый мөнәсәбәтләрне һәм институтларны үстерү өлешендә стратегик максат түбәндәгечә билгеләнә.

<u>СЦ-4</u> **Дәүләт, хосусый һәм дәүләти-хосусый институтларның тигез нисбәтле системасы конкурентлыкка сәләтле кластерларның, эшкуарлыкның (кече һәм урта бизнес) тотрыклы үсешен, эчке территориаль үсешне һәм тышкы кушылуны тәэмин итә.**

Шул ук вакытта уртак идеяне, ресурсларны дөрес тупларга мөмкинлек бирә торган комплекслы якын килүне табу мөһим. Хәзерге дөньяда конкурентлыкка сәләтне үстерүне стимуллаштыруның иң нәтиҗәле механизмы дип кластерлы якын килү танылды. Бүген алга киткән илләрдә кластерлар кысаларында икътисадның 50 процентган артыгы үсә һәм хезмәт белән шөгыльләнүчеләрнең 40 процентган артыгы туплана.

Кластерлы якын килү түбәндәгеләрне күз алдында тота:

• гамәлдәге индустриаль (аеруча сәнәгать) кластерларына бәйле рәвештә инновацион кластерлар булдыруны. Гамәлдәге индустриаль кластерларның инновацион потенциалы инновацион кластерларны үстерүгә стимул бирәчәк;

• бер-беренә кушылган технологик чылбырлар төзүне, алар республикада чыгарыла торган өстәмә бәянең өлешен арттыруны тәэмин итә;

• дәүләтнең икътисадый үсешкә катнашуының актив алымнарын кулланып, макроикътисадый җайга салудан сәнәгать сәясәтенә, технологик һәм кластерлы сәясәткә күчүне;

• эчке һәм тышкы базарларга үз товарларыбызны чыгаруда дәүләт ярдәмен;

• кластер сәясәтен эшләү процессына һәм чик буе территорияләре кластерларын төзүгә регионара кушылуны;

• вузлар, тикшеренү институтлары һәм бизнес арасында үсешне стимуллаштыруның, белем бирү һәм эшкуарлык үзәкләренә эре чит ил фирмаларын җәлеп итүнең дәүләт сәясәтен;

• университетлар базасында һәм тирәсендә конкурентлыкка сәләтле һәм югары технологияләр үзәкләре, технополислар төзүне;

• инновацион технологияләргә нигезләнгән кластерлар булдыру ярдәмендә артта калган территорияләрне «тарту»ны.

Татарстан Республикасында берничә ел дәвамында инде кластерлы якын килү гамәлгә ашырыла, республика икътисадын үстерүдәге төп нокта буларак билгеләнгән Кама инновацион территориаль-җитештерү кластеры (Кама кластеры) төзелде. Әлеге кластерның инвестицияле проектларын гамәлгә ашыру сәнәгать җитештерүе күләмен өч тапкырга арттырырга һәм аны ике триллион сумга кадәр җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.



Кама кластеры икътисадын үстерүдә төп әһәмият «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә сәнәгать-производство тибындагы «Алабуга» махсус икътисадый зонасына (алга таба — «Алабуга» СПТ МИЗ) бирелә, аның территориясендә хәзер 15 заманча завод эшли, инвесторлар тарафыннан 86 млрд. сум акча кертелде, 5 меңнән артык эш урыны булдырылды. Монда югары технологияле продукция — автомобильләр, җылылык изоляцияләү продукциясе, МДФ плитәләре, табак пыяла, пыялалы сүс һ.б. чыгарыла, алар иң элек импортны алмаштыру өчен билгеләнгән.

Татарстан Республикасының тышкы икътисадый мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә Татарстан Республикасының вәкаләтле, даими һәм сәүдә-икътисад вәкиллекләре эше нәтиҗәле корал булып тора. 2015 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының 15 вәкиллеге якын һәм ерак чит ил дәүләтләрендә һәм Татарстан Республикасының сигез вәкиллеге Россия Федерациясе субъектларында эшли. Барлык вәкиллекләрнең төп бурычларына Татарстанның сәүдә-икътисадый мәнфәгатьләрен тәкъдим итү һәм шул илләр һәм регионнар белән ике як өчен дә файдалы хезмәттәшлекне үстерү, шулай ук республика икътисадын үстерүнең төп юнәлешләренә ярдәм итү өчен потенциаль партнерларны һәм инвесторларны эзләү керә.

Дөнья тәҗрибәсе һәм Татарстанның уңышлы тәҗрибәсе Татарстан Республикасының икътисадый сәясәте токтасы итеп ***кластерлы активлашуны*** алу өчен нигез бирә, кластерлы активлашу дигәндә кластерларга һәм кластерлар төзи торган процессларга ярдәм күрсәтү, заманча икътисадны модернизацияләү һәм кооперация белән дәүләти-хосусый партнерлыгы механизмнары нигезендә «акыллы» икътисад булдыру ярдәмендә регионда конкурентлыкка сәләтне арттыруга һәм икътисадый үсешкә юнәлтелгән дәүләт икътисадый сәясәте аңлашыла.

Кластерлы активлашу нигездә икътисадый үсешне һәм регионара, халыкара базарларда югары конкурентлыкка сәләтлелекне тәэмин итә ала торган өстенлекле юнәлешләрдә күзәтелә.

Татарстан икътисадын бүгенге көнгә төп өч өлешкә бүләргә була:

• ***традицион икътисад*** (нигездә өченче технологик торыш);

• ***заманча икътисад*** (нигездә дүртенче технологик торыш);

• ***«акыллы» икътисад*** (бишенче — алтынчы технологик торышларның бергә килүе).

Традицион икътисад — XX гасыр уртасында технологик торышларның лидерлыгын югалткан икътисад, ул эш белән тәэмин итүнең, башлыча аграр өлкәдә, төп чыганагы булып тора. Заманча икътисад — кулланудан чыга торган технологик торышлар икътисады, бүген ул эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсе

югары булганда регионның база инфраструктурасы йөкләнешен һәм эшләвен тәэмин итә. Яңа инновацион «акыллы» икътисад, аның нигезен көч туплый торган бишенче технологик торыш һәм туып килә торган алтынчы технологик торыш тәшкил итә, киләчәктә Татарстан Республикасының лидерлыгына һәм үзүзен канәгатьләндерә алуына нигез була.

Заманча икътисад үсешенең чиге бар, стратегик перспективада аның өстәлгән бәясенең уртача еллык артымы елына 1,5 — 2 процентлы коридор белән чикләнәчәк. Әлеге чикне *«кызгылт сары сызык»* дип атыйк (3.28 нче рәсем). Аның булуы Татарстан икътисадының соңгы кулланучыны аз күз алдында тоткан күп тонналы/зур серияле җитештерүгә нык бәйле булуы белән аңлатыла (төп җитештерү куәтләре совет чорында ук төзелгән иде һәм советтан соңгы чорда да уңышлы эшләп килделәр).

«Кызгылт сары чик»не узып китүнең төп механизмын кластерлы активлашу тәшкил итәчәк.

Кластерлы активлашу ***индустриаль эволюциягә*** — локаль производстволар үстерүне стимуллаштыру аркылы конкуренцияне вакытлы чикләүдән (импортны алмаштырудан) ачык конкуренция базарында экспортка юнәлеш алган тотрыклы үсешкә күчәргә этәргеч бирәчәк.

Кластерлы активлашу эшкуарлыкның һәм инновацияләрнең экосистемаларын төзү сәясәтенә, инвестиция сәясәтенә яңа сыйфатлар өсти.




**3.28 нче рәсем. «Кызгылт сары сызык» заманча икътисадны һәм «акыллы» икътисадны аерып тора**



### 3.3.2. Эшкуарлык экосистемасы

***Хәзерге торыш***

Татарстан Республикасы актив эшчәнлеге һәм алдагы буыннар салган нигез нәтиҗәсендә соңгы елларда икътисад үсешендә һәм халыкның яшәү дәрәҗәсен арттыруда югары күрсәткечләргә иреште. 2014 ел йомгаклары буенча тулаем төбәк продукты күләме 1,6 трлн. сумнан артып китте, төп капиталга инвестицияләр соңгы биш елда 2,26 трлн. сум булды. Икътисадның диверсификация дәрәҗәсе арта бара: соңгы биш елда сәнәгать җитештерүе күләмендә эшкәртү секторының өлеше 58 алып 70 процентка кадәр, экспортның гомуми күләмендә чимал булмаган экспорт өлеше 35 алып 60 процентка кадәр артты.

Кече һәм урта эшкуарлыкның (алга таба — КУЭ) үсеш күрсәткечләре буенча республика Россиядә алдынгы урыннарны били. Татарстан Республикасы КУЭ — 480 меңнән артык кешене (икътисад өлкәсендә эшләүче барлык халыкның чиреге) эш урыннары белән тәэмин итүче 140 меңгә якын субъект ул. 2014 ел йомгаклары буенча республика икътисадында КУЭ өлеше 25,5 процент тәшкил итте (дөньяның алга киткән илләрендә әлеге күрсәткеч 40 процент белән 70 процент арасында тирбәлә).

Татарстан алып бара торган сәясәт аңа Россия регионнары арасында эшкуарлыкка ярдәм инфраструктурасы объектлары саны буенча, боларга махсус икътисадый зоналар, индустриаль парклар һәм технопарклар, дәүләт бизнес-инкубаторлары, яшьләр инновацион иҗат үзәкләре һәм башкалар керә, алдынгы булырга мөмкинлек бирә. Бүген эшкуарлыкка ярдәм итү иң мөһим өстенлекләрнең берсе булып тора. Республикада ел саен әлеге максатларга ике млрд. сумнан артык акча тотыла. КУЭка финанс ярдәменең соңгы өч елда 8,5 меңнән артык яңа эш урыны булдырган «Лизинг-грант» программасы, гарантия һәм микрофинанс фондлары, максатчан субсидияләр бирү кебек формалары һәм башка программалары бар. «Химград» Технополисы кече һәм урта инновацион югары технологияле компанияләрнең үз производстволарын үстерү өчен эре мәйдан булып тора, анда 215 профильле компания урнашкан. Полимерларны эшкәртү өлкәсендә Татарстан Республикасы Кластерлы үсеш үзәге төзелә.

Эшкуарлыкны үстерү — республиканың институциональ мохитен камилләштерүнең төп максатларның берсе һәм үзәк өлеше.

***Төп мәсьәләләр:***

• кластерлы активлашу сәясәте эшкуарлык үсешенә яңа күзлектән карарга мөмкинлек бирә. Конкурентлыкка сәләтле кластер — үзара бәйләнгән эре, урта һәм кече бизнес. Шул ук ва-

кытта аеруча инновацион юнәлешләрне һәм хезмәт күрсәтүләр, шул исәптән финанс һәм һөнәри, туристлык-рекреация хезмәт күрсәтүләре, комплексын үстерүдә, шулай ук кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль һәм көнкүреш сервислары өлкәсендә КУЭ роле бик зур. Бүген КУЭ эре корпорацияләр һәм холдинглар кысаларында бизнес төзү формасы буларак нәтиҗәле кулланыла;

• КУЭның иң перспективалы һәм нәтиҗәле формаларын профессионал сервис компанияләре тәшкил итә, чөнки аларга югары эшкуарлык культурасы, проектка таянып идарә итүне куллану, команда белән эшләү принциплары, хезмәткәрләргә өзлексез белем биреп тору һәм аларны камилләштерү, эш белән тәэмин итүнең сизгер формалары, продуктларны һәм хезмәт күрсәтүләрне персоналлаштыру, инновациялелек, партнерлар һәм конкурентлар белән үзара багланышлар кора алу хас;

• Татарстан Республикасында КУЭка ярдәмнең инновация-инвестиция инфраструктурасын үстерү дәүләт финанславы хисабына гына түгел, ә эре бизнес — кече предприятиеләр товарларын һәм хезмәт күрсәтүләрен потенциаль иң эре кулланучы хисабына да башкарылырга тиеш. Бу исә базар ихтыяҗларына эре компанияләрнең җайлаша алуын арттырырга, кече һәм урта бизнес белән субконтракт мөнәсәбәтләренең эшли торган системасын корырга һәм, иң мөһиме, кече һәм урта бизнесны җитештерү өлкәсенә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

Татарстан икътисадында профессинал сервис фирмаларының өлешен һәм ролен арттыру — үсешнең өстенлекле юнәлешләреннән берсе. Мондый фирмалар өчен, тулаем бизнес өчен булган кебек үк, уңай хуҗалык климаты, эшкуарлык экосистемасы кирәк.

**Ц-4.3** **Татарстан — КУЭ өлеше югары булган бизнес алып бару өчен уңайлы регион.**

*З-4.3.0.1* Татарстан Республикасында эшкуарлыкның кадрлар потенциалын үстерүне, эшкуарлык инициативасының үсешен һәм эшкуарларның кеше капиталыннан файдалана алуын киңәйтүне стимуллаштырырга.

*З-4.3.0.2* Эшкуарлар өчен (КУЭ субъектларын да кертеп) инфраструктураның һәм фондларның сыйфатын һәм һәркем өчен ачык булуын тәэмин итәргә.

*З-4.3.0.3* Эшкуарлык субъектларын бизнесның базардагы өлешен киңәйтүгә һәм нәтиҗәлелеген арттыруга стимуллаштырырга.

*З-4.3.0.4* Административ каршылыкларны киметергә һәм бизнес алып бару өчен максималь уңай шартлар тудырырга; бизнеска һәм эшкуарлыкка ярдәм өлкәсендә хезмәттәшлекне һәм координацияне ныгытырга.

*З-4.3.0.5* Инновацияләрнең бербөтен уңай экосистемасын төзергә, инновацион эшкуарлыкның өлешен арттырырга.

*З-4.3.0.6* Эшкуарларның (КУЭ субъектларын да кертеп) табигать ресурсларыннан тигез файдалана алуын тәэмин итәргә.

*З-4.3.0.7* Финанс ресурсларыннан һәркем файдалана алуны арттырырга, эшкуарлыкка ярдәмнең финанс механизмнарын камилләштерергә; инвестиция-финанс өлкәсендә эшкуарлык үсешен стимуллаштырырга (КУЭ субъектларын да кертеп).

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) «Кеше капиталы» юнәлеше буенча:

• Татарстан Республикасы уку йортларында эшкуарлыкка һәм лидерлыкка өйрәтү;

• кыска вакытлы махсус яңадан әзерлек программаларын да кертеп, эшкуарлык субъектлары өчен уку-укыту программалары системасын үстерү;

• тармак ресурс үзәкләрен төзү;

• кадрларны әзерләү һәм уртак программаларны гамәлгә ашыру буенча КУЭ белән ике як өчен дә файдалы мөнәсәбәтләрне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы, Чаллы шәһәре һәм Кама аръягы төбәге Сәүдә-сәнәгать палатасы һәм Әлмәт шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы каршында кадрлар үзәкләрен төзү;

• Татарстан Республикасына эшкуарлар җәлеп итү;

• региональ хезмәт базары кысаларында эш белән төрлечә тәэмин итүнең яңа формаларын үстерүне стимуллаштыру;

2) «Пространство, реаль капитал» юнәлеше буенча:

• эшкуарларга (КУЭ субъектларын да кертеп) ярдәмнең инновация-инвестиция инфраструктурасының яңа объектларын төзү һәм булганнарын үстерү;

• эшкуарларның (КУЭ субъектларын да кертеп) инфраструктурадан файдалана алуын тәэмин итү;

• төп фондларның эшкуарлар (КУЭ субъектларын да кертеп) тарафыннан яңартылуын стимуллаштыру;

3) «Базарлар» юнәлеше буенча:

• Татарстан Республикасында эре, урта һәм кече эшкуарлыкның үсешенә даими рәвештә диагностика үткәреп тору (кварталлык гавами хисап төзеп);

• Татарстан Республикасы бизнесының әйдәүче

дөньякүләм һәм Россия трансмилли компанияләре белән үзара хезмәттәшлеген киңәйтүне стимуллаштыру;

• КУЭ субъектларының республиканың эре предприятиеләре белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны стимуллаштыру; эре дәүләт корпорацияләре тарафыннан КУЭдан товарлар сатып алу планнарының аңлаешлылыгын һәм ачыклыгын тәэмин итү;

• дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контрактлар төзүдә булышлык күрсәтү, контракт системасына КУЭ субъектларын җәлеп итүне киңәйтү; Татарстан Республикасының бюджет өлкәсенә караган барлык предприятиеләрен товарларны җирле товар җитештерүчеләрдән сатып алуга стимуллаштыру; импортны алмаштыруда кече һәм урта компанияләрнең катнашуын киңәйтү;

• тышкы икътисадый элемтәләрне үстерү, КУЭ субъектлары җитештерә торган продукцияне региональ һәм чит ил базарларына чыгару өчен шартлар тудыру;

• аерым өлкәләрдә КУЭ үсешен стимуллаштыру (яшьләр эшкуарлыгы, социаль эшкуарлык һ.б.);

4) «Институтлар» юнәлеше буенча:

• эшкуарлык субъектларына дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын арттыру;

• республика территориясендә эшкуарлык субъектларына кагылышлы контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең сыйфатын күтәрү (тикшерүләрнең бердәм реестрын төзү, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру концепциясен гамәлгә ашыру; КУЭ субъектларына штрафлар рәвешендәге артык йөкләнешне киметү; эшкуарлык субъектларына карата антимонополь нормаларны нигезсез куллану тәҗрибәсен тикшерүдә тоту);

• эшкуарлык эшчәнлегенә икътисадый актив халыкны җәлеп итү;

• яңа бизнеслар булдыруны стимуллаштыру;

• эре бизнеслар кысаларында профессионал сервис компанияләрен булдыруны / бүлеп чыгаруны стимуллаштыру (бизнес-аутсорсингны стимуллаштыру);

• «Эшкуар йорты» порталын булдыру һәм үстерү (бүлекләрне «бер тапкыр басып алу» принцибы буенча төзеп: «Сату базарларын үстерү»; «Эшкуарлыкка ярдәм механизмнары һәм институтлары»; «Кеше капиталын үстерү»; «Инновацион эшкуарлык»; «Табигатьтән тотрыклы файдалану»; «Инфраструктураны һәм пространствоны үстерү»; «Финанслауны җәлеп итү»);



• Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә эшкуарлык инициативаларын социаль-икътисадый үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып үстерү гамәлләрен планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

• КУЭ ярдәм итү буенча дәүләт сәясәтен алга җибәрү (КУЭ имиджы буенча коммуникатив стратегия эшләү; эшкуарлык эшчәнлеген пропагандалау (шул исәптән яшьләр эшкуарлыгын үстерүгә басым ясап); эшкуарларның ярдәм чаралары һәм программалары турында хәбәрдарлыгын арттыру (интернет-коммуникацияләрне үстерү, дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре базасында эшкуарларга мәгълүмат бирү системаларын төзү, эшкуарлыкка ярдәмнең иң яхшы тәҗрибәләрен тиражлау, гамәлгә ашырыла торган чаралар буенча навигация системаларын үстерү);

• Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә эшкуарлыкны үстерү һәм инвестицияләр җәлеп итү буенча бүлекләр төзү һәм үстерү;

• бизнес белән хакимият арасында нәтиҗәле үзара хезмәттәшлек өчен эшкуарларның тармак ассоциацияләрен төзү һәм үстерү;

• эшкуарлар өчен даими эшли торган мәйданнар булдыру;

5) «Инновацияләр» юнәлеше буенча:

• технологияләр трансферына булышлык күрсәтү;

• дөньяда өч елдан кимрәк кулланыла торган алдынгы технологияләрне яисә тиешле тармакта кулланылышы 15 процентган артмаган технологияләрне куллануны стимуллаштыру, шулай ук фәнни уйлап табуларның коммерцияләшүенә ярдәмне тәэмин итү;

• КУЭ предприятиеләрендә җитештерүне сак башкару принципларын кертүне стимуллаштыру;

• яшьләр инновацион технопаркын төзү;

• инновацион эшкуарлыкны стимуллаштыру; патентка ия булучыларны һәм инновацион проектларны алга таба үстерү максатыннан аларның республика реестрын төзү;

• эшкуарлык субъектларының инновацион проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү;

• яңа инновацион продуктлар һәм материаллар куллануга рөхсәт бирә торган документацияне алдан әзерләү системасын төзү;

6) «Табигать ресурслары» юнәлеше буенча:

• эшкуарлар өчен (КУЭ субъектларын да кертеп) табигать ресурслары белән эш итү кагыйдәләреннән һәркем тигез файдалана алуны, аларның тотрыклылыгын һәм ачыклыгын тәэмин итү;

7)	«Финанс капиталы» юнәлеше буенча:

• региональ КУЭ субъектларының федераль ярдәм программаларына максималь керүен тәэмин итү;

• Татарстан Республикасының КУЭ инвестиция меморандумын төзү һәм аны квартал саен актуальләштерү;

• КУЭ субъектлары проектларын гамәлгә ашыру өчен инвестицияләр җәлеп итү белән бергә башкарыла торган гамәлләр җыелмасын җентекләп өйрәнү;

• экспортка ярдәм механизмнарының (финанс, инфраструктура, социаль) максималь тулы җыелмасын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

• эшкуарлык инициативаларын финанслауның башка төрле чыганакларын (краудфандинг, венчурлы финанслау, стартапларны дәүләт тарафыннан кредитлау һ.б.) үстерү;

• инвестиция-финанс өлкәсендә һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә эшкуарлыкны үстерүне стимуллаштыру.

**3.3.3. Инвестиция сәясәте**

***Хәзерге торыш***

2014 елда Россия регионнарында инвестицион климатның торышына илкүләм рейтинг йомгаклары буенча Татарстан Республикасы бизнеста инвестицияләр өчен иң уңайлы шартлар тәэмин итә торган Россия Федерациясе субъектлары бишлегенә керде. Актив инвестиция сәясәте төп капиталга инвестицияләр күләменең югары дәрәҗәдә булуын тәэмин итә. 2009 – 2013 еллар чорына динамикалы үсеш хас булды, аның нәтиҗәсендә республикада төп капиталга инвестицияләр күләме, 2013 елда 520,2 млрд. сумга җитеп, ике тапкырга артты. Шул ук вакытта 2014 елда инвестиция процессы тукталып тору тенденциясе күзәтелде. Ел йомгаклары буенча төп капиталга инвестицияләр күләме 542,8 млрд. сум, ягъни 2013 елның чагыштырыла торган бәяләренең 100 процентын тәшкил итте. Татарстан Республикасы Инвестиция советы, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, тармак министрлыклар, ведомстволар, консалтинг оешмалар, Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы һ.б. Татарстан Республикасында инвестиция процессының төп субъектлары булалар.

Хәзерге вакытта Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнарының уңай инвестиция климатын тәэмин итү эшчәнлеге стандартын (алга таба – Стандарт) актив кертеп җибәрү процессы бара. Татарстан Республикасында Стандартны үтәү кысаларында Инвестиция стратегиясе расланды (2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программасы нигезендә), анда Стандарт белән расланган барлык нормалар да җентекләп тикшерелде.



Инновация-инвестиция инфраструктурасын үстерүнең уңышлы мисалы буларак кече һәм урта җитештерү предприятиеләрен урнаштыру өчен 2004 елда «Мастер» Кама индустриаль паркын («КИП «Мастер» ААҖ) төзүне китерергә була. Хәзерге вакытта КИП «Мастер»дагы резидент компанияләрнең гомуми саны 244 берәмлек тәшкил итә, алар 4 989 эш урынын тәэмин итә.

Татарстан Республикасында шулай ук югары технологияләр өлкәсендәге беренче технопарк – Казан һәм Чаллы шәһәрләрендәге үз мәйданчыклары булган «ИТ-парк» эшләп килә. 2014 ел йомгаклары буенча 157 предприятие ИТ-парк резидентлары булып тора, аларда 3860 кеше эшли. «Алабуга» СПТ МИЗ уңышлы эшли, ул беренче чиратта эре инвесторларны җәлеп итү өчен билгеләнгән, бер үк вакытта эре һәм кече бизнес кооперацияләрен үстерү өчен яхшы мөмкинлекләр бирә. 2014 ел торышы буенча «Алабуга» СПТ МИЗ территориясендә 42 резидент компания теркәлгән.

Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә Россиянең ИТ-башкаласын – дөнья картасында яңа шәһәр төзү максатында «Иннополис» техник яңалык кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы төзелде, монда иң яхшы инновацион чишелешләр уйлап табыла һәм коммерцияләштерелә. «Иннополис» проекты кысаларында «Иннополис» университетын, торак һәм коммерция инфраструктурасын үстерү буенча аерымланган инвестиция проектлары гамәлгә ашырыла.

Инновацион икътисадны формалаштыру «акыллы» икътисад инновацион кластерлары кысаларында инжиниринг үзәкләрен үстерүгә нык бәйле булачак. Шулай итеп, берничә алдынгы региональ инжиниринг үзәге («КАИ-ЛАЗЕР» үзәге, «Эйдос» медицина фәне үзәге һ.б.) төзелде дә инде.

Республикада төзелгән инновация-инвестиция инфраструктурасы объектлары, тулаем алганда, үзләренең нәтиҗәлелеген күрсәттеләр. Бүгенге көн алдында муниципаль берәмлекләрдә сәнәгать мәйданчыкларын үстерү бурычы тора. Хәзерге вакытта 40 ка якын мәйданчык эшли. Резидентлар җәлеп итү һәм мәйданнарны тулысынча тутыру буенча эшне активлаштырырга кирәк.

***Төп мәсьәләләр:***

• дәүләт хакимияте органнарының инвестицияләр җәлеп итү һәм аларның нәтиҗәлелеге мәсьәләләренә җитәрлек дәрәҗәдә

игътибар бирмәве. Инвестицияләр өлкәсендә махсуслашкан орган өстенлекле инвестиция проектлары белән «бер тәрәзә» режимында һәм дәүләти-хосусый партнерлык принципларында эшләү буенча үзендә булган вәкаләтләрне тулысынча гамәлгә ашырмый;

- инвестиция портфеленең нисбәтсезлеге;
- инвестиция проектларының бердәм региональ мәгълүматлар базасы булмау;
- Татарстан Республикасында эшли торган финанс институтларының һәм профессионал инвесторларның эшчәнлеге тиешле дәрәҗәдә координацияләнмәү;
- заманча икътисадны модернизацияләү өлкәсендә оешкан инвестиция сәясәте, аның диверсификациясе булмау һәм «акыллы» икътисад төзелмәү, социаль системаның һәм инфраструктураның модернизацияләнмәве;
- халыкның финанслар буенча белем дәрәҗәсе түбән булу.

*Максатчан күзаллау һәм бурычлар*

**<u>СЦ-7</u>** **Татарстан Республикасы дөньякүләм дәрәҗәдә инвестиция ягыннан кызыклы. Финанс системасы югары нәтиҗәле.**

**Ц-7.1** **Финанс ресурсларының югары дәрәҗәдә һәркем файдалана алырлык булуы (инвестицияләр өчен бик кызыклы булу һәм инвестицияләр нәтиҗәлелеге).**

**Ц-7.2** **Финанс системасының югары нәтиҗәлелеге.**

*З-7.0.0.1* Финанс системасы өчен яхшы кадрларны җәлеп итүне тәэмин итәргә; бизнесның һәм халыкның финанслар буенча белем дәрәҗәсен арттырырга.

*З-7.0.0.2* Инвестиция инфраструктурасының һәм фондларның сыйфатын һәм һәркем өчен ачыклыгын күтәрергә.

*З-7.0.0.3* Инвестиция базарын үстерүне һәм инвестиция ресурсларының һәркем файдалана алырлык булуын арттыруны стимуллаштырырга.

*З-7.0.0.4* Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының инвестиция үсешенә сыйфатлы катнашуын тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.5* Инновацион алымнар һәм инвестицион үсеш кораллары кулланууда алдынгылыкны тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.6* Өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында табигать ресурсларыннан һәркемнең бертигез файдалана алуын тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.7* Инвестиция системасының финанс механизмнарын камилләштерергә; инвестиция процессында өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыра торган катнашучыларны стимуллаштыруны тәэмин итәргә; дәүләт ярдәме кораллары исемлеген киңәйтергә.



***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) «Кеше капиталы» юнәлеше буенча:

- инвестиция системасына сыйфатлы белгечләрне (дөньякүләм йолдызларны да кертеп) җәлеп итү;
- Татарстан Республикасы халкының инвестицияләр өлкәсендә белемен үстерү;

2) «Пространство, реаль капитал» юнәлеше буенча:

- финанс, инвестиция һәм һөнәри хезмәтләр күрсәтү инфраструктурасын үстерү;
- инновация-инвестиция инфраструктурасы объектларын үстерү һәм алар белән нәтиҗәле идарә итүне тәэмин итү;
- инновация-инвестиция инфраструктурасы объектлары кысаларында бизнес үстерүне стимуллаштыру;

3) «Базарлар» юнәлеше буенча:

- Татарстан Республикасының глобаль инвестиция ягыннан кызыклы булуын билгеләү һәм фараз системасын төзү;
- Татарстан Республикасы финанс системасының нәтиҗәлелеге дәрәҗәсен билгеләү; финанс системасының нәтиҗәлелегенә мониторинг ясау системасын раслау;
- Татарстан Республикасының инвестицион үсешенә диагностика үткәреп тору (кварталлык гавами хисап төзеп);
- Татарстан Республикасының инвестицион меморандумын төзү һәм квартал саен актуальләштереп тору;
- тулаем республиканың инвестиция ягыннан алга китүендә һәм өстенлекле проектлар портфелендә катнашу; инвестицияләр җәлеп итүдә катнашу;
- инвестиция өлкәсендә административ каршылыкларны бетерү;

4) «Институтлар» юнәлеше буенча:

- инвестиция процессы барышында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм инвестиция эшчәнлегенең башка субъектларының нәтиҗәле эшләвен һәм үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- инвестиция проектларын «бер тәрәзә» режимында һәм дәүләти-хосусый партнерлык принципларында сыйфатлы алып баруны тәэмин итү;
- финанс чараларын җәлеп итү һәм Татарстан Республикасы Инвестиция фондыннан нәтиҗәле файдалану;
- инновация-инвестиция инфраструктурасы объектлары резидентлары ихтыяҗлары өчен Гарантияле экспорт фондын төзү;
- инвестицияләр буенча эшкуарлык инициативаларын стимуллаштыру;
- дәүләти-хосусый партнерлыкның инвестиция механизмнарын үстерүне стимуллаштыру;

5) «Инновацияләр» юнәлеше буенча:

• инвестицияләрнең заманча механизмнарын һәм коралларын кертүне стимуллаштыру;

• инновацион проектларга инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм күрсәтү;

• инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыруның мәгълүмат мохитен үстерү;

6) «Табигать ресурслары» юнәлеше буенча:

• өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыру кысаларында табигать ресурслары белән эш итү кагыйдәләренең тотрыклылыгын һәм ачыклыгын тәэмин итү;

7) «Финанс капиталы» юнәлеше буенча:

• инвестицияләргә әзерлекнең югары дәрәҗәсендәге өстенлекле инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә (оешмаларга) дәүләт ярдәме күрсәтү; дәүләт ярдәме кораллары исемлеген киңәйтү;

• нигез икътисадый комплексларны үстерүнең дәүләт программалары кысаларында инвестицияләр җәлеп итүгә кушылу чараларының җыелмасын җентекләп өйрәнү.

Инвестицияләр өлкәсендә махсуслашкан орган инвестиция проектларына кушылуның тулысынча «бердәм тәрәзә» ролен башкарырга тиеш, аның кысаларында бизнес үсешенең барлык баскычларында ярдәм алымнарыннан һәркем файдалана алуга, эшкуарлык үстерүнең региональ, федераль һәм халыкара программаларында катнашуны да кертеп, булышлык күрсәтелә, инвестиция һәм венчур фондларының, «бизнес-ангелларның», үсеш институтларының, хосусый инвесторларның, кредит-финанс оешмаларының акчаларын җәлеп итүдә ярдәм күрсәтелә, инновация-инвестиция инфраструктурасы объектларына ярдәм ителә.

Инвестицияләр өлкәсендә махсуслашкан орган кысаларында Татарстан Республикасының инвестиция проектлары базасын булдыру эше җайга салынырга мөмкин.

*Төп адымнар:*

• республика территориясендә гамәлгә ашырыла дип уйланылган инвестиция проектлары турында мәгълүматка мониторинг ясау, проектны бизнес-идея дәрәҗәсендә өйрәнү, проектның инициаторы белән беренче элемтәләр урнаштыру, республикада билгеләнгән инвестицияләр кертүнең өстенлекле юнәлешләренә проектның туры килү-килмәвен алдан бәяләү;

• җентекләп өйрәнелгән проектларны — бизнесны планлаштыруның халыкара стандартларына туры китереп һәм эре россия һәм халыкара инвесторларның таләпләрен исәпкә алып эшләнгән бизнес планнары һәм финанс модельләре, шулай



ук раслый торган документлары (проект-смета документациясе, шартнамәләр һ.б.) булган проектларны сайлап алу;

• инвестиция проекты турында тулы мәгълүмат алу (бизнес-план, финанс моделе, инвестиция меморандумы форматында);

• проектка кыскача экспертиза ясау, бәяләмә язу;

• инвестиция проектына ярдәм итүнең иң уңай ысулларын сайлау.

Инвестиция проектларын алып бару бердәм мәгълүмат системасында гамәлгә ашырылачак, анда әлеге проектларның гомуми базасын туплау, финанс күрсәткечләренә анализ ясау мөмкинлеге булу, инвестиция һәм эшкуарлык субъектларының дәүләт органнары белән үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәләрен күрсәтү күздә тотыла.

Татарстан Республикасына күп кенә инвестицияләр кертүче эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары белән эшләү индивидуаль схемаларга корылырга тиеш.

Финанс ресурсларының чикләнгән булуы шартларында хәзергә республикада киң таралмаган дәүләти-хосусый партнерлык механизмнары мөһим урын ала. Татарстанда «СМАРТ Сити Казан», «Европа — Көнбатыш Кытай» халыкара транспорт коридорын һәм Свияжск регионара мультимодаль логистика үзәген төзү кебек эре масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә дәүләти-хосусый партнерлык тәҗрибәсен киңәйтү мәсьәләсе аеруча актуаль. «Мәскәү — Казан» югары тизлекле тимер юл магистрален төзү проекты стратегик мөһим.

### *Инновация-инвестиция инфраструктурасын үстерү*

Татарстан икътисадына инвестицияләр җәлеп итүне стимуллаштыруны инновация-инвестиция инфраструктурасының махсуслашкан объектларын төзү һәм аларга идарә итү буенча республикада урнашкан уңышлы тәҗрибәгә нигезләнеп алып бару максатка ярашлы була. Инновация-инвестиция инфраструктурасы объектларына билгеләмәләр беркетү һәм, аларның үзенчәлекләрен аңлап һәм төп формаларын аерып карап, гамәлдәге һәм планлаштырыла торган объектларны структурлаштыру мөһим: махсус икътисадый зона, индустриаль парк («гринфилд» — яңа гына бүлеп бирелгән, төзелешләр булмаган, кагыйдә буларак, элеккедән үк инфраструктура белән тәэмин ителмәгән җир кишәрлегендә төзелә торган индустриаль (сәнәгать) паркы һәм «браунфилд» — индустриаль паркның (сәнәгать паркының) махсус үзенчәлекләренә һәм аның резидентлары ихтыяҗларына туры китереп, кагыйдә буларак, реконструкция һәм (яисә) капиталь ремонт ясала торган төзелмәләр,

корылмалар һәм инфраструктура белән тәэмин ителгән элек булган җитештерү мәйданчыкларына нигезләнеп төзелә торган индустриаль парк (сәнәгать паркы), технопарк, югары технологияләр өлкәсендәге технопарк, бизнес-инкубатор, инжиниринг үзәге (гадәттә моңа технологияләрне коммерцияләштерү үзәге, сынаулар үткәрү һәм продукцияне сертификатлаштыру үзәге, тәҗрибә-конструкторлык полигоны керә).

Стратегик юнәлешнең асылы инновация-инвестиция инфраструктурасы объектларына идарә итү һәм аларны үстерү, резидентларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче идарәче компанияләрне (күп очракта хосусый булган) ныграк игътибар биреп стимуллаштырудан гыйбарәт. Идарәче компаниянең конкурентлыкка сәләте аның инновация-инвестиция инфраструктурасы объекты мөлкәте белән эш итү хокукы булганда арта. Бу исә нигез инфраструктураны гына түгел, ә күрсәтелә торган хезмәтләрнең тулы портфелен тәкъдим итү мөмкинлеген бирә (иң яхшы дөньяви үрнәкләр 100 төрдән артык хезмәт күрсәтәләр: консалтинг хезмәт күрсәтүләре, НИОКР инфраструктураны тәкъдим итү һәм хезмәт күрсәтү, көнкүреш сервислары, сәнәгать калдыкларын саклау, транспортлау һәм утильләштерү, инфраструктурага хезмәт күрсәтү, транспорт һәм логистика хезмәтләре күрсәтү һ.б.). Инновация-инвестиция инфраструктурасы объектын үстерүнең сыйфатлы (бизнес-планны, маркетинг планын, инвестицияләр һәм резидентлар җәлеп итү планын, объектка идарә итү планын һ.б. үз эченә алган) стратегиясе мөһим өлешне тәшкил итә.

***Инвестиция портфеле***

Татарстан Республикасының инвестиция портфеле составы 2015 елга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумына кертү өчен сайлап алынган өстенлекле проектлар исемлегенә, шулай ук Стратегияне эшләгәндә Татарстанның иң эре компанияләрен өйрәнү барышында предприятиеләр тарафыннан тәкъдим ителгән проектлар исемлегенә таянып билгеләнә. Инвестиция портфеленең структурасы 3.29 нчы рәсемдә күрсәтелде.






Источник: паспорта инвестиционных проектов, аналитика AV Group

**3.29 нчы рәсем. Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары портфеле**

Инвестиция портфеле структурасында 44 процентган артыгын (планлаштырыла торган финанс кертемнәре күләмнәре буенча) инфраструктура комплексы проектлары, беренче чиратта Иннополис территориясендә торак инфраструктурасын төзү, шулай ук Татарстан Республикасының транспорт һәм инвестиция инфраструктурасы объектларын булдыру каралган проектлар алып тора.

Инвестицияләр күләме буенча икенче урында нефть-газ химиясе комплексы («ТАНЕКО» ААЖ, «Түбән Кама нефтехим» ГАЖ, «Аммоний» ААЖ һ.б.) тора.

Инвестицияләр күләме буенча өченче урынны нигездә автомобиль төзелешен үстерү проектлары хисабына («КАМАЗ» ААЖ, «Форд Соллерс Холдинг» ЖЧЖ, «Мерседес-Бенц Тракс Восток» ЖЧЖ һ.б.) машина төзелеше комплексы алып тора.

Инвестиция портфеле структурасында дүртенче урынны агросәнәгать комплексы биләп тора.

Инвестицияләр күләме буенча бишенче урынны энергетика комплексы алып тора («Генерирлау компаниясе» ААЖ, «Челтәр компаниясе» ААЖ, «ТГК-16» ААЖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ААЖ).

Инвестиция портфеле составында хезмәт күрсәтүләр комплексы тармакларына караган проектлар юк диярлек.

### 3.3.4. Инновацияләр экосистемасы

Инновацион сәясәт «инновацияләр экосистемасы» төшенчәсенә нигезләнгән унификацияләүгә таянып эшләнә һәм гамәлгә ашырыла (3.30 нчы рәсем).




Субъекты:

- бизнес;
- наука (включая образование);
- государство.

Ключевые элементы экосистемы:

- спрос;
- кадры;
- финансирование;
- инфраструктура;
- администрирование.

Связующее измерение, ключевой фактор успеха:

- культура инноваций.

**3.30 нчы рәсем. Инновацияләр экосистемасын схема белән тасвирлау**



***Хәзерге торыш***

Татарстан Республикасында тулы инновацион системаны үстерүгә комачаулый торган төп проблемалар бөтен Россия икътисадына да хас, һәм алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

*Ихтыяҗ*:

• эре бизнесны инновацияләр уйлап табуга, сатып алуга һәм кертеп җибәрүгә начар кызыктыру;

• товарларны / хезмәт күрсәтүләр / технологияләрне таләпләре югарырак булган тышкы базарларга сатуның тупланган тәҗрибәсе һәм системасы булмау;

• инновацион чишелешләргә дәүләт заказы күләменең чикләнгән булуы һәм дәүләт заказы белән эшләүнең катлаулы булуы.

*Идарә итү:*

• аерым инновацион механизмнарны һәм программаларны гамәлгә ашыруның төрле объектлар, агентлыклар, министрлыклар һәм ведомстволар арасында килештерелмәве;

• инновацион үсеш күрсәткечләренең максатка ярашлы исемлеге һәм әлеге күрсәткечләргә мониторинг ясау программасының булмавы;

• инновацион процесста катнашучыларның үзара хезмәттәшлегенең хокукый нигезләрен хуплап чыгу һәм популярлаштыру өчен җавап бирә торган институтларның начар эшләве.

*Кадрлар:*

• бизнес-структураларда эшкуарларга һәм эчке эшкуарларга кытлык булу;

• яңа идеяләрне кертеп җибәрергә сәләтле фәнни-техник кадрларга кытлык булу;

• инновацион процесска ярдәм өлкәсендә кадрларга кытлык булу (югары технологияләр белән эшли торган хезмәткәрләрдән алып интеллектуаль милек буенча белгечләргә кадәр).

*Инфраструктура:*

• нигез инфраструктураның (юллар, электр челтәрләре, торак-коммуналь хуҗалык) үсеш дәрәҗәсе түбән булу, бу инновацион чишелешләрне кертеп җибәрүне кыенлаштыра;

• инновацион инфраструктура объектларының саны һәм колачлануы җитәрлек булмау;

• инновация-инвестиция инфраструктурасы объектларының программалы тәэминаты һәм эшчәнлеге оештырылу тиешле дәрәҗәдә нәтиҗәле булмау, алар төзелгән объектларны һәрвакытта да нәтиҗәле файдаланырга мөмкинлек бирми.

*Финанслау:*

• инновация чылбырының башлангыч чорларында һәм бөтен дәвамлылыгында аз финанслануы;

• эчке инновацияләрнең һәм гамәли фәнни тикшерүләрнең эре бизнес тарафыннан аз финанслануы;

• проектлардан чыкканнан соң инвесторларның мөмкинлекләрен чикли торган үсеш алмаган институтлар.

***Төп мәсьәләләр:***

• инновацияләргә сорауның түбән булуы;

• инновацияләр булдыру һәм кертү өчен стимулларның икътисадның монопольләшүе һәм дәүләтләшүе аркасында кимүе;

• иҗтимагый секторга җәмәгать контроле начар булуның шәһәр хуҗалыгына, транспорт, сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәләренә яңа технологияләр кертү өчен стимулларны көчсезләндерүе;

• күп кенә инновацион компанияләрнең халыкара алмашуга һәм кооперациягә начар үтеп керүе;

• инновацияләр культурасының күз алдына китерелгән торышы белән хәзерге вәзгыять арасында аерманың зур булуы (3.5 нче таблица)

**3.5 нче таблица. Инновацияләр культурасының югары дәрәҗәсе характеристикалары һәм хәзерге вәзгыять**

| Инновацияләр культурасының югары дәрәҗәсе характеристикалары | Татарстан Республикасында хәзерге вәзгыять |
|---|---|
| Инновация компетенция буларак кабул ителә.<br>Инновацион тәртипкә нигез күнекмә буларак өйрәтергә мөмкин дигән аңлау таралган<br>Инновация конкуренциядәге көрәш коралы буларак кабул ителә һәм конкурентлардан аерып карау өчен кулланыла<br>Инновация процесс буларак кабул ителә, уңышсызлыклар – бу процессның мәҗбүри өлеше<br>Инновация экспериментка һәм уртак (күмәк) эшкә нигезләнгән системалы төшенчә буларак кабул ителә | Инновацияләр белән эшләү өчен бердәй төшенчәләр аппараты юк<br>Инновацион үсешнең реаль мөмкинлекләре һәм файдасы турында барлык катнашучылар өчен мәгълүмат җитми<br>Инновацияләрдә һичшиксез була торган эшкуарлык һәм технологик тәвәкәллекләргә карата толерантлык дәрәҗәсе түбән<br>Аеруча фәнни ачышлар һәм уйлап табулар этабында башка катнашучыларга карата ышаныч түбән<br>Катнашучылар арасында челтәр эчендә үзара хезмәттәшлек дәрәҗәсе түбән, шул исәптән фәнни-тикшеренү оешмалары һәм сәнәгать арасында элемтәләр начар, кире элемтәләрнең җайга салынуы начар һәм кире элемтәгә җавап бирү механизмнары юк<br>Планлаштыруның кыска сроклы горизонты, монда һәм хәзер нәтиҗәсен күз алдында тоту |

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

<u>СЦ-5</u> **Татарстан Республикасында инновацияләрнең тулы экосистемасы булдырылды, ул «акыллы» икътисад үсешендә, яңа материаллар, продуктлар һәм**



**технологияләр булдыруда һәм коммерцияләштерүдә, республиканың глобаль конкурентлыкка сәләтендә Татарстан Республикасының лидер булуына мөмкинлекләр ача.**

**Ц-5.1 Икътисадның һәм социаль өлкәнең инновациялек дәрәҗәсе югары.**

**Ц-5.2 Технологияләрнең үсеше һәм һәркем файдалана алырлык булу дәрәҗәсе югары.**

**Ц-5.3 Мәгълүмат-коммуникация системасының сыйфаты югары.**

*З-5.0.0.1* Инновация системасы өчен кадрлар ресурсларын җәлеп итүне, әзерләүне, камилләштерүне һәм җибәрмәүне тәэмин итәргә.

*З-5.0.0.2* Инновация-инвестиция инфраструктурасын үстерүне тәэмин итәргә.

*З-5.0.0.3* Инновация экосистемасының ачыклыгы аркылы инновацияләргә ихтыяҗ булуны стимуллаштырырга.

*З-5.0.0.4* Рәсми һәм рәсми булмаган эчке институтларны үстерүне стимуллаштыру һәм Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институтын төзү аркылы үз-үзен җайга сала торган һәм үзеннән-үзе үсә торган инновация системасын үстерергә.

*З-5.0.0.5* Инновацияләрне финанслау системасын стимуллаштырырга. Венчурлы инвестицияләр базарын үстерергә.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) «Кеше капиталы» юнәлеше буенча:

• инновация системасы өчен кадрлар вузларда – инновацияләргә ярдәм өлкәләрендә галимнәр/тикшеренүчеләр, эшкуарлар, белгечләр, һөнәри белем системасында – КУЭ һәм эре бизнес ихтыяҗлары өчен техник белгечлекләр кадрлары җәлеп итү, әзерләү, камилләштерү һәм җибәрмәү;

2) «Пространство, реаль капитал» юнәлеше буенча:

• инновацион фирмаларга бизнес алып баруга уңайлы шартлар бирү һәм фирмалар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне һәм хезмәттәшлекне стимуллаштыру өчен инновация инфраструктурасын (технопарклар, технополислар) алга таба үстерү;

• регионда эшләүче белгечләрнең яшәү дәрәҗәсенең югары булуын, шулай ук инновацияләрне тиз арада булдыру һәм кертеп җибәрү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә торган комплекслы инфраструктура төзү һәм ярдәм итү;

3) «Базарлар» юнәлеше буенча:

• товарлар, хезмәт күрсәтүләр, технологияләр, капитал һәм кадрларның тышкы базарлары белән актив хезмәттәшлеген тәэмин итү;

• югары технологияле продукциянең халыкара базарына инновацион компанияләрнең чыгуына мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтү;

• инновацион компанияләрнең экспортына һәм фирмалар арасындагы халыкара элемтәләрне үстерүгә булышлык күрсәтүдә дәүләт ярдәме;

• инновацияләрне икътисадый стимуллаштыру;

• җитештерелә торган инновацияләрнең өстенлекле тармаклар/кластерлар буенча эчке һәм тышкы базарларда (продуктлар, хезмәт күрсәтүләр, технологияләр) конкурентлыкка сәләтле булуын һәм аларга ихтыяҗны тәэмин итү;

4) «Институтлар» юнәлеше буенча:

• дәүләтнең директив катнашуын таләп итмичә тышкы үзгәрешләргә тотрыклылыкны тәэмин итә торган эчке рәсми һәм рәсми булмаган институтларны үстерүне стимуллаштыру;

• Татарстан Республикасының һәр кешесе күзлегеннән чыгып каралган төгәл файдаларны тасвирлап, инновацион үсеш логикасын популярлаштыру;

• җәмгыятьтә ышаныч дәрәҗәсен арттыруны һәм челтәр эчендәге үзара хезмәттәшлекне арттыруны стимуллаштыру;

• инновацион процесста барлык катнашучылар белгән һәм һәркайсына аңлаешлы булган ачык уен кагыйдәләренең үтәлешен булдыру һәм тәэмин итү;

• экосистемада барлык катнашучылар өчен ачык үзара хезмәттәшлекнең һәм кире элемтәнең мөмкин булуын тәэмин итү;

• экосистема эшенә даими һәм үтә күренмәле мониторинг ясауны стимуллаштыру;

• Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институтын төзү (Стратегияне гамәлгә ашыруның икенче этабында);

• тотрыклы инновацион үсешнең төп факторлары — тәвәккәллекләргә һәм уңышсызлыкларга толерантлык дәрәҗәсен арттыру;

5) «Финанс капиталы» юнәлеше буенча:

• инновацион процессның барлык этапларында финанслау системасын, хосусый кертемнәргә өстенлек биреп, «акыллы» акчаларны җәлеп итүгә аерым игътибар биреп төзү;

• хосусый венчур фондларын һәм «бизнес-ангеллар»ны үстерүгә ярдәм итү;

• социаль әһәмиятле яисә башка махсус проектлардан тыш, дәүләт кертемнәренең өлешен киметүне стимуллаштыру.

### *Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институты*

Инновация экосистемасын төзү — барлык тармакларны һәм республика икътисадының барлык дәрәҗәләрен диярлек колачлый торган дәвамлы һәм катлаулы процесс. Куелган бурычларны хәл итүгә республика тарафыннан бирелә торган ресурслар нәтиҗәлерәк тотылсын өчен инновацион үсеш процессын координацияләү белән шөгыльләнәчәк һәм нәтиҗәләргә үзәкләштерелгән мониторинг ясауны гамәлгә ашырачак бер орган кирәк. Соңгы унъеллыкта төрле федераль һәм региональ инициативалар кысаларында инновация инфраструктурасы объектлары күп төзелде. Бу ресурсларны берләштерергә һәм алар өчен килештерелгән гамәлләр программасын төзергә кирәк.

Әлеге бурычны хәл итү өчен Стратегияне гамәлгә ашыруның беренче этабында Татарстан Республикасы БАРС бүлеге (кара 4.1) җавап бирәчәк; шуннан соң мөстәкыйль Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институтын аерып чыгару тәкъдим ителә, аның төп функцияләре 3.6 нчы таблицада бәян ителде, ә структурасы 3.31 нче рәсемдә күрсәтелде.

**3.6 нчы таблица. Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институтының төп функцияләре**

| Функция | Инновацияләр экосистемасына йогынты |
|---|---|
| Методологик база төзү | Инновацияләр экосистемасы әгъзаларына (дәүләткә, бизнеска, фәнгә һәм мәгарифкә), гомум кабул ителгән һәм һәркемгә аңлаешлы билгеләмәләрне кулланып, нәтиҗәләрне бәяләүнең гомум кабул ителгән һәм һәркемгә аңлаешлы методологиясенә таянып, инновацияләр турында бер телдә сөйләшергә мөмкинлек бирә. |
| Мәгълүмат интерфейсы | Инновацияләр экосистемасы әгъзаларына карарлар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматны тиз һәм җайлы алырга яисә аны мондый мәгълүматка ия булучылардан алырга мөмкинлек бирә. Шулай ук башка әгъзалар тарафыннан кабул ителгән карарлар буенча тиз һәм уңайлы кире элемтәне башкарырга мөмкинлек бирә. |
| Дәүләт тарафыннан көч куюның бердәм ноктасы | Дәүләтнең инновацияләрне үстерүгә юнәлтелгән барлык инициативаларының эшен дәүләт тарафыннан нәтиҗәле координацияләргә мөмкинлек бирә — йә турыдан-туры идарә механизмнары аркылы, йә профильле агентлыклар һәм ведомстволар аркылы. |
| Эчке һәм тышкы популярлашты-ручы | Киң халык катламнары арасында инновацияләрнең зарур булуын һәм файдасын аңлау дәрәҗәсен арттыра. Татарстанның инновацион экосистемасында катнашуга кешеләрне, оешмаларны, институтларны җәлеп итә. |
| Нәтиҗәлелекне арттыру буенча идеяләр генераторы | Дәүләт хакимиятенең барлык дәрәҗәләре, бизнес, фән һәм мәгариф өчен инновацион өндәмә буенча инициативалар җыя һәм төзи. Тәкъдимнәр кабул итүнең максатка ярашлылыгын нигезли, аларны кертеп җибәрергә ярдәм итә, нәтиҗәләргә мониторинг ясый. |




**3.31 нче рәсем. Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институтының оештырылу схемасы**

Инновацияләр экосистемасы икътисадның барлык өлкәләрен диярлек үз эченә алганга күрә, Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институты инновацияләр экосистемасын төзүнең аерым бурычларны хәл итүне максат иткән профильле үзәкләр эшен координацияләү, шулай ук инновацион үсеш программаларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча профильле министрлыклар һәм ведомстволар белән үзара хезмәттәшлек итү өчен билгеләнгән. Аерым бүлекчәләр һәм үзәкләр төп игътибарны, инновацион процесста төрле катнашучыларның аралашуын тәэмин итеп, инновация системасының төп өлешләрендәге өзеклекләрне бетерүгә бирәләр. Бүлекчәләрне һәм үзәкләрне төзү чыгымнарын киметү һәм ресурслардан нәтиҗәлерәк файдалану максатыннан, аларның бурычларын, вәкаләтләрен һәм буйсынуын беркадәр үзгәртеп, нигездә гамәлдәге структураларга таянып башкарырга тәкъдим ителә.

### 3.3.5. Кластерлы активлашу

***Максатчан күзаллау һәм бурычлар***

Кластерлы активлашу өч этапны үз эченә ала, һәркайсы өчен максатчан күзаллау билгеләнгән (3.32 нче рәсем).






3.32 нче рәсем. Татарстан Республикасы кластерлары (икенче һәм өченче этаплар)

**Ц-4.2 Татарстан Республикасында заманча икътисадның һәм «акыллы» икътисадның конкурентлыкка сәләтле кластерлар портфеле булдырылды.**

Төп кластерлар түбәндәгеләр: нефть-газ химиясе һәм энергетика комплекслары кластерлары, машина төзелеше кластеры, «Фән һәм мәгариф» кластеры һәм 10 инновацион кластер («Татарстанның технологик инициативасы» флагман проекты кысаларында), алар Татарстан Республикасының уңышлы үсешенә һәм аның глобаль конкурентлыкка сәләтле булуына ирешүенә көчле йогынты ясау сәбәпле иң югары өстенлеккә ия.

*Арадагы максатлар:*

2016 ел – зоналар буенча кластерлы активлашу. **Татарстан Республикасында Кама кластеры актив үсә һәм өч икътисадый зона югарылыгында кластерга кагылышлы инициативаларны ачыклау һәм гамәлгә ашыру башкарыла. Югары потенциалга ия региональ кластерлар ачыкланды, алар регионара һәм/яисә глобаль дәрәҗәдә конкурентлыкка сәләтле була алалар.**

2017 – 2021 еллар – кластерлы системаны бер тәртипкә китерү. **Татарстан Республикасында заманча икътисадның база кластерларын, шулай ук аларга бәйле рәвештә үзгәрешләрнең катализаторлары, ә киләчәктә – тулысынча үсеш лидерлары була алган «акыллы» икътисад инновацион кластерларын булдыру гамәлгә ашырыла.**

*З-4.2.0.1* Кластерларны кадрлар ресурслары белән тәэмин итәргә (кластерларның лидерларын һәм төп белгечләрен эзләү, җәлеп итү, камилләштерү һәм җибәрмәү).

*З-4.2.0.2* Инфраструктурага кагылышлы чикләүләрне бетерүне тәэмин итәргә; югары сыйфатлы инфраструктура һәм төп фондлар булдыруны стимуллаштырырга.

*З-4.2.0.3* Клиентларны күз алдында торткан конкурентлыкка сәләтле тармакларны һәм һәр кластерның нигезендә ятучы продуктларны ачыкларга һәм аларның үсешен тәэмин итәргә.

*З-4.2.0.4* Кластерларның институтларга бүленеп үсүен стимуллаштырырга; административ каршылыкларның кимүен тәэмин итәргә; төп уенчыларны билгеләргә һәм кластерларны үстерү институтларын төзергә.

*З-4.2.0.5* Инновацияләрдә лидерлыкны стимуллаштырырга.

*З-4.2.0.6* Табигать ресурсларыннан нәтиҗәле һәм тотрыклы файдалануны тәэмин итәргә.

*З-4.2.0.7* Кластерлар предприятиеләре өчен финанс ресурсларының һәркем файдалана алырлык булуын арттырырга, кластерларга ярдәм итүнең финанс механизмнарын камилләштерергә.



Кластерлы активлашуның беренче этабында заманча икътисад моделе кысаларында модернизацияләү гамәлгә ашырыла, ул бер рәт югары технологик проектларны һәм модернизацияләү гамәлләрен тормышка ашыру һәм конкурентлыкка сәләтне арттыру юлы белән башкарыла. Өч икътисадый зона кысаларында кластерлы иницитиваларны гамәлгә ашыру барышында Кама кластеры тәҗрибәсе киңәйтеләчәк, төп игътибар үзәк нефть-газ химиясе кластерын төзүгә нык игътибар биреләчәк (3.33 нче рәсем). Икенче һәм өченче этапларда өстенлек «акыллы» икътисад кластерларына биреләчәк, алар, заманча икътисад кластерларыннан аермалы буларак, конкурентлыкка сәләтле генә түгел, ә өр яңа продукция, материаллар һәм технологияләр дә җитештерергә тиеш булалар.



Источник: Татнефтехиминвест-холдинг, аналитика AV Group

3.33 нче рәсем. Нефть-газ химиясе комплексы кластеры – Татарстан Республикасының төп кластеры



Кластерлы активлашу бизнес өчен Татарстан Республикасы икътисадый сәясәтенең иң мөһим юнәлешләрен эзләп табуда һәм гамәлгә ашыруда катнашу, дәүләт ярдәмен алу (административ, инфраструктур, салым һәм финанс) мөмкинлекләрен киңәйтүне күз алдында тота. Бизнесның республиканы һәм бизнесны синхрон үстерергә мөмкинлек бирә торган стратегик документлар пакетын эшләү һәм тормышка ашыру аркылы тәэмин ителә торган максималь ачыклыгы һәм катнашуы аның кластерлы активлашуда катнашуы өчен мәҗбүри шартлар булып тора. Планлаштыруны синхронлаштыруга кластерларның төп предприятиеләрендә 2030 елга кадәр билгеләнгән түбәндәге стратегик документлар портфеле булганда ирешеп була:

- үсешнең озак вакытлы стратегик доктринасы;
- инвестицион проектлар портфеле базасында үсешнең комплекслы бизнес-планы;
- инновацион үсеш стратегиясе;
- конкурентлыкка сәләтле булуны арттыру (хезмәт җитештерүчәнлеген һәм җитештерү нәтиҗәлелеген арттыру) стратегиясе;
- глобаль алга чыгу стратегиясе.

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) «Кеше капиталы» юнәлеше буенча:

- кластерлар белгечләренә карата таләпләрне рәсмиләштерү;
- кластерларның кыйммәтләре һәм этик нормалары системасын төзү;
- иң яхшы лидерларны һәм талантларны (дөньякүләм йолдызларны да кертеп) кластерларга җәлеп итү һәм җибәрмәү;

2) «Пространство, реаль капитал» юнәлеше буенча:

- кластерлар үсешендәге инфраструктура чикләүләрен ачыклау;
- кластерларның өстенлекле инфраструктура проектлары портфелен булдыру;
- инновация-инвестиция инфраструктурасының гамәлдәге объектларын үстерүне һәм яңаларын төзүне (үсеш зоналары, индустриаль парклар һәм технопарклар) стимуллаштыру;
- махсуслашкан инжиниринг үзәкләрен төзү (аларның кысаларында коммерцияләштерү үзәкләрен, продукцияләрне сынау һәм сертификатлаштыру үзәкләрен һәм тәҗрибә-конструкторлык полигоннарын булдырып);

3) «Базарлар» юнәлеше буенча:

- төп тармакларны һәм продуктларны ачыклау (төп тармакларны һәм продуктларны локальләштерү һәм махсуслаштыру дәрәҗәсенә экспертиза бәяләмәсе);

• тармакара, региональ һәм регионара үзара хезмәттәшлек дәрәҗәсен билгеләү;

• потенциаль конкурентлыкка сәләтле кластерлар портфелен табу;

• төп кластерларны билгеләү;

• эчке һәм кластерара үзара хезмәттәшлекнең процесс/географик карта-схемасын төзү;

• кластерларның конкурентлыкка сәләтле продуктлары портфелен билгеләү;

• базарларга диагностика; кластерларның продуктларын тәкъдим итү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

• кластерлар продуктлары кысаларында чыгымнарны киметү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

4) «Институтлар» юнәлеше буенча:

• кластерлы үсешнең лидер-генераторларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү; кластерларның төп катнашучыларын билгеләү;

• кластерларда катнашучыларның стратегияләрен һәм бизнес-планнарын синхронлаштыру;

• кластерлы үсеш стратегиясен һәм ярдәмнең дәүләт механизмнары җыелмасын терки торган комплексларны (кластерлар үсә торганнарын) үстерү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

• кластерларның төп катнашучылары бизнесын оптимальләштерү/үзгәртеп кору системасын гамәлгә ашыру;

• кластерларда катнашучыларның үзара һәм алдынгы дөньякүләм компанияләр белән нәтиҗәле кластер кооперациясенә ярдәм итү;

• кластерларны үстерү институтларын төзү/билгеләү (үсеш институты, инжиниринг үзәге, турыдан-туры инвестицияләр фонды);

• кластерларда катнашучыларны халыкара хезмәт бүленешенә керү өчен стимуллаштыру, халыкара бизнес һәм технологик партнерларны җәлеп итү;

5) «Инновация» юнәлеше буенча:

• кластерларның төп инновацияләре исемлеген төзү; кластерларның инновацион проектлары портфелен билгеләү;

• кластерларда «өчле спираль»: бизнес — фән — хакимият кысаларында өзлексез үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү;

6) «Табигать ресурслары» юнәлеше буенча:

• ресурслар җыелмасын һәм аларга предприятиеләрнең ихтыяҗын һәм кластерлар проектларын билгеләү;

• кластерларның экологик стандартын булдыру.

7) «Финанс капиталы» юнәлеше буенча:

• кластерның өстенлекле проектларының инвестицион портфелен булдыру;



• кластерның өстенлекле проектларын инвестицияләр өчен тәкъдим итү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

• кластерның өстенлекле проектларына инвестицияләр (финанс һәм стратегик) җәлеп итүне тәэмин итүче программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

• кластерда катнашучыларга өстенлекле дәүләт ярдәмен (салым, финанс, инфраструктур, административ) тәэмин итү;

• кластерның үсеш дәрәҗәсенә мониторинг ясау һәм нәтиҗәлелеген бәяләү.

**3.3.6. Заманча икътисад һәм «акыллы» икътисад кластерларын максатчан күзаллау**

**<u>СЦ-3</u> Татарстан Республикасының махсуслашу тармаклары регионара һәм глобаль базарларда конкурентлыкка сәләтле.**

**3.3.6.1. Нефть-газ химиясе комплексы кысаларында кластерлар**

***Максатчан күзаллау***

**Ц-3.1 Татарстан Республикасында глобаль конкурентлыкка сәләтле вертикаль үтеп кергән нефть-газ химиясе кластеры һәм аңа бәйле булган, әмма чагыштырмача аерымланган, «Акыллы» материаллар (яңа пластиклар һәм композитлар) һәм «Биосистемалар» инновация кластерлары нәтиҗәле эшли, алар өстәлгән бәянең зур өлешен бирәләр.**

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) стратегик перспективада, нефть чыгаруның һәм нефть сервисының инновацион технологияләрен куллануга нигезләнеп, югары үзле нефть һәм табигый битум запасларының гамәлдәге чыганакларын нәтиҗәле файдалануны һәм актив чыгаруны озайту хисабына нефть чыгару күләмнәрен тотрыкландыруны тәэмин итү; нефть эшкәртү күләмен, сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру; күбесенчә күп тонналы модельләрдән ахыргы куллануны күз алдында тоткан конкурентлыкка сәләтле продукциянең уртача һәм аз тонналы линейкасының динамикалы үсүенә күчү, бу вакытта конкурентлыкка сәләтле берничә күп тонналы җитештерү модернизацияләнә һәм төзелә; газ химиясе юнәлешен актив үстерү һәм углеводородлы чималны транспортлауның федераль проектларын гамәлгә ашыруда катнашу; югары технологияле чиктәш юнәлешләрне («Акыллы» материаллар, «Акыллы» җиһаз, «Биосистемалар», «Тотрыклы энергетика») үстерүне сти-

муллаштыру; Идел нефть химиясе кластерын үстерүнең кушылу процессларында актив катнашу нигезендә **нефть-газ химиясе комплексын тигез үстерү.**

2) **«Акыллы» материаллар» кластерын үстерү (яңа пластиклар һәм композитлар)** (кара 3.3.7.2)[1];

3) **«Биосистемалар» инновацион кластерын үстерү** (кара 3.3.7.2).

*Нефть-газ химиясе кластерында төп катнашучылар*: «Татнефть» ААҖ (автомобиль шиннарын җитештерү заводларын да кертеп), «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ, «ТАНЕКО» ААҖ, «Казаноргсинтез» ААҖ, «Аммоний» ААҖ, «Техстрой» ЯАҖ, «Нәфис Косметикс» ААҖ, «Казан синтетик каучук заводы» ААҖ, «Л.Я. Карпов исемендәге Химия заводы» ААҖ, «Түбән Кама техуглерод» ААҖ, «Кварт» ЯАҖ, «Татхимфармпрепаратлар» ААҖ, «Менделеевсказот» ҖЧҖ, «Ниинефтепромхим» ААҖ, «Химград» технополисы.

**3.3.6.2. Энергетика комплексы кысаларындагы кластерлар**

***Максатчан күзаллау***

**Ц-3.2 Татарстан Республикасында энергетика кластеры һәм аның белән бәйләнешле «Тотрыклы энергетика» инновацион кластеры актив эшли.**

***Гамәлләр юнәлешләре***

1) ***Татарстан Республикасы икътисадының төп өлешләреннән берсе буларак*** **энергетика комплексын тигез үстерү*, шулай ук тулаем региональ икътисадның конкурентлыкка сәләтле булуын һәм яңа технологияләр куллану нигезендә конкурентлы бәяләр буенча кирәкле күләмдә энергия җитештерү, энергияне сак тотуның югары сыйфаты һәм югары ышанычлылыгы хисабына республиканың энергетик иминлеген тәэмин итү;***

2) **«Тотрыклы энергетика» инновацион кластерын үстерү** (кара 3.3.7.2).

*Энергетика кластерында төп катнашучылар*: «Генерирлау компаниясе» ААҖ, «ТГК-16» ААҖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ, «Челтәр компаниясе» ҖЧҖ.

---

1 «Акыллы» икътисад кластерларын төзү аерым флагман проектка бүлеп чыгарылды, аның тасвирламасы 3.3.7 пунктында бирелә.



**3.3.6.3. Машина төзелеше һәм башка эшкәртү сәнәгате комплексы кысаларындагы кластерлар**

***Максатчан күзаллау***

**Ц-3.3 Татарстан Республикасында өстәлгән бәянең зур өлешен бирә торган вертикаль керешкән субкластерлардан — «Автомобиль төзелеше», «Авиатөзелеш», «Судно төзелеше» («Акыллы» машиналар» конвергент инновацион кластерын төзеп) — гыйбарәт глобаль конкурентлыкка сәләтле машина төзелеше кластеры нәтиҗәле эшләп килә. «Акыллы» җиһаз» инновацион кластеры төзелде һәм нәтиҗәле эшли. Металлургиядә, җиңел, агач эшкәртү һәм йорт җиһазы сәнәгатендә кластерлы үсеш бара.**

***Гамәлләр юнәлеше:***

1) **автомобиль төзелеше:** республика предприятиеләре булган барлык сегментларда илкүләм сату базары һәм аның ихтыяҗлары белән өстенлек биреп эшләү нигезендә субкластерның югары конкурентлыкка сәләтен үстерү һәм тәэмин итү. Татарстан машина төзелеше икътисадының клиентларны күз алдында тотуы, технологик лидерлыгы, тотрыклылыгы һәм киләчәк өчен башлап куелган эш тармакта катнашучыларның көчле локальләшүе һәм кооперациясе, шулай ук тармакның дөнья лидерлары белән тыгыз хезмәттәшлеге аркылы тәэмин ителергә тиеш.

*Субкластерда төп катнашучылар*: «КАМАЗ» группасы; Ford Sollers («Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ, «Форд Соллерс Холдинг» ҖЧҖ); «ПО ЕлАЗ» ААҖ; автокомпонентларны җитештерүче предприятиеләр.

2) **суднолар төзелеше**: субкластерның барлык төп катнашучылары конкуренциядә өстенлеккә ия юнәлешләрдә уртак проектларны республика предприятиеләре тарафыннан гамәлгә ашыру нигезендә конкурентлыкка югары сәләтле булуын тәэмин итү (тикшеренүләр һәм уйлап табулар өлкәсендәге югары дәрәҗә белән җитештерү өлкәсендәге югары дәрәҗәнең туры килүе): күп максатлы кече хәрби корабльләр, тизйөрешле пассажир суднолары, «елга-диңгез» классындагы нефть ташу суднолары, корпусларының формасы гадәти булмаган инновацион корабльләр һәм суднолар (аквапланнар, тримараннар) төзү, шулай ук Арктика корабль төзелеше программасында катнашу, болар барысы да продукциянең суднолар төзелеше базарында конкурентлыкка югары сәләтле булуын тәэмин итәчәк һәм яңа озак вакытлы заказлар җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

*Субкластерда төп катнашучылар*: «Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» ААҖ; «А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» ААҖ; «ЭРА» Зеленодольск предприятие-

се» ААЖ; «Казан электротехника заводы» ААЖ; «Казан оптика-механика заводы» ААҖ; «В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» НПО» ААҖ. *Субкластерның чиктәш катнашучылары*: А.Н. Туполев исемендәге Казан техник милли тикшеренү университеты; Зеленодольск судно төзелеше техникумы һ.б.

3) **авиатөзелеш**: хәрби авиатөзелешнең (вертолетлар, фронт авиациясе, пилотсыз очу аппаратлары) глобаль лидерларыннан берсе буларак һәм граждан авиатөзелешенең (граждан-нар өчен махсус билгеләнештәге вертолетлар, эшлекле авиация, шул исәптән кече, пилотсыз очу аппаратлары) Россия лидеры һәм Татарстан Республикасының барлык югары технологияле сәнәгате локомотивы буларак «Авиатөзелеш» субкластерының конкуренциягә югары сәләтле булуын тәэмин итү.

*Субкластерда төп катнашучылар*: «Махсус авиация» КАЖ («Туполев» ААЖ һәм «С.П. Горбунов исемендәге КАПО» берләшмәсе), КАПО авиация технопаркы, «КАПО-Композит» заводы, «С.П. Горбунов исемендәге КАПО» һәм «Туполев» конструкторлык бюросының Казан филиалы базасында инженер-техник үзәк, «КАИ-Лазер» регионара инжиниринг үзәге, «Казан вертолет заводы» ААЖ, «М.П. Симонов исемендәге ОКБ» НПО» ААҖ, «Фирма «МВЭН» ҖЧҖ, «Электроприбор» Казан заводы» ААҖ, «Ак Барс» холдинг компаниясе» ААҖ (авиация һәм махсус билгеләнештәге продукция, самолетлар, вертолетлар һәм авиация двигательләре өчен эшләнмәләр), «Эникс» ЯАҖ Казан пилотсыз очу аппаратлары заводы, «Радиоприбор» ААҖ (хәрби һәм гражданлык билгеләнешендәге авиация өчен борт радиоэлектрон аппаратурасы) һәм «Радиоприбор» Әлмәт заводы» ААЖ, «В.И. Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» НПО» ААҖ (очкычлар һәм корабльләр өчен тану системалары).

4) **«Акыллы машиналар» инновацион кластеры** (кара 3.3.7).

5) **«Акыллы җиһаз» инновацион кластеры** (кара 3.3.7.2).

6) **металлургия сәнәгате**: сәнәгать кластерларының металлургия продукциясенә үсә баручы ихтыяҗын икенчел чималны куллануга (металлоломны эшкәртүгә) нигезләнеп тәэмин итү максатында Татарстан Республикасының металлургия комплексын үстерү. Металлургия сәнәгатендә производствоның локальләшү дәрәҗәсен күтәрү һәм металлургиянең республика сәнәгать кластерларына катнашу дәрәҗәсен арттыру. Җитештерүнең яңа ресурс һәм энергия ягыннан нәтиҗәле технологияләрен кертү, икътисадның югары технологияле тармакларына ихтыяҗны тәэмин итү өчен кирәкле яңа перспективалы корычлар һәм эретмәләр җитештерүне оештыру.

*Кластерлы үсештә төп катнашучылар*. Металлолом җыю һәм эшкәртү: «Интерметтрейд» ҖЧҖ; «Казан производство берләшмәсе» ҖЧҖ. Металлургия производствосы: «Әлмәт торба заводы» ААҖ (корыч торбалар); «Кама коюю заводы — КАМАЗ-Металлургия» ААҖ (автомобильләр өчен запас частьләрне чуеннан һәм корычтан кою); «ТЭМ-ПО» Чаллы торба заводы» ЯАҖ (корыч торбалар); «Нефть автоматикасы» ААЖ, Бөгелмә ш.; «А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» ААҖ (чуеннан һәм корычтан кою, титаннан кою, төсле металллардан кою, төзелеш өчен билгеләнгән металл конструкцияләр). Әзер металл эшләнмәләр җитештерү: «Казан корыч профильләр» ҖЧҖ (юка табаклы цинкланган корыч һәм өсте капланган цинкланган корыч); «Металл түбә заводы» ҖЧҖ (өсте капланган металл прокаттан түбә һәм дивар материаллары); «Кукмара металл савыт-саба заводы» ААҖ (коелган алюминий савыт-саба, көйдерми торган өслекле савыт-саба, туризм һәм ял товарлары, икмәк пешерә торган савытлар).

7) **җиңел сәнәгать**: нефть эшкәртү продуктларыннан алынган химик җепселләрдән һәм җепләрдән техник текстиль һәм аның нигезендә продукция җитештерү буенча субкластер булдыру һәм үстерү. Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе кластеры белән интеграция дәрәҗәсен арттыру.

*Субкластерда төп катнашучылар*: полиамид һәм полиэфир җепләр һәм җепселләр җитештерүчеләр; техник текстиль (тукылган яисә тукылмаган материаллар) җитештерүчеләр; техник текстиль нигезендә эшләнмәләр җитештерүчеләр; дәүләт (Татарстан Республикасы). Татарстан Республикасының төп җиңел сәнәгать предприятиеләре: «Полиматиз» ЯАҖ һәм «Эластик» заводы» (тукылмаган материал) ҖЧҖ; «Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы (оек-оекбашлар җитештерү) ААҖ; «Адонис» ААҖ (ир-атлар һәм балалар костюмнары); «Сафьян» ААҖ (күн һәм күн эшләнмәләр); «Спартак» аяк киеме фабрикасы ААҖ (күн аяк киеме); «Кукмара итек басу-киез комбинаты» ААҖ (киез аяк киеме, киез).

8) **агач эшкәртү сәнәгате һәм мебель җитештерү**: конкурентлыкка сәләтле югары өстәлгән бәяле мебель субкластерын булдыру һәм үстерү. Бәя барлыкка китерү чылбырының барлык этапларының конкурентлыкка сәләтен арттыру (агач җитештерүдән һәм әзерләүдән алып ахыр продукцияне сатканга кадәр), агачны барлык нечкәлекләре белән эшкәртү буенча җитештерү куәтләрен арттыру һәм мебель производстволарын киңәйтү һәм өстенлекле проектларны гамәлгә ашыру юлы белән материаллар һәм комплектлау кирәк-яраклары җитештерү (нигез проект — агач плиталар җитештерү заводы — МДФ, ДСП һәм ОСБ), Алабуга шәһәрендә «Кастамону Интегрейтед вуд индастри»). Яңа сату базарларына чыгу.

*Субкластерда төп катнашучылар*: агач әзерләүче предприятиеләр, транспорт компанияләре; материаллар, комплектлау кирәк-яраклары, фурнитуралар һәм упаковкалар җитештерүчеләр; мебель җитештерүчеләр. Агач эшкәртү тармагының төп предприятиеләре: «Зеленодольск фанера заводы» ААҖ, «Идел буе фанера-мебель комбинаты» ҖЧҖ (фанера); «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ (агач плиталар); «Синтекс-2» ҖЧҖ, «Агат» мебель фабрикасы, мебель җитештерүче «Комфорт идеясы» ҖЧҖ һәм башка предприятиеләр (кече һәм урта бизнес); «С.П. Титов исемендәге Чаллы картон-кәгазь комбинаты» НП» (картон һәм кәгазь) эшчеләр ЯАҖ; «Агротехмаштөзелешсервис» ААҖ (санитария-гигиена өчен кәгазь продукциясе).

### 3.3.6.4. Аргросәнәгать комплексы (АПК) составындагы кластерлар

***Максатчан күзаллау***

**Ц-3.4 Татарстан Республикасында югары сыйфатлы продукция чыгаруга һәм өстәлгән бәя булдыруга йөз тоткан конкурентлыкка сәләтле вертикаль интеграцияләнгән АПК кластеры нәтиҗәле эшли. Аның кысаларында төп субкластерлар: «Ашлык», «Шикәр», «Май», «Яшелчә», «Бәрәңге», «Җиләк-җимеш», «Ит», «Сөт», «Аквакультура», шулай ук аерым «Экотуклану» инновацион кластеры эшли.**

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1. Татарстан Республикасының азык-төлек иминлеген тәэмин итү, авыл хуҗалыгы продукциясенең һәм азык-төлек продуктларының төп төрләре белән үз-үзен тәэмин итү дәрәҗәсен арттыру;

2. конкуренциягә сәләтле инновацион продуктлар һәм технологияләр эшләү һәм аларның коммерцияләшүе (импорт алмашу, био- һәм нанотехнологияләр үсеше). Авыл хуҗалыгы культураларының селекция-генетика үзәкләрен һәм кошчылыкта, дуңгызчылыкта һәм мөгезле эре терлек үрчетүдә селекция-токым үзәкләре төзү;

3. кластер (субкластерлар) кысаларында АПК предприятиеләре үсешен тәңгәлләштерү (җитештерү һәм сату программаларын килештерү, кооперация үсеше);

4. АПК өлкәсендә эшкуарлык үсешен кызыксындыру (кече һәм урта бизнес үсешенә басым ясала). Авылда хуҗалык итүнең кече рәвешләрен үстерү (крестьян фермер) хуҗалыклары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, гаилә фермалары);



5. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы кысаларында АПК үсеше өлкәсендә Стратегияне гамәлгә ашыру барышы өчен җаваплы структур бүлекчә – «АПК үстерү институты» төзү. «АПК үстерү» проект мәйданчыгы белән идарә итү;

6. агросәнәгать бизнесын оптимальләштерү урта сроклы программасын гамәлгә ашыру;

7. «Идел-Кама» үсеш полюсы кысаларында югары керемле сату базарларына (Мәскәү шәһәре, Мәскәү өлкәсе) чыгу һәм лидерлык. Ваклап сату челтәрләре белән эшне активлаштыру;

8. авыл хуҗалыгы машина төзелешен үстерү. АПК матди-техник базасын яңарту, модернизацияләү һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру;

9. авыл хуҗалыгы җирләре әйләнешен камилләштерү һәм алардан файдалануның икътисадый нәтиҗәлелеген арттыру. Җирләрнең уңдырышлылыгын арттыруны тәэмин итү;

10. ябык грунтта яшелчәләр җитештерүнең конкурентлыкка сәләтен киңәйтү;

11. комплекслы агроэкологик районлаштыру шартларында органик авыл хуҗалыгын үстерү;

12. авыл хуҗалыгы чималын эшкәртүне этаплап арттыру һәм аны максималь итү;

13. бәя барлыкка китерү чылбырының барлык этапларында ассортиментны киңәйткәндә һәм югары сыйфатны тәэмин иткәндә продукциянең конкурентлыкка сәләтен арттыру;

14. югары сыйфат стандартларына туры килә торган «тирән» эшкәртү продукциясе җитештерү (Европа стандартлары, «хәләл»);

15. кеше капиталын, инфраструктураны һәм институциональ мохитне үстерү, инвестицияләр үсешен тәэмин итү өчен уңайлы шартлар тудыру, шулай ук сату (тәкъдим итү һәм сатып җибәрү) базарларын киңәйтүгә ярдәм итү;

16. агро- һәм экотуризмны, шулай ук альтернатив мәшгульлекнең башка төрләрен үстерү;

17. «Икътисад аша социаль» үсеш моделен гамәлгә ашыру. Озак сроклы перспективада авыл территорияләрен социаль үстерү өчен база буларак АПКны икътисадый үстерү (торак һәм социаль уңайлыклар белән тәэмин итү). АПК предприятиеләренең рентабельлеген арттыру исәбенә АПКда хезмәт хакын республика буенча уртача дәрәҗәгә кадәр күтәрү.*АПК кластерында төп катнашучылар:*

**Ашлык субкластеры**: «Союз Агро» ҖЧҖ, «Ак Барс» ХК» ААҖ төркеме предприятиеләре («Свияга» СХП» ҖЧҖ, «Ак Барс Буа» ҖЧҖ, «Ак Барс Кайбыч» ҖЧҖ), «Кызыл

Шәрык Агро» ААҖ, «Азнакай» агрофирмасы» ҖЧҖ, «Ленино-горск» агрофирмасы» ҖЧҖ.

**Шикәр субкластеры**: Буа шикәр заводы («Ак Барс» ХК» ААҖ, Нурлат шикәр заводы («Агроинвест» идарәче компаниясе), Зәй шикәр заводы («Төркемнәрнең агрокөче» ЯАҖ). Чимал җитештерүчеләр: «Ак Барс» ХК» ААҖ төркеме предприятиеләре («Ак Барс Буа» ҖЧҖ, «Ак Барс Чүпрәле» ҖЧҖ, «Свияга» СХП» ҖЧҖ, «Авангард» ҖЧҖ), «Төркемнәрнең агрокөче» ҖЧҖ холдинг компаниясе предприятиеләре («Зәй шикәре» агрофирмасы» ҖЧҖ).

**Май субкластеры**: «Нәфис Косметикс» төркеме предприятиеләре, шул исәптән «Казан май экстракция заводы» ААҖ (үсемлек мае җитештерү), «Казан май комбинаты» ААҖ (май продукциясе җитештерү), «Нәфис Косметикс» ААҖ (химия продукциясе җитештерү), «Эссен Продакшн АГ» ЯАҖ. Чимал җитештерүче төп предприятиеләр: «ТАТАГРО» ҖЧҖ, «Көнчыгыш Бөртекпродукт» ЯАҖ, «ВЗП Биләр» ҖЧҖ, «ВЗП Болгар» ААҖ.

**Яшелчә субкластеры**: «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ (ябык грунтта яшелчәләр җитештерү: кыяр, помидор, борыч, баклажан, яшел тәмләткечләр); ачык грунтта яшелчә үстерү белән шөгыльләнүче 20гә якын авыл хуҗалыгы оешмасы.

**Бәрәңге субкластеры**: крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыклары (бәрәңгене төп җитештерүчеләр) һәм (перспективада) эшкәртү предприятиеләре.

**Җиләк-җимеш субкластеры**: крестьян (фермер) хуҗалыклары, (перспективада) авыл хуҗалыгы оешмалары һәм эшкәртү предприятиеләре.

**Ит субкластеры**. Кош ите җитештерү: «Чаллы-Бройлер» ҖЧҖ, «Ак Барс» ХК» ААҖ; мөгезле эре терлек ите җитештерү: «Ак Барс» ХК» ААҖ, «Кызыл Шәрык Агро» ИК» ҖЧҖ; дуңгыз ите җитештерү: «Камский бекон» ҖЧҖ.

**Сөт субкластеры**: «Просто Молоко» ИК» ҖЧҖ эшкәртү предприятиеләре (9 сөт эшкәртү заводы: «Казан сөт заводы», «Бөгелмә сөт комбинаты», «Мамадыш май-сыр комбинаты», «Чаллы сөт комбинаты» һ.б.), «Эдельвейс-М» сөт продуктлары комбинаты» ЯАҖ («Danone-Юнимилк» компанияләре төркеме составына керә), «Зеленодольск сөт комбинаты» ААҖ.

**«Аквакультура» субкластеры:** «Арча балыкчылык хуҗалыгы» ҖЧҖ, «Ушнә» балыкчылык хуҗалыгы» ААҖ, «Кайбыч балыкчылык хуҗалыгы» ААҖ, «Дымка» балыкчылык хуҗалыгы» ААҖ, «Зәй балыкчылык хуҗалыгы» ААҖ, «Зәй балык питомнигы» ҖЧҖ, «Чулман» ҖЧҖ.

**«Экотуклану» инновацион кластеры** (кара 3.3.7.2).



***3.3.6.5. Ифраструктура, сәүдә һәм куллану сервислары, эшлекле һәм социаль хезмәт күрсәтүләр тармакларында кластер үсеше***

***Инфраструктураны максатчан күзаллау***

**Ц-3.5 Татарстан Республикасында инфраструктура глобаль конкурентлык сәләтенә ирешә: «Евразия хабы» транспорт-логистика кластеры, «Төзелеш һәм яңа төзелеш материаллары» кластеры нәтиҗәле эшли, торак-коммуналь хуҗалык һәм телекоммуникацияләр, шулай ук «Акыллы» инфраструктура» инновацион кластеры үсә.**

Татарстанның глобаль конкурентлыкка сәләтен арттыру һәм «Идел-Кама» үсеш полюсын үстерү хәлиткеч рәвештә инфраструктурага бәйле. Инфраструктура кластерлары «Акыллы» машиналар» (яңа транспорт, робот техникасы, пилотсыз технологияләр) һәм «Акыллы» мәгълүмат технологияләре» (ясалма интеллект, идарәнең һәм программа тәэминатының профильле системалары, когнитив технологияләр) инновацион кластерлар продукциясенә кызыксындыру ихтыяҗын тәкъдим итәләр.

***Гамәлләр юнәлешләре***

1) **«Евразия хабы» транспорт-логистика кластеры:** дөнья транспорт киңлегенә кушылып (транспортның барлык төрләрен үстерү), транспорт-логистика хезмәт күрсәтүләренең конкурентлык базарын (Свияжск регионара мультимодаль логистик үзәген, «Көньяк капкалар» транспорт-логистика проектын үстерү) булдыруга, шулай ук транспорт инфраструктурасын алдан үстерү нигезендә республика бердәм транспорт пространствосын булдыру аша әчке мобильлеккә ирешүгә нигезләнеп, интенсив үсеш һәм Евразия масштабында глобаль үзәк дәрәҗәсенә ирешү.

*Төп катнашучылар*: «Казан» халыкара аэропорты» ААҖ, «Бегишево», аэропорты» ААҖ, «Казан авиапредприятиесе» ААҖ, «Бөгелмә» аэропорты» ҖЧҖ, С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы – «Туполев» ААҖ филиалы, Су юлларының һәм суднолар йөрешенең Казан районы, «Татфлот» суднолар йөреше компаниясе» ААҖ, «Логистика һәм Татарстан автойөртүләре» НП. «РЖД» ААҖ филиаллары: Горький тимер юлы, Куйбышев тимер юлы; Казан шәһәрендә «Халыкара автомобиль йөртүчеләр ассоциациясе» вәкиллеге; «Q Park Казан», «Биек Тау», «Константиновский» логистика комплекслары.

2) **«Төзелеш һәм яңа төзелеш материаллары» кластеры:** Татарстанның инновацион төзелеш материаллары һәм

технологияләре өлкәсендә лидер буларак (Казан һәм Чаллы — төзелеш материалларының Россия сәнәгать үзәкләре), ә республика предприятиеләренең — глобаль инновацион төзелеш базарында төп уенчылар статусында үсүе. Төзелеш комплексының кластер активациясе, предприятиеләр кооперациясе һәм аларны берләштерү, производстволарны туплау, Татарстан Республикасы компанияләренең глобаль инновацион төзелеш базарына чыгуы һәм Россия Федерациясе территориясендә төзелеш проектларын гамәлгә ашыруда лидерлыкка ирешү.

*Төп катнашучылар*: «Камгэсэнергострой» ААҖ, «Главнефтегазстройсервис» ИК» ҖЧҖ, «КАЗАН» ПСО» ҖЧҖ, «Казметрострой» ААҖ, «Ортэкс» ҖЧҖ, «Трест «Камдорстрой» ЯАҖ, «Татавтодор» ААҖ, «Контакт-С» ҖЧҖ, «Казаньцентрстрой» ААҖ, «АК БАРС Строй» ҖЧҖ, «Нефтегазинжиниринг» ҖЧҖ, «Казан силикат стена материаллары заводы» ҖЧҖ, «Казан төзелеш материаллары комбинаты» ҖЧҖ, «Төзелеш материаллары комбинаты» ҖЧҖ, «Фон» — «Ключищинская керамика» ЯАҖ филиалы, Кощаково кирпеч заводы, «Бөгелмә — төзелеш керамикасы» ҖЧҖ, «ҖБИ-3» Заводы» ААҖ, «Кулонстрой» ЯАҖ, «Йортлар төзү комбинаты» ҖЧҖ, ААҖ «КамгэсЗЯБ», «Кварт» ЯАҖ, «Кама Тамагы гипс рудники» ААҖ, «Фоника Гипс» (ТМ «Аксолит») ҖЧҖ;

3) **торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү**: коммуналь хезмәт күрсәтүләр һәм торак фонды белән идарә итү өлкәсендә конкурентлык базарын булдыру һәм аның сыйфатын арттыру. ТКХ комплексы — лаеклы тормыш сыйфатын тәэмин итүдә үзәк звено.

*Төп катнашучылар:* «Жилбытсервис» ААҖ, «Жилкомсервис» ҖЧҖ, «Ремстрой» ҖЧҖ, «Горзеленхоз» ААҖ, «Торак һәм комфорт» ИК, «Уютный дом» ИК, «Паритет» ИК, «Татжилремпроект» ДУП.

4) **телекоммуникацияләр үсеше**: дөньяви телекоммуникация челтәренә кушылу, халыкара стандартлардан файдалану нигезендә элемтә хезмәтләре базарын булдыру, элемтәнең төп нәтиҗәлелек күрсәткечләренә — файдалану мөмкинлеге, сыйфат һәм ышанычлылык балансына ирешү. Татарстан — элемтәнең заманча форматлар һәм тиешле инфраструктура белән югары тәэмин ителеш территориясе.

*Төп катнашучылар*: «Таттелеком» ААҖ, «Телесет» ҖЧҖ, «ТатАИСнефть» ҖЧҖ, «Сальвадор» ҖЧҖ, «Татсвязьпроект» ААҖ;

5) **«Акыллы» инфраструктура» инновацион кластеры** (кара 3.3.7.2).



*Сәүдә һәм куллану сервисларын максатчан күзаллау*

**Ц-3.6 Татарстан Республикасында «Сәүдә һәм куллану сервислары» конкурентлыкка сәләтле кластеры нәтиҗәле эшли. Халыкның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен глобаль конкурентлык базарын үстерү исәбенә тотрыклы үсеш бара (максималь сыйфатлы товарның минималь бәясе, инфраструктурадан файдалану мөмкинлеге һәм комфорт, югары сервис дәрәҗәсе). Татарстан — сәүдә һәм хезмәт күрсәтүләр территориясе «24/7», Евразия масштабындагы заманча коммерция үзәге. Сәүдә һәм куллану сервисларының классик төрләрен үстерү, заманча формаларга юнәлешне үзгәртү, шулай ук юкка чыгарылган һәм электрон коммерция формаларын киң тарату.**

*Кластерда төп катнашучылар*: «Бәхетле-1» ҖЧҖ, «Эдельвейс» СК» ЯАҖ, «Оптовик» ҖЧҖ («Эссен» гипермаркетлары), «Чаллы-Икмәк» сәүдә йорты ҖЧҖ, «Камилла» сәүдә йорты» ҖЧҖ, «Ак Барс Регион» ҖЧҖ .

***Финанс, һөнәри, туристлык-рекреацион, мәгълүмати-технологик хезмәт күрсәтүләрне максатчан күзаллау***

**Ц-3.7 Татарстан Республикасында түбәндәге конкурентлыкка сәләтле кластерлар эшли: «Финанс һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләр», «Цивилизацияләрнең кушылуы» (мәдәният, туризм һәм рекреация), шулай ук «Акыллы» мәгълүмат технологияләре» инновацион кластеры**

***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) **«Финанс һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләр» кластеры**: белемнәргә нигезләнгән югары җитештерүчән бизнес-хезмәт күрсәтүләрне алдан үстерү; финанс, инвестицион, иминият һәм башка һөнәри[1] хезмәт күрсәтүләрнең глобаль конкурентлыкка сәләтле базарын булдыру, бердәм дөнья киңлегенә кушылу аша «Казан — региональ финанс үзге» кластер проектын үстерү; финанс һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләргә халыкның һәм оешмаларның ихтыяҗларын максималь канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле оешкан системаны булдыру. Махсуслаштырылган инновацион-инвестицион инфраструктураны үстерү. Татарстан икътисадында финанс секторының мөстәкыйль ролен акрынлап көчәйтү һәм аның кайбер сегментларын Россия эчендә дә, чит илләрдә дә махсуслаштыру предметына әверелдерү.

1 Һөнәри хезмәт күрсәтүләргә түбәндәге төрләр керә: консалтинг, юридик, аудиторлык, инвестицион, иминият, рекрутинг, архитектур хезмәт күрсәтүләр, шулай ук активлар белән идарә итү һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр урнаштыру буенча хезхмәт күрсәтүләр

*Төп катнашучылар:* Банк секторы: «Ак Барс Банк» ААҖ, «АИКБ «Татфондбанк» ААҖ, «Банк «Аверс» ҖЧҖ, «КБ «Интехбанк» ААҖ, «Акибанк» ААҖ, «Спурт Банк» ААҖ, «АКБ «Энергобанк» ҖЧҖ, «АКБ «БТА-Казань» ААҖ. Иминләштерү секторы: «НАСКО» ААҖ, «СГ «АСКО» ҖЧҖ, «СО«Талисман» ААҖ, «СК «Чулпан» ЯАҖ, «СК «Итиль Армеец» ААҖ. Кыйммәтле кәгазьләр базары: «Татарстан Республикасының үзәк депозитарие» ААҖ, «ПРОФИК» ҖЧҖ, «Элемтә» инвестиция компаниясе» ҖЧҖ, «Карат» инвестиция компаниясе» ЯАҖ, «АГРО БРОКЕР» ҖЧҖ, «Фараон-К» ҖЧҖ, шулай ук һөнәри консультацион хезмәт күрсәтә торган региональ компанияләр.

2) **туристлык кластеры**. Кластер үзәгендә – Татарстан Республикасы мәдәнияте: креатив индустрияләрнең конкурентлыкка сәләтле һәм яшәешкә сәләтле үзәген формалаштыруга, мирасның һәм традицияләрнең сакланышын, һәркем өчен мәдәни тормышта һәм иҗади үзбилгеләнештә катнашу мөмкинлеген тәэмин итә торган кызыклы мәдәни мохит булдыруга ярдәм итә торган нисбәтле экосистема. Туристлык объектларын һәм инфраструктураны үстерү юлы белән туристларның урнашу, күңел ачу, туклану һәм трансферларга ихтыяҗларын тәэмин итүче сыйфатлы турпродуктлардан гыйбарәт булган конкурентлыкка сәләтле глобаль туризм һәм рекреация системасы республиканың бай мәдәни-тарихи мирасына һәм табигать-ресурс куәтенә нигезләнә.

**3) мәгълүмати-технологик үсеш**. Глобаль базарга чыгу, инновацион инфраструктура тәэмин итү, шулай ук югары квалификацияле белгечләр әзерләү исәбенә тотрыклы үсеш. Глобаль мәгълүмат технологияләре базарында конкурентлык сәләтенә, яңа мәгълүмат технологияләре һәм программа продуктлары булдыруда һәм коммерцияләштерүдә, шулай ук югары сыйфатлы һәм нәтиҗәле инновацион инфраструктурада лидерлыкка ирешү. Инновацион кластерлар формалаштыру, «Акыллы» мәгълүмат технологияләре» инновацион кластеры төп кластерга әвереләчәк (3.3.7.2).

**4) «Иннополис – югары технологияләр һәм иновацияләр шәһәре» флагман проекты** (3.3.7.1).

***Социаль хезмәт күрсәтүләрне максатчан кузаллау***

**Ц-3.8 Татарстан Республикасында конкурентлыкка сәләтле түбәндәге социаль-инновацион кластерлар эшли: «Фән һәм мәгариф» («Smart-мәгариф» инновацион кластерын төзеп, 14 фәнни-белем бирү субкластерын берләштерә), «Сәламәтлек саклау» («Сәламәт яшәү рәвеше» инновацион кластерын төзеп, өч территориаль субкластерны берләштерә).**



***Гамәлләр юнәлешләре:***

1) **«Фән һәм мәгариф» кластеры**. Бөтен гомер буена юнәлешен алдан белеп һәм өзлексез укыту буенча хезмәт күрсәтүләрнең югары дәрәҗәсен тәэмин итүче глобаль конкурентлыкка сәләтле кластер булдыру. Мәгариф һәм квалификация күтәрү өлкәсендә югары технологияле бизнес-хезмәт күрсәтүләрне үстерү. Кластерлы алым нигезендә мәгариф ресурсларының нәтиҗәле территориаль-тармак оешмаларын булдыру. Тармак заказчыларын (эш бирүчеләрне) һәм дәүләт хакимияте тармак башкарма органнарының координацияләүдәге ролен исәпкә алып, һөнәри белем бирү оешмаларын берләштерә торган региональ кластер системасын булдыру.

*Кластерда төп катнашучылар*: һөнәри белем бирү оешмалары, ресурс үзәкләре, корпоратив университетлар, инновацион компанияләр;

2) **«Smart-мәгариф» инновацион кластеры** (3.3.7.2);

3) **«Сәламәтлек саклау» кластеры**. Республика халкы өчен файдалану мөмкинлеге булган һәм башка регионнардагы халык өчен кызыксындыру уяткан дөнья дәрәҗәсендәге сәламәтлек саклау хезмәтләрен тәэмин итә торган заманча логистика һәм транспорт системалары ярдәмендә пациентларга үзәкләштерелгән ярдәм күрсәтү системаларының иң яхшы дөньяви практикалары нигезендә идарә ителә торган өч төп үсеш үзәгендә (Казан, Кама, Әлмәт икътисадый зоналарында) урнашкан күп функцияле территорияара интеграцияләнгән медицина-реабилитация кластеры булдыру. Республика медицина оешмаларын дөнья рейтингы системасына кертү сәламәтлек саклау системасы эшенең сыйфатын тизрәк үстерүгә һәм башка регионнардан пациентлар җәлеп итүгә ярдәм итәчәк.

4) **«Сәламәт яшәү рәвеше» инновацион кластеры** (3.3.7.2).

### 3.3.7. Икътисадый үсешнең флагман проектлары

#### 3.3.7.1. «Иннополис – югары технологияләр һәм инновацияләр шәһәре» флагман проекты

«Иннополис» федераль әһәмияттәге проектның максаты – югары, шул исәптән мәгълүмати технологияләр өлкәсендә махсуслашкан квалификацияле белгечләрне сыйфатлы әзерләүне, аларның югары тормыш дәрәҗәсен һәм нәтиҗәле эшен тәэмин итүче уникаль экосистема буларак яңа шәһәр төзү.

Проектның **актуальлеге** түбәндәге факторларга бәйле:

• икътисадны диверсификацияләү һәм икътисадый үсешне тизләтү максатларында мәгълүмат технологияләре тармагын тизрәк үстерү зарурлыгы;

• гамәлдәге мәгариф системасының югары технологияләр

өлкәсендә, ИТне кертеп, җитәрлек санда югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә сәләтле булмавы;

• Россия Федерациясе субъектларында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә аеруча квалификацияле белгечләр өчен алдынгы халыкара үзәкләр белән конкуренциягә сәләтле тормыш сыйфатының һәм эшкә урнашу мөмкинлекләренең булмавы.

Проект түбәндәге төп элементларны төзүне һәм үстерүне үз эченә ала.

1. **Эшлекле инфраструктура**, аның үзәк өлеше – «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зона («Иннополис» МИЗ), анда киләчәк резидентларга ташламалы салым ставкалары каралган. Махсус икътисадый зона Иннополис шәһәре экосистемасының мөһим өлеше һәм, резидендлар өчен бизнесны уңышлы алып бару һәм аларның проектларын нәтиҗәле үстерү өчен уңайлы шартлар тудырып, аның инвестицион җәлеп итүчәнлегенең аерылгысыз элементы булып тора.

2. **Яңа «Иннополис» университеты**, бары тик югары технологияләре өлкәсендә генә белгечләр әзерләү буенча гына махсуслаша, әлегә 2000 студентка исәпләнелә, киләчәктә 5000 студентка кадәр арттырылачак. «Иннополис» университеты яңа шәһәрнең интеллектуаль үзәгенә әвереләчәк һәм үз илебезнең инновацион индустриясен яңа сыйфат дәрәҗәсенә күтәрү өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләячәк. Халыкара дәрәҗәдәге университетта фәнни тикшеренүләр алып барылачак һәм югары технологияләр өлкәсендә бакалавриат, магистратура һәм аспирантура программалары буенча белгечләр әзерләнәчәк. Шулай ук мәктәп балаларын югары уку йортына кадәр, әзерләү һәм ИТ-компанияләре белгечләренең квалификацияләрен күтәрү курслары каралган.

3. **Торак һәм социаль инфраструктура** заманча таләпләргә җавап бирә, ул югары, шул исәптән мәгълүмат технологияләре өлкәсендә һәм катнаш өлкәләрдә югары квалификацияле белгечләр һәм аларның гаилә әгъзаларын җәлеп итүнең һәм кызыксындырып тотуның төп факторларының берсе булачак.

Иннополис шәһәренә шәһәр округы статусы бирелер дип планлаштырыла, ягъни ул Татарстан Республикасында өченче шәһәр округы булачак. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары 2014 елның 26 ноябрендә Иннополис поселогын район әһәмиятендәге шәһәр итеп үзгәртү һәм аны Введенская Слобода авыл җирлеге составыннан чыгару турында закон кабул иттеләр. 2015 елда җирле үзидарә органнарын төзү һәм район әһәмиятендәге шәһәрне шәһәр округы итеп үзгәртү буенча эшләрне дәвам итү планлаштырыла.



Булачак шәһәрнең перспектив саны, RSP Architects Planners & Engineers (Сингапур) архитектура-планлаштыру бюросы әзерләгән план нигезендә, 155 мең кешене тәшкил итәчәк, шуның 60 меңе – югары квалификацияле белгечләр. Проект 2030 елга кадәр планлаштырыла, ләкин урнашу, беренче 5 мең кеше өчен торак төзелеше төгәлләнгәч, 2015 елда ук башлана.

«Иннополис» проекты **Татарстан Республикасы өчен түбәндәге нәтиҗәләрне** бирәчәк:

• халык саны арту;

• регионның тулаем продукциясендә югары технологияле товарлар өлеше арту;

• эш урыннары саны арту;

• ИТ-белгечләренең Мәскәүгә һәм чит илләргә китүен кыскарту;

• республиканың глобаль инвестиция җәлеп итүчәнлеген арттыру;

• республика базарына яңа ИТ-компанияләрнең килүе;

• Татарстан Республикасының, яшәү урыны буларак, җәлеп итүчәнлеге үсеше;

• муниципаль һәм республика бюджетларына салым җыемнары үсеше;

• яңа инфраструктура объектларыннан файдалана алачак, якындагы торак пунктларда яшәүчеләр өчен өстәмә социаль файда.

«Иннополис» проектының **гомумроссия нәтиҗәләре**:

• икътисадны диверсификацияләү;

• Россия ИТ -тармагының конкурентлыкка сәләтен арттыру;

• югары технологияләр өлкәсендәге белгечләр өчен эш урыннары санын арттыру;

• ИТ-белем бирүдә махсуслаша торган халыкара дәрәҗәдәге университет исәбенә илдә белем бирүне үстерү;

• ИТ өлкәсендә тикшеренүләр санын арттыру;

• инфраструктура һәм социаль мохит сыйфатының яңа стандартларын булдыру.

Иннополис шәһәрендә үсеп килүче яшьләрнең һәм талантлы белгечләрнең аралашуы һәм аларны үстерү өчен уникаль мохит барлыкка киләчәк. Беренче класслы белгечләрнең күпләп җыелуы яңа идеяләрне даими үстерергә, яңа технологияләр һәм карарлар эшләргә һәм аларны гамәлгә кертергә, инновацияләрне сынарга мөмкинлек бирәчәк.

Шуның нәтиҗәсендә, Иннополис шәһәре әлеге Стратегияне гамәлгә ашыру кысаларында инновацион идеяләр, проектлар һәм программалар буенча фикер алышу өчен төп

мәйданчык буларак файдаланылачак. Иннополис дәүләт органнарының, компанияләрнең, стартапларның экспертлары, вәкилләре, халыкара эксперт берлекләре вәкилләре өчен республика мәйданчыгы булачак, анда яңа стратегик юнәлешләр эшләнәчәк, гамәлгә ашырыла торган дәүләт программаларына үзгәрешләр кертеләчәк, яңа дәүләт программаларын эшләү һәм Татарстан Республикасының яңа флагман проектлары буенча тәкъдимнәр формалашачак.

**3.3.7.2. «Татарстан технологик инициативасы» флагман проектлары**

Хәзерге вакытта товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне глобаль җитештерү этаплары бөтен дөнья буенча бүленгән, бу исә түбән продукт һәм субпродукт инновацион кластерлары үсеше өчен мөмкинлекләр тудыра, шулар нигезендә сәнәгатьне масштаблы яңартырга һәм аерым товарлар төрләрен һәм хезмәт күрсәтүләрне җитештерүдә әйдәүче позицияне биләргә сәләтле, бөтен дөньяны белемнәр һәм технологияләр белән төп тәэмин итүче «акыллы» икътисад булдырырга ярдәм итәчәк.

Технологик трендлар, төп технологияләрдә һәм инновацияләрдә булган башлангычлар нигезендә Татарстан Республикасында «акыллы» икътисад кластерларын (3.34 нче рәсем) «Татарстан технологик инициативасы» комплекслы флагман проекты («акыллы» икътисадның 10 инновацион кластеры) кысаларында гамәлгә ашыру күздә тотыла. Проект Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2014 елның 4 декабрендәге юлламасында искә алынган «Милли технологик инициатива» кысаларында пилот проекты булырга мөмкин.

«Акыллы» икътисад үсеше принципиаль яңа технологияләрдән (бишенче, алтынчы, ә киләчәктә җиденче технологик торышлардан) һәм Татарстан Республикасының җитештерү кластерларының традицион өстенлекләреннән бергә файдалана торган заманча предприятиеләр һәм проектлар булдыру аша гамәлгә ашырылачак. Инновацион кластерлар традицион бәйләнешләр һәм ресурслар базасында, шулай ук иң яңа технологик казанышларны куллану нигезендә инновацион продукция чыгару чылбырларын булдыру өчен төрле субъектларның фәнни һәм җитештерү куәтен тупларга тиеш. Уңышның төп шарты — кластерның төп субъектларының халыкара хезмәт бүленешенә кереп китү сәләте, халыкара технологик партнерларны, шулай ук финанс һәм стратегик инвесторларны җәлеп итү.






**3.34 нче рәсем. Инновацион үсешнең төп технологияләре һәм инновацияләре һәм өстенлекле юнәлешләре**

«Акыллы» икътисадның 10 инновацион кластеры технологияләрне һәм заманча икътисадый комплекслар продуктларын конвергенцияләү барышында формалаша, икътисадый комплекслар кластерлы активация барышында синергетик нәтиҗә исәбенә яңа үсеш дәрәҗәсенә чыгарга һәм «акыллы» икътисадның нигезе булып әверелергә мөмкин.



**3.35 нче рәсем. «Татарстан технологик инициативасы» флагман проекты — Татарстан Республикасының «акыллы» икътисады инновацион кластерлары**



Инновацион кластерларны төзү юнәлешләре:

1) **«Акыллы» материаллар» инновацион кластеры** (яңа пластиклар һәм композитлар, наноструктурлаштырылган материаллар). Эре нефть газ химиясе һәм энергетика бизнесы, «Идея» ИПТ базасында нанотехнологик кластер формалаштыруны да кертеп, тармак фәне һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә яңа полимер һәм композицион, наноструктурлаштырылган материаллар эшләү, аларны гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче инновацион компанияләрнең яңаларын барлыкка китерү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыру («Татарстан Республикасында нанотехнологияләр өлкәсендә инновацион территориаль кластер төзү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 октябрендәге 988-ПУ номерлы Указы нигезендә). Нанотехнологияләрне һәм «бизнес — фән — дәүләт» бәйләнешен булдыру буенча институциональ алымнарны да кертеп, иң яңа технологияләр нигезендә заманча «акыллы» материаллар җитештерүне үстерү. Стратегик перспективада республикада нанопродукция нигезендә яңа материалларның күп тапкыр үсешен фаразларга мөмкин (2014 елда нанопродукция күләме 40 млрд. сумнан артык). «Кама Кристалл Технолоджи» компаниясенең синтетик сапфир җитештерү проектын гамәлгә ашыру. «КАПО-Композит» композицион агрегатлар эшләү һәм җитештерү буенча компетенцияләр үзәге. «КЗСК-Силикон» кремний-органик продукция җитештерү комплексы. Автомобиль шиннары җитештергәндә наноторбалар куллану буенча «Роснано» ААҖ һәм «Түбәнкамашин» ААҖ проектын гамәлгә ашыру. Машина төзелешенең барлык юнәлешләре өчен композит материалларга наноторбалар куллану проекты;

2) **«акыллы» машиналар» инновацион кластеры**. «Автомобиль төзелеше», «Авиатөзелеш», «Суднолар төзелеше» машина төзелеше субкластерларының төп предприятиеләре, тармак фәне һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә транспорт чараларын һәм алар өчен файдаланыла торган җайланмаларны җитештерү юнәлешләрен конвергенцияләү өлкәсендә инновацион компанияләрнең яңаларын барлыкка китерү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыру. Яңа машиналар эшләү, гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату: пилотлы һәм пилотсыз транспорт (авиация, автомобильләр, суднолар, шулай ук кечкенә, микро һәм нано- пилотсыз транспорт), «акыллы» двигательләр (гибрид, энерго-, био-, газ-, гелио-, электр двигательләре) һәм башка интеллектуаль транспорт системалары;

3) **«Акыллы» җиһаз» инновацион кластеры**. Ягулык-энергия-химия һәм машина төзелеше кластерларының төп предприятиеләре, тармак фәне һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә электрон һәм технологик җиһазның киң спектрын эшләү һәм житештерү белән шөгыльләнүче инновацион компанияләрнең яңаларын барлыкка китерү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыру. Конкурентлыкка сәләтле җитештерү җиһазын, электр җиһазын һәм электрон компонентларны үз илебездә җитештерүне үстерү исәбенә Россиянең милли иминлеген тәэмин итүгә ярдәм итү. Яңа нефть-сервис, газ, энергия, электр, азык-төлек җиһазлары, шулай ук станоклар төзелеше, робот техникасы (манипуляцион, оча торган, күчмә, нано- һәм кешегә охшаш роботлар, «акыллы» сервислар) эшләү, гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату. Аддитив технологияләр (3D-бастырып чыгару).булдыру, үстерү һәм алардан файдалану проектлары;

4) **«акыллы» мәгълүмат технологияләре» инновацион кластеры**. Эре предприятиеләр, тармак фәне һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә мәгълүмат технологияләре һәм программа продуктлары өлкәсендә (ясалма интеллект (IoE, IoT), когнитив технологияләр, компьютер сервислары, идарә системалары, мәгълүмат иминлеге) инновацион компанияләрнең яңаларын барлыкка китерү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыру. Кулланылышка кереп баручы мәгълүмат технологияләрен булдыру һәм коммерцияләштерү, «Иннополис» шәһәре базасында югары квалификацияле белгечләр әзерләү үзәге булдыру. «Акыллы» мәгълүмат технологияләре кластеры «Сәламәт яшәү рәвеше» (электрон медицина һәм фармакология сервислары, авыруларны профилактикалау һәм сәламәтлек торышын гомуми мониторинглау системалары), «Акыллы» машиналар» (робот техникасы, пилотсыз технологияләр), «Акыллы» инфраструктура» (идарә һәм мониторинг системалары), «Биосистемалар», «Тотрыклы энергетика» инновацион кластерлары белән үзара хезмәттәшлек бәйләнешендә үсә.

5) **«Smart-мәгариф» инновацион кластеры**. «Фән һәм мәгариф» кластерының төп оешмалары белән тыгыз хезмәттәшлектә инновацион белем бирү хезмәтләрен эшләү, гамәлгә кертү һәм күрсәтү белән шөгыльләнүче инновацион компанияләрнең яңаларын барлыкка китерү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыру. Барлык дәрәҗәләрдәге уку-укыту программаларын эш бирүчеләр белән берлектә әзерләнә торган региональ «компетенцияләр базалары» нигезендә инновацион икътисад ихтыяҗларына яраклаштыру. Россия һәм



дөнья дәрәҗәсендә белгечләр җәлеп итеп, «ачык университетлар» ярдәмендә уку-укыту программаларыннан файдалану мөмкинлеген арттыру;

6) **«Сәламәт яшәү рәвеше» инновацион кластеры**. «Акыллы» медицина (электрон медицина һәм фармакология сервислары, авыруларны профилактикалау һәм сәламәтлек торышын гомуми мониторинглау системалары) юнәлешендә инновацион компанияләрне үстерү һәм спорт-савыктыру проекты инициативалары комплексын (физик культураны һәм спортны үстерү (шул исәптән «Татарстан – спорт регионы» проектын гамәлгә ашыру), сәламәт туклану культурасын популярлаштыру, алкоголизмны һәм наркоманияне профилактикалау, тәмәке тартуга каршы көрәш һәм сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру буенча башка чаралар) гамәлгә ашыру өчен уңай шартлар тудыру;

**7) «Акыллы» инфраструктура» инновацион кластеры**. Инфраструктура комплексының эре предприятиеләре, тармак фәне һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте белән тыгыз хезмәттәшлектә пространство һәм инфраструктура («акыллы» шәһәр, җирдән «акыллы» файдалану, «акыллы» юл, «акыллы» йорт һ.б.) үстерү өлкәсендә карарлар әзерләү, гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче инновацион компанияләрнең яңаларын барлыкка китерү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыру;

8) **«Экотуклану» инновацион кластеры**. Органик продукция җитештерү стандартларын үтәү һәм җитештерүнең, эшкәртүнең югары өстәлгән бәяләр бирә торган яңа экологик чиста технологияләр куллану нигезендә югары сыйфатлы яңа органик продукцияне эшләү, гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче инновацион компанияләрнең яңаларын барлыкка китерү һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыру;

9) **«Тотрыклы энергетика» инновацион кластеры**. Заманча эре энергетикада («акыллы» генерация һәм «акыллы» челтәрләр, яңа аккумуляторлар һәм үткәргечләр һ.б.) яңа технологияләр һәм энергиянең тотрыклы чыганакларын (кояш энергиясе, җил һәм су, биомасса энергиясе, атом энергиясе һәм көнкүреш калдыкларыннан алына торган энергия) куллану нигезендә инновацион тотрыклы энергетика үстерү өчен уңай шартлар тудыру;

10) **«Биосистемалар» инновацион кластеры.** Республикада кече биотехнологик предприятиеләрнең инновацион һәм технологик куәтен үстерү, интеллектуаль капиталның оптималь коммерция рәвеше буларак, кече һәм урта инновацион биотех-

нологик компанияләр тудыруны кызыксындыру нигезендә сәламәтлек саклауда, сәнәгатьтә һәм авыл хуҗалыгында био- һәм нанотехнологияләр куллануга басым ясап, биотехнология тармагын инновацион үстерү өчен шартлар тудыру. Сәламәтлек саклау һәм фармацевтика (биофармацевтика, парафармацевтика, вакциналар, диагностик системалар, биоөстәмәләр, биоэнергетиклар), сәнәгать (энзимнар, микроорганизмнар, күзәнәк технологияләре, ферментлар, биокатализаторлар, биоягулык, биопластик, калдыкларны чистарту һәм юкка чыгару өчен биочаралар) һәм авыл хуҗалыгы (агробиостимуляторлар, ген биоинженериясе, селекция, биостимуляторлар, биоашламалар, агробиокуркынычсызлык) био- һәм нанотехнологияләр конвергенциясе, шулай ук традицион өлкәләрдә фәнни белемнәр базасында өч биотехнологик юнәлеш формалаштыру.

## 4. Стратегияне гамәлгә ашыру механизмы

### 4.1 Татарстан Республикасы үсеше белән стратегик идарә итү системасы

Россия һәм дөнья дәрәҗәсендә республиканың конкурентлыкка сәләтен арттыру буенча Стратегиядә каралган амбициоз бурычларга ирешү республикадагы идарә системасының нәтиҗәлелеген (проектлы алым нигезендә планлаштырылган озак сроклы нәтиҗәләргә ирешү аша) һәм тотрыклылыгын (алдынгы ысулларны кулланып һәм иң яхшы белгечләрне җәлеп итеп, идарә итү системасының югары сыйфатлы эшенең гарантиясен тәэмин итү) арттыруга юнәлдерелгән проактив — «тере» идарәне гамәлгә кертү ихтыяҗына бәйле.

Республикада гамәлдәге идарә системасында кайбер җитешсезлекләр бар:

- идарә системалары күп булса да гиперүзәкләштерү, карарлар кабул итә торган бердәнбер үзәк — Татарстан Республикасы Президенты;
- инициативаның җитәрлек булмавы, бары тик башкаруга гына йөз тоту;
- муниципаль дәрәҗәдәге идарәнең йомшаклыгы;
- формаль гамәлдә булган системада дәүләт йөкләмәләренең идарәгә басым ясавы — реаль нәтиҗәгә (кәгазьгә түгел) максатның йомшак булуы, проектлы идарә итүнең җитәрлек файдаланылмавы;
- идарә органнарының агымдагы, аз әһәмиятле эш белән шөгыльләнүе;
- тармак һәм пространство өстенлекләренең үзгәреп торуы һәм структурасы йомшак булу;



- ведомствоара хезмәттәшлеккә әзерлекнең булмавы, белешмәләр базасын кабатлау, аларны вакытсыз актуальләштерү, белешмәләр алмашуның кыенлыгы;
- Стратегияне координацияләүнең бердәм үзәге булмау, җаваплылыкның билгесезлеге;
- икътисад һәм социаль өлкә белән идарә итүдә дәүләтнең өстенлеге, бизнес кызыксынучанлыгының һәм җәлеп итүчәнлегенең түбән булуы.

*Максатчан күзаллау һәм бурычлар*

| | |
|---|---|
| **Ц-4.1** | **Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы үсешенә стратегик идарә итү системасы (ТР ССУР) — киләчәк белән идарә итүнең «тере» системасы төзелгән һәм нәтиҗәле эшли — тотрыклы үсешкә, икътисадның һәм яшәеш сыйфатының конкурентлыкка сәләтен арттыру шартларын булдыруга юнәлдерелгән, даими гамәлдәге проект мәйданнары һәм тышкы һәм эчке мохитне диагностикалый торган тәңгәлләштерелгән стратегик кораллар җыелмасын эшләүче, актуальләштерүче һәм контрольдә тотучы эшче төркемнәр кысаларында хакимиятнең, бизнесның һәм җәмгыятьнең үзара сыгылмалы эшчәнлек механизмыннан файдаланып, конкурентлык мохитендә үзгәрешләргә оператив йогынты ясарга сәләтле система.** |
| *З-4.1.0.1* | Татарстан Республикасы үсешенең стратегик өстенлекләре мониторингын билгеләргә һәм тәэмин итәргә. |
| *З-4.1.0.2* | Проект мәйданчыклары кысаларында республика үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә хакимиятне, бизнесны һәм җәмгыятьне җәлеп итүне тәэмин итәргә. |
| *З-4.1.0.3* | Кластер активациясен тәэмин итәргә. |
| *З-4.1.0.4* | Тармак һәм территориаль планлаштыру механизмнарын, стратегик программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлекле оештырылган структуралар (институтлар һәм үсеш агентлыклары төзеп) синхронлаштыруны тәэмин итәргә. |
| *З-4.1.0.5* | Механизмнарны үстерү идарәсенә дәүләт хосусый партнерлыгын кертүне һәм дәүләт идарәсенә региональ бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итәргә; |
| *З-4.1.0.6* | Стратегиянең мониторингын һәм актуальләштерелүен тәэмин итәргә. |

Стратегияне эшләү этабында түбәндәге системаны формалаштыру өчен алшартлар булдырылды.

Түбәндәге төп юнәлешләр буенча төзелгән 13 проект мәйданчыгы эшләде:

• регионара конкуренция — 7,
• икътисадый зоналар — 3,
• икътисадый җитештерү комплекслары — 3.

Мәйданчыкларда хакимият, бизнес һәм эксперт җәмгыяте вәкилләре үзара нәтиҗәле эш итте.

ТР ССУР кысаларында Стратегияне гамәлгә ашыру этабында Стратегиянең гамәлгә ашырылуын тәэмин итүче функцияләр рациональ бүленергә тиеш, аерым алганда, — барлык кызыксынучы якларның гамәлләренә мониторинг, координация һәм кызыксындыру алып барылырга тиеш.

Стратегияне гамәлгә ашыру белән идарә итүнең координациясен тәэмин итүче ТР ССУР үзәге — Татарстан Республикасының көчәйтелгән Икътисад министрлыгы, анда Стратегияне гамәлгә ашыруны координацияләүгә һәм мониторинглауга, аны яңартуга, Стратегияне гамәлгә ашыруны тәэмин итүче Татарстан Республикасы дәүләт программалары өчен максатчан индикаторлар булдыруга җаваплы Стратегияне гамәлгә ашыруны анализлау бюросы (БАРС) төзеләчәк.

БАРС — аналитик һәм креатив орган, ул:

• Стратегияне гамәлгә ашыру барышын анализлый, алар өчен стратегик максатлар билгели;
• министрлыкларның эшен анализлый;
• дәүләт максатчан программалары өчен стратегик максатлар формалаштыра;
• кластерлы активацияне тәэмин итә;
• республика үсеше өчен яңа юнәлешләр һәм проектлар эзли;
• Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Стратегияне гамәлгә ашыруга багышланган утырышлары өчен докладлар тәкъдим итә.

БАРС «Татарстан-2030» проектының проект мәйданчыклары активлыгына ярдәм итәчәк, инициативалар агымын тәэмин итәчәк һәм кайбер очракларда мәйданчыклар базасында аерым муниципальара һәм тармакара проектларга этәргеч бирү өчен координация структуралары төзергә ярдәм итәчәк.

БАРС анализлый һәм контрольдә тота торган юнәлешләр «Татарстан 7+5+3» моделенә (4.1 нче рәсем) туры килә, бу БАРСның оештыру структурасында чагылыш табарга мөмкин:

• биш база икътисадый комплексында кластерлы активация барышын анализлаучы һәм җайга салучы кластерлы үсеш блогы;



• республика буенча тулаем һәм өч икътисадый зона һәм агломерация буенча пространство үсешен анализлаучы һәм җайга салучы территориаль үсеш блогы;
• республиканың институциональ, инновацион һәм инвестицион үсешен, шулай ук республиканы алга җибәрү һәм аның предприятиеләре продукциясен сатуны анализлаучы һәм җайга салучы бүлекчәләр җыелмасы.




**4.1 нче рәсем. Татарстан Республикасы үсешенең стратегик идарә системасы белән контрольдә тотылучы юнәлешләр**

Моннан тыш, Татарстан Республикасының үсеш институтлары системасына ревизия ясау, аны ныгыту һәм, бәлки, үзгәртеп кору һәм төзеп бетерү күздә тотыла торган түбәндәге принциплар:

• үсеш институты Татарстан Республикасы икътисадының һәм (яисә) социаль өлкәсенең төп юнәлешләреннән берсен кызыксындыру өчен төзелә;
• үсеш институты проектлы алымнан файдалана (проектларны гамәлгә ашыруга сыйфатлы партнерларны һәм экспертларны җәлеп итеп), ягъни «нәтиҗәгә» эшли, ул һәр проект һәм институт өчен тулаем Стратегия нигезендә эшләнә торган эшчәнлекнең бишьеллык планнарында раслана һәм ел саен актуальләштерелә торган төп нәтиҗәлелек күрсәткечләре җыелмасы буларак билгеләнә;

• үсеш институты Татарстан Республикасы катнашында да, вазыйфаи компетенцияләргә ия булган үзенә бурычларны һәм тәвәккәллекне озак сроклы контракт нигезендә алырга әзер булган хосусый партнерны җәлеп итеп, дәүләт-хосусый партнерлыгы кысаларында да төзелергә мөмкин;

• үсеш институты аны үзгәртеп кору нәтиҗәсендә гамәлдәге оешма рәвешендә дә булырга мөмкин;

• үсеш институтлары бюджеттан ел саен расланган траншеялар исәбеннән һәм нәтиҗәләргә ирешкән өчен (куелган бурычларны гамәлгә ашыру, инвестиция проектларын гамәлгә кертү, нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләренә ирешү) бүләкләүләр исәбеннән финанслана; үсеш институты төзелгәннән соң ике-өч ел эчендә төп финанслау чыганаклары җәлеп ителгән инвестицияләрдән комиссион түләүләр булырга тиеш;

• үсеш институтлары өстенлекле чаралар һәм проектлар кысаларында аны тиражлау максатыннан нәтиҗәләргә ирешүнең иң яхшы практикасын туплаган «компетенцияләр үзәкләре» булып тора;

• үсеш институты иң яхшы белгечләр һәм тармак экспертларын җәлеп итеп төзелә; үсеш институты хезмәткәрләре дәүләт хезмәткәрләре булып тормый, бу эшчәнлек нәтиҗәләренә турыдан-туры бәйле булган, конкурентлыкка сәләтле түләүгә мөмкинлек бирә.

Үсеш институтлары системасы флагман проектларны, Стратегиянең төп икътисадый комплексларын һәм төп өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә тиеш. Мәсәлән, нефть-газ-химия комплексын үстерү институты «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖне үзгәртеп кору юлы белән төзелә, агросәнәгать комплексын үстерү институты Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының структур бүлекчәсе буларак төзелә, машина төзелеше комплексын үстерү институты Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан төзелә.

**4.2. Гамәлгә ашыру инструментлары, мониторинг**

Татарстанда индикатив планлаштыруның һәм программа идарәсенең (2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеш программасын үтәүнең нәтиҗәле мониторингы, идарә итүгә дәүләт йөкләмәләре үтәлешенә контроль һ.б.) күпьеллык уникаль тәҗрибәсе, шулай ук эре һәм катлаулы проектлар белән идарә тәҗрибәсе тупланды. (2013 елгы Универсиада). Бу Стратегияне гамәлгә ашыру белән идарә итү өчен ышанычлы нигез тудыра.

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы законы планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында эшләнә торган төп гамәлгә ашыру инструментларын – стратегик планлаштыру документларын билгеләде. Аларга түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы (алга таба шулай ук – Чаралар планы);

2) Татарстан Республикасы дәүләт программалары;

3) Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы.

Стратегияне һәм флагман проектларны гамәлгә ашыру буенча эшләрнең төп юнәлешләре, җаваплы башкаручыларны һәм гамәлгә ашырудан көтелгән нәтиҗәләрне күрсәтеп, Чаралар планында детальләштереләчәк. Үз чиратында, Чаралар планы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларының гамәлдәгеләренә үзгәрешләр кертеләчәк, шулай ук, кирәк булганда, яңалары эшләнәчәк, аларда финанслау күләмнәре һәм чыганаклары күрсәтелеп, конкрет чаралар билгеләнәчәк.

Шулай итеп, Стратегия нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча төп эш Чаралар планын һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны контрольдә тотуга бәйле булачак. Шул рәвешле, Стратегиянең, Чаралар планының һәм дәүләт программаларының үзара бәйләнеше һәм даими координацияләнгән янарышы тәэмин ителергә тиеш (4.2 нче рәсем).




**4.2 нче рәсем. Стратегияне һәм Чаралар планын яңартуны синхронлаштыру схемасы**

Актуальләштерү, корректировкалау һәм яңарту (кирәк булганда) процедуралары – даими процесс: стратегик документлар

җыелмасын елга бер тапкыр актуальләштерү, өч елга бер тапкыр корректировкалау һәм алты елга бер тапкыр яңарту башкарыла. Процедура планлаштырылган күрсәткечләрдән аермалы гамәлләргә китергән сәбәпләрне һәм факторларны анализлауны, шулай ук корректировкаланган текстларны һәм лимитларны Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары белән килештерүне һәм раслауны күздә тота.

Ел саен актуальләштерү Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты юлламасына бәйле. Юлламага узган ел өчен Стратегия үтәлешенә анализ һәм киләсе ел өчен Стратегияне гамәлгә ашыру өстенлекләре кертеләчәк.

Өстенлекләр еллар буенча бүленеп, озак сроклы перспективага билгеләнә һәм дәүләт хакимияте органнарының Стратегия үтәлеше максатларына юнәлдерелгән финанс чараларын һәм башка ресурсларны бүлүендә чагыла. Өстенлекләр озак сроклы дәүләт программалары, чаралар һәм шул исәптән федераль дәрәҗәдәге проектларның үтәлешен исәпкә алырга тиеш. Юлламада күрсәтелгән өстенлекләр нигезендә Стратегиягә кирәкле өстәмәләр әзерләнә, алар гавами фикер алышу өчен Интернет челтәренә урнаштырыла.

Стратегияне гамәлгә ашыру мониторингы механизмы социаль-икътисадый күрсәткечләрнең бердәм мәгълүмат базасын булдыру аша региональ статистика системасын камилләштерүне күздә тота. Бу Чаралар планының үтәлешен характерлый һәм аның нәтиҗәлелеген бәяли торган дөрес мәгълүматны оператив алырга мөмкинлек бирә.

Стратегиянең аерым чараларын гамәлгә ашыру буенча оператив хисаплылыкның төп төре — Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тармак органнары хисаплары. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте тармак органнары җитәкчеләре Стратегияне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекнең нәтиҗәләре һәм төп юнәлешләре турында ел саен хисап тоталар.

Гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган мөһим инструментларның берсе — Стратегияне төрле максатчан төркемнәрдә үтәү һәм Стратегия нигезендә республиканың тулаем һәм аның аерым территорияләренең, Стратегиянең флагман проектларының брендлау системасын һәм брендларын булдыру.

Стратегияне гамәлгә ашыру уңышы өчен идарә итүнең муниципаль дәрәҗәсен активлаштыру һәм муниципаль берәмлекләрнең стратегик планлаштыру документларын эшләвен һәм (яисә) яңартуын нәтиҗәле оештыру мөһим, бу эш 2016 елга билгеләнгән.



### 1.3. Дәүләт программалары исемлеге

Стратегия нигезендә Стратегияне гамәлгә ашыру максатларында тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программалары җыелмасы төгәлләштерелде (4.1 нче таблица).

Барлык гамәлдәге дәүләт программалары 2020 елга кадәр гамәлгә ашырыла (шул елны кертеп). Кирәк булганда, аларга Стратегия максатлары һәм бурычлары нигезендә үзгәрешләр кертеләчәк. Шулай ук тармак комплексларын үстерү бурычларын гамәлгә ашыру максатларында кайбер дәүләт программаларын эшләү күздә тотыла.

**4.1. нче таблица. Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләүгә, кабул ителүгә әзерләнә торган дәүләт программалары исемлеге**

| № т/б | 2015 елда гамәлдәге Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге | Татарстан Республикасы яңа дәүләт программалары исемлеге (2016 елның 1 гыйнварыннан соң кабул ителә торган) | Стратегияне гамәлгә ашыру этаплары буенча гамәлдә булу чорлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016–2018 | 2019–2021 | 2022–2024 | 2025–2030 |
| 1. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру | | + | + | | |
| 2. | | Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру | | + | + | + |
| 3. | 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы | | + | + | | |
| 4. | | Татарстан Республикасының Химик һәм биологик куркынычсызлык системасы | | + | + | + |
| 5. | | Татарстан Республикасында нефть чыгаруны һәм нефть эшкәртүне үстерү | | + | + | + |
| 6. | | Татарстан Республикасында сәнәгатьне үстерү | + | + | + | + |
| 7. | 2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу | | + | + | | |
| 8. | | Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын һәм авыл территорияләрен үстерү | | + | + | + |
| 9. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү | | + | + | | |
| 10. | | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү | | + | + | + |
| 11. | 2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү | | + | + | | |



| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | 2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгы базарын үстерү [1] | | + | + | | |
| 13. | | Татарстан Республикасы транспорт-логистика комплексын үстерү | | + | + | + |
| 14. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак белән һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү | | + | + | | |
| 15. | | Татарстан Республикасында торак комплексын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү | | + | + | + |
| 16. | 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү | | + | + | | |
| 17. | | Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү | | + | + | + |
| 18. | 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» | | + | + | | |
| 19. | | Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү | | + | + | + |
| 20. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү | | + | + | | |
| 21. | | Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү | | + | + | + |
| 22. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү | | + | + | | |
| 23. | 2015 –2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү [2] | | + | + | | |
| 24. | | Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү | | + | + | + |
| 25. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү | | + | + | | |

1 2020 елдан соң шундый ук программа ярдәмче программа буларак «Татарстан Республикасы транспорт-логистика комплексын үстерү» дәүләт программасына керәчәк.
2 2020 елдан соң шундый ук программа ярдәмче программа буларак «Татарстан Республикасында мәгарифне һәм фәнне үстерү» дәүләт программасына керәчәк.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 26. | | Татарстан Республикасында туризмны үстерү | | + | + | + |
| 27. | 2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» | | + | + | | |
| 28. | | Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү | | + | + | + |
| 29. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру | | + | + | | |
| 30. | | Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү | | + | + | + |
| 31. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрне үстерү | | + | + | | |
| 32. | | Татарстан Республикасында «Ачык Татарстан» мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрне үстерү | | + | + | + |
| 33. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм аның инновацион икътисады | | + | + | | |
| 34. | | Татарстан Республикасы икътисадының конкурентлыкка сәләтен арттыру | | + | + | + |
| 35. | | Татарстан Республикасында сәүдә һәм экспортны үстерү | | + | + | + |
| 36. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш | | + | + | | |
| 37. | | Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш | | + | + | + |
| 38. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү | | + | + | | |



| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 39. | | Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү | | + | + | + |
| 40. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану | | + | + | | |
| 41. | | Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану | | + | + | + |
| 42. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү | | + | + | | |
| 43. | | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү | | + | + | + |
| 44. | 2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән идарә итү | | + | | | |
| 45. | | Татарстан Республикасы дәүләт финанслары белән идарә итү | + | + | + | + |
| 46. | 2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү | | + | | | |
| 47. | | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү | + | + | + | + |
| 48. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру | | + | + | | |
| 49. | Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 – 2016 еллар )[3] | | + | | | |

3 2010 елдан соң шундый ук программа ярдәмче программа буларак «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасына кертеләчәк.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 50. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү[4] | | + | + | | |
| 51. | | Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру | | + | + | + |
| 52. | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | | + | + | | |
| 53. | | Татарстан Республикасында юстицияне үстерү | | + | + | + |
| 54. | 2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру | | + | + | | |
| 55. | | Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру | | + | + | + |

4 2010 елдан соң шундый укпрограмма ярдәмче программа буларак «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасына кертеләчәк.



2030 елга кадәр Татарстан Республикасының
социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы икътисадый комплекслары структурасы

Икътисадны «база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар» вертикаль-интегральләшкән система форматында структурлаштыру ОКВЭД буенча башлангыч белешмәләр, шулай ук өстәмә аналитика нигезендә башкарыла. Мондый структура Татарстан Республикасы үсешенә идарә итү системасының яңа каркасын төзергә мөмкинлек бирәчәк.

Диагностика, максатларны кую, гамәлләрнең юнәлешләрен билгеләү Стратегиядә икътисадый комплекслар буенча башкарыла һәм тасвирлана. Икътисадый комплекслар буенча икътисад структурасы ОКВЭД буенча икътисад структурасыннан тармакка бәйле рәвештә кайбер комплексларда 1, 2 һәм 3 тәртиптәге структур элементлар төркемнәргә берләштерелгәнлектән бераз аерыла.

**Таблица. ОКВЭД га карата икътисадый комплекслар структурасы**

| Икътисад структурасы: база икътисадый комплекслар – икътисадый комплекслар – тармаклар | ОКВЭДның тиешле бүлекләре |
|---|---|
| **Нефть-газ-химия комплексы** | |
| Ягулык-энергетика казылмаларын чыгару | CA. Ягулык-энергетика казылмаларын чыгару |
| Нефть продуктлары җитештерү | DF.23.2. Нефть продуктлары җитештерү |
| Химия производствосы | DG. ХИМИЯ ПРОИЗВОДСТВОСЫ |
| Резина һәм пластмасс әйберләр җитештерү | DH. РЕЗИНА ҺӘМ ПЛАСТМАСС ӘЙБЕРЛӘР ҖИТЕШТЕРҮ |
| Торбаүткәргеч транспорт | I.60.3. Торбаүткәргеч транспорт |
| Газсыман ягулык җитештерү һәм бүлү | E.40.2. Газсыман ягулык җитештерү һәм бүлү |
| **Энергетика комплексы** | |
| Электр энергиясе җитештерү, тапшыру һәм бүлү | E.40.1. Электр энергиясе җитештерү, тапшыру һәм бүлү |
| Пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) җитештерү, тапшыру һәм бүлү | E.40.3. Пар һәм кайнар су (җылылык энергиясе) җитештерү, тапшыру һәм бүлү |
| **Машина төзелеше һәм башка эшкәртү производстволары комплексы (Машина төзелеше комплексы, МК)** | |
| **Машина төзелеше** | |

| | |
|---|---|
| Машиналар һәм җиһазлар җитештерү | DK. МАШИНАЛАР ҺӘМ ҖИҺАЗЛАР ҖИТЕШТЕ |
| Электр җайланмалары җитештерү | DL. ЭЛЕКТР ҖАЙЛАНМАЛАРЫ, ЭЛЕКТРОН ҺӘМ ОПТИК ҖАЙЛАНМАЛАР ҖИТЕШТЕРҮ |
| Транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү | DM. ТРАНСПОРТ ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ ҖИҺАЗЛАР ҖИТЕШТЕРҮ |
| Автомобильләр җитештерү | DM.34. Автомобильләр, прицеплар һәм ярымприцеплар җитештерү |
| Суднолар төзү һәм ремонтлау | DM.35.1. Суднолар төзү һәм ремонтлау |
| Очу аппаратлары җитештерү | DM.35.3. Очу аппаратлары, космик аппаратларны кертеп, җитештерү |
| Башка транспорт чаралары | DM.35.2. Тимер юл хәрәкәте составын җитештерү (локомотивлар, трамвай мотор вагоннары һәм башка хәрәкәт составы) |
| | DM.35.4. Мотоцикллар һәм велосипедлар җитештерү |
| | DM.35.5. Башка төркемнәргә кертелмәгән бүтән транспорт чаралары һәм җайланмалары җитештерү |
| Металлургия производствосы | DJ. МЕТАЛЛУРГИЯ ПРОИЗВОДСТВОСЫ ҺӘМ ӘЗЕР МЕТАЛЛ ӘЙБЕРЛӘР ҖИТЕШТЕРҮ |
| **Җиңел, агач эшкәртү сәнәгате һәм башка эшкәртү производстволары** | |
| Текстиль һәм тегү производствосы | DB. ТЕКСТИЛЬ ҺӘМ ТЕГҮ ПРОИЗВОДСТВОСЫ |
| Тире һәм күн әйберләре җитештерү | DC. ТИРЕ ҺӘМ КҮН ӘЙБЕРЛӘРЕ ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ АЯК КИЕМЕ ҖИТЕШТЕРҮ |
| Агач эшкәртү һәм агачтан әйберләр җитештерү | DD. АГАЧ ЭШКӘРТҮ ҺӘМ АГАЧТАН ӘЙБЕРЛӘР ҖИТЕШТЕРҮ |
| Целлюлоза-кәгазь производствосы | DE.21. Целлюлоза, агач массасы, кәгазь, картон һәм алардан әйберләр җитештерү |
| Башкалар | DN. БАШКА ПРОИЗВОДСТВОЛАР |
| **Агросәнәгать комплексы (АПК)** | |
| **Авыл хуҗалыгы** | **A.01. Авыл хуҗалыгы, аучылык һәм әлеге өлкәләрдә хезмәт күрсәтүләр** |
| Үсемлекчелек | A.01.1. Үсемлекчелек |
| Терлекчелек | A.01.2. Терлекчелек |
| **Азык-төлек продуктлары җитештерү** | **DA.15. Азык-төлек продуктлары җитештерү** |
| Ит һәм ит продуктлары җитештерү | DA.15.1. Ит һәм ит продуктлары җитештерү |
| Үсемлек һәм терлек майлары җитештерү | DA.15.4. Үсемлек һәм терлек майлары җитештерү |
| Сөт продуктлары җитештерү | DA.15.5. Сөт продуктлары җитештерү |



| | |
|---|---|
| Он-ярма җитештерү сәнәгате продуктлары, крахмал продуктлары производствосы | DA.15.6. Он-ярма җитештерү сәнәгате продуктлары, крахмал продуктлары производствосы |
| Терлекләр өчен әзер азык җитештерү | DA.15.7. Терлекләр өчен әзер азык җитештерү |
| Эчемлекләр җитештерү | DA.15.9. Эчемлекләр җитештерү |
| Башка азык-төлек продуктлары җитештерү | DA.15.2. Балык һәм диңгез продуктлары эшкәртү һәм консервлау |
| | DA.15.3. Бәрәңге, җиләк-җимеш һәм яшелчә эшкәртү һәм консервлау |
| | DA.15.8. Башка азык-төлек продуктлары җитештерү |
| **Балыкчылык, балык үрчетү** | **B. БАЛЫКЧЫЛЫК, БАЛЫК ҮРЧЕТҮ** |
| **Урман хуҗалыгы** | A.02. Урман хуҗалыгы |
| **Инфраструктура комплексы (ИК)** | |
| Сәүдә комплексы | **G. КҮПЛӘП ҺӘМ ВАКЛАП САТУ; РЕМОНТ** |
| Төзелеш комплексы һәм ТКХ | Төзелеш комплексы һәм ТКХ |
| Торак-коммуналь хуҗалык комплексы | Торак-коммуналь хуҗалык комплексы |
| Су җыю, чистарту һәм бүлү | E.41. Су җыю, чистарту һәм бүлү |
| Агым суларны, калдыкларны җыю һәм шундый эшчәнлек | O.90. Агым суларны, калдыкларны җыю һәм шундый эшчәнлек |
| Күчемсез мөлкәт белән операцияләр | K.70. Күчемсез мөлкәт белән операцияләр |
| **Төзелеш комплексы** | |
| Төзелеш | F. ТӨЗЕЛЕШ |
| Башка металл булмаган минерал продуктлар җитештерү | DI. БАШКА МЕТАЛЛ БУЛМАГАН МИНЕРАЛ ПРОДУКТЛАР ҖИТЕШТЕРҮ |
| Башка файдалы казылмалар табу | CB.14. Башка файдалы казылмалар табу |
| **Транспорт-логистика комплексы** | |
| Тимер юл транспорты | I.60.1. Тимер юл транспорты |
| Автомобиль транспорты | I.60.2. Автомобиль транспорты |
| Су транспорты | I.61. Су транспорты эшчәнлеге |
| Һава транспорты | I.62. Һава транспорты эшчәнлеге |
| Ярдәмче һәм өстәмә транспорт эшчәнлеге | I.63. Ярдәмче һәм өстәмә транспорт эшчәнлеге (I.63.3. турагентлыкларның хезмәт күрсәтүләреннән тыш) |
| **Телекоммуникацион комплекс** | I.64. Элемтә |
| **Хезмәт күрсәтүләр комплексы (КУ)** | |
| **Фәнни-белем бирү комплексы** | |
| Мәгариф | M. МӘГАРИФ |
| Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр | K.73. Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр |

| | |
|---|---|
| **Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтүләр комплексы** | **N. СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ һәм социаль хезмәт күрсәтүләр** |
| **Туристик-рекреацион комплекс** | |
| Кунакханәләр һәм рестораннар | Н. КУНАКХАНӘЛӘР ҺӘМ РЕСТОРАННАР |
| Туристлык агентлыклары эшчәнлеге | I.63.3. Турагентлыкларның хезмәт күрсәтүләре |
| Ял итүне һәм күңел ачуларны, физик культура һәм спортны оештыру эшчәнлеге | O.92. Ял итүне һәм күңел ачуларны, физик культура һәм спортны оештыру эшчәнлеге |
| **Мәгълүмат-технология комплексы** | **K.72. Исәпләү техникасыннан һәм мәгълүмат технологияләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек** |
| **Дәүләт һәм хосусый хезмәт күрсәтүләр комплексы** | |
| Финанс комплексы | J. ФИНАНС ЭШЧӘНЛЕГЕ |
| Дәүләт идарәсе, хәрби иминлекне, мәҗбүри социаль тәэминатны тәэмин итү комплексы | L. ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕ, ХӘРБИ ИМИНЛЕКНЕ, МӘҖБҮРИ СОЦИАЛЬ ТӘЭМИНАТНЫ ТӘЭМИН ИТҮ КОМПЛЕКСЫ |
| Эшлекле һәм шәхси хезмәт күрсәтүләр комплексы | O.91. Иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеге |
| | O.93. Шәхси хезмәт күрсәтүләр |
| | K.71. Машиналарны һәм операторсыз җиһазларны арендалау; прокат |
| | K.74. Башка төр хезмәт күрсәтүләр |
| | DE.22. Нәширлек һәм полиграфия эшчәнлеге; язма мәгълүмат чыганакларын тиражлау |

Искәрмә: Икътисадый комплекслар структурасын төзегәндә ОКВЭД нигезендә Татарстан Республикасы икътисадында чагылдырылмаган эшчәнлекнең түбәндәге төрләре күрсәтелмәде:

- CB.13. Металл ятмаларын чыгару;
- DA.16. Тәмәке әйберләре җитештерү;
- DF.23.1. Кокс җитештерү;
- DF.23.3. Атом-төш материаллары җитештерү.



2030 елга кадәр
Татарстан Республикасының
социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә
2 нче кушымта

**2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенең максатлары һәм бурычлары системасы**

**Төп стратегик максат (ГСЦ)**

<u>ГСЦ</u> **Татарстан-2030 – глобаль конкурентлыкка сәләтле тотрыклы регион, «Идел-Кама» үсеш полюсы драйверы. Татарстан – кеше капиталының, институтларның, инфраструктураның, икътисадның, тышкы интеграциянең (Россиянең үзәк Евразия регионы) һәм эчке пространствоның үзара бәйлелегенең сыйфаты буенча алдынгы; алда бара торган темплар белән үсә торган, халыкара эш бүленешенә югары дәрәҗәдә кушылган регион.**

*Стратегик максатлар (СЦ)*

<u>СЦ-1</u> **Кеше капиталы**. Тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә. Республика яшәүнең югары сыйфатына ирешү өчен шартлар тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда алдынгы булып тора.

<u>СЦ-2</u> **Пространство, реаль капитал**. Балансны территориаль-пространство үсеше мохитнең югары конкурентлык сәләтен тәэмин итә; инфраструктура глобаль конкурентлык сәләтенә ия. Җитештерү фондлары нәтиҗәле кулланыла.

<u>СЦ-3</u> **Базарлар.** Татарстан Республикасының махсуслаштыру тармаклары регионара һәм глобаль базарларда конкурентлыкка сәләтле.

<u>СЦ-4</u> **Институтлар**. Дәүләт, хосусый һәм дәүләт-хосусый институтларның балансны системасы конкурентлыкка сәләтле кластерларның, эшкуарлыкның (кече һәм урта бизнесның), эчке территориаль үсешнең һәм тышкы интеграциянең тотрыклы үсешен тәэмин итә.

<u>СЦ-5</u> **Инновацияләр һәм мәгълүмат**. Республика «акыллы» икътисад үстерүдә, яңа материаллар, продуктлар һәм технологияләр булдыруда һәм аларны коммерцияләштерүдә алдынгы булып тора.

<u>СЦ-6</u> **Табигать ресурслары**. Табигать ресурслары тотрыклы үсеш принциплары нигезендә нәтиҗәле кулланыла.

**СЦ-7** **Финанс капиталы**. Республика дөньякүләм дәрәҗәдәге инвестицияләр өчен кызыклы булып тора. Финанс системасы югары нәтиҗәле.

**Юнәлешләр буенча максатлар (Ц) һәм бурычлар (З)**
**Кеше капиталы**

**СЦ-1** **Тупланган кеше капиталы Татарстан Республикасының конкурентлык сәләтен тәэмин итә. Республика яшәүнең югары сыйфатына ирешү өчен шартлар тудыру аша төп актив буларак кеше капиталын туплауда алдынгы булып тора.**

**Ц-1.1** **Татарстан – туучылар саны югары һәм халыкның миграция агымы тотрыклы булган үсә торган регион.**

*З-1.1.0.1* Ике һәм өч балалы гаиләләрнең өлешен арттыру исәбенә туучылар санын алга таба арттырырга.

*З-1.1.0.2* Хатын-кызларга ата-ана бурычларын хезмәт мәшгульлеге белән бергә алып бару өчен шартлар тудырырга.

*З-1.1.0.3* Хезмәткә сәләтле яшьтә үлүчеләр санын һәм идарә ителә торган сәбәпләрдән үлемнәрне киметү исәбенә күтелгән гомер озынлыгын озайтуны тәэмин итәргә.

*З-1.1.0.4* Регионның социаль-икътисадый үсешенә халыкның картаюы йогынтысының тискәре нәтиҗәләрен җиңеләйтергә.

*З-1.1.0.5* Халыкның һәм хезмәт мигрантларының агымын җайга салу өчен шартлар булдырырга.

*З-1.1.0.6* Республикадан яшь буынның, квалификацияле белгечләрнең читкә китүен киметү өчен шартлар тудырырга.

*З-1.1.0.7* Республикада мигрантларның адаптацияләнүенә һәм интеграцияләнүенә ярдәм итү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга.

**Ц-1.2** **Мәгариф системасы Татарстан җәмгыятенең һәм икътисадының ихтыяҗларына туры килә торган кеше капиталын булдыруны тәэмин итә.**

**Ц-1.2.1** **Гаиләләр балаларны һәрьяклап үстерүдә һәм аларны мәктәптә укуга әзерләүдә нәтиҗәле ярдәм белән тәэмин ителде.**

*З-1.2.1.1* Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү торышын һәрьяклап тикшерергә.

*З-1.2.1.2* Уңайлы файдалану мөмкинлекләрен исәпкә алып, инфраструктураны яңартырга, заманча мультимедия технологияләрен гамәлгә кертергә.



*З-1.2.1.3* Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган секторның өлешен арттырырга.

*З-1.2.1.4* Татарстан Республикасының күпмәдәни киңлеген һәм заманча технологияләрне исәпкә алып, яңа Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә уку-укыту программаларын эшләргә.

*З-1.2.1.5* Гаиләләрдә һәм яслеләрдә балаларның иртә үсешен тәэмин итеп бару системасын булдырырга.

*З-1.2.1.6* Балаларның үсешен тәэмин итеп баруның ведомствоара координацияләү системасын эшләргә.

*З-1.2.1.7* Авырлыкларны иртә ачыклау һәм аларны хәл итүдә ярдәм итү өчен балаларның үсешен индивидуаль тәэмин итеп бару системасын булдырырга.

**Ц-1.2.2** **Гомуми белем бирү, индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, һәр мәктәп баласының социальләшүен һәм белем алуда югары казанышларга ирешүен, мәгълүмати технологияләр өлкәсендә күнекмәләр үсешен тәэмин итә.**

*З-1.2.2.1* Заманча архитектура, идарә итү, технологик һәм педагогик чишелешләрне берләштерә торган мохит булдырырга.

*З-1.2.2.2* Белем бирү ресурсларыннан файдалану тигезлеген тәэмин итә торган механизмнар эшләргә.

*З-1.2.2.3* Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив белем бирүне тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.4* Гаиләләрнең, урындагы җәмәгатьнең, бизнесның уку-укыту процессында, белем бирү сыйфатын бәяләүдә һәм мәктәпләр белән идарә итүдә катнашу мөмкинлекләрен киңәйтергә.

*З-1.2.2.5* Укытуның заманча рәвешләрен, профильле укытуны кертеп, үстерү исәбенә, гомуми һәм өстәмә белем бирүне интеграцияләү исәбенә белем алучыларның белем алу индивидуальлегенең һәм академик мобильлегенең югары дәрәҗәсен тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.6* Белем бирү сыйфатын бәяләүнең республика системасын булдырырга.

*З-1.2.2.7* Россия Федерациясендә алдынгылыкка ирешү өчен мәгълүмат технологияләре һәм математика өлкәсендә белем бирүне үстерүгә өстенлек бирергә.

*З-1.2.2.8* Сәләтле балаларны һәм яшьләрне барларга һәм аларга ярдәм итәргә.

*З-1.2.2.9* Педагогик белем бирү системасын яңартырга.

*З-1.2.2.10* Иң яхшы яшь педагогик кадрлар килүен һәм аларның һөнәри үсешен тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.11* Мәктәпләрне үз-үзен укыту оешмалары буларак үстерү стратегияләрен гамәлгә ашыручы алдынгы директорлар корпусын оештырырга.

*З-1.2.2.12* Балалар-үсмерләр оешмаларының республика системасын һәм хәйрия, граждан-патриотик, экологик һәм башка юнәлештәге хәрәкәтләрне үстерүне оештыру-методик алып баруны тәэмин итәргә.

*З-1.2.2.13* Дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

**Ц-1.2.3 Һөнәри белем масштаблары һәм сыйфаты инновацион икътисад таләпләренә һәм халыкның социаль ихтыяҗларына туры килә, һөнәри белем бирү оешмалары белән эффектив системалы идарә итү җайга салынган.**

*З-1.2.3.1* Белем бирү программаларының яраклашучанлыгын арттырырга, халыкның төрле категорияләренә гомер буена һөнәри белем алу мөмкинлеген тудырырга.

*З-1.2.3.2* Һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимизацияләргә.

*З-1.2.3.3* Эш бирүчеләр белән, шул исәптән инновацион предприятиеләр белән нәтиҗәле партнерлык булдырырга.

*З-1.2.3.4* Һөнәри өйрәтү программаларын иҗтимагый-һөнәри аккредитацияләү һәм һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны сертификацияләү системасын оештырырга.

*З-1.2.3.5* Урта һөнәри белем бирү системасына ребрендинг үткәрергә.

*З-1.2.3.6* Урта һөнәри белем бирү системасы өчен кадрлар әзерләргә.

**Ц-1.2.4 Татарстан — югары белемнең конкурентлыкка сәләтле үзәге, талантлар җәлеп итүче лидер регион.**

*З-1.2.4.1* Әйдәп баручы тикшеренү һәм инновация университетларында җитди конкурентлыкка сәләтле булган белем бирүгә ирешергә.

*З-1.2.4.2* Массакүләм югары белемнең канәгатьләнерлек сыйфатын тәэмин итәргә.

*З-1.2.4.3* Россия Федерациясенең әйдәп баручы югары уку йортлары һәм чит ил университетлары белән партнерлыкны үстерергә.

*З-1.2.4.4* Татарстан икътисадының инновацион секторы белән партнерлыкны үстерергә.

*З-1.2.4.5* Юнәлешләр буенча югары уку йортлары төркемнәрен формалаштырырга: югары белем бирүнең федераль



һәм халыкара базарларында конкурентлыкка сәләтле җитди федераль югары уку йортлары; регионның һәм макрорегионның икътисадый ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшли торган көчле бакалавриаты булган (шул исәптән урта һөнәри белем бирү белән берлектә) югары уку йортлары; халыкның сыйфатлы социаль-икътисадый һәм гуманитар белгечлекләргә ихтыяҗын тәэмин итә торган киң юнәлештәге югары уку йортлары (шул исәптән «аерымланган» территорияләрдә).

*З-1.2.4.6* Югары уку йортлары базасында өзлексез белем бирү системасын оештыру аркылы филиаллар челтәре сыйфатын яхшыртырга (шул исәптән хезмәт эшчәнлегенә актив кушылган халык өчен).

*З-1.2.4.7* Регионның һәм макрорегионның эш бирүчеләре, аеруча инновация компанияләре белән югары белем бирү системасын координацияләү һәм аның белән үзара хезмәттәшлек итү механизмнарын үстерергә.

*З-1.2.4.8* Югары уку йортларында идеяләрне һәм эшләнмәләрне коммерцияләштерү системасын җайга салырга.

**Ц-1.3 Татарстан Республикасы халкының һәм сәламәтлек саклау системасының мөһим бурычлары — сәламәтлекне саклау һәм озак яшәү.**

*З-1.3.0.1* Персоналның мотивациясен арттырырга һәм тармакның кадрлар потенциалын ныгытырга.

*З-1.3.0.2* Аерым авырулардан үлүчеләр санын киметергә (кан әйләнеше системасы авыруларыннан, юл-транспорт һәлакәтләре җәрәхәтләреннән, шеш авыруларыннан, туберкулездан һ.б.).

*З-1.3.0.3* Халыкта авыруларның көчәюен киметүгә һәм сәламәтлекне саклап калуга юнәлдерелгән тәртип модельләрен формалаштырырга.

*З-1.3.0.4* Сәламәтлек саклау системасын модернизацияләргә, бу аның нәтиҗәлелеген арттырачак.

*З-1.3.0.5* Эш бирүчеләрнең үз хезмәткәрләренең сәламәтлеген саклауга, һөнәри һәм һөнәргә бәйле авыруларның барлыкка килүен кисәтүгә юнәлдерелгән хезмәт шартларын тудыруга мотивациясен арттырырга.

*З-1.3.0.6* Сәламәтлек саклау өлкәсенең ресурс базасын киңәйтергә, медицинада икътисадның үсеш ноктачисленрын булдырырга.

*З-1.3.0.7* Татарстан сәламәтлек саклау системасының җитди конкурентлык сәләтен арттырырга, республика

халкының һәм башка регионнарда яшәүчеләрнең инновацион технологияләрдән файдалана алуын тәэмин итәргә, тармакның кадрлар потенциалын саклап калырга һәм арттырырга, Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итәргә.

*З-1.3.0.8* Ярдәм күрсәтүнең перспектив һәм заманча модельләрен кертү һәм, дәүләт заказын саклап калган килеш, медицина персоналын эзлекле рәвештә хосусый практикага күчерү исәбенә гамәлдәге сәламәтлек саклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрергә.

*З-1.3.0.9* Медицина иминияте һәм социаль иминият системаларын бүлү, иминләштерелгән затларның үз сәламәтлекләрен саклау буенча шәхси җаваплылыгын арттыру шартларында бәла-каза хәвефләреннән озак сроклы тупланма иминиятне кертү исәбенә халыкның медицина ярдәменә дифференциацияләнгән ихтыяҗларын канәгатьләндерергә.

**Ц-1.4 Мәдәни тормышның сыйфаты һәм төрлелеге кеше капиталын җәлеп итүнең һәм туплауның реаль факторлары.**

*З-1.4.0.1* Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә Татарстан Республикасының югары казанышларына булышырга.

*З-1.4.0.2* Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирү системасын яхшырту, гомуми һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары һәм мәдәният учреждениеләре кооперациясе һәм интеграциясе исәбенә иҗади кадрларны арттырып әзерләүне тәэмин итәргә.

*З-1.4.0.3* Мәдәни туризм факторы буларак мәдәни мирасны сакларга һәм актуальләштерергә.

*З-1.4.0.4* Иҗади индустрияләрнең интенсив үсеше һәм экспорт өчен эчке базарны һәм мөмкинлекләрне арттыру исәбенә аларның конкурентлык сәләтен арттыру өчен шартлар тудырырга.

*З-1.4.0.5* Шәһәр агломерацияләрендә мәдәният инфраструктурасын алдан үстерүне тәэмин итәргә.

*З-1.4.0.6* Күчмә мәдәният-мәгълүмат комплексларын һәм гастроль эшчәнлеген тарату аша авылда һәм ерак территорияләрдә яшәүчеләрнең мәдәниятнең югары казанышларыннан файдалана алуын һәм мәдәният тормышында катнашуын тәэмин итәргә.

*З-1.4.0.7* Аралашуның һәм үз-үзеңне тотуның гомуми культурасын арттырырга.



**Ц-1.5 Үзгәрүчән хезмәт базары, халыкны эш белән тәэмин итүгә булышу һәм социаль яклау системасы эш белән тәэмин итүнең нәтиҗәле булуын һәм кеше капиталын үстерүдән кокурент керемнәр алуны тәэмин итә.**

*З-1.5.0.1* Инновацион икътисад өчен Татарстан Республикасына кадрлар җәлеп итәргә һәм аларны саклап калырга.

*З-1.5.0.2* Үзгәрүчәнлекне, яклангалыкны һәм идарә ителүчәнлекне тәэмин итә торган хезмәт базары моделен кертергә.

*З-1.5.0.3* Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышуның актив чаралары өчен төгәл максатлар билгеләп, эш белән тәэмин итү хезмәтләренең эффективлыгын һәм нәтиҗәлелеген күтәрергә.

*З-1.5.0.4* Эшче көчләрне нәтиҗәлерәк файдалану өчен республика чикләрендә халыкның территориаль мобильлеген һәм хезмәт миграциясен җиңеләйтергә.

*З-1.5.0.5* Хезмәт базарына республиканың икътисадый актив булмаган халкын, аеруча балалы хатын-кызларны, башка регионнардан хезмәт мигрантларын җәлеп итәргә, пенсия яшендәге халыкның хезмәт активлыгын саклауны стимуллаштырырга.

*З-1.5.0.6* Мохтаҗлыкны бәяләү һәм социаль килешү принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла торган программалар ярдәмендә балалары булган ярлы гаиләләрнең социаль яклангалык дәрәҗәсен арттырырга.

*З-1.5.0.7* Озак яшәүгә ярдәм итү максатыннан өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшыртырга һәм алардан һәркемнең файдалана алуын арттырырга.

**Пространство, реаль капитал**

**<u>СЦ-2</u> Нисбәтле территориаль-пространство үсеше мохитнең югары конкурентлык сәләтен тәэмин итә; инфраструктура җитди конкурентлыкка сәләтле була. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла.**

**Ц-2.1 Пространство кеше ресурсларын саклап калу һәм җәлеп итү өчен, гомернең төрле этапларында һәм төрле тормыш рәвешләре контекстында шәхеснең тулы кыйммәтле үсеше өчен шартлар тудыра.**

**Ц-2.2 Пространство үсеше Татарстан Республикасының социаль-икътисадый факторларына һәм география хәленә – Евразия үзәгендә урнашуга нигезләнеп бара.**

**Ц-2.3** **Пространство хәл итүләре дөньяви җәмгыятьтә Татарстан Республикасы статусын күтәрүгә, хезмәт һәм технологияләр бүленешенең дөньякүләм системасында уникаль урынын табуга булыша.**

**Ц-2.4** **Пространство алдынгы стандартларга туры килә һәм яңа технологик торышларны танытуга булыша** (3.7 нче рәсем).

**Ц-2.5** **Республика территориясендә бердәм социомәдәни пространство саклана.**

**Ц-2.6** **Интеллектуаль һәм экологик чиста технологияләр һәм хәл итүләр нигезендә үсә торган өч агломерацияне: (Казан, Кама һәм Әлмәт агломерацияләрен) берләштерә торган челтәр тибындагы өчтөшле Идел-Кама метрополисы формалашты.**

**Ц-2.7** **Пассажирлар хәрәкәте өчен таләп ителә торган мөмкинлекләрне тәэмин итүче транспорт-коммуникация системасы сыйфатының югары күрсәткечләренә ирешелде.**

**Ц-2.8** **Татарстан Республикасында барлык эчке, агломерацияләр арасындагы, регионнар арасындагы транспорт юнәлешләренең, шулай ук халыкара транспорт коридорларының югары синергиясе: «Идел-Кама» үсеше полюсының тотрыклы тиз йөрешле транспорт каркасы формалашты.**

*З-2.0.0.1* Фаразлана торган саны 4 182 мең кеше[1] булачак (2013 ел белән чагыштырганда 350 мең кешегә артык) республика халкының тормыш эшчәнлегенең сыйфатлы пространство белән, дүртенче технологик торышның булган ресурсларыннан файдаланып һәм, 2030 елга кадәр алтынчы торышка күчү перспективасы белән, 2020 елга бишенче торышта эшчәнлеккә актив күчүгә бәйле эшчәнлек өлкәләрендә эш белән тәэмин итәргә.

*З-2.0.0.2* Транспорт-коммуникация системасының сыйфатын арттырырга. Транспорт-коммуникация системасы пассажирларның күчеп йөри алуын тәэмин итәргә тиеш: торак һәм эшлекле районнар эчендә — 30 минут эчендә; агломерацияләрнең үзәк эшлекле районнарында (үзәкләрендә) — 0,5 — 1 сәгать эчендә; агломерациянең үзәк эшлекле районнары (үзәкләре) арасында — 1,5 — 2 сәгать эчендә; күрше регионнарның агломерацияләре үзәкләре белән — 3 — 4 сәгать эчендә; транспортның төрле төрләрендә

1 Стратегиянең база (максатчан) сценарие буенча



Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре белән — 4 — 8 сәгать эчендә.

*З-2.0.0.3* Пространство белән идарә итүнең, перспектив мәгълүмат технологияләрен кулланып, яңа дәрәҗәсенә күчәргә. Идарәнең яңа системасында пространствоның барлык структур элементлары һәм барлык кызыксынучы затлар күрсәтелергә, коллектив идарә итү методлары кертелергә тиеш.

Базарлар

<u>СЦ-3</u> **Татарстан Республикасының махсуслашу тармаклары регионара һәм глобаль базарларда конкурентлык сәләте.**

**Ц-3.1** **Татарстан Республикасында глобаль конкурентлыкка сәләтле вертикаль үтеп кергән нефть-газ химиясе кластеры һәм аңа бәйле булган, әмма чагыштырмача аерымланган, «Акыллы» материаллар» (яңа пластиклар һәм композитлар) һәм «Биосистемалар» инновация кластерлары нәтиҗәле эшли, алар өстәлгән бәянең зур өлешен бирәләр.**

**Ц-3.2** **Татарстан Республикасында энергетика кластеры һәм аның белән бәйләнешле «Тотрыклы энергетика» инновацион кластеры актив эшли.**

**Ц-3.3** **Татарстан Республикасында өстәлгән бәянең зур өлешен бирә торган вертикаль үтеп кергән субкластерлардан — «Автомобиль төзелеше», «Авиатөзелеш», «Судно төзелеше» («Акыллы» машиналар» конвергент инновацион кластерын төзеп) — гыйбарәт глобаль конкурентлыкка сәләтле машина төзелеше кластеры нәтиҗәле эшләп килә. «Акыллы» җиһаз» инновацион кластеры төзелде һәм нәтиҗәле эшли. Металлургиядә, җиңел, агач эшкәртү һәм йорт җиһазы сәнәгатендә кластерлы үсеш бара.**

**Ц-3.4** **Татарстан Республикасында югары сыйфатлы продукция чыгаруга һәм өстәлгән бәя булдыруга йөз тоткан конкурентлыкка сәләтле вертикаль үтеп кергән АПК кластеры нәтиҗәле эшли. Аның кысаларында төп субкластерлар: «Ашлык», «Шикәр», «Май», «Яшелчә», «Бәрәңге», «Җиләк-җимеш», «Ит», «Сөт», «Аквакультура», шулай ук аерым «Экотуклану» инновацион кластеры эшли.**

**Ц-3.5** **Татарстан Республикасында инфраструктура глобаль конкурентлык сәләтенә ирешә: «Евразийский хаб» транспорт-логистика кластеры, «Төзелеш һәм яңа**

төзелеш материаллары» кластеры нәтиҗәле эшли, торак-коммуналь хуҗалык һәм телекоммуникацияләр, шулай ук «Акыллы» инфраструктура» инновацион кластеры үсә.

Ц-3.6 Татарстан Республикасында «Сәүдә һәм куллану сервислары» конкурентлыкка сәләтле кластеры нәтиҗәле эшли: халыкның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен глобаль конкурентлык базарын үстерү исәбенә тотрыклы үсеш ала (максималь сыйфатлы товарның минималь бәясе, инфраструктурадан файдалану мөмкинлеге һәм комфорт, югары сервис дәрәҗәсе). «24/7» Татарстан – сәүдә һәм хезмәт күрсәтүләр территориясе Евразия масштабындагы заманча коммерция үзәге. Сәүдә һәм куллану сервисларының классик төрләрен үстерү, заманча формаларга юнәлешне үзгәртү, шулай ук юкка чыгарылган һәм электрон коммерция формаларын киң тарату.

Ц-3.7 Татарстан Республикасында түбәндәге конкурентлыкка сәләтле кластерлар эшли: «Финанс һәм һөнәри хезмәт күрсәтүләр», «Цивилизацияләрнең кушылуы» (мәдәният, туризм һәм рекреация), шулай ук «Акыллы» мәгълүмати технологияләр» инновацион кластеры

Ц-3.8 Татарстан Республикасында конкурентлыкка сәләтле түбәндәге социаль-инновацион кластерлар эшли: «Фән һәм мәгариф» («Smart-мәгариф» инновацион кластерын төзеп, 14 фәнни-белем бирү субкластерын берләштерә), «Сәламәтлек саклау» («Сәламәт яшәү рәвеше» инновацион кластерын төзеп, өч территориаль субкластерны берләштерә).

Институтлар

<u>СЦ-4</u> Дәүләт, хосусый һәм дәүләти-хосусый институтларның тигез нисбәтле системасы конкурентлыкка сәләтле кластерларның, эшкуарлыкның (кече һәм урта бизнес) тотрыклы үсешен, эчке территориаль үсешне һәм тышкы кушылуны тәэмин итә.

Ц-4.1 Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы үсешенә стратегик идарә итү системасы (ТР ССУР) – киләчәк белән идарә итүнең «тере» системасы төзелгән һәм нәтиҗәле эшли – тотрыклы үсешкә, икътисадның һәм яшәеш сыйфатының конкурентлылык сәләтен арттыру шартларын булдыруга юнәлдерелгән, даими гамәлдәге проект мәйданнары



һәм тышкы һәм эчке мохитне диагностикалый торган тәңгәлләштерелгән стратегик кораллар җыелмасын эшләүче, актуальләштерүче һәм контрольдә тотучы эшче төркемнәр кысаларында хакимиятнең, бизнесның һәм җәмгыятьнең үзара сыгылмалы эшчәнлек механизмыннан файдаланып, конкурентлык мохитендә үзгәрешләргә оператив йогынты ясарга сәләтле система.

*З-4.1.0.1* Татарстан Республикасы үсешенең стратегик өстенлекләре мониторингын билгеләргә һәм тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.2* Проект мәйданчыклары кысаларында республика үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә хакимиятне, бизнесны һәм җәмгыятьне җәлеп итүне тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.3* Кластер активациясен тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.4* Тармак һәм территориаль планлаштыру механизмнарын, стратегик программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлекле оештырылган структуралар, институтлар һәм үсеш агентлыклары төзеп, синхронлаштыруны тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.5* Механизмнарны үстерү идарәсенә дәүләти-хосусый партнерлыгын кертүне һәм дәүләт идарәсенә региональ бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итәргә.

*З-4.1.0.6* Стратегиянең мониторингын һәм актуальләштерелүен тәэмин итәргә.

**Ц-4.2 Татарстан Республикасында заманча икътисадның һәм «акыллы» икътисадның конкурентлыкка сәләтле кластерлар портфеле булдырылды.**

Төп кластерлар түбәндәгеләр: нефть-газ химиясе һәм энергетика комплекслары кластерлары, машина төзелеше кластеры, «Фән һәм мәгариф» кластеры һәм 10 инновацион кластер («Татарстанның технологик инициативасы» флагман проекты кысаларында), алар Татарстан Республикасының уңышлы үсешенә һәм аның глобаль конкурентлыкка сәләтле булуына ирешүенә көчле йогынты ясау сәбәпле иң югары өстенлеккә ия.

*Арадаш максатлар:*

2016 ел – зоналар буенча кластерлы активлашу. **Татарстан Республикасында Кама кластеры актив үсә һәм өч икътисадый зона дәрәҗәсендә кластерга кагылышлы инициативаларны ачыклау һәм гамәлгә ашыру башкарыла. Югары потенциалга ия региональ кластерлар ачыкланды, алар регионара һәм/яисә глобаль дәрәҗәдә конкурентлыкка сәләтле була алалар.**

2017 – 2021 еллар – кластерлы системаны бер тәртипкә китерү. **Татарстан Республикасында заманча икътисадның база кластерларын, шулай ук аларга бәйле рәвештә үзгәрешләрнең катализаторлары, ә киләчәктә – тулысынча үсеш лидерлары була алган «акыллы» икътисад инновацион кластерларын булдыру гамәлгә ашырыла.**

*З-4.2.0.1* Кластерларны кадрлар ресурслары белән тәэмин итәргә (кластерларның лидерларын һәм төп белгечләрен эзләү, җәлеп итү, камилләштерү һәм җибәрмәү).

*З-4.2.0.2* Инфраструктурага кагылышлы чикләүләрне бетерүне тәэмин итәргә; югары сыйфатлы инфраструктура һәм төп фондлар булдыруны стимуллаштырырга.

*З-4.2.0.3* Клиентларны күз алдында тоткан конкурентлыкка сәләтле тармакларны һәм һәр кластерның нигезендә ятучы продуктларны ачыкларга һәм аларның үсешен тәэмин итәргә.

*З-4.2.0.4* Кластерларның институтларга бүленеп үсүен стимуллаштырырга; административ каршылыкларның кимүен тәэмин итәргә; төп уенчыларны билгеләргә һәм кластерларны үстерү институтларын төзергә.

*З-4.2.0.5* Инновацияләрдә лидерлыкны стимуллаштырырга.

*З-4.2.0.6* Табигать ресурсларыннан нәтиҗәле һәм тотрыклы файдалануны тәэмин итәргә.

*З-4.2.0.7* Кластерлар предприятиеләре өчен финанс ресурсларының һәркем файдалана алырлык булуын арттырырга, кластерларга ярдәм итүнең финанс механизмнарын камилләштерергә.

**Ц-4.3** **Татарстан – КУЭ өлеше югары булган бизнес алып бару өчен уңайлы регион.**

*З-4.3.0.1* Татарстан Республикасында эшкуарлыкның кадрлар потенциалын үстерүне, эшкуарлык инициативасының үсешен һәм эшкуарларның кеше капиталында катнаша алуын киңәйтүне стимуллаштырырга.

*З-4.3.0.2* Эшкуарлар (КУЭ субъектларын да кертеп) өчен инфраструктураның һәм фондларның сыйфатын һәм ачык булуын тәэмин итәргә.

*З-4.3.0.3* Эшкуарлык субъектларын бизнесның базардагы өлешен киңәйтүгә һәм нәтиҗәлелеген арттыруга стимуллаштырырга.

*З-4.3.0.4* Административ каршылыкларны киметергә һәм бизнес алып бару өчен максималь уңай шартлар тудырырга; бизнеска һәм эшкуарлыкка ярдәм өлкәсендә



хезмәттәшлекне һәм координацияне ныгытырга.

*З-4.3.0.5* Инновацияләрнең бербөтен уңай экосистемасын төзергә, инновацион эшкуарлыкның өлешен арттырырга.

*З-4.3.0.6* Эшкуарларның (КУЭ субъектларын да кертеп) табигать ресурсларыннан тигез файдалана алуын тәэмин итәргә.

*З-4.3.0.7* Финанс ресурсларыннан һәркем файдалана алуны арттырырга, эшкуарлыкка ярдәмнең финанс механизмнарын камилләштерергә; инвестиция-финанс өлкәсендә эшкуарлык үсешен стимуллаштырырга (КУЭ субъектларын да кертеп).

**Инновацияләр һәм мәгълүмат**

**СЦ-5** **Татарстан Республикасында инновацияләрнең тулы экосистемасы булдырылды, ул «акыллы» икътисад үсешендә, яңа материаллар, продуктлар һәм технологияләр булдыруда һәм коммерцияләштерүдә, республиканың глобаль конкурентлыкка сәләтендә Татарстан Республикасының лидер булуына мөмкинлекләр ача.**

**Ц-5.1** **Икътисадның һәм социаль өлкәнең инновациялек дәрәҗәсе югары.**

**Ц-5.2** **Технологияләрнең үсеше һәм һәркем файдалана алырлык булу дәрәҗәсе югары.**

**Ц-5.3** **Мәгълүмат-коммуникация системасының сыйфаты югары.**

*З-5.0.0.1* Инновация системасы өчен кадрлар ресурсларын җәлеп итүне, әзерләүне, камилләштерүне һәм җибәрмәүне тәэмин итәргә.

*З-5.0.0.2* Инновация-инвестиция инфраструктурасын үстерүне тәэмин итәргә.

*З-5.0.0.3* Инновация экосистемасының ачыклыгы аркылы инновацияләргә ихтыяҗ булуны стимуллаштырырга.

*З-5.0.0.4* Рәсми һәм рәсми булмаган эчке институтларны үстерүне стимуллаштыру һәм Татарстан Республикасы Инновацион үсеш институтын төзү аркылы өзлексез җайга сала торган һәм үзеннән-үзе үсә торган инновация системасын үстерергә.

*З-5.0.0.5* Инновацияләрне финанслау системасын стимуллаштырырга. Венчурлы инвестицияләр базарын үстерергә.

**Табигать ресурслары**

**<u>СЦ-6</u>** **Тотрыклы үсеш принциплары базасында табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану.**

**Ц-6.1** **Табигать ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеге.**

**Ц-6.2** **Үсешнең югары тотрыклылыгы (киләчәк буыннарның объектив ихтыяҗларыннан һәм гомумән табигатьтән чыгып, табигать ресурсларыннан нисбәтле файдалануны саклап калу).**

**Ц-6.3** **Җир ресурсларыннан файдалануның югары нәтиҗәлелеге.**

*З-6.0.0.1* Татарстан Республикасында табигать ресурсларыннан системалы һәм рациональ файдалануны тәэмин итәргә: булган табигать ресурслары җыелмасын ачыкларга һәм реестрны актуальләштерергә; предприятиеләрнең һәм проектларның ресурсларга ихтыяҗын ачыкларга; проектларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурсларның фаразлана торган балансын булдырырга; квартал саен ресурс базасыннан рациональ файдалану мониторингын үткәрергә.

*З-6.0.0.2* Тотрыклы үсеш системасын булдыруны һәм аның үсешен тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.3* Әйләнә-тирә мохиткә экологик йөкләнешне киметергә: табигать ресурслары белән эш итү өлкәсендә контрольлек системасын камилләштерергә; җитештерү технологияләренә экологик таләпләрнең нәтиҗәлелеген һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны арттырырга; экологик юнәлешле проектларга дәүләт ярдәмен гамәлгә ашырырга.

*З-6.0.0.4* Җирләрдән файдалануның югары нәтиҗәлелегенә ирешүне тәэмин итәргә.

*З-6.0.0.5* Калдыклар белән эш итүнең комплекслы программасын эшләргә һәм аны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә (калдыкларны максималь дәрәҗәдә җыюны һәм тулысынча эшкәртүне оештырырга).

**Финанс капиталы**

**<u>СЦ-7</u>** **Татарстан Республикасы дөньякүләм дәрәҗәдә инвестиция ягыннан кызыклы. Финанс системасы югары нәтиҗәле.**

**Ц-7.1** **Финанс ресурсларының югары дәрәҗәдә һәркем файдалана алырлык булуы (инвестицияләр өчен бик кызыклы булу һәм инвестицияләр нәтиҗәлелеге).**

**Ц-7.2** **Финанс системасының югары нәтиҗәлелеге.**



*З-7.0.0.1* Финанс системасы өчен иң яхшы кадрларны җәлеп итүне тәэмин итәргә; бизнес вәкилләренең һәм гомумән халыкның финанс ягыннан грамоталылыгын арттырырга.

*З-7.0.0.2* Инвестиция инфраструктурасының һәм фондларның сыйфатын һәм һәркем өчен ачыклыгын күтәрергә.

*З-7.0.0.3* Инвестиция базарын үстерүне һәм инвестиция ресурсларының һәркем файдалана алырлык булуын арттыруны стимуллаштырырга.

*З-7.0.0.4* Дәүләт һәм хакимият органнарының инвестиция үсешенә сыйфатлы катнашуын тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.5* Инновацион алымнар һәм инвестицион үсеш коралларын куллануда алдынгылыкны тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.6* Өстенлекле инвестицион проектларны гамәлгә ашыру кысаларында табигать ресурсларыннан һәркемнең бертигез файдалана алуын тәэмин итәргә.

*З-7.0.0.7* Инвестиция системасының финанс механизмнарын камилләштерергә; инвестиция процессында өстенлекле инвестицион проектларны гамәлгә ашыра торган катнашучыларны стимуллаштыруны тәэмин итәргә; дәүләт ярдәме кораллары исемлеген киңәйтергә.

2030 елга кадәр
Татарстан Республикасының
социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә
3 нче кушымта

**2030 елга кадәр**
**Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясендә кулланыла торган кайбер терминнарга һәм атамаларга аңлатмалар**

*Әлеге Стратегия максатларында түбәндәге төшенчәләр һәм терминнар кулланыла:*

**«Кеше капиталы» юнәлеше буенча терминнар**

**Гипертекстлы дәреслекләр** — иерархия буенча оештырылган текстлы һәм график мәгълүматның зур күләмен карауны, шулай ук аны тиз эзләп табуны тәэмин итә торган электрон дәреслекләр.

**Балалар сервислары** — балалар мәнфәгатьләрендә социаль, мәдәни, медицина һәм белем бирү буенча хезмәт күрсәтүләр.

**Директорлар корпусы** — үзләрендә белем бирә торган оешмалар буларак мәктәпләрнең үсеш стратегияләрен гамәлгә ашыручы директорлар-лидерлар корпусы.

**Дифференциацияләнгән медицина иминияте —** ике ярдәмче системадан тора торган медицина ярдәме күрсәтү системасы: социаль иминият (мәҗбүри медицина иминияте махсус моделе кысаларында медицина ярдәме өчен түләүдә гражданнарның шәхсән катнашуы) һәм социаль тәэминат (иҗтимагый чыганаклар исәбеннән халыкның социаль киеренке катламы мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашыру).

**Дуаль укыту** — дәресләрнең практик өлеше эш урынында үткәрелә торган укыту системасы. Татарстанда ул югары технологияле предприятиеләр базасында гамәлгә ашырылачак.

**«Инфраструктур» югары уку йортлары** — икътисадның «йомшак» (мәгариф, сәламәтлек саклау, ваклап сату) һәм «каты» (ТКХ, транспорт) инфраструктурасы өчен региональ хезмәт базарының кадрларга ихтыяҗларын тәэмин итүче югары уку йортлары. Региональ кабул итүгә йөз тоталар, масштаблы фәнни-тикшеренү эшчәнлеген алып бармыйлар.

**Глобаль уку йортлары консорциумы —** федераль һәм глобаль дәрәҗәләрдә белем бирү һәм тикшеренүләр үткәрү өлкәсендә үзара файдалы хезмәттәшлек максатында Татарстанның югары белем бирү буенча кайбер мәгариф оешмалары кооперациясенең челтәр моделе.



**Креатив индустрия** - башлангычы иҗади компонент булган социаль-мәдәни практикалар төре, еш кына экспериментларга, новаторлыкка якын һәм шуңа күрә һәрвакытта да коммерция максатларына хезмәт итми.

**Югары белем һәм тормыш шартлары өчен уртача премия чагыштырмасының институциональ тозагы —** Татарстан Республикасы, бер яктан, югары белем алган, зур керемнәр алырлык белгечләре булган регионнардан, икенче яктан, алынган югары белемнән керем үсешләре аз булса да яшәү шартлары яхшырак булган регионнардан калыша торган хәзерге вакыттагы вәзгыять.

**«Белем бирү казанышлары траекториясе» проекты** — укучыларның белем алу казанышлары нәтиҗәләрен исәпкә алуның бердәй электрон персональләштерелгән системасы.

**Алдан белем бирү системасы** — «эш бирүче — һөнәри мәгариф оешмасы — хезмәткәр» катгый элемтәсенә корылган һөнәри белем бирү системасы, монда төп бәйләнеш механизмнары: эш бирүче белән бергә әзерләнә торган хезмәт ресурсларына ел саен яңартыла торган ихтыяҗларга фараз, һөнәри белем бирү программаларының һөнәри стандартлары системасы.

**Социаль контракт —** аз керемле граждан белән башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы арасында кешегә авыр тормыш хәленнән чыгарга ярдәм итү һәм гражданга социаль адаптация программалары чараларын үтәү максатында гражданга һәм аның гаиләсенә дәүләт социаль ярдәме (акчалата түләүләр, социаль хезмәт күрсәтүләр, яшәр өчен кирәкле товарлар) турында үзара йөкләмәләр хакындагы шартнамә.

**Функциональ грамоталылык —** төрле өлкәләрдә (мәгълүмат, технология, тел, финанс, медиа һәм башкалар) стандарт тормыш бурычларын хәл итәргә мөмкинлек бирә торган гамәли юнәлешле белемнәр һәм күнекмәләр дәрәҗәсе.

**Цифрлы мәктәп** — белем бирү процессы мәгълүмат-коммуникация технологияләрен һәм белем бирү чараларын (электрон дәреслекләр һәм методик материаллар, коммуникация һәм төркемләп эшләүне оештыру чаралары, онлайн-укыту сервислары, ата-аналар белән заманча аралашу чаралары) киң куллануга корылган мәктәп.

**Кеше капиталы** — товарлар җитештерү һәм хезмәт күрсәтүләр максатларында аерым бер чор эчендә индивидларда гәүдәләнеш тапкан һәм файдаланыла торган гыйлемнәрнең туплланган дәрәҗәсе, белем дәрәҗәсе һәм эш тәҗрибәсе (күнекмәләр, квалификация, һөнәри тәҗрибә).

**Кеше потенциалы** — аерым табигый-экологик һәм социаль-икътисадый шартларда ил гражданнарының үсеш дәрәҗәсен һәм мөмкинлекләрен чагылдыра торган күпкырлы ачыктан-ачык һәм

яшерен үзенчәлекләрнең интеграль формасы. Ул кеше үсеше индексы ярдәмендә үлчәнә (ИЧР), аңа өч бертөрле компонент керә:

1) сатып алу сәләте паритеты (ППС) буенча бер кешегә исәпләнгән эчке тулаем продукт күрсәткече белән АКШ долларларында билгеләнә торган керем;

2) грамоталылык күрсәткечләре (2/3 үлчәме белән) һәм 6 яшьтән 23 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләр арасында укучылар өлеше (1/3 үлчәме белән) ярдәмендә билгеләнә торган белем;

3) уртача гомер озынлыгы (көтелгән гомер озынлыгы) аша билгеләнә торган гомер озынлыгы.

Кеше потенциалы кеше капиталын формалаштыру өчен нигез булып тора. Кешенең белем алу һәм җитештерү эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган шартлар бу трансформациягә ярдәм итәргә яисә комачауларга мөмкин.

**Мәдәниятнең экосистемасы** – социаль-мәдәни өлкә (мәдәният, белем бирү, туризм) оешмаларының һәм учреждениеләренең үзара эшчәнлегенә нигезләнгән мәдәни багланышлар системасы. Ул конкурентлыкка сәләтле иҗади кластер булдыруны, кызыклы мәдәни мохит булдыруны, мирасны һәм традицияләрне саклауны, яшәү урынына һәм керем дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә һәркем өчен мәдәни тормышта һәм иҗат белән шөгыльләнүдә катнашу мөмкинлеген тәэмин итә.

**Эксплораториум** – балалар һәм яшьләр тарафыннан фән нигезләрен һәм әйләнә-тирә мохит күренешләрен өйрәнү максатында фәнни тәҗрибәләр һәм экспериментлар үткәрү өчен интерактив фәнни музей яисә мәктәптә өстәмә белем бирү оешмасында махсус оештырылган киңлек.

**Нәтиҗәле контракт** - дәүләт (муниципаль) учреждение хезмәткәре белән анық вазыйфаи бурычлары, хезмәт өчен түләү шартлары, башкарыла торган дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләренең хезмәт һәм сыйфат нәтиҗәләреннән чыгып, кызыксындыру түләүләрен билгеләү өчен эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре һәм критерийлары, шулай ук социаль ярдәм чаралары төгәлләштерелгән хезмәт шартнамәсе (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 26 ноябрендәге 2190 номерлы күрсәтмәсе).

**«Пространство» юнәлеше буенча терминнар**

**Агломерация (шәһәр агромерациясе)** – интенсив җитештерү, транспорт һәм мәдәни элемтәләр белән берләштерелгән, урыны-урыны белән кушылып киткән торак пунктларның, башлыча, шәһәр торак пунктларының, компактлы тупланhistory. Агломерациянең *моноүзәкләштерелгән* (бер эре



үзәк-шәһәр тирәсенә тупланган) һәм *полиүзәкләштерелгән* (берничә үзәктән-шәһәрдән торган) төрләре бар. Торак пунктларның якынлыгы агломерация эффекты бирә – шәһәр агломерацияләрендә производстволарның һәм башка икътисадый объектларның пространство концентрациясеннән чыгымнарны киметү исәбенә икътисадый һәм социаль файда китерә. Татарстанда агломерацияләр (шәһәр агломерацияләре) – Казан, Кама һәм төзелеп килә торган Әлмәт агломерациясе. Һәркайсында үзәк муниципаль берәмлек, агломерация поясы һәм шәһәр агломерацияләренең барлыкка килә торган йогынты поясы билгеләнә.

**«АлаБег»** – Алабуга шәһәре ипподромы районында перспективада Кама елгасы аша күперне үз эченә ала торган Кама агломерациясенең тизйөрешле транспорт каркасының структура барлыкка китерү элементы.

**Идел-Кама метрополисы** – Татарстан халкының зур күпчелеген туплый торган, төзелеп килүче урнашу системасы атамасы, өч «акыллы» агломерация – Казан, Кама һәм Әлмәт – ешенә нигезләнә торган челтәр тибындагы өчүзәкле метрополис.

**Икътисадый үсеш коридоры** – транспорт-логистика каркасын алдан үстерү зонасында берләшә торган үсеш полюслары.

**Үсеш полюсы** – үзенең барлык йогынты зонасында алга таба икътисадый эшчәнлек үсешенә китерергә сәләтле алга киткән һәм киңәя барган тармаклар исәбенә ашыгыч темплар белән үсүче регион яисә үзара бәйләнештәге күрше регионнар төркеме. Монда бер яисә берничә регион үсеш полюсын үстерү үзәген формалаштыра.

**«Идел-Кама» үсеш полюсы** – Татарстан Республикасы бизнесының потенциал интеграция территориясе, Татарстанның лидерлык территориясе. Үсеш полюсына башлыча, Татарстаннан кала аңа чиктәш регионнар: Башкортостан Республикасы, Оренбург өлкәсе, Самара өлкәсе, Ульяновск өлкәсе, Чуваш Республикасы, Мари Эл Республикасы, Киров өлкәсе, Удмурт Республикасы керә. Алга таба интеграцион процесслар Идел буе федераль округында тулысынча һәм Идел буе федераль округының кайбер чиктәш регионнарында таралырга тиеш. Киләчәктә Татарстан өчен интеграцияне Идел бассейны кысаларында: Түбән Идел (Волгоград һәм Әстерхан өлкәләре), Урта Идел (Тверь, Мәскәү, Ярославль, Иваново һәм Кострома өлкәләре) көчәйтү максатка туры килә. Үсеш полюслары өчен көчле регионнарның үзара йогынтылы катнаш зоналарына туры килә торган катнаш берләшү үзенчәлеге хас.

**Пространство** – халыкның социаль активлыгының җәмгыятьнең ирешелгән дәрәҗәсенә бәйле төп төрләре комплек-

сы гамәлгә ашырыла торган мохит; бу — системаның объект торышы аспектларына (планлаштырыла торган структура, функциональ зоналаштыру, инфраструктура һ.б.) статик һәм үсеш динамикасында комплекслы модель тасвирларга мөмкинлек бирә торган гомуми төшенчәсе.

**Пространство үсеше** — абигать мохите үзенчәлекләрен, файдалы казылмаларның, шулай ук мәдәният һәм табигать мирасы объектларының булуын исәпкә алып, территориядә халыкның урнашуын оештыру, хуҗалык объектларын — хезмәт кую урыннарын, транспорт һәм инженерлык инфраструктурасының линияле һәм башка объектларын урнаштыру белән характерлана торган максатчан юнәлешле эшчәнлек (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше доктринасы, РААСН, 2014).

**Транспорт-коммуникация пространствосы** — кешенең яшәеш тирәлеге, аның рәвеше һәм функциясе кешеләрнең тотрыклы күченеп йөрүләре һәм үзара эшчәнлеге белән билгеләнә торган пространство.

**Тотрыклы үсеш** — кешенең тормыш шартлары яхшыра, ә әйләнә-тирә мохиткә йогынты биосфераның хуҗалык ешлыгы чикләрендә кала торган җәмгыять үсеше, димәк, кешелек яшәешенең табигый нигезе бозылмый. Тотрыклы үсеш концепциясе, регионны мохитнең котылгысыз диградациясе халәтенә күчү ихтималын кисәтә торган тышкы ярдәм кысаларында, үзоешу аша регионның үсешен күздә тота. Кешелек өчен тулаем бу концепция бай регионнардан ярлы регионнарга экологик белемнәр һәм мәгълүмат белән киң алмашуны гамәлгә ашырып, финанс ресурсларының өлешчә, максатчан юнәлешле, ярдәм итү йөзеннән күчешен күздә тота. Термин, бер яктан, даими үсеш зарурлыгын (шул исәптән матди) ассызыклый торган, икенче яктан, әлеге үсешне чикли торган каршылыкны үз эченә ала.

**Флагман проектлар** — регионның берничә максатчан юнәлеш буенча, кагыйдә буларак, алга баруын тәэмин итеп, регион үсешенә сизелерлек йогынты ясый торган перспективалы масштаблы проектлар.

**«Чиста юл»** — Татарстан Республикасында Казан шәһәрен, «Казан» халыкара аэропортын, Алексеевск штп., Чистай шәһәрен, Кама Аланы штп., Түбән Кама шәһәрен, Бигеш аэропортын, Чаллы шәһәрен, ихтимал, Менделеевск шәһәрен дә, тоташтыра торган өстәмә тизйөрешле яңа элемтә.

**«Идел-Кама агымы» эко-зонасы** — Идел, Кама, Нократ һәм Агыйдел елгалары буенда урнашкан муниципаль районнарның су пространстволары һәм яр буе ландшафтлары үсешенең комплекслы күренешен барлыкка китерә торган тармакара региональ масштаблы проект.



**Татарстан Республикасы икътисадый зонасы** — республиканың чагыштырмача башка зоналардан аерымланган, социаль-икътисадый һәм пространство үзенчәлегенә ия булган гадәти табигый һәм административ чикләрдә төзелгән территория өлеше. Зоналарның чикләре муниципаль берәмлекләр чикләренә туры килә.

### «Икътисад» юнәлеше буенча терминнар

**Аддитив технологияләр** (ингл. — Additive Manufacturing, AF) — гомуми билге белән берләштерелгән катламлы синтез технологияләре җыелмасы: аларны кулланганда объектны (модельләр, детальләр һ.б.) төзү, «артык» материалны бетерү юлы белән детальләр булдырыла торган традицион технологияләрдән аермалы буларак, материал өстәү (ингл. add — өстәү) юлы белән башкарыла.

**БАРС (Стратегияне гамәлгә ашыруны анализлау бюросы)** — Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы составында төзү планлаштырыла торган бүлекчә, аның бурычларына Стратегияне координацияләү һәм мониторинглау, яңарту, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм дәүләт программалары өчен Стратегиянең гамәлгә ашырылуын тәэмин итүче максатчан индикаторлар булдыру керәчәк. Бу структура Малайзиянең стратегик планнарын югары нәтиҗәле итеп гамәлгә ашыручы REMANDU стратегик идарә органына охшаш.

**Биотехнология** — биологик объектлар ярдәмендә кеше өчен кирәкле продуктлар һәм эффектлар табу ысуллары һәм алымнары җыелмасы. Биотехнология составына геннар, күзәнәк һәм экология инженериясе керә.

**Бизнесның глобаль конкурентлыкка сәләтлелеге** — глобаль (халыкара) дәрәҗәдә бизнесның конкурентлыкка сәләтлелеге — халыкара базарларда ихтыяҗы булган продукцияне җитештерү һәм хезмәт күрсәтүләрне башкару, кирәкле ресурсларны җәлеп итү сәләте.

**Регионның глобаль конкурентлыкка сәләтлелеге —** глобаль конкуренциядә региональ бизнесның уңышы (барыннан да элек, махсуслашу тармакларында), әлеге бизнесның халыкара хезмәт бүленешенә керүе; глобаль халыкара конкуренциядә кеше капиталын, инвестицияләрне, туристларны, халыкара вакыйгаларны, иң яхшы шартлар һәм актив маркетинг тудыру юлы белән җәлеп иткән өчен глобаль регионара конкуренциядә регионның уңыш казану сәләте.

**Киңколачлы Интернет** (Internet of Everything, IoE) — Интернет үсешенең алга таба баскычы, аның кысаларында кеше файдалана торган күпчелек физик объектлар («әйберләр») белән

үзара эшчәнлек булачак. Бу бизнес өчен зур мөмкинлекләр үсешенә китерә торган бердәй, масштаблы, идарә ителә торган инфраструктура төзергә мөмкинлек бирәчәк (бер төр җайланмалар икенчеләренең мөмкинлекләрен һәм белешмәләрен эшкә җигәргә һәм төрле өлкәләрдә новаторлык мәсьәләләре китереп чыгарырга мөмкинлек бирәчәк). 2022 елга IoE базары 14 трлн. АКШ долларыннан артачак (Cisso фаразлары буенча).

**RCI индексы** (AV Regions Competition Index, AV RCI, регионның конкуренция индексы) – регионара конкурентлыкка сәләтне анализлау өчен кулланыла торган методика. Регионның конкуренция индексы – территориянең фактта ресурслар һәм сату базарлары өчен конкуренциягә сәләтен тасвирлый торган, конкуренция факторларын фактта гамәлгә ашыруда чагыла торган комплекслы бәя (регионара конкуренция нәтиҗәләрен чагылдыра торган индикаторлары бәяли). Регионнарның конкуренциясен системалы бәяләү конкуренциянең төп җиде юнәлеше буенча башкарыла:

- продукт (сату базарлары);
- институтлар;
- кеше капиталы;
- мәгълүмат һәм технологияләр;
- табигать ресурслары;
- финанс капиталы;
- реаль капитал.

Конкуренция индексын исәпләү өчен чыганак буларак регионнарның статистика күрсәткечләреннән һәм гавами тикшеренүләр нәтиҗәләреннән файдаланыла.

**Инновацион экосистема (инновацияләр экосистемасы)** – дәүләтнең һәм җәмгыятьнең инновацияләрне булдыру һәм алардан файдалану барышының нәтиҗәлелеген билгеләүче инновацияләргә хирыслыгын тасвирлаучы инновацион эшчәнлек өлкәсендәге барлык элементларның үзара мөнәсәбәтләре җыелмасы («2020 елга кадәр чорга БДБ катнашучы дәүләтләре инновацион хезмәттәшлегенең дәүләтара программасы турында» БДБ хөкүмәтләре башлыклары Советы карары).

**Заманча икътисадның индустриаль кластеры (индустриаль кластер)** – заманча инфраструктура сыйфатына төп ихтыяҗны чагылдыручы төп җитештерү фондларының бинәнеше һәм йөкләнешенең югары дәрәҗәсен тәэмин итүче агымдагы өстәмә бәя булдыруда сизелерлек роль уйный торган гамәлдәге технологик торыш казанышларын һәм дүртенче, бишенче технологик торышларны инновацион модернизацияләү мөмкинлекләрен берләштерә торган заманча икътисадның (башлыча) гамәлдәге индустрия кластеры.



**«Акыллы» икътисадның инновацион кластеры (инновацион кластер)** – эре индустриаль бизнес, тармак фәне һәм хакимият арасында тыгыз хезмәттәшлектә (бәя булдыру чылбырының регион эчендә дә, регионара һәм халыкара челтәрләренә тоташу ярдәме белән) бишенче һәм алтынчы (җиденче) технологик торыш казанышларын үз эченә алган инновацион «акыллы» икътисад нигезендә яңа материаллар, продукция һәм технологияләр эшләү, гамәлгә кертү, җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче яңа инновацион компанияләр ачу һәм гамәлдәгеләрен үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән югары технологик кластер. Бу кластерлар инновацион эшкуарлыкның һәм инвестицияләрнең төп объектлары буларак кеше капиталына, институтларга, инновацион экосистемага, табигатьтән файдалануның тотрыклылыгына, инфраструктураның яңа сыйфатына булачак ихтыяҗны формалаштыралар.

**Инновацион территориаль кластер** – чикләнгән территориядә урнашкан предприятиеләр һәм оешмалар җыелмасы (кластерда катнашучылар), ул түбәндәгеләрнең булуы белән тасвирлана: бер яисә берничә тармакта (икътисадый эшчәнлекнең төп төрләрендә) фәнни җитештерү чылбырының кластерда катнашучыларын берләштерү; кластерда катнашучыларның эшчәнлеген координацияләү һәм кооперация механизмы; һәр предприятие, оешма эшчәнлегенең икътисадый файдасын һәм нәтиҗәлелеген аларның концентрациясе һәм кооперациясенең югары дәрәҗәсе исәбенә арттыруда чагыла торган синергетик эффект (Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы билгеләмәсе).

**Интернет** (Internet of Things, IoT) – үзара аралашу яисә кеше катнашыннан башка тышкы мохит белән аралашу өчен корылган технологияләр белән тәэмин ителгән физик объектларның («әйберләрнең») челтәрле үзара эшчәнлек системасы.

**Кластерлы активация** – кооперация механизмнары, дәүләтихосусый партнерлык һәм индустриаль эволюция нигезендә кластерлы процессларга, заманча икътисадны модернизацияләүгә ярдәм итү һәм «акыллы» икътисад булдыру ярдәмендә регионда конкурентлыкка сәләтне һәм икътисадый үсешне арттыруга юнәлдерелгән дәүләт икътисадый сәясәте.

**Кластерлы үсеш** – кагыйдә буларак, дәүләт сәясәте чаралары белән хупланган кластерларны формалаштыру һәм ныгыту процесслары.

**Когнитив технологияләр** – кешенең интеллектуаль сәләтләрен үстерүгә махсус юнәлдерелгән мәгълүмати технологияләр.

**«Татарстан: 7+5+3» моделе** – Татарстанның үсешен анализлауга, тасвирлауга һәм планлаштыруга регионның һәм аның

махсус тармакларының конкурентлыкка сәләтен синхрон арттыру әһәмиятенә басым ясый торган интеграль методик алым. Модель регионны карауның ике дәрәҗәсен берләштерә: тышкы — регионара конкуренциянең **җиде** юнәлеше буенча башка регионнарга карата Татарстанның конкурентлык позициясен чагылдыра һәм эчке — **өч** икътисадый зона буенча **алты** төп икътисадый комплекс структурасын (һәр кластерда һәм үсеш проектында күрсәтеп) тасвирлый. Конкуренциянең җиде юнәлеше (базарлар; институтлар; кеше капиталы; инновацияләр, мәгълүмат һәм технология; табигать ресурслары; реаль капитал; финанс капиталы) интерпретацияләнгән булырга һәм бизнеска карата (предприятиеләргә, хуҗалык комплексларына), регионга карата кулланылырга мөмкин, ул модельне регионара һәм бизнес-конкуренциянең үзара бәйле процессларын өйрәнү һәм тасвирлауның уңайлы универсаль инструменты итәргә мөмкинлек бирә.

«Татарстан: 7+5+3» моделеннән файдаланып, мәгълүмат туплау, эшкәртү һәм анализлау, шулай ук Стратегияне гамәлгә ашыруны формалаштыру һәм мониторинглау (максатлар, индикаторлар, чаралар һәм проектлар буенча) билгеләнә.

**Нанотехнология** — теоретик нигезләү, тикшеренүләрнең практик ысуллары, анализ һәм синтез, шулай ук аерым атомнар һәм молекулалар белән тикшереп торылучы манипуляция юлы белән бирелгән атомар структура ярдәмендә продуктларны җитештерү һәм куллану методлары җыелмасы белән эш итүче фундаменталь һәм гамәли фән һәм техника дисциплинаара өлкәсе.

**«Кызгылт сары сызык»** — заманча икътисад кысаларында үсеш чикләре турында күзаллауны чагылдыра торган заманча икътисад белән «акыллы» икътисад арасындагы шартлы чик. Бу чик икътисадның ахыр кулланучыга аз юнәлдерелгән эре тонналы (эре серияле) җитештерүгә бәйлелегенең югары булуы белән аңлатыла. Заманча икътисадның үсеш чиге бар: стратегик перспективада анын өстәлгән бәягә уртача еллык үсеше бер елга 1,5 — 2 процент коридор белән чикләнәчәк.

**Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш өстенлекләре** — Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең аеруча әһәмиятле максатлары һәм бурычлары.

**Үсешкә стратегик идарә итү системасы (киләчәк белән идарә итү системасы)** — синхронлаштырылган стратегик инструментлар җыелмасын эшләүче, актуальләштерүче һәм тикшереп торучы, эчке һәм тышкы мохитне диагностикалаучы даими гамәлдәге проект мәйданчыклары һәм эшче төркемнәр кысаларында, хакимиятнең, бизнесның һәм җәмгыятьнең үзара



эшчәнлегендә сыгылмалы механизмнан файдаланып, конкурент мохиттә үзгәрешләргә ашыгыч йогынты ясарга сәләтле, икътисадның тотрыклы үсешенә, конкурентлыкка сәләтен арттыру һәм тормыш сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән комплекслы камил идарә системасы.

**Заманча икътисад** — кулланудан чыга торган технологик торышлар икътисады, эш белән тәэмин ителеш югары булганда регионның база инфраструктурасы йөкләнешен һәм техник ярдәмен тәэмин итә.

**Социогуманитар технологияләр** — идарә эшчәнлеге структураларының һәм модельләренең асылы буенча синтетик һәм эчтәлеге буенча социомәдәни үзгәрешләрне формалаштыру технологияләре. Идарә итүнең социогуманитар технологияләре оештыру үзгәрешләренең барлык социомәдәни контекстын: илнең яисә регионның тарихи тәҗрибәсен, җәмгыятьнең һәм оешманың иң яхшы мәдәни традицияләрен, оештыру культурасы үзенчәлекләрен һәм башкаларны, шулай ук идарә субъектларының күзаллауларын исәпкә алып, идарә системаларын төзүгә һәм үзгәртеп коруга өр яңа алымны чагылдыралар.

**«Татарстанның технологик инициативасы»** — Татарстан Республикасы «акыллы» икътисадының инновацион кластерлар портфелен булдыруның һәм үстерүнең комплекслы проекты. «Милли технологик инициатива» кысаларында пилот проекты булырга мөмкин (Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы, 2014 елның 4 декабре). Стратегиянең комплекслы флагман проекты.

**Технологик торыш** — бердәм техник дәрәҗәдәге һәм икътисадый системаның бер структур ярдәмче системасы буларак карала торган — тармаклар кебек ярдәмче системага карата альтернатив үзара бәйле производстволар (үзара бәйле технологик чылбырлар) җыелмасы. Бер технологик торышка керүче производстволар, тыгыз бәйләнештә булганга күрә тәңгәл үсәләр: технологик торышның бер өлешендәге үзгәреш калганнарын да үзгәртүгә китерә. Икътисадта әйдәүче технологик торышларның алмашынуы фәнни-техник алгарышның тигез барышын билгеләми.

**Традицион икътисад** — XX гасыр уртасында технологик торышларның лидерлыгын югалткан, төп шөгыльләнү чыганагы башлыча аграр өлкә булган икътисад.

**«Өчле спираль»** — милли һәм региональ дәрәҗәләрдә фән, бизнес һәм дәүләт мөнәсәбәтләре динамикасы аша инновацион үсешне тасвирлый торган һәм предприятиеләр белән дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрнең лидеры буларак фәннең перспектив роленә нигезләнгән институциональ модель.

**«Акыллы» икътисад** – көч туплый торган бишенче технологик торышка һәм туып килә торган алтынчы (җиденче) технологик торышка нигезләнгән яңа инновацион киләчәк икътисады.

**Максатчан күзаллау** – системаның яисә объектның киләчәк торышын сыйфат һәм (яисә) сан ягыннан тасвирлау, ул әлеге системаның яисә объектның үсеше белән идарә итүнең максаты булып тора.

**Икътисадый комплекс** – технологик яктан бәйле тармакларның юнәлеше буенча якын эшчәнлеге җыелмасыннан гыйбарәт булган тармакара комплекс, региональ икътисадның ярдәмче системасы. Стратегияне эшләү кысаларында алты база икътисадый комплексы билгеләнә: дүрт җитештерү комплексы (нефть-газ-химия комплексы, энергетика комплексы, машина төзелеше һәм башка эшкәртү сәнәгате комплексы, агросәнәгать комплексы) һәм ике тәэмин итүче (инфраструктура комплексы һәм хезмәт күрсәтүләр комплексы), 17дән алып һәм алга таба 60 ка кадәр ваграк комплекска һәм тармакка бүленә.



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 522. 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү стратегиясен әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 17 июне
№ 41-ТРЗ

Татарстан Республикасының әлеге Законы бөтен кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

«2030 елга кадәр чорга
Татарстан Республикасының
ягулык-энергетика комплексын
үстерү стратегиясен раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү стратегиясе

### I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү стратегиясе (алга таба – Стратегия) 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын озак вакытлы үстерүнең максатларын һәм бурычларын билгели, аларны, ягулык-энергетика ресурсларын максималь нәтиҗәле кулланып, тулаем төбәк продукты үсешен һәм халыкның яхшы тормышта яшәвен тәэмин итүнең нигезләре итеп карый.

Стратегияне эшләгәндә түбәндә бәян ителгән факторлар исәпкә алынды.

Базарда сланец газы барлыкка килү һәм энергия ресурсларын импортка кертүче күп кенә эре илләрнең үз-үзләрен энергетика белән тәэмин итүгә күчүенә бәйле рәвештә дөнья базарларындагы зур үзгәрешләр, нефть чыгару коэффициентын (алга таба – НЧК) күтәрү һәм нефть эшкәртү тирәнлеген арттыру буенча Россия Федерациясендә уңай динамика булмау, Россия Федерациясендә икътисадый үсеш темплары акрынаю элегрәк Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән тармак программалары документларын актуальләштерүгә ихтыяҗ тудырды.

Аерым алганда, Россия Федерациясе Хөкүмәте 2009 елда кабул ителгән 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең Энергетика стратегиясен яңадан карый. Алга таба, 2015 елның III – IV кварталларында 2035 елга кадәр чорга Россиянең Энергетика стратегиясе кабул ителгәннән соң, ягулык-энергетика комплексы тармакларын – нефть, газ, күмер һәм электр энергетикасын үстерүнең генераль схемалары һәм программалары актуальләштереләчәк. Россия фәннәр академиясенең Энергетика тикшеренүләре институты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Аналитика үзәге экспертлары дөньякүләм энергетика үсешенең төп тенденцияләрен һәм Россиянең ягулык энергетика комплексы һәм тулаем алганда ил икътисады өчен озак вакытлы перспективада булырга мөмкин куркынычларны анализладылар.



Түбәндәге уңай күренешләр бар:

ягулыкны дөньякүләм куллану структурасын, углеводород чималының өстенлекле булуын саклап калу (2010 елда 53,6 процент һәм 2040 елга 51,4 процент);

ягулык кәрҗинендә табигый газ өлешенең, иң беренче чиратта, дөньякүләм куллану күләменең 60 процентка арту хисабына (елына 5,3 трлн. куб метрга кадәр) 2010 елдагы 21 проценттан 2040 елга 25 процентка кадәр арттыру. Сланец газы өлеше газ чыгаруның гомуми күләмендә якынча 11 процент тәшкил итәчәк. Сыекландырылган табигый газ базарының үсеш динамикасы аеруча Төньяк-Көнчыгыш Азия илләрендә югары;

торгызыла торган чыганакларга нигезләнеп җитештерелә торган энергия өлешенең югары үсеш темплары – 2010 елда 3,7 процент һәм 2040 елга 12,5 процент, атом энергетикасы өлешен 6 процент дәрәҗәсендә саклап калу, күмер өлешен 28 проценттан 25 процентка кадәр киметү;

нефть һәм газ базарларының төбәкләшү үсеше юнәлешен ныгыту, дөньякүләм энергия куллануда үсеп килүче илләрнең икътисадлары үсү һәм өлешләре арту.

Россия Федерациясе дөньядагы нефть продуктларын җитештерүче әйдәп баручы илләр исәбенә керә. 2014 елда ил территориясендә нефть һәм газ конденсатын эшкәртүне һәм товар нефть продуктларын сәнәгать җитештерүен нефть чималын беренчел эшкәртү буенча барлыгы елына 299 млн. тонна егәрлекле 68 махсуслашкан нефть эшкәртү предприятиесе гамәлгә ашырды. Әлеге күрсәткеч буенча Россия Федерациясе, «Бритиш Петролеум» әзерләгән 2014 ел дөньякүләм энергетикасына статистик күзәтүдән күренгәнчә, АКШ һәм Кытайдан кала дөньяда өченче урында тора.

Моның белән бергә Россия Федерациясенең нефть эшкәртү тармагы илдә нефть эшкәртү производстволары даими яңарып торса да, төп җитештерү фондларының шактый таушалганлыгы, шулай ук нефть эшкәртү тирәнлегенең түбән булуы (2014 ел йомгаклары буенча 72,4 процент) белән сыйфатлана. Моннан тыш, файдалы булмаган территориаль структура, гамәлдәге эшкәртү куәтләренең технологик катлаулылыгы дәрәҗәсе түбән булуы саклана. Аерым алганда, Нельсонның (NCI) катлаулылык коэффициенты буенча Россия Федерациясенең нефть эшкәртү производстволары дөньядагы әйдәп баручы нефть продуктларын җитештерүчеләрдән калышалар. NCI индексы АКШ нефть эшкәртү заводлары (алга таба – НЭЗ) өчен 9,6, Европа НЭЗ өчен – 6,5 җитә, шул ук вакытта Россия НЭЗның әлеге күрсәткече, уртача алганда, 5,1 дән артмый.

Углеводород чималын эшкәртүне тирәнәйтүгә, үз илебез сәнәгатен яңартуга юнәлдерелгән Россия Федерациясе Стратегиясе эчке базарның, нефть экспортына альтернатива буларак, югары сыйфатлы һәм югары өстәлгән бәягә ия булган нефть продуктларына ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен нефть эшкәртүчеләрдән һәм нефть химикларыннан нәтиҗәле гамәлләр таләп итә. Шуңа күрә 2011 елда илнең иң эре нефть компанияләре, Федераль монополиягә каршы хезмәт, Ростехкүзәтчелек һәм Росстандарт тарафыннан нефть эшкәртү производстволарын технологик яктан яңадан җиһазлау һәм яңарту буенча дүртьяклы килешүләр имзаланды.

Россия Федерациясенең нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрен яңарту буенча мөһим бурычларга түбәндәгеләр керә:

эшкәртелмәгән нефть сатудан нефть продуктлары һәм нефть химиясе продуктларын сатуга күчү;

гамәлдәге экологик стандартлар таләпләренә туры килә торган нефть продуктларын җитештерү;

углеводород чималын эшкәртүнең тирәнлеген һәм комплекслылыгын арттыру максатларында гамәлдәге предприятиеләрне яңарту, яңа производстволар төзү;

газ һәм нефть чималын эшкәртүнең үз илебезгә хас технологияләрен үстерү.

Әлеге Стратегия 2006 – 2020 елларга Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексын үстерү программасының төп нигезләмәләрен исәпкә ала һәм шул ук вакытта ирешелгән нәтиҗәләр һәм тармак трендлары нигезендә республиканың ягулык-энергетика комплексы тармакларын үстерүнең максатчан күрсәткечләрен актуальләштерә. Шулай, мисал өчен, Татарстан Республикасы нефть сәнәгате предприятиеләре тарафыннан нефть чыгару, шул исәптән югары үзле нефть чыгару, һәм геологик тикшерү процессларында яңа технологияләр кертү 2006 елдан алып 2013 елга кадәр чорда 259,7 млн. тонна күләмдә нефть чыгаруны һәм 304,4 млн. тонна күләмдә углеводород чималы запасларын үстерүне (планлаштырылган күләмнәре тиешенчә 246,7 млн. тонна һәм 259 млн. тонна иде) тәэмин итте.

Шулай итеп, әлеге Стратегияне эшләүне дөньяда авыр чыгарыла торган нефть запасларын һәм традицион булмаган углеводород чыганакларын табуның бик тиз үсеп китүе, Татарстан Республикасында «җиңел» нефть запасларының нык кимүе, нефть эшкәртүдә яңа технологияләр уйлап табу һәм кертеп җибәрү, Россиянең энергетика системасын үзгәртеп төзүнең дәвам итүе таләп итте.



## II. Татарстан Республикасы дәүләт энергетика сәясәтенең максатлары, бурычлары һәм механизмнары

Әлеге Стратегиянең максаты тулаем төбәк продукты үсешен һәм халыкның яшәү сыйфаты күтәрелешен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексының матди-чимал базасының тотрыклы үсешен һәм энергетика секторының ягулык-энергетика ресурсларын һәм потенциалын мөмкин кадәр нәтиҗәле кулланылышын тәэмин итү булып тора.

Күрсәтелгән максатка ирешү һәм энергия ресурсларына эчке һәм тышкы ихтыяҗны тәэмин итү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итәргә кирәк:

геологик тикшерү эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрү, җир асты байлыкларыннан тулысынча, энергияне һәм ресурсларны сак тотып углеводород чималын чыгару һәм аны комплекслы, тирәнтен эшкәртүнең инновацион технологияләрен кертүгә нигезләнеп, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалануны тәэмин итү;

җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә үз илебез компанияләре күрсәтә торган сервис һәм инжиниринг хезмәтләре базарын үстерү;

Татарстан Республикасының сәнәгать һәм социаль өлкәсендә тармак энергетика инфраструктурасының гамәлдәгесен модернизацияләү һәм яңасын төзү;

инвестиция, инновация, энергияне сак тоту һәм экология тармакларында хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеген стимуллаштыручы корал буларак тармакка караган салым законнарын камилләштерүне дәвам итү.

Моннан тыш, ягулык-энергетика ресурсларыннан һәм энергетика секторы мөмкинлекләреннән максималь нәтиҗәле файдалану өчен түбәндәгеләрне тәэмин итәргә кирәк:

җитештерү куәтенең җитәрлек резервлары булу, энергетика коммуникацияләренең үткәрү сәләте һәм ягулыкның рациональ резервларын булдыру хисабына энергетика секторының производство структурасы эшләвенең норматив ышанычлылыгын;

икътисад тармакларының структурасын камилләштерү һәм технологик яңарту хисабына тулаем төбәк продуктының энергия сарыф итү күләмен һәм электр тоту күләмен киметү.

Куелган бурычлар Татарстан Республикасы вәкаләтләре кысаларында дәүләт энергетика сәясәтенең түбәндәге чараларын һәм механизмнарын файдаланып хәл ителәчәк:

әлеге Стратегиядә билгеләнгән максат күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итү өчен ягулык-энергетика комплексы

предприятиеләренең идарә итү органнарында дәүләт вәкиллеге институтыннан файдалану;

җир асты байлыкларыннан файдалану максатлары өчен җир кишәрлекләре бирү мәсьәләсендә законнар белән җайга салу чараларын камилләштерү;

ягулык-энергетика комплексы предприятиеләре өстенлекле инвестиция һәм инновация проектларын тормышка ашырганда салым стимуллаштыруын куллану;

электр энергиясе (куәте) базарында конкуренция өчен челтәр чикләүләрен бетерү;

гамәлдәге котельнялардагы җиһазларны электр һәм җылылык энергиясен катнаш җитештерүне тәэмин итә торган газ турбиналы җайланмага күчерүгә ярдәм итү;

энергия нәтиҗәлелеге нормативларын һәм максатчан күрсәткечләрен эшләү аша энергияне сак тотуның икътисадый мотивацияләү системасын кертү;

автомобиль транспорты өчен традицион нефть ягулыгы төрләре урынына газ мотор ягулыгын куллануны автомобильгә газ тутыру компрессор станцияләренең гамәлдәге челтәрен киңәйтү аша стимуллаштыру;

ягулык-энергетика комплексы предприятиеләрен үстерүне һәм яңартуны күз алдында тоткан норматив хокукый актлар кабул итү инициативасы белән чыгу;

энергия ресурсларын табу, җитештерү, транспортлау һәм куллануның әйләнә-тирә мохиткә, климатка һәм кешеләр сәламәтлегенә тискәре йогынтысын киметү максатларында экологик стандартларны производствода куллануга стимуллаштыру;

ягулык-энергетика комплексы һәм энергетика инфраструктурасы тармакларын тирәнтен модернизацияләүне, шул исәптән дәүләти-хосусый партнерлык механизмын куллануны киңәйтү хисабына тәэмин итү;

Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексы предприятиеләренә аларны федераль максатчан һәм дәүләт программаларына кертүдә ярдәм итү.



## III. Татарстан Республикасының нефть-газ комплексын үстерү

### 3.1. Татарстан Республикасының нефть-газ комплексына гомуми характеристика

Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексы нефть чыгаруны һәм нефть эшкәртүне, энергетиканы һәм газ белән тәэмин итү системасын үз эченә ала. Республиканың ягулык-энергетика комплексы составына керүче тармаклар куллана торган чималга һәм энергия ресурсларына тыгыз бәйләнгән.

Республиканың ягулык-энергетика комплексы республика икътисадының нигезе булып тора. 2014 ел йомгаклары буенча комплекс предприятиеләре тарафыннан сәнәгать производствосының 50 процент күләме чыгарылган, төбәк кеременең 75 проценты тәэмин ителгән. Тулаем өстәмә бәясендә ягулык-энергетика комплексы өлеше 47,5 процент тәшкил иткән.

Нефть-газ комплексының нигезе нефть чыгарудан гыйбарәт. Нефть Татарстан Республикасының 22 муниципаль районы территориясендә чыгарыла. Нефть алына торган чыганаклар Көньяк-Татар гөмбәзендә, Төньяк-Татар гөмбәзенең көньяк-көнчыгыш сөзәклегендә һәм Мәләкәс иңкүлегенең көнчыгыш бортында тупланган (1 нче рәсем).



1 нче рәсем. Нефтьне геологик өйрәнү, тикшерү һәм чыгаруга лицензияләр бирелгән җирләрнең һәм Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының бүленмәгән фондының урнашу схемасы



2006 – 2014 еллар чорында Татарстан Республикасында нефть чыгаруның гомуми күләме 292,8 млн. тонна булып, сәнәгать категорияләре запаслары артымы 327,4 млн. тонна тәшкил итте.

Нефть чыганакларының җир асты байлыкларыннан һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән углеводород чималын эзләү һәм бәяләү максаты белән файдалану хокукына гамәлдәге лицензия фонды 146 лицензиядән гыйбарәт, шул исәптән 62 – «Татнефть» ААҖнә, 83 – кече нефть компанияләренә (алга таба – КНК), 1 – «Башнефть» ААҖнә карый. 2014 елның 1 октябренә углеводород чималының лицензия фонды структурасы түбәндәгечә:

114 лицензия – тикшерү һәм чыгаруга;

31 лицензия – эзләү, тикшерү һәм чыгаруга;

бер лицензия – җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә.

Татарстан Республикасында углеводород чималы ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү максатында сәнәгать җитештерүе структурасын диверсификацияләү, нефтьне комплекслы, тирәнтен эшкәртүне оештыру һәм алга таба үстерү стратегиясе тормышка ашырыла. 2005 елдан алып 2014 елга кадәр Татарстанда эре инвестиция проектларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә сәнәгать җитештерүе структурасында нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате продукциясе өлеше нефть сәнәгате кертеме 39,4 проценттан 22,4 процентка кадәр кимү җирлегендә 20,8 проценттан 37,1 процентка кадәр үсте.

Республика территориясендә ел саен 33 млн. тоннага якын нефть чыгарыла. Татарстанның нефть табу тармагын «Татнефть» ААҖ предприятиеләре, аларга чыгарыла торган нефтьнең 80 проценты туры килә, һәм 33 КНК тәшкил итә. 2014 елда еллык нефть чыгару күләме буенча «Татнефть» ААҖ Россия Федерациясендә нефть компанияләре арасында алтынчы урынны алып тора.

2014 елда Татарстан Республикасында 33,1 млн. тонна нефть һәм нефть белән бергә якынча 960 млн. куб метр газ чыгарылды, шул исәптән 26,2 млн. тонна нефть һәм нефть белән бергә чыккан 884,9 млн. куб метр газ «Татнефть» ААҖгә туры килә.

Татарстан Республикасы нефть белән бергә чыккан газны утильләштерү дәрәҗәсе буенча илнең нефть сәнәгате лидерларының берсе булып тора. Хәзерге вакытта әлеге күрсәткеч республиканың барлык нефть компанияләре буенча 95 процент тәшкил итә (1 нче таблица).

1 нче таблица

Татарстан Республикасында нефть белән бергә чыккан газны жыю һәм утильләштерү

| Күрсәткечнең исеме / еллар | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Нефть белән бергә чыга торган газны жыю, млн. куб метр | 874,6 | 871,5 | 882,2 | 824,1 | 882,7 | 943,8 | 960 |
| Эшкәртүгә кабул итү, млн. куб метр | 800,1 | 802,5 | 818 | 765,7 | 832,7 | 844,9 | 909,5 |
| Утильләштерү дәрәҗәсе, процент | 91,4 | 92 | 92,7 | 92,9 | 94,3 | 89,5 | 95 |

**3.2. Татарстан Республикасының углеводородлар минерал-чимал базасының бүгенге хәле**

Хәзерге вакытта төп эре нефть чыганакларының табигый ярлылануы һәм озак вакыт файдаланылуы аркасында Россия Федерациясенең нефть сәнәгате чимал базасы тотрыклы рәвештә начарая башлады. Илдәге барлык нефть чыгаруның 70 процентын тәшкил итүче актив запаслар 40 процентка кадәр кимеде. Аларны чыгару 75 процентка кадәр артты. Авыр чыгарыла торган запаслар 60 процент тәшкил итә, аларны чыгару дәрәҗәсе түбән булып кала (30 процентка кадәр).

Авыр чыгарыла торган запаслар Татарстан Республикасында тагын да күбрәк һәм ул 78,4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясендә запаслар 2006 елдан башлап киңәйтелгән рәвештә торгызыла. Россия Федерациясендә нефть запасларын тулыландыруның торышы 2 нче таблицада китерелде.

2 нче таблица

Россия Федерациясендә 1986 – 2014 елларда нефть запасларын торгызу торышы

| Күрсәткеч исеме / еллар | 1986 – 1990 | 1991 – 1995 | 1996 – 2000 | 2001 – 2005 | 2006 – 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Нефть запаслары артымы, млн. тонна | 6 890 | 2 344 | 1 245 | 1 253 | 3 434 | 700 | 680 | 635 | 530 |
| 2. Нефть чыгару, млн. тонна | 2 760 | 1 840 | 1 538 | 2 077 | 2 460 | 511,4 | 518,0 | 523,4 | 526,7 |
| 3. Минерал-чимал базасын яңадан торгызу, процент | 249 | 127 | 80 | 60 | 139,6 | 136,8 | 131,3 | 121,3 | 100,6 |

Хәзерге вакытта Россия Федерациясендә нефть якынча 1600 чыганактан алына, һәм тотрыклылык чорыннан соң 2000 елдан башлап нефть чыгару кабат үсә башлады. 2010 елда нефть чыгару күләме 500 млн. тоннадан артып китеп, 505 млн. тоннага кадәр җитте. Әлеге күрсәткечләр 2030 елга кадәр чорга Россиянең Энергетика стратегиясендә һәм 2020 елга кадәр Нефть тармагын



үстерүнең генераль схемасында китерелә торган нефть чыгаруның фаразланган еллык дәрәҗәләреннән артып китте (3 нче таблица).

3 нче таблица

2008 елдан алып 2014 елга кадәр чорда Россия Федерациясендә нефть чыгару дәрәҗәсе

| Нефть чыгару, елына млн. тонна / еллар | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Чынбарлыкта | 488,1 | 494,2 | 505,2 | 511,0 | 518,0 | 523,4 | 526,7 |
| ЭС-2030 | 488,0 | 494,0 | 494,0 | 494,0 | 495,0 | 495 | 495 |
| Россия Федерациясе Генсхемасы: | | | | | | | |
| планлаштырылган вариант | 488,0 | 494,0 | 496,0 | 484,0 | 473,0 | 462 | 454 |
| проекттагы вариант | 488,0 | 494,0 | 496,0 | 505,0 | 513,0 | 522 | 531 |

Илдә нефть чыгаруны киләчәктә үстерү резервы, нефть һәм газның чимал базасын тулыландыру булып нефть бирүне арттыру алымнарын (алга таба – НБАА) кертү масштабларын киңәйтү һәм югары үзлекле нефть (алга таба – ЮҮН), аеруча югары үзле нефть (алга таба – АЮҮН) запасларын, шулай ук аз үтемле коллекторлардагы запасларны ала башлау тора.

Анализ күрсәткәнчә, Россия Федерациясендә нефть алу коэффициенты 1965 елдан башлап үзгәрми кими барды. Бары соңгы елларда гына аның тотрыклана башлавы күзәтелә. Татарстан Республикасында 1995 елдан алып 2013 елга кадәр «Татнефть» ААҖ ятмалары буенча НЧК 0,42 алып 0,47 кадәр артты.

Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында НЧКның чагыштырма динамикасы 2 нче рәсемдә китерелде.




**2 нче рәсем. Россия, Татарстан, АКШ һәм Ханты-Манси автоном округында нефть бирү проекты динамикасы**

НЧК киму сәбәпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Катламнардан нефть алу технологияләренең һәм аларның нефть бирүчәнлеген арттыру алымнарының чынбарлыктагы геологик төзелешенә туры китереп сайланмавы;

кайбер нефть компанияләрендә скважиналарның бик зур эксплуатацияләү фондын (50 процентка кадәр һәм күбрәк) кулланылыштан чыгару хисабына эшкәртү системаларының балансы бозылу;

бик аз чыгымнар белән максималь табыш алу максатларында аеруча продуктив катламнарны алдан эшкәртү;

катламнарның НБАА кулլануның кискен кимүе һәм НЧК арттыруның яңа нәтиҗәле технологияләрен эзләү;

нефть бирүне арттыруның заманча өченчел алымнарын уйлап тапканда һәм файдалануга керткәндә салым стимуллаштыру чаралары булмау.

Замана шартларында табышны абсолют үстерү түгел, ә аны табуның икътисадына, углеводород чималын ил эчендә нефть эшкәртү һәм нефть химиясе предприятиеләрендә тирәнтен эшкәртүне тәэмин итүгә күбрәк әһәмият бирелә башлады.

Татарстан Республикасында 2015 елның 1 гыйнварына Дәүләт запаслар балансында 928,3 млн. тонна күләмендә А+В+С1 категориясендәге нефтьнең суммар чыгарыла торган запаслары белән 205 нефть чыганагы исәпкә алынган. С2 категориясендәге алдан бәяләнгән запаслар күләме 175,2 млн. тонна, Д1+Д2 категориясе ресурслары – 862,1 млн. тонна. Нефть чыганакларыннан нефтьне сәнәгать максатларында ала башлаган вакыттан бирле республика буенча тупланма нефть чыгару 3181,2 млн. тонна тәшкил итте.

«Миллер энд Ленц, Лтд.» бәйсез компаниясе бәяләве буенча, 2014 елның 1 гыйнварына «Татнефть» ААҖнең расланган сәнәгать категорияләре запасларының күләме 847,3 млн. тонна тәшкил итә.






3 нче рәсем. Чыганаклардан нефтьне алып бетерү буенча «Татнефть» ААҖ нефтен чыгару бүленеше




4 нче рәсем. 2014 елның 1 гыйнварына «Татнефть» ААҖ чыганаклары буенча А+В+С1 категориясенә караган чыгарыла торган нефть запаслары структурасы

«Татнефть» ААҖ һәм КНК мәгълүматлары буенча, нефть чыгаруны запаслар белән тулыландыру 4 нче һәм 5 нче таблицаларда күрсәтелде.

2014 елга «Татнефть» ААҖ буенча минерал-чимал базасын торгызу 142 процент тәшкил итә, республиканың КНК буенча – 141,4 процент.

4 нче таблица

«Татнефть» ААҖ буенча нефть чыгаруны запаслар белән тулыландыру динамикасы

| Күрсәткеч исеме / еллар | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Нефть чыгару, млн. тонна | 25,3 | 25,4 | 25,7 | 25,8 | 25,9 | 25,9 | 25,9 | 26,0 | 26,1 | 26,2 |
| 2. C1+C2 категориясе буенча запаслар артымы (запасларны исәптән төшерү белән), млн. тонна, шул исәптән | 6,6 | 33,7 | 22 | 16,2 | 47,2 | 24,8 | 20,3 | 18,4 | 34,4 | 37,2 |
| ГТЭ хисабына | 2,7 | 27,7 | 19 | 12,4 | 39,3 | 21,1 | 8,5 | 16,5 | 13 | 10,7 |
| НЧК үзгәртү һәм яңадан бәяләү хисабына | 3,9 | 6 | 3 | 3,8 | 7,9 | 3,7 | 11,8 | 1,9 | 21,4 | 26,5 |
| 3. Минерал-чимал базасын торгызу, процент | 26,1 | 132,7 | 85,6 | 62,8 | 182,2 | 95,8 | 78,4 | 70,8 | 131,8 | 142 |

*«Татнефть» ААҖ мәгълүматлары буенча*

5 нче таблица

КНК буенча нефть чыгаруны запаслар белән тулыландыру динамикасы

| Күрсәткеч исеме / еллар | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Нефть чыгару, млн. тонна | 5,5 | 6,0 | 6,3 | 6,6 | 6,8 | 6,7 | 6,8 | 6,9 | 6,9 | 7,0 |
| 2. C1+C2 категориясе буенча запаслар артымы (запасларны исәптән төшерү белән), млн. тонна, шул исәптән | 3,1 | 11,2 | 8,5 | 13,9 | 21,1 | 33,2 | 16,2 | 18,4 | 15,4 | 9,9 |
| агымдагы ГТЭ хисабына | 1,7 | 4,3 | 2,2 | 12,2 | 6,8 | 6,7 | 11,9 | 16,0 | 12,7 | 7,8 |
| НЧК үзгәртү һәм яңадан бәяләү хисабына | 1,4 | 6,9 | 6,3 | 1,7 | 14,3 | 26,5 | 4,3 | 2,4 | 2,7 | 2,1 |
| 3. Минерал-чимал базасын торгызу, процент | 56,4 | 186,7 | 134,9 | 210,6 | 310,3 | 495,5 | 238,2 | 266,7 | 223,2 | 141,4 |

*КНК мәгълүматлары буенча*



### 3.3. Татарстан Республикасының углеводородлар минерал-чимал базасын торгызу

Традицион геология-тикшерү эшләре (алга таба – ГТЭ) хисабына запасларны арттыру мөмкинлекләре территориянең тикшерелүе арткан саен тотрыклы кими бара. Татарстан Россия Федерациясенең барлык субъектлары арасында иң күп тикшерелгән территория булып тора. Хәзерге вакытта республикада ГТЭ хисабына запаслар артымы 40 процент тәшкил итә. 2030 елга артымның зур өлеше бүгенге көндә иң аз өйрәнелгән АЮҮН һәм Пермь ятмаларының табигый битумнары, доманик ятмалар запаслары хисабына башкарылачак.

ГТЭ юнәлешләрен сайлаганда запасларның интеграль артымы нәтиҗәлелеге мәсьәләләре белән беррәттән аларның сыйфаты, бигрәк тә актив һәм табыш бирә торган чыгаруга кертеп җибәрә алырлык запаслар өлеше мәсьәләләренә дә таянып эш итәргә кирәк. КНК өчен, лицензияле территорияләрдә тикшерелмәгән кишәрлекләрне, шулай ук C2+C3 категорияләрендәге запасларны һәм ресурсларны эзләү перспективаларының чикләнгәнлеген исәпкә алып, ГТЭ өчен түбәндәге мәсьәләләр өстенлекле булырга тиеш:

НЧК күтәрү;

токым-коллекторларның кондицион әһәмиятен, геологик-гидродинамик модельләрне тәгаенләп, гамәлдәге ятмаларның запасларын яңадан бәяләү;

тикшерүнең инновацион технологияләрен кертеп җибәрү;

файдаланыла торган ятмаларны тикшереп бетерү.

6 нчы таблицада запасларны киңәйтелгән рәвештә торгызуны тәэмин итүче эзләү-тикшерү бораулавының таләп ителә торган күләмнәре китерелде. 2010 – 2030 еллар чорында Татарстан Республикасы буенча запаслар артымы 560,7 млн. тонна, нефть чыгаруның гомуми күләме 568,75 млн. тонна тәшкил итәчәк.

2014 – 2030 елларда Татарстан Республикасында артымның зур булмаган үсү темплары белән нефть чыгаруның тотрыклануы түбәндәгеләр хисабына тәэмин ителәчәк:

эзләү-тикшерү бораулавы күләмнәрен арттыру;

яңа технологияләр буенча горизонталь башлы скважиналар бораулау күләмен арттыру (девон ятмаларына горизонталь скважиналар, карбонат коллекторларга күптармаклы скважиналар, нефть чыгарыла торган чыганакларда ян горизонталь көпшәләр, шул исәптән горизонталь скважиналар конструкциясенә «КВАРТ» ЯАҖнең импортны алмаштырырлык бүртүче пакерларын да тоташтырып);

НБАА системалы технологияләрен кертү;

битумсыман нефть чыга торган чыганакларны (ятмаларны) җылыту алымнары белән чыгара башлау буенча эш күләмнәрен киңәйтү;

аз үтемле коллекторлар ятмаларын, кишәрлекләрен файдалануга кертү;

ЮҮН һәм АЮҮН ятмаларын чыгаруның яңа технологияләрен кертү (7 нче таблица).

Монан тыш, Татарстан Республикасында тагын да югарырак баскычтагы инновацион технологияләрне басу шартларында сынау буенча фәнни полигон төзү тармак инновацияләрен кертүне киңәйтүнең әһәмиятле резервы булып тора. Әлеге полигонны оештыру эшен Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы белән берлектә «Татнефть» ААЖ алып бара.



6 нчы таблица

Запасларны арттыру, сейсмологик тикшерү эшләре, эзләү-тикшерү бораулавы күләмнәре

| | Күрсәткеч исеме / еллар | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 | 2010 – 2030 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татнефть» ААЖ | Запасларны арттыру, млн. тонна | 24,8 | 20,3 | 18,4 | 34,4 | 37,2 | 26,5 | 27,4 | 28,1 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 27,0 | 568,1 |
| | Сейсмологик тикшерү эшләре күләмнәре, шул исәптән | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | 2Д, озынл. км | 4111 | 3760 | 1095 | 141 | 309 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 11616 |
| | 3Д, км2 | 0 | 82 | 622 | 692 | 694 | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 | 600 | 550 | 550 | 550 | 500 | 500 | 500 | 500 | 450 | 450 | 450 | 10690 |
| | Эзләү-тикшерү бораулавы күләме, мең м | 18,8 | 19,1 | 22,0 | 19,2 | 14,3 | 18,0 | 18,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 409,4 |
| КНК | Запасларны арттыру, млн. тонна | 28,7 | 16,2 | 18,4 | 15,4 | 9,9 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 6,5 | 192,6 |
| | Сейсмологик тикшерү эшләре күләмнәре, озынл. км | 410 | 1450 | 103 | 123 | 800 | 800 | 750 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 700 | 14 236 |
| | Эзләү-тикшерү бораулавы күләме, мең м | 41 | 43 | 40 | 28 | 29 | 30 | 31 | 34 | 30 | 34 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 35 | 725 |
| ТР буенча барысы | Запасларны арттыру, млн. тонна | 53,5 | 36,5 | 36,8 | 49,8 | 47,1 | 33 | 33,9 | 34,6 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 33,5 | 760,7 |
| | Эзләү-тикшерү бораулавы күләме, мең м | 59,8 | 62,1 | 62 | 47,2 | 43,3 | 48 | 49 | 54 | 50 | 54 | 55 | 55 | 55 | 55 | 55 | 55 | 55 | 55 | 55 | 55 | 55 | 1 138,1 |

7 нче таблица

Нефть чыгару, файдалану бораулавы һәм нефть чыгаручы яңа скважиналарны кертү күләме

| Күрсәткеч исеме / еллар | | 2014 | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 | 2014 – 2030 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татнефть» ААҖ | Нефть чыгару, мең тонна, шул исәптән | 26223 | 26547 | 27363 | 28061 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 27000 | 459194 |
| | АЮУН Ашалчы чыганагы, мең тонна | 237 | 382 | 631 | 813 | 1522 | 1875 | 2365 | 2550 | 2726 | 2918 | 3074 | 3189 | 3336 | 3500 | 3653 | 3783 | 3940 | 40494 |
| | Файдалану бораулавы*, мең м | 410 | 663 | 640 | 456 | 637 | 478 | 607 | 436 | 523 | 466 | 481 | 462 | 482 | 485 | 492 | 501 | 496 | 8715 |
| | Нефть чыгаручы яңа скважиналарны кертү | 265 | 558 | 539 | 231 | 424 | 279 | 401 | 236 | 322 | 277 | 300 | 288 | 312 | 320 | 333 | 333 | 339 | 5757 |
| | Икенче ян көпшәләрне бораулау (БС, БГС) | 61 | 65 | 65 | 67 | 69 | 70 | 70 | 75 | 80 | 80 | 82 | 82 | 85 | 90 | 90 | 90 | 90 | 1 311 |
| КНК | Нефть чыгару, мең тонна | 6863 | 6521 | 6500 | 6500 | 6500 | 6500 | 6500 | 6500 | 6500 | 6500 | 6500 | 6500 | 6428 | 6318 | 6234 | 6140 | 6057 | 109561 |
| | Файдалану бораулавы, мең м | 266 | 279 | 277 | 282 | 288 | 274 | 280 | 247 | 271 | 241 | 257 | 241 | 217 | 213 | 212 | 206 | 205 | 4256 |
| | Нефть чыгаручы яңа скважиналарны кертү | 241 | 248 | 258 | 244 | 249 | 246 | 242 | 225 | 244 | 232 | 233 | 222 | 209 | 201 | 199 | 195 | 198 | 3886 |
| ТР буенча барысы | Нефть чыгару, мең тонна | 33086 | 33068 | 33863 | 34561 | 33500 | 33500 | 33500 | 33500 | 33500 | 33500 | 33500 | 33500 | 33428 | 33318 | 33234 | 33140 | 33057 | 568755 |
| | Файдалану бораулавы, мең м | 676 | 942 | 917 | 738 | 925 | 752 | 887 | 683 | 794 | 707 | 738 | 703 | 699 | 698 | 704 | 707 | 701 | 12971 |
| | Нефть чыгаручы яңа скважиналарны кертү | 506 | 806 | 797 | 475 | 673 | 525 | 643 | 461 | 566 | 509 | 533 | 510 | 521 | 521 | 532 | 528 | 537 | 9643 |

** – АЮУН өчен бораулауны исәпкә алып*



Татарстан Республикасында запасларны һәм нефть чыгаруны арттыруның беренче чираттагы резервлары 8 нче таблицада китерелде.

8 нче таблица

Татарстан Республикасында углеводородлар запасларын һәм нефть чыгаруны арттыру потенциалы

| Чаралар һәм ресурслар | Көтелә торган нәтиҗәләр |
|---|---|
| Традицион нефть объектлары | |
| Чыгаруны инновацион проектлау | |
| Чыгаруның соңгы стадиясендәге эре чыганаклар буенча:<br>токымнарны һәм ятмалар флюидларын геологик тикшерүнең яңа алымнарын, скважиналарның геофизик һәм гидродинамик интерпретацияләүнең яңа алымнарын куллану;<br>яңа геологик-гидродинамик модельләр төзү;<br>чыгаруның яңа системаларын куллану;<br>ятмаларның аеруча суланган кишәрлекләрендә өр-яңа НБАА кертү, файдалануның махсус режимнарын, су куллануны тикшерүдә тоту һәм исәпкә алуның автоматлаштырылган системаларын кертү;<br>нефтьнең калдык запасларының бер өлешен чыгару ысулларын уйлап табу. | Чыгарыла торган запаслар артымы якынча 1 млрд. тонна. НЧК 0,4-0,5 алып 0,6-0,7 кадәр арта. |
| Татарстан Республикасының 38 проценттан артык табышын бирә торган вак һәм уртача чыганаклар буенча:<br>карбонатлы коллекторларда ятмаларны чыгару (баланс запаслары – 2,6 млрд. тонна, чыгарыла торганнар – 440 млн. тонна, НЧК – 0,17, 0,11 алып 0,25 кадәр);<br>югарырак үзле нефть һәм югары үзле нефть ятмаларын эшкәртү (НЧК – 0 алып 0,3 кадәр). | Чыгарыла торган запаслар артымы 400 млн. тонна. НЧК 0,25-0,4 кадәр арта. |

### 3.4. Татарстан Республикасында нефть чыгару тармагын үстерү

Чыгаруның соңгы стадиясендәге чыганаклардан нефть чыгаруны алга таба үстерү түбәндәге бурычларны хәл итү белән бәйле:

киптерелә торган запаслардан нефть чыгаруны арттыру;

ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыруның өченчел ысулларын кертү юлы белән авыр чыгарыла торган нефть запасларын актив чыгара башлауны тәэмин итү.

Татарстан нефть компанияләре үзләштерә торган горизонталь бораулау технологияләрен (горизонталь скважиналар, тармакланган горизонталь скважиналар, күптармаклы скважиналар, ян көпшәләр), скважиналарны бергә-аерым файдалану һәм җылыту алымнарын киң куллану киптерелә торган запаслардан нефть чыгаруны нәтиҗәле арттыра барырга мөмкинлек бирә.

Авыр чыгарыла торган нефть запаслары булган аз нәтиҗәле чыганакларда нефть чыгару өчен бөтенләй икенче төрле юллар табарга кирәк. Аларның рентабельле чыгарылуын тәэмин итүнең төп шарты булып коллектор үзенчәлекләре, коллекторлар тибы якын булган файдалану объектларының оптималь зурлыкларын һәм аларны туендыручы флюидларны аерып алу тора. Татарстан Республикасында нефть ятмаларын чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыруның Татарстан белгечләре уйлап тапкан комплекслы технологияләре түбәндәгеләрдә иң күп кулланыш тапты:

начар үтемле һәм балчыклы терриген коллекторларда;

ЮҮН булган терриген коллекторларда;

карбонатлы коллекторларда.

НБАА һәм тармак яңы зонасын эшкәртү (алга таба – ТЯЗЭ) хисабына өстәмә табышның 2030 елга кадәр планлаштырыла торган күләмнәре 5 нче рәсемдә күрсәтелде.




**5 нче рәсем. НБАА һәм ТЯЗЭ хисабына өстәмә табышның 2030 елга кадәр планлаштырыла торган күләмнәре**

6 нчы рәсемдә 2030 елга кадәр КНК буенча запасларны торгызуны тәэмин итү юнәлешләре китерелде.






**6 нчы рәсем. КНК буенча запасларны торгызуны тәэмин итү юнәлешләре**

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең эксперт мәгълүматлары буенча, тулаем республика буенча, «Татнефть» ААҖ һәм КНК буенча нефть чыгаруның перспективадагы күләмнәре 7 нче рәсемдә китерелде.




**7 нче рәсем. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы буенча нефть чыгару**

Тотрыклы нефть чыгаруны, углеводород чималы запасларын киңәйтелгән торгызуны тәэмин итү максатларында түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

ГТЭ хисабына чынбарлыктагы артымы һәм булган алымнары буенча кабул ителгән проект карарларын үтәгәндә чынбарлыкта чыгарыла торган запасларны билгеләп, барлык КНКнә ГТЭ, НЧК күтәрү хисабына запасларны арттыру белән эшләрнең гамәлдәге торышына җентекле анализ ясарга;

чыгарыла торган запасларга, аларны бүленгән төркемнәре һәм категорияләре буенча дифференциацияләп, чыганаклар буенча җентекле анализ ясарга;

яңача якын килү белән геологик-гидродинамик модельләрне тәгаенләргә;

шуңа нигезләнеп эшкәртүнең кимендә НЧКның расланган күрсәткечләрен яисә, яңача инновацион якын килүләрне исәпкә алып, тагын да югарырак күрсәткечләрне тәэмин итәрлек яңа системаларын проектларга. Бер үк вакытта аерым-аерым НБАА һәм ТЯЗЭ хисабына өстәмә табышны объектив бәяләү буенча эш үткәрергә кирәк.

Үсешнең адреслы стратегиясен билгеләү өчен Татарстан Республикасының барлык КНКен өч категориягә бүләргә була (9 нчы таблица):

нефть чыгару темплары түбән булу һәм нефть запаслары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителү;

нефть запаслары аз булганда нефть чыгару темпларының чагыштырмача югары булуы;

нефть запаслары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителгәндә нефть чыгару темплары бик түбән булу.



9 нчы таблица

Татарстан Республикасының КНКнә категорияләр буенча сыйфатлама

| КНК исеме | Башлангыч чыгарыла торган запаслар, мең тонна | Тупланма нефть чыгару, мең тонна | Агымдагы чыгарыла торган запаслар, мең тонна | Нефть запаслары, мең тонна | | 2013 елда нефть чыгару, мең тонна | Запаслар белән тәэмин ителеш, ел | Агымдагы чыгарыла торган запаслар темпы, процент | 2013 елда запаслар артымы, мең тонна | Нефть буенча уртача дебит, тонна/тәүлек |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | C2 | C3 | | | | | |
| Чыгару темплары түбән КНК | | | | | | | | | | |
| «Татнефтетодача» ЯАҖ | 33 382 | 5 147 | 28 235 | 3 404 | 104 | 529,1 | 53 | 1,87 | 25 | 5,1 |
| «СМП-Нефтегаз» ААҖ | 11 088 | 5 318 | 5 770 | 296 | 670 | 307,2 | 19 | 5,32 | 40 | 4,7 |
| «ГРИЦ» ААҖ | 4 276 | 1 386 | 2 890 | 752 | 230 | 107,0 | 27 | 3,70 | 55 | 2,6 |
| «Меллянефть» ААҖ | 3 160 | 1 116 | 2 044 | 147 | 2 906 | 71,0 | 29 | 3,47 | 49 | 3,8 |
| «Татойлгаз» ААҖ | 18 323 | 6 695 | 11 628 | 1 265 | 1 346 | 410,5 | 28 | 3,53 | 87 | 3,2 |
| «ТНП-Зюзеевнефть» | 16 568 | 5 433 | 11 135 | 59 | - | 340,7 | 33 | 3,06 | - | 4,4 |
| «Татнефтепром» ААҖ | 25 622 | 7 342 | 18 280 | 544 | - | 261,7 | 70 | 1,43 | 6 311 | 2,4 |
| «ТатРИТЭКнефть» ССП | 69 841 | 12 323 | 57 518 | 10 367 | 7 224 | 966,3 | 60 | 1,68 | 806 | 6,8 |
| «Кара-Алтын» ЯАҖ | 40 433 | 7 531 | 32 902 | 3 386 | - | 510,1 | 65 | 1,55 | 2 181 | 3,5 |
| «ВУМН» ҖЧҖ | 11 936 | 3 212 | 8 724 | 1 229 | - | 175,6 | 50 | 2,01 | - | 5,4 |
| «Шешмаойл» ААҖ | 21 539 | 5 041 | 16 498 | 3 038 | 761 | 410,6 | 40 | 2,49 | 3 737 | 3,0 |
| «Иделойл» ААҖ | 11 736 | 1 911 | 9 825 | 150 | 161 | 176,0 | 56 | 1,79 | - | 2,5 |
| «Кондурчанефть» ААҖ | 6 249 | 837 | 5 412 | 468 | - | 66,4 | 82 | 1,23 | 66 | 2,3 |
| «Булгарнефть» ААҖ | 8 568 | 2 667 | 5 901 | 1 204 | - | 173,2 | 34 | 2,94 | 729 | 4,7 |
| | 282 721 | 65 959 | 216 762 | 26 309 | 13 402 | 4 505,3 | 48 | 2,08 | 13 999 | - |
| Нефть запаслары белән тәэмин ителешләрендә проблемалар булган КНК | | | | | | | | | | |
| «Татех» ЯАҖ | 17 895 | 8 615 | 9 280 | 3 801 | 657 | 461,2 | 20 | 4,97 | 31 | 3,0 |
| «Алойл» ЯАҖ | 7 170 | 3 175 | 3 995 | 1 689 | - | 277,4 | 14 | 6,94 | - | 4,1 |
| «Татнефть-Геология» ҖЧҖ | 5 409 | 1 931 | 3 478 | 364 | - | 169,6 | 21 | 4,88 | 1 110 | 7,6 |
| «Геотех» ЯАҖ | 3 998 | 1 631 | 2 367 | 1 548 | 707 | 116,4 | 20 | 4,92 | 30 | 4,9 |
| «Акмай» ААҖ | 386 | 146 | 240 | 37 | - | 17,4 | 14 | 7,25 | - | 4,2 |
| «Геология» ЯАҖ | 5 395 | 2 664 | 2 731 | 382 | 430 | 177,6 | 15 | 6,50 | 15 | 3,3 |
| «ТНГК-Развитие» ҖЧҖ | 9 006 | 4 843 | 4 163 | 2 347 | - | 233,3 | 18 | 5,60 | - | 5,3 |
| «Охтин-Ойл» ЯАҖ | 6 448 | 3 573 | 2 875 | 414 | - | 180,0 | 16 | 6,26 | - | 5,5 |
| «Троицкнефть» ЯАҖ | 9 878 | 2 729 | 7 149 | 941 | - | 239,3 | 30 | 3,35 | 128 | 4,5 |
| «МНКТ» ААҖ | 7 525 | 2 493 | 5 032 | 573 | - | 121,9 | 41 | 2,42 | - | 3,6 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 73 110 | 31 800 | 41 310 | 12 096 | 1794 | 1 993,9 | 21 | 4,83 | 1 314 | - |
| Проблемалы КНК | | | | | | | | | | |
| «Карбон-Ойл» ҖЧҖ | 5 071 | 300 | 4 771 | 2 386 | 112 | 38,5 | 124 | 0,81 | - | 2,0 |
| «Елабуганефть» ААҖ | 1 490 | 328 | 1 162 | - | - | 15,9 | 73 | 1,37 | - | 2,0 |
| «Нократойл» ААҖ | 660 | 113 | 547 | - | - | 6,3 | 87 | 1,15 | - | 2,2 |
| «Трансойл» ҖЧҖ | 6 517 | 1 813 | 4 704 | 950 | 713 | 144,6 | 33 | 3,07 | - | 3,6 |
| «Нурлат нефть компаниясе» ҖЧҖ | 1 206 | 21 | 1 185 | 181 | - | 3,3 | 361 | 0,28 | - | 1,8 |
| «Макойл» ЯАҖ | 1 269 | 200 | 1 069 | 45 | - | 17,2 | 62 | 1,61 | - | 1,5 |
| «Селенгушнефть» ЯАҖ | 1 550 | 107 | 1 443 | 570 | 1 402 | 9,7 | 149 | 0,67 | - | 1,7 |
| «ВЕЛЛойл» ЯАҖ | 588 | 22 | 566 | 548 | 334 | 4,1 | 139 | 0,72 | - | 2,4 |
| «Дружбанефть» ААҖ | 1 116 | 238 | 878 | 30 | 2 015 | 21,6 | 41 | 2,46 | 169 | 2,3 |
| | 19 467 | 3 142 | 16 325 | 4 710 | 4 576 | 261,1 | 63 | 1,60 | 169 | - |



КНК беренче төркеменең төп бурычы файдаланыла торган объектлардан нефть чыгару темпларын елына башлангыч чыгарыла торган запаслардан 5 – 6 процентка кадәр сайлап алуны арттыру эшеннән гыйбарәт. Бу исә тутыру скважиналары санының чыгару скважиналарына карата нисбәтен арттыру, иң нәтиҗәле НБАА һәм ТЯЗЭ киң куллану хисабына тәэмин ителергә мөмкин.

КНК икенче төркеме өчен планлаштырылган ГТЭ күләмнәрен үтәү белән бергә чыганакларның геологик төзелешенә иң яхшы туры килә торган НБАА куллану актуаль. Әлеге очракта шул геологик шартларда НБАА куллануның нәтиҗәлелегенә анализ ясарга кирәк – алар арасыннын иң нәтиҗәлесе сайлап алына һәм аларны кертеп җибәрүнең махсус проектлары төзелә. Боларның барысы да чыгарыла торган нефть запасларын арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Бер үк вакытта файдаланыла торган чыганакларны тикшереп бетерү буенча чаралар төзү өчен скважиналар фондын яңарту зарур.

КНК өченче төркеме аеруча катлаулы чыганакларны үзләштерә. Монда проблемалы төгәл чыганаклар материалларында (керн, ятмалар флюидлары, бораулаган скважиналар) нефтьне этеп чыгаруның фундаменталь тикшеренүләрен үткәреп, ике-өч инновацион чыгару проектын төзү таләп ителә. Бу эшләр нәтиҗәләре буенча әлеге төркем чыганакларының киләчәге турында нәтиҗә ясап булачак.

### 3.5. Татарстан Республикасының традицион булмаган углеводородлар чыганакларын үзләштерү мәсьәләләре һәм перспективалары

Традицион булмаган углеводородлар категориясенә авыр нефть, табигый битумнар, битумлы комнар, нефтьле сланецлар керә. Моннан тыш, бу категориягә традицион булмаган газ ресурслары да карый: күмер чыганаклары, суда эрегән газлар, сланецлы һәм тыгыз формадагы газлар (8 нче рәсем). Традицион булмаган нефтьләрнең дөньякүләм ресурслары 1,3 – 1,4 трлн. тонна дип бәяләнә. Алардан гамәлдәге чыгару технологияләре белән рентабельле рәвештә 171,5 млрд. тонна углеводород чыгарылырга мөмкин.




**8 нче рәсем. Геологик ресурслар, млрд. тонна шартлы ягулык (Белонин М.Д. буенча)**

3.5.1. Татарстан Республикасы катламнарының Пермь комплексының югары үзле нефтьләре һәм табигый битумнары

Татарстанның Пермь катламнары битумнарын сыек, ярымсыек һәм каты консистенциядәге (үзлелеге 600 алып 1 млн. кадәр спз), күкерте күп булган (3,7 – 7,0 процент), 5,8 алып 88,0 процентка кадәр майлар, 8,7 алып 57,0 процентка кадәр сумалалар, 3,3 алып 61,0 процентка кадәр асфальтеннар булган оксидлашкан югары үзле нефтьләр тәшкил итә.

Тикшерү эшләре һәм кернны лабораториядә тикшеренү нәтиҗәләренә ясалган анализ битумнар ятмалары төзелешенең нефть чыганаклары белән охшашлыгын раслады. Битумнардан гыйбарәт катламнар токым авырлыгына карата составында 1 алып 20 процентка кадәр битум (поралар күләменә 40 – 98 процент) булган, битум белән туенганлык бер процентка һәм аннан да кимрәккә кадәр төшә торган чикләре билгеләнгән тупланмалардан гыйбарәт.

Углеводородлар ятмаларын, углеводородларның дөньякүләм кабул ителгән классификациясенә таянып, нефть алуны арттыруның заманча алымнарын куллануның потенциалын билгеләү максатларында түбәндәгечә бүләргә мөмкин:



түбән үзле (җиңел) нефтьләрдән торган, үзлелеге 10 мПа с кадәр;

югарырак үзле, үзлелеге 200 мПа с кадәр;

югары үзле, үзлелеге 200 алып 1 000 мПа с кадәр;

аеруча югары үзле, авыр нефтьләр, үзлелеге 1000 алып 10 000 мПа с кадәр;

табигый битумнар (алга таба – ТБ), үзлелеге 10 000 мПа с артык.

Бу классификациядән чыгып, Татарстан Республикасының Пермь утырма комплексы углеводородлары АЮҮНкә һәм ТБга керәләр.

Татарстан Республикасының Пермь катламнарында углеводород чималы ресурслары төрле авторлар тарафыннан узган йөзьеллыкның икенче яртысында 30 елдан артык вакыт дәвамында өйрәнелделәр. Аларга бирелгән бәя, хәтта республиканың төньяк районнарын да кертеп (40 млрд. тоннага кадәр), 4 млрд. тонна белән 21 млрд. тонна арасында тирбәлде. Ресурсларның мөмкин булырлык күләме 7 – 8,7 млрд. тонна тәшкил итә, шул исәптән үзләштерү өчен өстенлекле ресурслар 1,5 – 2 млрд. тонна, бу күләмдә аны 1974 елда «Татнефть» берләшмәсенең геологик хезмәте кабул иткән. 1978 елдан башлап ике чыганак – Мордва Кармалкасы һәм Ашалчы – ТБ чыгаруның скважиналы технологияләрен эшләтеп карау өчен полигон булдылар. Узган елларда әлеге чыганакларда түбәндәге технологияләр уйлап табылды һәм апробация үтте:

махсус төзелгән кернсайлагыч белән көпшәк битумлы комлыкларда кернны сайлап алу;

битум скважиналарын эшләтеп карау;

термогаз генераторы, югары ешлыктагы электромагнит кыры, пар, УЭСК-100 электроҗылыту җайланмасы кулланып ятма эчендә януны тәкъдим итү;

составында битум күп булган ятмага һава, пар һәм пар газы белән термоциклик тәэсир итү;

һаваны, парны һәм пар газын катламнарга тутыру;

фильтрацион агымнарны үзгәртү;

түбән температуралы окислаштыру ысулы белән ТБ чыгару.

Моннан тыш, Пермь авыр нефтьләре чыганакларын эзләү һәм тикшерү, үзле һәм ЮҮН ятмаларын контурлаштыру методикасы, локаль күтәрүнең төрле структур-геологик шартларында ятмаларның чыгару мөмкинлекләрен өйрәнү технологияләре эшләнде.

Битумнар чыгаруның скважиналы алымнарын эшләү буенча тикшеренүләр һәм тәҗрибә-сәнәгать эшләрен үткәрү ТБ ятмаларын җылылык ысулларын (ятма эчендә яну, пар белән

этеп чыгару, пар газы, дулкынлы НБАА, горизонталь бораулауны пар гравитациясе белән берләштерү) кулланып чыгаруның нәтиҗәле булуын күрсәтте. Мордва Карамалысы чыганагының тәҗрибә участогында, ятма эчендә януны кулланып, скважиналы ысуллар белән чыгару нәтиҗәсендә нефтьне зур күләмнәрдә табуга ирешеп булды — 35 процент тирәсе.

Алга таба «Татнефть» ААҖдә SAGD (пар гравитациясе дренажы алымы) технологиясе принициплары нигезендә АЮҮН чыганакларыннан нефть чыгаруның үз технологияләре комплексы төзелде, ул 2012 елда фән һәм техника өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте бүләге белән билгеләп үтелде. Геологик өйрәнелгәнлекнең агымдагы торышында бүгенге көндә эшләнгән технологияләрне кулланып, Ашалчы чыганагында АЮҮН чыгаруның фаразлы күрсәткечләре 9 нчы рәсемдә китерелде.




**9 нчы рәсем. Ашалчы чыганагында «Татнефть» ААҖ АЮҮН ятмаларын үзләштерү проектын үстерүнең фаразлы варианты**

### 3.5.2. Традицион булмаган, шул исәптән сланец катламнары углеводородлары

Соңгы ун елда традицион булмаган углеводород чыганакларын, беренче чиратта, сланец катламнарыннан булган углеводородларны файдалануга кертү нәтиҗәсендә энергия чыганакларының дөнья базары шактый үзгәрде. Традицион углеводородлардан аермалы буларак, алар үзләштерү өчен авыр булган катламнарда тупланган йә продуктив булмаган тирәлектә таралганнар. Әлеге углеводородлар начар хәрәкәтләнә яки җир астында ятма шартларда хәрәкәтләнмиләр, шуңа күрә аларны җир астыннан чыгару өчен махсус ысуллар таләп ителә, бу үз чиратында аларның үзбәясен арттыра.

Чит ил экспертлары бәяләвенчә, 2008 елда планетада сланец нефтенең чыгарыла торган ресурслары 820,0 млрд. тонна дип билгеләнгән. Халыкара энергетика агентлыгы мәгълүматлары буенча, сланец нефтенең чыгарыла торган запаслары 33 ил буенча гына да ачык 600 чыганакта 2013 елның 1 гыйнварына 450,0 млрд. тонна күләмендә булган.

Сланец нефте запаслары традицион запаслар күләменнән шактый артык булуын исәпкә алсак, хәзерге вакытта Россиянең барлык вертикаль-интегральләшкән нефть компанияләре сланец нефте чыганакларыннан нефть чыгару методикасын эшләү буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-сәнәгать эшләре алып баралар.

Татарстан территориясендә нефть-сланец кырларын арттыру перспективалары, беренче чиратта, югары девонның доманикоид формация токымнары — семилукск (доманика) горизонты, шулай ук речицк (мендым) горизонты һәм Кама-Кинель сыгылышлар системасының үзәк һәм ян зоналарының доманикоид формацияләре белән бәйле. Аерым алганда, семилукск һәм речицк горизонтларында нефть булу Ромашкино чыганагының бер төркем мәйданнарына, Ерсубайкино, Березовский һәм башка чыганакларга хас. Татарстан Республикасы территориясендә сланец катламнарында нефть булу перспективаларын бәяләү буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып бару белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе шөгыльләнә.

«Татнефть» ААҖ дә традицион булмаган углеводород чыганакларын өйрәнү буенча еллык программалар тормышка ашырыла. Бу программалар кысаларында Баулы чыганагында сланец катламнарының берсе буенча ятманы гидроөзү башкарылган, тәүлегенә 8 тонна дебитка ирешелгән. 2014 елда Баулы чыганагында доманик катламнарыннан 26 млн. тонна сәнәгать категориясе запаслары компания балансына куелган.

Тармакның фәнни җәмәгатьчелеге булырга мөмкин башка углеводород чыганаклары сыйфатында нефть чыганакларының Җир тирәнлекләреннән, флюид үткәрүче каналлар аша кристаллик фундаменттан углеводородлар белән туенуы теориясе, шулай ук өстәмә бүленеп чыгучы җылылыкны ЮҮН термик чыгару өчен киләчәктә файдаланып, түбән карбон катламнарыннан күмерләрне җир астында газлаштыру мөмкинлеге турында фикер алыша, әмма ул гипотеза буларак кына карала.

### 3.6. Нефть эшкәртү сәнәгате

Нефть эшкәртү сәнәгате Татарстан Республикасының чагыштырмача яшь тармагы булып тора. Аның формалашуы 1999 елдан башлап Татарстан Республикасы Хөкүмәте дәрәҗәсендә кабул ителгән программалы документларны тормышка ашыру кысаларында узды.

Хәзерге вакытта Россия Федерациясендә нефть чыгару күләменең якынча 6 проценты, ә 2012 елда «ТАНЕКО» ААҖ нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексын (алга таба – «ТАНЕКО» комплексы) кулланылышка керткәннән соң – Россия нефть эшкәртүенең барлык күләменнән 6 проценттан артыгы Татарстанга туры килә. Тармак, сәнәгать җитештерүенең гомумреспублика күләмен алганда, аның якынча 17 процентын һәм, сальдирлашкан керем күләмен алганда, аның 14 процентын бирә.

Татарстан Республикасының нефть эшкәртү сәнәгатен «ТАИФ-НК» ААҖ нефть эшкәртү комплексы һәм «Татнефть» ААҖ составына керүче «ТАНЕКО» комплексы тәшкил итә.

Хәзерге вакытта үзенә Нефть эшкәртү заводын, Бензиннар заводын һәм газ конденсатын эшкәртү буенча производствоны берләштергән «ТАИФ-НК» ААҖ ел саен 8,4 млн. тоннадан артык углеводород чималын эшкәртә. Россия Федерациясенең нефть эшкәртү заводлары (алга таба – НЭЗ) арасында «ТАИФ-НК» ААҖ эшкәртү тирәнлеге буенча 75,6 процент күрсәткече белән җиденче урынны алып тора, бу 2014 елның 72,4 процентка тигез уртача тармак дәрәҗәсеннән шактый югары.

«ТАНЕКО» комплексын төзү табыла торган нефтьне үзебездә эшкәртүне оештыру максатларында 2005 елда «Татнефть» ААҖ тарафыннан башланды. Проект уртак проектлау, җиһазлар китерү, төзелешне производство куәтләрен вакытыннан алда кулланылышка кертеп алып бару шартларында баскычлап тормышка ашырыла.

«ТАНЕКО» комплексының гамәлдәге производство куәтләре түбәндәге производстволар белән күрсәтелгән:

нефтьне беренчел эшкәртү;

гидрокрекинг һәм нигез майлар;

күкерт;

инфраструктураны тәэмин итү.

Нефть эшкәртү тирәнлегенең уртача еллык күрсәткече 73,54 процент тәшкил итте. Җитештерү проект куәтеннән (елына 7 млн. тонна) 115 процент йөкләнеш дәрәҗәсенә чыгарылды.

Татарстан Республикасының НЭЗ куәтләрне алга таба үстерү буенча эшне дәвам итәләр, бу киләчәктә республиканың сыйфатлы мотор майларына ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерергә,



нефть химиясе производстволарын чимал белән тәэмин итүне яхшыртырга, шулай ук нефть продуктларының экспортка чыгуы дәрәҗәсен шактый үстерергә мөмкинлек бирәчәк.

2005 елдан алып 2014 елга кадәр Татарстан Республикасында нефть чыгару күләмендә нефть экспорты өлеше шактый кимеде – 62 проценттан 32,6 процентка кадәр. «ТАИФ-НК» ААҖ НЭЗда, «ТАНЕКО» комплексында нефтьне беренчел эшкәртү күләме 2005 елдагы 6,8 млн. тоннадан 2014 елга 17,1 млн. тоннага кадәр артты.

10 нчы таблица

Татарстан Республикасында нефть чыгару һәм эшкәртү динамикасы

| Күрсәткеч исеме / еллар | 2005 | 2006 | 2007 | 2008 | 2009 | 2010 | 2011 | 2012 | 2013 | 2014 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Нефть чыгару, млн. тонна | 30,7 | 31,3 | 31,9 | 32,3 | 32,5 | 32,4 | 32,5 | 32,7 | 32,9 | 33,1 |
| 2. Нефть эшкәртү, млн. тонна | 6,8 | 7,7 | 7,8 | 7,9 | 7,56 | 8,35 | 10,65 | 15,6 | 16,1 | 17,1 |
| 3. Нефть экспорты, млн. тонна | 19,1 | 18,2 | 18,9 | 18,5 | 18,5 | 20,4 | 18,7 | 13,8 | 13,0 | 10,8 |

2030 елга кадәрге перспективада Татарстанның нефть эшкәртү сәнәгатен үстерүнең төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

иң яхшы технологик күрсәткечләргә ирешү, шул исәптән нефтьне эшкәртү тирәнлеге, ачык төстәге нефть продуктларын сайлап алу буенча;

товар продукциясенең заманча дөньякүләм һәм законнарда билгеләнгән россия сыйфат стандартлары һәм техник регламентлар таләпләренә туры килүен тәэмин итү;

полуфабрикат нефть продуктларын, карасу төстәге нефть продуктларын җитештерүне минимальләштерү яисә тулысынча бетерү;

Россия нефтенең гомуми экспорт агымында югары күкертле нефтьләр булуны киметү буенча гомумдәүләт күләмендәге стратегик бурыч буларак чимал буенча куәтне елына 22 – 23 млн. тоннага кадәр арттыру перспективасы белән Татарстан чыганакларында киң таралган авыр югары күкертле карбон нефтьләрне нәтиҗәле эшкәртүне тәэмин итү;

югары сыйфатлы нефть продуктлары товарлары җитештерү өчен зарур ярдәмчел чимал сатып алудан бәйлелекне минимальләштерүне тәэмин итү, шулай ук республикага читтән кертелә торган кирәкле чималны сатып алуга озак вакытлы килешүле мөнәсәбәтләр төзү;

тармак предприятиеләренең энергия һәм ресурсларын сак тотуына ирешү.

Татарстан Республикасында нефтьне һәм табигый битумнарны эшкәртүнең югары тирәнлеген тәэмин итүгә, төбәкнең химия һәм нефть химиясе сәнәгате өчен чимал чыгаруга, Россия һәм дөнья базарларында сату потенциалы булган нефть продуктларын сыйфатына карата өстенлекле таләпләрне исәпкә алып җитештерү өчен эшли торган технологик һәм экологик прогрессив, конкурентлыкка сәләтле нефть эшкәртү сәнәгатенең тотрыклы эшләве һәм алга таба формалашуы 2030 елга кадәр перспективада тармакны үстерүнең төп максаты булып тора.

Әлеге максатка ирешү өчен хәл итәргә кирәк булган бурычлар:

алга чыгу тизлегендә заманча, дөньякүләм дәрәҗәдәге прогрессив технологияләрне файдалануга нигезләнгән, нефтьне (бигрәк тә күкерте күп булган, югары үзле нефтьне), табигый битумнарны мөмкин булган кадәр тирән эшкәртә торган нефть эшкәртү производстволарын төзү;

«традицион булмаган» нефтьне эшкәртү буенча үз илебезнең алдынгы технологияләрен булдыруда катнашу, киләчәктә бу өлкәдә технологик алдынгылыкны тәэмин итеп (төбәктә туры килә торган инновацион, инжиниринг оешмалары, җайланмалар һәм ярдәмче химия продукцияләре (катализаторлар һ.б.) җитештерүчеләрне булдырып);

яңа производстволарны нефть продуктлары сыйфатының дөньякүләм стандартларына ирешүгә юнәлдерү;

төбәк нефть химиясенең перспективалы чималга ихтыяҗын нефть эшкәртүне үстерү планнары белән тигезләшүен тәэмин итү;

импортны алыштырырлык һәм экспортка чыгарырлык продукция эшләп чыгару белән төгәлләнә торган табигый чималны комплекслы эшкәртү белән шөгыльләнүче тармакны төбәк һәм төбәкара территориаль-тармак кластерларына кушып җибәрү;

яңа производстволарны рациональ урнаштыру, ул нефть эшкәртү объектлары тупланган урыннарда экологик зыянны минимальләштерүне тәэмин итүче технологияләрне генә куллану белән бергә транспорт һәм бүтән инфраструктура чыгымнарын киметүне тәэмин итәчәк;

бизнесны һәм инновацион эшчәнлекне территориаль оештыруның төбәк формаларын — технопаркларны, бизнес-инкубаторларны, укыту кластерларын һәм тармак өчен яңа технологияләр һәм кадрлар бирә торган башка формаларын булдыру һәм аларга ярдәм итү;

2030 елдан соң дөнья җәмәгатьчелеге альтернатив ягулык технологияләренә күчкән очракта, шулай ук төбәк икътисадының башка өлкәләренә синергетик тәэсир итү



мәнфәгатьләрендә эшчәнлекне диверсификацияләү, куркынычларны минимальләштерү максатларында ягулыкның альтернатив технологияләрен булдыруда катнашу.

Хәзерге вакытта «ТАИФ-НК» ААҖнең төп проекты булып Авыр калдыкларны тирән эшкәртү комплексы (алга таба — АКТЭК) төзелеше тора, аны гамәлгә керткәннән соң Россия Федерациясенең нефть эшкәртү сәнәгатенә дөньякүләм стандарттагы нәтиҗәле нефть эшкәртү производствосы өстәләчәк.

Әлеге киң колачлы, капитал таләп итүче стратегик проектның төп максаты — сыйфатның дөньякүләм һәм Европа таләпләренә туры килә торган ачык югары ликвидлы нефть продуктларын чыгаруны үстерүне тәэмин итеп, эретелгән югары күкертле мазут җитештерүне туктату. АКТЭКын проектлаганда ресурсларны сак тотуның алдынгы технологияләрен кертү, шулай ук НЭЗның проектлана торган һәм гамәлдәге объектларыннан әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметергә мөмкинлек бирүче чаралар эшләү күздә тотыла.

2016 елга планлаштырыла торган АКТЭКын эшләтә башлау белән нефть эшкәртү күләме кимендә 95 процент тәшкил итәчәк һәм нефть эшкәртү тулысынча диярлек калдыксыз булачак. АКТЭК эшләп чыгарачак барлык продукция яхшыртылган экологик сыйфатларга ия булачак: нафтада, автобензиннарда һәм дизель ягулыгында (10 ppm артык түгел), сыекландырылган углеводородлы газларда күкертнең аз булуы. Бу югары сыйфатлы һәм ликвидлы нефть продуктлары Татарстан Республикасында гына түгел, ә Россия Федерациясендә дә сатылачак, шулай ук экспортка чыгарылачак.

«ТАИФ-НК» ААҖнең яңа производстволарын төзү һәм гамәлдәгеләрен модернизацияләү буенча эре инвестиция проектларын тормышка ашыруны исәпкә алган перспективалы үсеш схемасы 10 нчы рәсемдә китерелде.




10 нчы рәсем. «ТАИФ-НК» ААЖдә житештерүне оештыруның перспективалы схемасы



«ТАНЕКО» комплексының этаплар буенча перспективалы үсеш схемасы 11 нче рәсемдә китерелде.

«ТАНЕКО» комплексын төзү проектын тормышка ашыруның чираттагы этаплары кысаларында акрынайтылган кокслау җайланмасын һәм нафтаны гидрочистарту җайланмасын проектлау һәм төзү алып барыла. 2015 елда әлеге җайланмаларны файдалануга кертү ягулык мазутын чыгаруны туктатырга, 77 процент дәрәҗәдә ачык төстәге нефть продуктларын сайлап алуны тәэмин итәргә һәм эшкәртү тирәнлеген 90 процентка җиткерергә мөмкинлек бирәчәк.

2016 – 2017 елларда каталитик риформинг һәм җиңел нафтаны изомеризацияләү җайланмаларын төзүне тәмамлау, киләчәктә исле углеводородлар алу комплексын эшләтеп җибәрү планлаштырыла. Әлеге җайланмалар җыелмасы югары сыйфатлы автомобиль бензиннары һәм бензол, параксилол кебек индивидуаль исле кушылмалар эшләп чыгарырга мөмкинлек бирәчәк.

«ТАНЕКО» комплексының беренче чиратының соңгы баскычында каталитик риформинг, керосинны һәм дизель ягулыгын гидрочистарту җайланмасын файдалануга кертү планлаштырыла, бу «Евро-5» иң югары экологик классындагы мотор ягулыгын житештеру күләмен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

2020 елга «ТАНЕКО» комплексында нефть эшкәртү күләмен елына 14 млн. тоннага кадәр арттыру буенча эшләр алып барыла. Яңа ЭЛОУ-АВТ-6 җайланмасын проектлау һәм төзү буенча эшләр башланган.

2030 елга «ТАНЕКО» комплексында, 14 млн. тонна нефть эшкәртүне исәпкә алып, түбәндәге товар продукциясен житештеру планлаштырыла:

нефть химиясе производстволары өчен сыекландырылган газлар;

реактив ягулык;

дизель ягулыгы (5 класс);

автомобиль бензины (5 класс);

бензол;

параксилол;

вакланган күкерт;

2 сСт нигез мае;

4 сСт нигез мае;

товар кокс.

2030 елга кадәр чорда нефть эшкәртүне үстерүнең карала торган сценариесендә Татарстан Республикасының барлык нефть эшкәртү производстволарында тагын да активрак инвестиция-инновация процессы күздә тотыла (инвестицияләр буенча мәгълүматлар 11 нче таблицада китерелде). Әлеге процесс

нигездә предприятиеләрнең үз чаралары хисабына финансланачак, һәм аның нәтиҗәсе, эшләп чыгаруның физик күләмнәрен арттырудан бигрәк, предприятиеләрнең үз көчләре белән, шулай ук Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка оешмалары тарафыннан да уйлап табыла торган яңа технологияләрне кертү хисабына гамәлдәге производстволарны техник яктан яңадан җиһазлаудан гыйбарәт булачак.

2020 елга республиканың нефть эшкәртү тармагының фәнни һәм технологик потенциалы конкурентлыкка сәләтле дәрәҗәгә җитәчәк дип көтелә, һәм үзебезнең яңа технологияләр турында экспортка чыгарырлык һәм импортны алыштырырлык продукт дип сөйләп булачак.

Тармак предприятиеләренең инвестиция программаларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасында нефть эшкәртү куәтләре 2014 елдагы 14 млн. тоннадан 22 млн. тоннага кадәр үсәчәк, моның белән бергә нефть продуктларын эшләп чыгару һәм экспортка чыгару күләмнәре артачак, шулай ук углеводород чималын эшкәртү буенча республика эчендәге кооперацияне алга таба үстерү кысаларында Татарстан Республикасы нефть химиясе предприятиеләренә нефть продуктларын һәм углеводородлы газлар китерү дә артачак (12 нче таблица).

11 нче таблица

Татарстан Республикасының нефть эшкәртү тармагын үстерүгә инвестицияләр күләме

| Күрсәткеч исеме/еллар | 1999-2009 | 2010-2013 | 2014-2015 | 2016-2020 | 2021-2025 | 2026-2030 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Нефть эшкәртү предприятиеләренең төп капиталына инвестицияләр күләме, млрд. сум | 140,5 | 202,8 | 119,9 | 58,3 | 6,9 | 7,1 |

*Татарстанстат мәгълүматлары һәм тармак предприятиеләре фаразы («ТАНЕКО» комплексын төзүнең икенче чиратын исәпкә алмыйча)*

12 нче таблица

«ТАИФ-НК» ААҖдә һәм «ТАНЕКО» комплексында эшкәртелә торган нефтьнең перспективалы күләме

| Күрсәткеч исеме/еллар | 2014 | 2015 | 2020 | 2025 | 2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| Эшкәртелә торган нефть күләме, млн. тонна шул исәптән: | 15,9 | 15,4 | 21,4 | 21,4 | 21,4 |
| «ТАИФ-НК» ААҖ | 7,4 | 7,4 | 7,4 | 7,4 | 7,4 |
| «ТАНЕКО» комплексы | 8,5 | 8,5 | 14,0 | 14,0 | 14,0 |

*Тармак предприятиеләренең фараз мәгълүматлары буенча*





11 нче рәсем. «ТАНЕКО» ААҖдә производстволарны оештыруның перспективалы схемасы

2030 елга кадәр перспективада Татарстан Республикасының нефть эшкәртү сәнәгате предприятиеләре чыгара торган төп товар продукция күләмнәре 13 нче таблицада китерелде.

13 нче таблица

Нефть эшкәртү тармагында төп товар продукция җитештерү

| Товар продукциясе исеме | 2015 | 2020 | 2025 | 2030 |
|---|---|---|---|---|
| Турыдан-туры куыла торган бензин/ БГС/Нафта, мең тонна | 3 680,9 | 3 738,3 | 2 506,3 | 2 506,3 |
| «ТАИФ-НК» ААҖ | 1 735,0 | 2 237,3 | 2 237,3 | 2 237,3 |
| «ТАНЕКО» комплексы | 1 945,9 | 1 501,0 | 269,0 | 269,0 |
| Автобензиннар, мең тонна | 570,0 | 2 401,0 | 3 741,0 | 3 741,0 |
| «ТАИФ-НК» ААҖ | 570,0 | 680,0 | 680,0 | 680,0 |
| «ТАНЕКО» комплексы | 0 | 1 721,0 | 3 061,0 | 3 061,0 |
| Дизель ягулыгы, мең тонна | 3 675,5 | 6 790,6 | 10 873,6 | 10 873,6 |
| «ТАИФ-НК» ААҖ | 2 325,6 | 4 039,6 | 4 039,6 | 4 039,6 |
| «ТАНЕКО» комплексы | 1 350,9 | 2 751,0 | 6 834,0 | 6 834,0 |
| Керосин/авиакеросин, мең тонна | 893,0 | 1 569,9 | 1 781,9 | 1 781,9 |
| «ТАИФ-НК» ААҖ | 404,0 | 628,9 | 628,9 | 628,9 |
| «ТАНЕКО» комплексы | 489,0 | 941,0 | 1 153,0 | 1 153,0 |
| Мазут, мең тонна | 3 893,7 | 2 047,2 | 1 541,0 | 0 |
| «ТАИФ-НК» ААҖ | 1 973,0 | 0 | 0 | 0 |
| «ТАНЕКО» комплексы | 1 920,7 | 2 047,2 | 1 541,0 | 0 |
| Күкерт, мең тонна | 102,0 | 291,6 | 374,6 | 374,6 |
| «ТАИФ-НК» ААҖ | 44,9 | 126,6 | 126,6 | 126,6 |
| «ТАНЕКО» комплексы | 57,1 | 165,0 | 248,0 | 248,0 |

*Тармак предприятиеләренең фараз мәгълүматлары буенча*

## 3.7. Газ тармагы

3.7.1. Татарстан Республикасында табигый газны куллану

Татарстан Республикасы Россиянең Идел буе регионында иң эре табигый газ кулланучыларның берсе булып тора. Табигый газ нигездә Татарстанның беренчел энергия ресурсларына ихтыяҗын тәэмин итә. Татарстан Республикасы кулланучыларына табигый газ сату мәсьәләләре буенча «Газпром» ААҖ белән күпьеллык тотрыклы хезмәттәшлек республиканың нәтиҗәле һәм динамикалы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Республика газ тармагының төп предприятиеләре түбәндәгеләр: «Газпром төбәкарагаз Казан» ЯАҖ – газ сату буенча махсуслашкан төбәк оешмасы, «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ – төбәк газ бүлү оешмасы һәм сыекландырылган углеводородлы газларны саклауны, күпләп һәм ваклап сатуны гамәлгә ашыручы «Газпром сыекландырылган газ» ҖЧҖ.

Табигый газны куллануның шактый зур күләмнәрен, аңа бәяләрнең даими үсеп торуын, газ базарында катнашучылар



саны артуын исәпкә алып, Татарстан Республикасында табигый газны нәтиҗәле куллану мәсьәләләренә зур әһәмият бирелә.

Татарстан Республикасында формалашкан энергияне сак тоту һәм энергия ресурслары нәтиҗәлелеге өлкәсендә законнар базасы кысаларында газны рациональ һәм нәтиҗәле куллануны тәэмин итү буенча зур тәҗрибә тупланган.

Республикада табигый газ китерүне һәм куллануны исәпкә алу һәм контрольдә тоту системасын камилләштерү буенча эшләр даими башкарыла. Татарстан Республикасында табигый газны кулланунын тагын да төгәлрәк исәпкә алынуын тәэмин итү өчен шартлар тудыру максатларында 2008 елда «Газпром» ААҖ, Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлык һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында табигый газ, сыеклаңдырылган табигый газ һәм газ конденсаты чыгымын һәм күләмен исәпләү чараларының эталон һәм сынау базасын камилләштерү буенча Хезмәттәшлек турында килешү имзаланды.

Сәнәгатьтә һәм энергетикада икътисадый үсеш темпларының тотрыклы югары динамикасы булганда, газны рациональ куллануны тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар нәтиҗәсендә республикада газны уртача еллык куллану 2000 елдан алып 2013 елга кадәрге чорда 14,5 млрд. куб метр дәрәҗәсендә саклана.

Газ куллануның төп күләме энергетикага һәм торак-коммуналь хуҗалыкка туры килә – 2013 ел йомгаклары буенча республика эчендә куллануның 69,1 проценты. 2000 елдан алып 2013 елга кадәрге чорда энергетикада һәм торак-коммуналь хуҗалыкта куллану күләмнәре 3,6 процентка кимегән.

Энергетикада кулланыла торган ягулык-энергетика ресурслары балансында газга туры килә торган өлешнең югары булуы аның, башка энергия чыганаклары белән чагыштырганда, бәя, ягулык һәм экология ягыннан өстенлекләре белән аңлатыла. Шулай, республиканың иң эре энергетика компанияләренең («Генерирлау компаниясе» ААҖ, «ТГК-16» ААҖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ААҖ, «ТГК Урыссу ГРЭС» ЯАҖ) ягулык балансында табигый газ өлеше 99 процент тәшкил итә.

2000 елдан башлап газ кулланучы халык саны шул ук дәрәҗәдә калган дияргә була: 2000 елда – 13,7 процент, 2013 елда – 13,1 процент.

Бюджет оешмалары тарафыннан куллану, 2000 ел белән чагыштырганда, 2013 елда 3,3 тапкырга кимегән. Шул рәвешле куллануның гомуми күләмендә әлеге төркемнең чагыштырма авырлыгы 2,2 процenttан 0,7 процентка кадәр үзгәргән.

Шул ук вакытта җитештерү үсешенең тотрыклы югары темпларын тәэмин иткән сәнәгать комплексы өчен газ куллануның

сизелерлек уңай динамикасы хас иде, 2000 ел белән чагыштырганда, 2013 елда арту 1,4 тапкырга булган. Күрсәтелгән чорда гомумреспублика күләмендә сәнәгатьтә газ куллану 12 проценттан 17 процентка кадәр арткан.

Халыкны, торак-коммуналь һәм социаль комплексларны тәэмин итү өчен дә, шулай ук сәнәгатьтә стратегик проектларны тормышка ашыру өчен дә табигый газга өстәмә ихтыяҗ барлыкка килү Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенең уңай динамикасы нәтиҗәсе булып тора.

Шул ук вакытта сәнәгатьтә газ куллануның алга китеп үсү тенденциясе 2030 елга кадәр фаразлана торган чорда сакланып калачак.

Табигый газ нефть-газ химиясе сәнәгате өчен кыйммәтле чимал булып тора, аны үстерү Татарстан Республикасы икътисады өчен дә, шулай ук тулаем алганда Россия Федерациясе икътисады өчен дә көчле импульс бирергә мөмкин.




**12 нче рәсем. Татарстан Республикасында табигый газны куллану динамикасы һәм фаразы**

Газны ягулык буларак куллanудан чимал максатларында куллануга күчерү тагын да югарырак өстәмә бәяле производствоның үсүен тәэмин итәчәк, республика бюджеты керемнәрен тулыландырырга, өстәмә эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Илкүләм конкурентлыкка сәләтлелек нигезләрен формалаштыру, чимал экспортына бәйлелекне бетерү һәм Татарстан Республикасының үз эчендә Түбән Кама, Әлмәт, Менделеевск



сәнәгать районнарын, Чаллы шәһәрен һәм «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын алган Түбән Кама сәнәгать үзәгендә нәтиҗәле яңа предприятиеләр булдыру буенча бурычларны үтәү өчен углеводород чималын чыгару һәм эшкәртү процессларын камилләштерүгә юнәлдерелгән киң колачлы проектлар тормышка ашырыла.

Күрсәтелгән проектларга Менделеевск шәһәрендәге Аммиак, метанол һәм вакланган карбамид җитештерү комплексын; «ТАИФ-НК» ААҖнең нефть эшкәртү заводының Авыр калдыкларны тирәнтен эшкәртү комплексын; «ТАНЕКО» комплексын төзү проектлары; Ашалчы нефть-битум чыганагыннан яңа җылыту алымнарын кулланып чыгару керә.

Газның сәнәгатьтә кулланылуы арту белән бергә яңа кулланучыларны энергия белән ышанычлы тәэмин итү өчен республиканың энергетика комплексының табигый газга да ихтыяҗы артачак.

Әгәр сәнәгатьтә табигый газ куллануның, яңа җитештерү куәтләрен төзү һәм гамәлдәгеләрен модернизацияләү буенча республика предприятиеләре проектларын исәпкә алсак, 3,3 тапкырга арту ихтималы булса, электр энергетикасы һәм коммуналь өлкә, халык һәм бюджет оешмалары өчен 2030 елда газ куллану артымы, 2013 ел белән чагыштырганда, иң күбе 30 процент булачак.

Тулаем алганда, республикада газ куллану 2030 елга, 2013 ел белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга артыр дип фаразлана.

3.7.2. Татарстан Республикасын газлаштыру

Газлаштыру күрсәткечләре буенча Татарстан Республикасы Россия төбәкләре арасында әйдәп баручы урынны алып тора. Татарстан Республикасын газлаштыру дәрәҗәсе 99 процентка җитә, шул ук вакытта газлаштыруның шәһәр һәм авыл торак пунктлары өчен бер үк дәрәҗәдә югары күрсәткечләргә ия булуы Татарстанга хас үзенчәлек булып тора. Газлаштырылган фатирларның һәм индивидуаль торак йортларның гомуми саны 1,39 миллионга җитә. Республикада ел саен уртача 19 мең фатир газлаштырыла (13 нче рәсем).




**13 нче рәсем. Татарстан Республикасында газлаштыру дәрәҗәсе һәм газлаштырылган фатирлар саны**

Социаль өлкәне тәэмин итү белән бәйле перспективалы мәсьәләләрне хәл итү өчен республикада социаль-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны һәм торак фонды объектларын газлаштыру буенча даими эш алып барыла. 2006 елдан башлап газ бүлүче челтәрләр буенча газ китерү хезмәтләрен күрсәтүнең Тарифлар буенча федераль хезмәт белән килешенеп билгеләнә торган тарифына махсус өстәмә бәя Татарстан Республикасында газлаштыру буенча эшләрне финанслауның төп чыганагы булып тора. Газ бүлүче челтәрләр буенча газ китерү хезмәтләрен күрсәтү тарифына махсус өстәмә бәя хисабына финанслана торган газлаштыру программалары буенча чыгымнарның суммар күләме 2006 елдан алып 2014 елга кадәрге чорда 1748 млн. сум тәшкил итә.

Газлаштыруны алга таба үстерү буенча эшләр торак һәм социаль инфраструктура объектларын төзүне, шулай ук сәнәгать предприятиеләренең ихтыяҗлары артуны исәпкә алып дәвам ителәчәк.

Татарстан Республикасының газ хуҗалыгында 5,6 мең км магистраль газүткәргечләр һәм кулланучыга тоташтыручы газүткәргечләр, шулай ук 38,7 мең км бүлүче газүткәргечләр файдаланыла.

Республикада гамәлгә ашырыла торган киң колачлы инвестиция проектларын табигый газ белән тәэмин итү өчен газ транспортлау куәтләрен үстерүгә ярдәм итү эшчәнлекнең мөһим юнәлеше булып тора.



2014 елда «Газпром промгаз» ААҖ белән берлектә Татарстан Республикасын газ белән тәэмин итүнең һәм газлаштыруның генераль схемасы әзерләнде.

Татарстан Республикасында табигый газга ихтыяҗның сценарияле фаразы 2020 елга кадәрге чорга төбәк инвестиция проектларының тормышка ашырылу ихтималын исәпкә алып эшләнде. Түбән Кама сәнәгать үзәге территориясендә газ транспортлау куәтләрен төзү проекты «Газпром» ААҖнең инвестиция программасына кертелде, ул «Газпром» ААҖ хисабына финансланачак. «Газпром» ААҖнең профильле структуралары тарафыннан проект алды әзерлеге башкарыла һәм газүткәргеч үтү трассасы сайлана.

Татарстан Республикасының Кама аръягы зонасын һәм Казан шәһәрен газ белән ышанычлы һәм өзлексез тәэмин итү максатларында, 2030 елга кадәрге чорга перспективалы үсешне исәпкә алып, «220 – 285 км участогында Миңлебай – Казан газүткәргечен реконструкцияләү» проекты тормышка ашырыла. Әлеге газүткәргечне файдалануга кертү аның үткәрү сәләтен хәзерге елына 2,3 млрд. куб метрдан 5 млрд. куб метрга кадәр арттырырга мөмкинлек бирәчәк. 2012 – 2013 елларда 72,2 км газүткәргеч, өч электрохимик коррозиядән саклау станциясе һәм газ үлчәү үзәге төзелде. Эшләр 2015 елда да дәвам итте.

«Газпром» ААҖнең инвестиция программасы кысаларында «Иннополис» инновацион үзәге өчен газ инфраструктурасын төзү буенча эшләр башкарыла.

Хәзерге вакытта республиканың газ транспортлау системасының үткәрү сәләте кайбер участокларда үзенең максимумына җитте, бу аңа яңа кулланучыларны тоташтыруны чикли.

Татарстан Республикасында газ транспортлау системасын киләчәктә үстерү максатларында «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ тарафыннан 2030 елга кадәр магистраль газүткәргечләрнең, кулланучыга тоташтыручы газүткәргечләрнең, газ бүлү станцияләренең реконструкцияләү һәм яңаларын төзү объектларының өстенлекле исемлеге әзерләнде.

Югарыда санап кителгән объектларны төзү республиканың газ транспортлау системасы куәтен арттырырга һәм аңа потенциаль кулланучыларны тоташтыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

### 3.7.3. Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгын куллану

Татарстан Республикасында газ мотор ягулыгын төп кулланучы – республиканың автотранспорт комплексы.

Автомобиль транспорты өчен традицион нефть төрләре

урынына газ мотор ягулыгын куллану Татарстан Республикасында экология шартларын яхшырту өчен аерым әһәмияткә ия. Табигый газ бәясенең ягулыкның традицион төрләре бәясенә караганда түбәнрәк булуы аны куллану нәтиҗәсендә транспорт хезмәтләре күрсәтү бәясен төшерергә дә мөмкинлек бирә.

Транспорт комплексында газ мотор ягулыгын куллануны киңәйтү өчен республика территориясендә автомобильләргә газ салу станцияләре челтәре булдыру зарур.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә 11 автомобильгә газ тутыру компрессор станциясе (алга таба – АГТКС) урнашкан, берсенең эшчәнлеге вакытлыча туктатылган. АГТКСнең уртача еллык йөкләнеше проект куәтенең 10 – 12 процент тәшкил итә.

Барлык АГТКС «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнә карый.

Республика транспорт оешмаларына ярдәм итү максатларында «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ түбәндәге мөмкинлекләргә ия:

гамәлдәге АГТКСдә газ баллонлы автотранспортны һәм газ салучы күчмә автомобильләрне тәүлек буе өзлексез газ салу белән тәэмин итү;

компримирланган табигый газда (алга таба – КТГ) эшләү өчен автотехниканы яңадан җиһазлау буенча, автомобильләрнең газ баллонлы җайланмаларына техник хезмәт күрсәтү һәм төзекләндерү буенча, газ баллоннарын яңадан таныклау буенча, ягулык сыйфатында КТГ кулланыла торган автомобильләрдә эшләү өчен йөртүчеләрне әзерләү буенча килешү нигезендә хезмәт күрсәтү.

Татарстан Республикасын тулысынча газлаштыру һәр торак пунктында АГТКС урнаштырырга мөмкинлек бирә, нәтиҗәдә автомобиль хуҗалары экологик чиста һәм икътисадый яктан отышлы мотор ягулыгы – КТГ белән тәэмин ителә.

Хәрәкәт башлана торган, урта һәм соңгы пунктларда АГТКС булган шәһәрара ташуларны башкарганда, шулай ук АГТКС булган шәһәр эче маршрутларында йөргәндә газ баллонында йөри торган автотехникадан, шул исәптән газ мотор ягулыгында эшли торган пассажир автобусларыннан файдалану максатка ярашлы була.

Табигый газны җитештерү, сату һәм куллану өчен шартлар тудыру максатларында 2013 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте, «Газпром» ААҖ һәм «Газпром газ мотор ягулыгы» ҖЧҖ арасында Мотор ягулыгы сыйфатында табигый газны куллануны киңәйтү турында килешү төзелде.

Татарстан Республикасы Россиядә газ мотор ягулыгы базарын үстерү буенча Россия Федерациясенең пилот төбәкләренең



берсе итеп билгеләнде. Казан шәһәрендә әлеге эштә «Газпром» ААҖнән вәкаләтле оешма – «Газпром газ мотор ягулыгы» ҖЧҖ филиалы ачылды.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең профильле башкарма органнары, «Газпром газ мотор ягулыгы» ҖЧҖ, «КАМАЗ» ААҖ (техника җитештерүче), «РариТЭК» ҖЧҖ (техниканы метан куллануга үзгәртеп җиһазландыручы рәсми дилер), «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ катнашында республикада газ мотор ягулыгы базарын үстерүне күздә тоткан уртак карарлар әзерләнә. Татарстан Республикасының тиешле дәүләт программасы кабул ителде һәм тормышка ашырыла.

Программа кысаларында инде 2013 елда ук (программаның беренче этабында) республика предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан газ мотор ягулыгында эшләүче 1,1 мең данә автомобиль һәм махсус техника чаралары сатып алынды, 2014 – 2018 елларга (икенче этапта) КТГда эшли торган 5 мең берәмлектән артык автотранспорт чарасы сатып алу, 31 АГТКС һәм 65 бүлендек АГТКС төзү планлаштырыла.

2019 елдан алып 2023 елга кадәрге чорда (өченче этапта) КТГда эшли торган 8,8 мең берәмлек автотранспорт чарасы сатып алу, 29 АГТКС һәм 85 бүлендек АГТКС төзү планлаштырыла.

Шул ук вакытта газ баллонында йөри торган метанда эшләүче автомобиль техникасының киң спектрын (автобуслар, коммуналь, төзелеш һәм махсус, авыл хуҗалыгы техникасы) уйлап табу һәм җитештерү «КАМАЗ» ААҖ һәм «РариТЭК» ҖЧҖ тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында мотор ягулыгы сыйфатында табигый газ куллануны алга таба киңәйтү максатында 2014 елның июнендә Теләче муниципаль районы территориясендә сыекландырылган табигый газ җитештерү, саклау һәм тарату буенча елына 112 мең тоннага кадәр үстерү мөмкинлеге белән елына 56 мең тонна куәтле комплекс төзелә башлады. Сыекландырылган табигый газны кулану, КТГ икътисадый һәм экологик өстенлекләрен саклап, бер тапкыр ягулык салудан автомобильнең йөрүен өч тапкырга арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Әмма кулланучыларның газ мотор ягулыгын куллануда кызыксындырырлык федераль норматив хокукый база булмау аны куллануны киңәйтүне тыеп торучы фактор булып тора.

2013 елга кадәр Россиядә газ мотор ягулыгын куллануны стимуллаштыруның бердәнбер чарасы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарыннан гыйбарәт, аның нигезендә КТГ чик сату бәясе АИ-76 маркалы бензин бәясенең 50 процентыннан артык булмаган күләмендә билгеләнгән. Ә АИ-76 маркалы бензинны җитештерү туктатылуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе

Энергетика министрлыгы тарафыннан КТГ җибәрү бәясенең чик күрсәткечен дизель ягулыгы бәясенең 50 процентыннан артык булмаган күләмендә билгеләү турында карар әзерләнгән (Россия Федерациясе Хөкүмәте карары проекты).

Шул ук вакытта Россиядә газ мотор ягулыгы базарының динамик үсеше өчен дәүләт ярдәменең чаралар комплексын күздә тоткан федераль законнарны алга таба үстерергә кирәк. Аларда, иң элек, транспортны газ мотор ягулыгына күчергәндә автопредприятиеләр өчен салым ташламалары, түләүләрдән һәм пошлиналардан азат итү, газ мотор ягулыгы сатып алуларын федераль дәрәҗәдә субсидияләү, максатчан төбәк программалары каралган булырга тиеш. Ягулыкның әлеге төрен киң куллану автомобиль ташуларының үзкыйммәте кимүгә китерәчәк, һәм, нәтиҗә буларак, төбәкләр һәм тулаем алганда Россия икътисадының югары тизлек белән үсүенә ярдәм итәчәк.

3.7.4. Татарстан Республикасында җир асты газсаклагычын төзү

Җир асты газсаклагычлары (алга таба – ҖАГС) – Россиянең газ белән тәэмин итү буенча бердәм системасының аерылгысыз өлеше ул. Алар газны төп кулланучылар урнашкан төбәкләрдә тупланган. Аларны куллану газның төрле сезоннарда төрле күләмнәрдә кулланылуын җайга салырга, аны китерү ешлыгын һәм күләмнәрен үзгәртергә һәм аларның ышанычлылыгын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Аерым чорларда табигый газ җитмәү белән бәйле экстремаль вәзгыятьләр килеп туа. Беренче чиратта ягу чорында температура кинәт түбән төшү вакытында газ кытлыгы барлыкка килә. Газ белән тәэмин итү буенча гадәттән тыш хәлләр Татарстан Республикасы территориясендә, шулай ук аннан читтә урнашкан магистраль һәм бүлү газүткәргечләрендә һәлакәтләр вакытында да килеп туарга мөмкин.

Газ сәнәгатен үстерүнең «Газпром» ААҖ гамәлгә ашыра торган, шул исәптән эчке ихтыяҗларны тотрыклы, өзлексез һәм икътисадый нәтиҗәле канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән бурычлары нигезендә 2005 елдан башлап Татарстан Республикасы территориясендә ҖАГС төзү буенча эшләр алып барыла.

Татарстан Республикасында ҖАГС төзү буенча проект «Газпром» ААҖнең 2012 – 2015 елларга Россия Федерациясе территориясендә җир асты газсаклагычлары системасы объектларын төзү, реконструкцияләү һәм файдалануга кертү буенча инвестиция программасына кертелгән.

Зарур булган тикшеренү һәм геологик тикшерү эшләре комплексын үткәргәннән соң, ҖАГС төзү өчен Алексеевск районының Чистай районы белән чиктәш җирендәге мәйданчык (Арбузов ҖАГС) сайланды. ҖАГС урнашу урынының республиканың географик үзәгендә булуы газны газсаклагычтан Казан шәһәре ягына таба, шулай ук нефть-газ химиясе тармагының гигантлары – «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ, «ТАНЕКО» комплексы, «Түбән Кама шин» ААҖ тупланган тиз үсүче Түбән Кама сәнәгать үзәге кулланучыларына транспортлауның иң отышлы логистикасын тәэмин итә.

Республика ҖАГСның проект куәте – 1 млрд. куб метрдан артык, 2015 елда объект буенча проект эшләре алып барыла. Экспертизалар үткәргәннән соң 2015 – 2016 елларда ҖАГС төзелеше башланачак, «Газпром» ААҖ планнары буенча, 2018 елга ҖАГС коллекторы ятмасына газны тутырып карау гамәлгә ашырылачак.

Республика территориясендә ҖАГС төзү буенча проектны тормышка ашыру газның төрле сезоннарда төрле күләмнәрдә кулланылуын җайга салырга, аны китерү ешлыгын һәм күләмнәрен үзгәртергә һәм аларның ышанычлылыгын тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

## IV. Татарстан Республикасы энергетика тармагы

### 4.1. Татарстан Республикасы энергетика тармагының бүгенге хәле

Татарстан Республикасы энергосистемасы Самара, Киров, Ульяновск, Оренбург өлкәләре һәм Марий Эл, Чуваш, Удмурт, Башкортостан республикаларының энергетик системалары белән чиктәш.

Республиканың энергосистемасы 3,8 млн. халкы булган 68 мең кв. км мәйданны биләп тора.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы энергосистемасында дүрт электр һәм җылылык энергиясен җитештерүче – «Генерирлау компаниясе» ААҖ, «ТГК-16» ААҖ, «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ һәм «ТГК Урыссу ГРЭС» ЯАҖ катнаш эшләп чыгару режимында эшли.

Барлык дүрт компания электр энергиясе һәм куәтенең күпләп сату базары (алга таба – ЭЭКСБ) субъекты статусына ия һәм аның сәүдә системасына керә ала. Шуңа күрә эшләп чыгарыла торган энергиянең конкурентлыкка сәләтлелеге һәм ЭЭКСБ һәм электр энергиясенең ваклап сату базарында ихтыяҗ станцияләр җиһазларының техник торышына, аларның заманча энергия нәтиҗәлелеге таләпләренә туры килүенә нык бәйле.

2015 елның 1 гыйнварына энергосистеманың билгеләнгән электр куәте –7056 МВт, җылылык куәте 15283 Гкал/сәг. тәшкил итә, компанияләр буенча мәгълүмат 14 нче таблицада китерелде.

14 нче таблица

Компанияләр һәм станцияләрнең Татарстан Республикасы энергосистемасында билгеләнгән электр һәм җылылык куәте

| Электр станциясе исеме | Билгеләнгән куәт | |
|---|---|---|
| | электр, МВт | җылылык, Гкал/сәг. |
| «Генерирлау компаниясе» ААҖ, шул исәптән | 5215 | 7933 |
| Казан ТЭЦ-1 | 220 | 630 |
| Казан ТЭЦ-2 | 410 | 991 |
| Чаллы ТЭЦ | 1 180 | 4 092 |
| Алабуга ТЭЦ | – | 420 |
| Түбән Кама ГЭС | 1 205 | – |
| Зәй ГРЭС | 2 200 | 110 |
| Азино пар казаннары бинасы | – | 360 |
| Горки пар казаннары бинасы | – | 200 |
| КЦ БСИ | – | 540 |
| Савиново пар казаннары бинасы | – | 590 |
| «ТГК-16» ААҖ, шул исәптән | 1 300 | 5 643 |
| Казан ТЭЦ-3 | 420 | 1 897 |
| Түбән Кама ТЭЦ (ПТК-1) | 880 | 3 746 |
| «Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ, шул исәптән | 380 | 1 580 |
| Түбән Кама ТЭЦ (ПТК-2) | 380 | 1 580 |
| «ТГК Урыссу ГРЭС» ЯАҖ | 161 | 127 |
| Урыссу ГРЭС | 161 | 127 |

Электр энергиясен тапшыру электр челтәрләре компанияләре челтәрләре буйлап гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында иң эре электр челтәре оешмасы булып «Челтәр компаниясе» ААҖ тора. 2015 елның 1 гыйнварына республикада шулай ук 52 чиктәш челтәр оешмасы эшли иде.

«Челтәр компаниясе» ААҖ филиаллары тарафыннан 18142 подстанция (алга таба – ПС) файдаланыла, шул исәптән 35-500 кВ көчәнешле 374 подстанция, 6 (10) кВ көчәнешле 17768 бүлү подстанциясе (алга таба – БП) һәм трансформатор подстанцияләре (алга таба – ТП). 35-500 кВ көчәнешле подстанцияләрдә гомуми йөкләнешләре 18303,3 МВА булган көч трансформаторлары (алга таба – КТ) эшли.

0,4-500 кВ көчәнешле һава линияләренең (алга таба – ҺЛ) гомуми озынлыгы – 58712,2 км, 0,38-110 кВ көчәнешле кабельле электртапшыргыч линияләрнең гомуми озынлыгы 8724,2 км тәшкил итә.



Татарстан Республикасы энергосистемасы Урта Идел Берләшкән энергетика системасының электр куллануның территориаль структурасында иң эреләреннән, ул электр энергиясен суммар куллануда иң зур чагыштырмача авырлыкка ия – 24,7 процент, һәм фараз чорында әлеге күрсәткеч җитди үзгәрешләр кичермәячәк.

*Казан энергорайоны*

Казан энергорайоны үтә дефицитлы булып тора. 2014 елда энергорайонның кышкы (җәйге) максимумнарында куллану 1299/992 МВт булды, шул ук вакытта әлеге чорда генерирлау 550/171 МВт тәшкил итә.

Казан энергорайонын электр белән тәэмин итү өч электр станциясеннән гамәлгә ашырыла: Казан ТЭЦ-1, Казан ТЭЦ-2, Казан ТЭЦ-3, ә җитешмәгән егәрлек 500 һәм 220 кВ көчәнешле транзит ҺЛ буенча бирелә.

Казан энергорайонының электр энергиясен төп кулланучыларына нефть химиясе сәнәгате, авиатөзелеш, мотор төзү, судно төзү, коммуналь-көнкүреш секторы һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре керә.

*Түбән Кама энергорайоны*

Түбән Кама энергорайоны дефицитлы булып тора. Энергорайонның кышкы (җәйге) максимумнарында куллану 1715/1433 МВт була, шул ук вакытта әлеге чорда генерирлау 1473/953 МВт тәшкил итә.

Түбән Кама энергорайонын электр белән тәэмин итү өч электр станциясеннән гамәлгә ашырыла: Түбән Кама ТЭЦ (ПТК-1), Түбән Кама ТЭЦ (ПТК-2), Чаллы ТЭЦ, ә җитешмәгән егәрлек 220 һәм 110 кВ көчәнешле транзит ҺЛ буенча бирелә.

Түбән Кама энергорайонының электр энергиясен төп кулланучыларына сәнәгать предприятиеләре, шул исәптән нефть химиясе, нефть эшкәртү, нефть чыгару, автомобиль төзү, авыл хуҗалыгы һәм коммуналь-көнкүреш секторы предприятиеләре керә.

*Урыссу энергорайоны*

Урыссу энергорайоны дефицитлы булып тора. Энергорайонның кышкы (җәйге) максимумнарында куллану 768/601 МВт була, шул ук вакытта әлеге чорда генерирлау 463/410 МВт тәшкил итә.

Энергорайонда 500-220-110 кВ бүлү җайланмасы белән Бөгелмә-500 ПС һәм 161 МВт егәрлекле Урыссу ГРЭС эшли. Урыссу энергорайонын электр белән тәэмин итүне Урыссу ГРЭС гамәлгә ашыра, ә Бердәм энергетика системасы һәм Татарстанның

Региональ диспетчер идарәсенең операцион зоналарының башка энергорайоннары белән элемтә (алга таба – РДИ ОЗ) ҺЛ-500-220-110 кВ буенча гамәлгә ашырыла.

Урыссу энергорайонының электр энергиясен төп кулланучыларына нефть чыгару һәм нефть химиясе сәнәгате, коммуналь-көнкүреш секторы һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре керә.

Урыссу энергорайонының актив егәрлегенең җитешмәве арта бару үзенең электр кулланулы һәм электр энергиясен перспектив кулланучыларның артуы белән аңлатыла.

*Буа энергорайоны*

Буа энергорайоны дефицитлы булып тора. Энергорайонның кышкы (җәйге) максимумнарында куллану 82/48 МВт була, шул ук вакытта әлеге районда генерирлау чыганаклары юк.

Буа энергорайонында 220-110 кВ бүлү җайланмасы белән белән Студенец ПС эшли. Буа энергорайонын электр белән тәэмин итү 220 кВ көчәнешле Канаш-Студенец (I һәм II чылбыр) ҺЛ буенча Чуваш ЭСнең Канаш ПСнән һәм 110 кВ көчәнешле Төрләмә – Бишбатман ҺЛ буенча Чуваш ЭСнең Төрләмә ПСнән гамәлгә ашырыла, ә ЕЭС һәм Татарстан РДИ ОЗ башка энергорайоннары белән элемтә 110 кВ көчәнешле ҺЛ буенча башкарыла.

Буа районында төп сәнәгать кулланучыларына азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы сәнәгате предприятиеләре керә.

Татарстан энергетика тармагының төп проблемалы мәсьәләләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

2015 елның 1 гыйнварына «Челтәр компаниясе» ААҖнең төп производство фондларының (электртапшыргыч линияләр, трансформаторлар) физик таушалуы 57 процент тәшкил итә, СН1 (35 кВ) көчәнешле электр тапшыру линияләре буенча таушалганлык 67 процентка җитә. Моның белән бергә «Челтәр компаниясе» ААҖ челтәрләре буенча транспортлау барышында электр энергиясен югалтулар 2009 елдагы 9,5 проценттан 2013 елда 7,2 процентка кадәр кимеде. «Челтәр компаниясе» ААҖ челтәрләрендә югалтулар дәрәҗәсе илдә иң түбәннәренең берсе булуга карамастан, әлеге күрсәткеч сәнәгать ягыннан алга киткән илләрдәге челтәр югалтулары күрсәткечләренә караганда (4 – 5 процент) югарырак.

Генерирлау объектлары буенча төп производство фондларының иң күп физик таушалуы Урыссу ГРЭС буенча – 84,4 процент, «Түбән Кама ТЭЦ» ААҖ буенча 58,4 процент тәшкил итә. Мондый хәл зур капитал кертемнәре таләп ителүгә, энергетика объектларын модернизацияләүнең үз-үзен аклау вакытының озын булуына бәйле.



Татарстан Республикасыннан читтә йөкләнеш бирү турында килешүләр программасы буенча яңа генерирлау куәтләре күпләп төзелү белән бергә республика энергетика объектларының генерирлау куәтләренең таушалуы һәм мораль яктан картаюы электр энергиясе һәм куәтләренең күпләп сату базарында Татарстан энергетика компанияләренең конкурентлыкка сәләте кимүгә һәм киләчәктә иске станцияләрне эксплуатацияләүдән чыгаруга китерә. Шулай, 2019 елга Татарстан Республикасында станцияләрдә суммар куәте 2804 МВт булган генерирлау җиһазларын файдаланудан алу планлаштырыла, шул исәптән «Генерирлау компаниясе» ААҖ объектларында – 2610 МВт: Казан ТЭЦ-2 – 190 МВт (2017 ел), Казан ТЭЦ-1 – 220 МВт (2018 ел), Зәй ГРЭС – 2200 МВт (2018 ел), «ТГК Урыссу ГРЭС» ЯАҖ – 161 МВт (2018 ел), «ТГК-16» ААҖ – 33 МВт (Казан ТЭЦ-3).

Шулай да, күрсәтелгән проблемаларга карамастан, Татарстан Республикасы энергосистемасы төп бурычны – кулланучыларны электр һәм җылылык энергиясе белән ышанычлы һәм өзлексез тәэмин итүне хәл итә ала.

4.1.1. Электр һәм җылылык энергиясен җитештерү һәм куллану структурасы

Татарстан Республикасында электр энергиясен эшләп чыгару нигездә җылылык һәм конденсацион электр станцияләрендә гамәлгә ашырыла. Гидроэлектростанция өлешенә (Түбән Кама ГЭС) эшләп чыгаруның 7 – 8 проценты туры килә.

2014 елда республикада 21,5 млрд. кВт/сәг. электр энергиясе эшләп чыгарылган, бу 2009 ел белән чагыштырганда бер процентка кимрәк.



**14 нче рәсем. Татарстан Республикасы электр станцияләренең электр энергиясен эшләп чыгару структурасы**

Соңгы елларда станцияләр тарафыннан электр энергиясен эшләп чыгаруның кимүе күзәтелә, бу, республикадан читтә заманча технологияләрне актив рәвештә гамәлгә керткәндә, республикада электр энергиясенең заманча чыганаклары тиешенчә файдалануга кертелмәү аркасында республика генерирлавының конкурентлылык сәләте төшү белән аңлатыла.

Татарстан Республикасында электр энергиясен эчке куллану күләме 2009 елдан 2014 елга кадәрге чорда 3,3 млрд. кВт/сәг., ягъни 13 процентка арткан. Электр энергиясен куллануның артуы республиканың машина төзелеше, нефть химиясе, нефть чыгару кебек энергияне күпләп куллана торган тармакларында җитештерү үсү белән аңлатыла.

Карап тикшерелә торган чорда куллланучылар төркемнәре киселешендә электр энергиясен куллану структурасының үзгәрүе күренә. 2014 ел йомгаклары буенча куллланучыларның түбәндәге төркемнәре буенча электр энергиясенең күп кулланылуы күзәтелә:

химия, нефть химиясе – 24,4 процент (2009 ел белән чагыштырганда 5 процентка арткан);

бүтән куллланучылар – 19,2 процент (2009 ел белән чагыштырганда 8 процентка кимегән);

нефть чыгару – 17,7 процент (2009 ел дәрәҗәсендә);

халык һәм торак-коммуналь хуҗалык – 14 процент (2009 ел дәрәҗәсендә).






**15 нче рәсем. 2009 һәм 2014 елларда Татарстан Республикасында электр энергиясен куллану динамикасы**




**16 нчы рәсем. 2009 һәм 2014 елларда Татарстан Республикасында электр энергиясен куллану структурасы**

2014 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында катнаш җитештерү режимында эшләп чыгарыла торган җылылык энергиясен җибәрү 34,3 млн. Гкал тәшкил иткән, бу 2009 елга карата 14,3 процентка артыграк.




**17 нче рәсем. 2009 – 2014 елларда Татарстан Республикасында җылылык энергиясен җибәрү динамикасы**

4.1.2. Электр һәм җылылык энергиясен җитештерү һәм куллану фаразы

Татарстан Республикасында сәнәгать җитештерүе үсүгә бәйле рәвештә киләсе елларда да электр энергиясен куллануның артуы планлаштырыла: 2014 ел белән чагыштырганда, 2020 елда – 9,1 процентка, 2025 елда – 15,8 процентка, 2030 елда – 23,2 процентка. Шулай булгач, энергосистеманың иң югары йөкләнешләре дә артачак (2030 елга 4699 МВт, бу 2013 ел күрсәткеченнән 688 МВт югары).




**18 нче рәсем. 2015 – 2030 елларда Татарстан Республикасында электр энергиясен куллану динамикасы фаразы**






**19 нчы рәсем. 2015 – 2030 елларда Татарстан Республикасында еллык иң югары йөкләнешләр динамикасы фаразы**




**20 нче рәсем. 2020 – 2030 елларда Татарстан Республикасында электр энергиясен куллану структурасы фаразы**

Үсеш темпларын ел саен тизләтә бару һәм, нәтиҗә буларак, электр энергиясенең һәм куәтенең кулланучылар тарафыннан кулланылуы арта бару сәбәпле Татарстан Республикасына энергетика куәтләрен арттырырга кирәк.




21 нче рәсем. 2013 – 2030 елларда Татарстан Республикасында электр энергиясен эшләп чыгару фаразы




22 нче рәсем. 2013 – 2030 елларда Татарстан Республикасында җылылык энергиясен җибәрү фаразы



Сәнәгатьтә җитештерү күләмнәре үсүгә карамастан, кулланучыларга җылылык энергиясен җибәрү дәрәҗәсе акрын үсә, бу эре сәнәгать компанияләренең энергияне сак тоту буенча киң колачлы чаралар кертүе белән бәйле.

Перспективада катнаш эшләп чыгару шартларында җылылык энергиясен җитештерүне арттырырга кирәк.

## 4.2. Татарстан Республикасы энергия системасын үстерүнең төп юнәлешләре

Татарстан Республикасы электр энергетикасын үстерүнең стратегик максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасының барлык кулланучыларын электр һәм җылылык энергиясе белән ышанычлы тәэмин итү;

яңа заманча технологияләр базасында энергетика тармагының кокурентлыкка сәләтен арттыру һәм тотрыклы үсешен тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын киметү.

Әлеге максатларны гамәлгә ашыру өчен иң мөһиме – энергия системасының җитештерү объектларын модернизацияләү.

Татарстан Республикасы энергия системасын модернизацияләүнең төп принциплары:

электр һәм җылылык энергиясен катнаш җитештерүне, ягулыкның чагыштырмача чыгымнарын киметүне тәэмин итә торган, шулай ук гамәлдәге газ казаннары биналарын иң югары җылылык йөкләнеше булган зоналарга кысрыклап чыгарып, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметә торган объектларга өстенлек бирү;

җылылык белән үзәкләштерелгән тәэмин итү системаларын максималь өстенлекле куллану;

электр энергиясен һәм куәтен күпләп сату базарында электр энергиясенең һәм куәтенең конкурентлыкка сәләтен тәэмин итү;

ягулыкның кулланыла торган төрләрен дифференциацияләү;

республикада электр куәтләренә кытлыкны бетерү;

кулланучыларны электр белән ышанычлы тәэмин итүне булдыру;

электр челтәрләренә технологик тоташу мөмкинлеген булдыру өчен Татарстан Республикасы шәһәрләрен һәм районнарын электр белән тәэмин итү инфраструктурасын алга китеп үстерүгә шартлар тудыру.

### 4.2.1. Генерирлау куәтләрен үстерү

Кулланучыларны энергия белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыру, Татарстан Республикасының энергетик кур-

кынычсызлыгын һәм үз-үзен канәгатьләндерә алуын тәэмин итү, генерирлау куәтләрен һәм электр челтәре хуҗалыгын яңарту максатларында энергия комплексы предприятиеләре тарафыннан яңа куәтләр кертү буенча яңа проектларны гамәлгә кертү, гамәлдәгеләрен реконструкцияләү буенча чаралар башланды һәм планлаштырыла.

2014 елның декабрендә «Генерирлау компаниясе» ААҖ Казан ТЭЦ-2 дә 220 МВт куәтле пар-газ җайланмасын (алга таба – ПГҖ) төзү эшләрен төгәлләде.

«ТГК-16»ААҖ Казан ТЭЦ-3 тә 2017 елда 388,6 МВт куәтле газ турбиналы җайланманы (алга таба – ГТҖ) файдалануга кертүне планлаштыра.

«Түбән Кама ТЭЦ» ҖЧҖ станциясендә станциянең электр куәтен 730 МВт куәтенә кадәр арттыру буенча проект гамәлгә ашырыла. 2015 елга 350 МВт куәтле җайланманы гамәлгә кертү планлаштырылган.

«ТГК Урыссу ГРЭС» ЯАҖдә пар-газ технологияләре базасында энергетик куәтләр төзү мәсьәләсе карала.

Куәтләрне гамәлдән чыгаруны исәпкә алып, өстәмә рәвештә Казан ТЭЦ-1 дә 230 МВт куәтле (2018 ел) ПГҖ кертү, Зәй ГРЭС куәтләрен алыштыру таләп ителә.

Моннан тыш, республикада электр энергиясен эшләп чыгаруны арттыру пар казаннары биналарына электр һәм җылылык энергиясен катнаш җитештерүне тәэмин итә торган газ турбиналы җиһазлар кую хисабына мөмкин.

Хәзерге вакытта «Әлмәт җылылык челтәрләре» ААҖдә район пар казаннары биналары базасында суммар электр куәте – 24 МВт, гомуми җылылык куәте 22,6 МВт булган өч кече ТЭЦ төзү буенча проект тормышка ашырылган. Кече ТЭЦта эшләп чыгарыла торган җылылык энергиясе кулланучыларның кайнар су ихтыяҗларына, ә электр энергиясе пар казаннары биналарының, «Әлмәт җылылык челтәрләре» ААҖ насос станцияләренең үз ихтыяҗларына тотыла. Артып калган электр энергиясе «Татнефть» ААҖ бүлекчәләре ихтыяҗлары өчен тышкы электр челтәренә бирелә.

Татарстан Республикасының Зеленодольск районында Россиядә иң эре кече энергетика объекты – General Electric (GE) корпорациясе составына керүче GE Jenbacher (Австрия) фирмасының газ пешкәкле когенерирлау җайланмалары базасында электр һәм җылылык энергиясен җитештерү буенча «Майский» энергоүзәге эшли башлады. Энергоүзәкнең кушма электр куәте хәзерге вакытта 54 МВт, җылылык куәте 110 МВт тәшкил итә. Киләчәктә электр куәтен 75 МВт ка кадәр арттыру планлаштырыла.



Электр һәм җылылык энергиясен җитештерү буенча ГТҖ базасында үз генерирлау куәтләре «Түбән Кама нефтехим» ААҖдә бар. Энергия җайланмаларының гомуми электр куәте – 75 МВт, җылылык куәте 119 МВт тәшкил итә.

«Аммоний» ААҖдә 31 МВт куәтле энергия җайланмасын куллануга кертү планлаштырыла.

Шулай итеп, энергетика субъектлары электр станцияләренең һәм гомумән алганда икътисадның билгеләнгән куәте, генерирлау куәтләрен гамәлгә кертү һәм чыгаруны исәпкә алып, 5838 МВт тирәсе була.

4.2.2. Электр челтәре хуҗалыгын үстерү

Үстерүнең төп юнәлешләре Казан, Түбән Кама һәм Урыссу энергорайоннарының электр челтәре хуҗалыкларының перспективалы үсешенә бәйле. Бу районнарда урнашкан эре компанияләрнең тәкъдим ителгән куәте 15 нче таблицада китерелде.

Планлаштырыла торган чаралар электр энергиясенә арта бара торган ихтыяҗны канәгатьләндерергә, шулай ук Татарстан Республикасының барлык кулланучыларын электр белән тәэмин итүнең сыйфатын һәм ышанычлылыгын күтәрергә мөмкинлек бирәчәк.

15 нче таблица

«Челтәр компаниясе» ААҖ буенча төп эре тәкъдим итүчеләр

| Предприятие исеме | Тәкъдим ителгән куәт, МВт | | | | | | Энерго-район исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2014 елга | 2015 елга | 2016 елга | 2017 елга | 2018 елга | макси-маль | |
| «ТАНЕКО» комплексы | 89,61 | 90,98 | 90,98 | 133,33 | 133,33 | 273 | Түбән Кама |
| «Алабуга» МИЗ | 110 | 130 | 152 | 194 | 245 | 568 | Түбән Кама |
| «Аммоний» ААҖ («Менделеевсказот» ҖЧҖ йөкләнешен дә исәпкә алып) | 32 | 32 | 32 | 32 | 32 | 32 | Түбән Кама |
| «Иннополис МИЗ» ААҖ | 8,2 | 8,2 | 8,2 | 25,4 | 25,4 | 48,5 | Буа |
| «Яңа Тура» инвестицион компаниясе, Казан шәһәре | 14,9 | 14,9 | 14,9 | 14,9 | 14,9 | 14,9 | Казан |
| «ТатСталь» ЯАҖ | 0 | 0 | 0 | 0 | 152,5 | 152,5 | Урыссу |
| «ТАИФ-НК» ААҖ КГПТО | 0 | 0 | 82 | 82 | 82 | 82 | Түбән Кама |
| «НКНХ» ААҖ (субабонентлары белән) | 398,63 | 398,63 | 573,27 | 573,27 | 573,27 | 573,27 | Түбән Кама |
| «Кама Кристалл Технолоджи» ҖЧҖ | 13,474 | 19,91 | 26,63 | 26,63 | 26,63 | 26,63 | Түбән Кама |
| «ПК «ЗТЭО» ЯАҖ (гамәлдәге йөкләнешне исәпкә алып) | 130 | 130 | 130 | 130 | 130 | 130 | Түбән Кама |
| «СМАРТ Сити Казан» халыкара инвестицион технополисы | 1 | 2 | 15 | 24 | 24 | 40 | Казан |

Электр челтәре хуҗалыгын үстерү буенча чараларны башкару түбәндәге төп мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән:

Киндери һәм Бөгелмә ПСнә 500/220 автотрансформаторларының югары йөкләнеше. Әлеге ПСләрнең АТ йөкләнеше 55 – 90 процент күрсәткечләр диапозонында була;

220 – 110 кВ челтәренең кайбер кабельле һәм һава электртапшыргыч линияләренең һәм трансформаторларының югары йөкләнеше;

500 кВ челтәрендәге буыннарны сүндергәндә 110 – 220 кВ челтәрләрендә артык йөкләнеш барлыкка килү;

кыска ялганыш токларының зур булуы һәм 500, 220 һәм 110 кВ лы сүндергечләрнең сүндерү мөмкинлекләренең җитәрлек булмавы электр челтәрләрендәге өзеклекләрне киметү буенча төрле чаралар күрүгә ихтыяҗ барлыкка китерә;

идарә итү чараларының һәм реактив куәтне компенсацияләүнең җитәрлек булмавы һәм түбән нәтиҗәлелеге сәбәпле Татарстан Республикасы энергосистемасы челтәрендә көчәнешне җайга салуның катлаулылыгы, эшкә яраклы җайланмаларның булмавы;

АТга йөкләнеш зур булганда җайга салу;

110 – 220 кВ йөкләнештә идарә итүнең һәм реактив куәтне компенсацияләүнең җайга салына торган чараларының җитәрлек санда булмавы;

җирнең бәясе югары булу сәбәпле электр челтәрләре объектларын компактлы урнаштыру зарурлыгы.

Төп проблемаларны хәл иткәндә электр челтәре хуҗалыгын үстерүгә концептуаль якын килү зарур:

төп электр челтәре схемасы аны этаплап үстерүне тормышка ашыруга мөмкинлек бирә торган җитәрлек дәрәҗәдә сыгылмалылыкка ия булырга һәм электр станцияләре йөкләнешләре арту шартлары үзгәрүгә һәм аларның үсешенә яраклашу мөмкинлегенә ия булырга тиеш;

бүлү челтәрләре схемалары һәм параметрлары электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын булдырырга тиеш, бу вакытта кулланучыларны электр белән тәэмин итү челтәрнең тулы схемасында да һәм бер ҺЛ яки автотрансформаторны (яки трансформаторны) ремонтка чыгарганда да йөкләнешне чикләмичә электр энергиясе сыйфатына карата норматив таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла;

Татарстан Республикасы энергосистемасы электр челтәренең перспективалы схемасы гадәти һәм бер ремонт схемасында нормативлар бозылганда һәлакәткә каршы автоматиканы куллануны күздә тотарга тиеш түгел;



һәлакәткә каршы идарә итүне куллану һәлакәткә каршы автоматиканың локаль җайланмалары базасында гына рөхсәт ителә;

югары көчәнештәге электртапшыргычлар линияләре буйлап Урта Идел берләшкән энергетика системасы электр станцияләреннән тышкы энергия белән тәэмин итүне тормышка ашыру белән бергә гамәлдәге электр станцияләрендә яңа генерирлау объектларын кору һәм гамәлдәге электр станцияләрен техник яктан яңадан җаһазландыру хисабына Татарстан Республикасы энергосистемасының куәткә һәм энергиягә дефицитын каплау;

йөкләнешнең югары тыгызлыгы, энергия белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын һәм нәтиҗәлелеген булдыру шартларында Татарстан Республикасының эре шәһәрләрендә тукландыру үзәкләре йөкләнеш үзәкләренә максималь якынайтылырга һәм энергосистемада параллель эшләү шартларында да, шулай ук бүленгән йөкләнеш өчен аерым эшләү шартларында да ышанычлылык, ешлыкны һәм актив куәтне җайга салу, көчәнешне һәм реактив куәтне җайга салу һәм башкалар буенча таләпләрне тәэмин итәргә тиешләр;

электр челтәрләрен техник яктан яңадан җиһазлау электр үткәрү сәләтен, шул исәптән ҺЛ һәм ПСне көчәнешнең югарырак классына күчерү юлы белән арттыруны күздә тота;

йортлар күпләп төзелгән шәһәр районнарында югары үткәрү сәләтенә ия кабель челтәрләрен һәм, югары көчәнешле бүлү җайланмаларында элегаз җиһазларын кулланып, ябык ПСне киң файдалану;

гамәлдәге ПС урынына иң яңа технологияләр буенча эшләнгән яңа ПС кору юлы белән ачык типтагы 110 – 500 кВ куәтле ПС һәм шәһәр эчендә сузылган ҺЛ реконструкцияләү үткәрү. ҺЛ реконструкцияләүне аларны кабельле линияләргә алыштыру юлы белән башкару планлаштырыла;

агымны бүлү, көчәнеш төрләре белән идарә иткәндә яңа технологияләр һәм җиһазлар куллану;

кыска ялганыш токларын чикли торган яңа технологияләр һәм җиһазлар куллану;

норматив срокларын эшләп бетергән һәм сүндерү мөмкинлеге кыска ялганыш токлары дәрәҗәсенә туры килми торган 110 кВ һәм югары куәтле сүндергечләрне этаплап алыштыру;

яңа материаллар, алдынгы технологияләр нигезендә төзелгән яңа типтагы көч һәм коммутация җиһазларын кулану, ПСдә – элегазлы сүндергечләр, 110, 220, 500 кВ куәтле

ПСдә элегаз изоляциясе белән комплектлы бүлү җайланмалары, 500 кВ куәтле өч фазалы АТ куллану;

югары үткәрү сәләтен тәэмин итү, югалтуларны киметү, электртапшыргыч линияләрен тышкы тискәре йогынтыдан саклау — композит үткәргечләр һәм тегелгән полиэтиленнан ясалган үткәрү сәләте югары булган кабельләр куллану.

Электр хуҗалыгының алга таба үсеше һәлакәткә каршы һәм режимлы автоматика, телемеханика һәм элемтә системалары, электр энергиясен исәпкә алуның автоматлаштырылган системаларына бәйле.

Бердәм энергетика системасының ышанычлы эшләвен тәэмин итү максатларында «Россиянең Бердәм энергетика системасы» ААҖ һәм «Челтәр компаниясе» ААҖ арасында төзелгән Технологик багланышлар турында килешү нигезендә «Челтәр компаниясе» ААҖ түбәндәгеләргә бурычлы:

«Челтәр компаниясе» ААҖ энергия объектларының Татарстан төбәк диспетчер идарәсе белән технологик мәгълүмат алмашу системаларының эшләвен тәэмин итәргә;

план-графикта каралган түбәндәге гамәлләрне башкарырга:

Татарстан төбәк диспетчер идарәсенә телеметрик мәгълүмат тапшыру;

кулланучыларны челтәрдән өзүнең дистанциядән башкарылуын кертү;

реле саклау һәм һәлакәткә каршы автоматика җайланмаларыннан һәлакәт мәгълүматларын мониторинглау һәм җыю системаларын кертү.

Әлеге эшләрне башкармау Татарстан Республикасының һәм аның янәшәсендәге регионнарның система төзү челтәрендәге технологик бозылуларга китерергә мөмкин.

Электр энергиясе исәбен алуның автоматлаштырылган системаларын кертү электр челтәре эше режимын контрольдә тоту функцияләрен киңәйтүне тәэмин итә, актив һәм реактив энергия күчешләрен анализлау нигезендә электр тапшыру линияләренең, «Челтәр компаниясе» ААҖ ПС җиһазларының һәм кулланучыларның электр энергиясенә ихтыяҗларын фаразларга, электр челтәре төенләнешләрендә һәм кулланучыларда компенсацияләүче җайланмаларны кертү буенча чаралар эшләргә мөмкинлек бирә, бу исә үз чиратында электр челтәрләрендәге югалтуларны киметә.

Хәзерге вакытта «Челтәр компаниясе» ААҖдә «Smart Grid» интеллектуаль актив-адаптив челтәрен кертү һәм үстерү эше алып барыла.

Гомуми кабул ителгән фикер буенча, «Smart Grid» — ул максималь автоматлаштырылган, үз эченә электр станциясеннән



кулланучыга параллель рәвештә электр энергиясе агымы һәм мәгълүмат барып җитүне тәэмин итә торган идарә итү, контрольдә тоту һәм мониторинглау инструментларын, мәгълүмат технологияләрен һәм коммуникация чараларын туплаган челтәр, ул шулай ук түбәндәгеләрне тәэмин итә:

кулланучыларны электр белән тәэмин итүнең билгеләнгән ышанычлылык һәм сыйфат дәрәҗәсен;

челтәр өлешләрендә электр энергиясен югалтуны киметүне;

эксплуатацияләүнең оптималь чыгымнарын;

электр энергиясен куллану чыгымнарын оптимальләштерү буенча кулланучыларга шартлар тудыруны.

«Интеллектуаль челтәр» — электр энергетикасының сыйфатлы яңа технологик дәрәҗәгә күчүе, энергетика һәм электр челтәре хуҗалыгының төп проблемаларын иң нәтиҗәле чаралар белән хәл итү мөмкинлеге ул.

Бүлү челтәрләренең һәлакәт режимнарында эшләве белән идарә итүне автомат секцияләштерүнең һәм үзәктән ераклашкан автоматлаштыруның интеллектуаль коммутация аппаратлары (реклоузерлар, йөкләнеш сүндергечләре, идарә ителә торган аергычлар) базасында төзелгән системаларын кертү иң перспективалы юнәлешне тәшкил итә.

Интеллектуаль челтәрләр кертүнең икенче юнәлешен электр челтәрләре предприятиясе дәрәҗәсендә электр энергиясен исәпкә алуның интегральләшкән автоматлаштырылган системасын үстерү тәшкил итә.

Электр энергиясен исәпкә алуның автоматлаштырылган мәгълүмат-үлчәү системаларын куллану мәсьәләнең төп һәм иң перспективалы чишелеше булып тора.

Интеллектуаль челтәрләр кертүнең өченче юнәлеше — «Челтәр компаниясе» ААҖдә «Цифрлы подстанция» объектын төзү.

Гамәлгә ашырылырга тиешле «Цифрлы подстанция» проекты Татарстан Республикасында автоматлаштырылган ПС төзергә мөмкинлек бирәчәк, аларда идарә итү, реле саклау, автоматика, үлчәү һәм исәпкә алу цифрлы форматта эшләячәк, боларга көч һәм коммутация җиһазлары белән идарә итү җайланмалары, шулай ук аларның техник торышына автоконтроль керә. Мондый ПС барлыкка килү электр энергетикасының сыйфатлы яңа дәрәҗәгә күчүенең башлангыч ноктасы булып тора. Шул ук вакытта җиһазларны эксплуатацияләү буенча күп еллар дәвамында җыелган норматив документлар, ремонтлау ешлыгы һәм күләмнәре, эксплуатацияләүдә эшләүче персонал саны һәм квалификациясе, башка бик күп нәрсәләр сизелерлек үзгәрә.

4.2.3. Җылылык белән тәэмин итү системаларын үстерү үзенчәлекләре

Җылылык белән тәэмин итү системаларын үстерүнең ике төп альтернативасы аларны үзәкләштерүдән һәм үзәктән читләштерүдән гыйбарәт.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының эре һәм урта шәһәрләрендә кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүнең төп ысулы — җылылык белән үзәкләштерелгән тәэмин итү.

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне оештыруның төп принциплары буларак түбәндәгеләр билгеләнгән:

җылылык белән тәэмин итүне оештыру өчен электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгаруны өстенлекле куллануны тәэмин итү;

җылылык белән үзәкләштерелгән тәэмин итү системаларын үстерү.

Җылылык һәм электр энергияләрен катнаш эшләп чыгаруны күбрәк куллану нәтиҗәсендә ирешелгән җылылык белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасының төп өстен яклары ягулык ресурсларын сак тотудан һәм әйләнә-тирә мохиткә антропоген йөкләнешне киметүдән гыйбарәт. Әмма аларга ирешү өчен генерирлау куәтләрен һәм җылылык челтәрләрен модернизацияләү өчен зур күләмдә капитал салу сорала.

Җылылык белән тәэмин итү системаларын үзәктән читләштерү аерым кулланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кече һәм урта егәрлекле җылылык чыганакларын куллануны күз алдында тота. Автоном җылылык чыганакларын куллану җылылык челтәрләрендәге югалтуларны, химик әзерлек продуктларының атмосферага чыгуын киметергә, челтәрдәге суны югалтуны иң түбән дәрәҗәгә җиткерергә, җылылык трассаларын салу буенча зур күләмле эшләр башкару зарурлыгын төшереп калдырырга мөмкинлек бирә.

Җылылык бирүнең үзәкләштерелгән һәм үзәктән читләштерелгән системаларын, икътисадый максатка ярашлы булудан чыгып, иң оптималь яраклаштырырга кирәк. Җылылык белән тәэмин итүнең автоном системалары аз катлы йортлар төзелгән зур булмаган торак пунктларда һәм үзәкләштерелгән җылылык челтәрләренә тоташтыру объектив кыйммәт булган кайбер шәһәр районнарында икътисадый яктан үз-үзен аклый.

Җылылык белән үзәкләштерелгән тәэмин итү икътисадый яктан үзен аклаган зоналарда аңа кулланучыларны күпләп тоташтыруга ирешергә кирәк. Җылылык белән тәэмин итү челтәреннән кулланучыларның бер өлешен өзү әлеге хезмәт



күрсәтүнең калган кулланучылар өчен объектив кыйммәтләнүенә һәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың техник-икътисадый күрсәткечләренең төшүенә китерә.

### 4.3. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү

Татарстан Республикасында энергия ресурсларын нәтиҗәле куллануны бәяләү өчен кулланыла торган беренчел энергия чыганаклары күләмнәренең шартлы ягулык тонналарында 2007 елның чагыштырма бәяләрендә тулаем төбәк продуктына (алга таба — ТТП) карата мөнәсәбәте буларак ТТПның энергия сыйдырышлылыгы индикаторы кулланыла, аның динамикасы 23 нче рәсемдә күрсәтелде.

Индикаторның акрынлап төшүе күзәтелә, бу беренчел энергия чыганаклары буенча натураль күрсәткечләрдә ТТПның энергия сыйдырышлылыгы кимүен күрсәтә. 2013 елда энергия сыйдырышлылыгы индикаторы кимү 2012 ел белән чагыштырганда 4,9 процент һәм 2007 ел белән чагыштырганда 23,4 процент тәшкил итте. Татарстан Республикасының эчке төбәк продуктының энергия сыйдырышлылыгы кимүнең уртача еллык темплары 4,3 процент булды, бу Россия Федерациясе Энергетика стратегиясендә планлаштырылган Россиянең эчке тулаем продуктының энергия сыйдырышлылыгы кимү темпларын узып китте.




**23 нче рәсем. Беренчел энергия чыганаклары буенча 2007 ел бәяләре белән чагыштырганда Татарстан Республикасы ТТПның гамәлдәге һәм фаразлана торган энергия сыйдырышлылыгы**

Киләчәктә Татарстан Республикасы икътисадының үсүе һәм гражданнарның яхшы тормышта яшәү фаразлары энергетика ресурсларына сорау артуның алшарты булып тора.

Республика икътисадының нәтиҗәле энергия технологияләрен киң колачлы кертү белән ныгытылмаган энергия сыйдырышлы үсүгә йөз тотуы, бер яктан, республиканың җитештерү секторының конкурентлыкка сәләтен югалту, ә икенче яктан — энергия ресурсларына эчке сорауның ташкын сыман интенсификацияләнүе белән яный. Моның нәтиҗәсендә, хәтта аларны җитештерүне үстерүнең техник яктан тормышка ашырыла торган максималь күрсәткечләренә ирешкән очракта да, аларга ихтыяҗ тәкъдим белән тәэмин ителә алмаячак. Үсешнең мондый юлы энергетика ресурслары дефициты кризисына китерәчәк.

Әлеге шартларда энергетика ресурсларына ихтыяҗ һәм энергия нәтиҗәлелеге белән идарә итүнең дәүләт республика сәясәтен тормышка ашыру мөһим әһәмияткә ия була.

Соңгы ун елда республиканың бары тик энергия сыйдырышлы сәнәгать предприятиеләре генә энергияне сак тотучы җитештерү технологияләрен кертү белән шөгыльләнгәннәр. Шул ук вакытта эчке тулаем продуктның энергия сыйдырышлылыгын бер процентка киметү аның 0,4 процент үсешен тәэмин итә ала.

Икътисад структурасын югары технологик һәм азрак энергия сыйдырышлы производстволар ягына үзгәртеп төзү һәм энергия экономияләүнең технологик чаралары ТТПның энергия сыйдырышлылыгын, 2007 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда, 2020 елга 40 процентка һәм 2030 елга 58 процентка киметергә мөмкинлек бирергә тиеш.

Электр энергиясе һәм газ куллануны киметүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган чаралар кертүгә аерым игътибар итәргә кирәк.

Җылылык энергиясенә ихтыяҗ белән идарә итү өлкәсендә төп чара — сорау һәм тәкъдим нәтиҗәсендә барлыкка килүче һәм, кулланучыларда аның чыгымнарын киметүнең шактый зур потенциалы булуны исәпкә алып, җылылык энергиясенең чынбарлыктагы куллану бәясенә адекват тиңләштерергә сәләтле базар бәяләрен куллану тармагын киңәйтү булырга тиеш.

Әлеге үзгәрешләр энергетика ресурсларын кулланучыларга, беренче чиратта сәнәгать предприятиеләренә җитештерү процессларын алдан ук яңа базар таләпләренә яраклаштырырга, производствоны техник яктан яңадан җиһазлау һәм энергияне сак тотучы җиһазларны һәм технолгияләрне ашыгыч рәвештә кертү буенча күп капитал таләп итә торган чараларны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирү өчен этаплап үткәрелергә тиеш.



Энергиянең нәтиҗәлелеген арттыруга финанс ресурсларын җәлеп итү һәм дөрес техник юлларны кулланып гына түгел, ә планлаштырып, идарә итеп һәм контрольдә тотып та ирешелә.

Республикада энергиянең нәтиҗәлелеге белән индикатив идарә итү системасын камилләштерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк. Энергия нәтиҗәлелеге индикаторлары нигезендә аларны киметү буенча башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнарының гамәлләре билгеләнә.

Моңа бәйле рәвештә, икътисадның энергия күп таләп ителә торган төп тармаклары буенча кабул ителгән һәм эшләнә торган республика дәүләт программаларына энергияне сак тоту буенча бүлек һәм тиешле индикаторлар өстәү өлешендә төзәтмәләр кертү мөһим бурычларның берсе булып тора.

Энергияне сак тотуны икътисадый мотивацияләү ысуллары аерым әһәмияткә ия. Болар: энергия нәтиҗәлелеге нормативлары һәм стимуллаштыруның икътисадый системасы. Энергия нәтиҗәлелеге булмаган җиһазларны кулланган өчен түләүнең ел саен артуы аны яңартуга яисә алмаштыруга этәрәчәк. Энергия нәтиҗәлелеге булмаган яңа җиһазны куйган өчен бер тапкыр түләнә торган шактый зур түләү кертү төзүченең, энергия нәтиҗәлелегенә игътибар итмичә, төзелеш бәясен киметү мөмкинлекләрен бетерергә ярдәм итәчәк.

Энергия ресурсларын кирәгеннән артык күп сарыф итү белән көрәшне катгыйландырырга кирәк.

Энергияне сак тоту буенча чараларны турыдан-туры бюджеттан финанслау әһәмиятле озак вакытлы нәтиҗәләргә сирәк китерә, чөнки гамәлгә ашырыла торган проектларга мониторинг ясаганда чынбарлыктагы икътисадый нәтиҗәне бәяләү һәм чыгымнарны компенсацияләү, персоналны бүләкләү һәм чираттагы чараларны башкару өчен каралган уртак финанс әйләнешеннән экономияләнгән чаралар кире алынмый. Экономияләү тагын да күбрәк экономияләүгә китерми.

Энергияне нәтиҗәле куллануны тәэмин итүче җиһазлар һәм гади җиһазлар бәясендәге аерманы кредитлау ысулын кулланырга кирәк, бу вакытта кредит булачак экономия нәтиҗәсендә алынган чаралардан кайтарылачак. Хосусый төзүчеләрне энергияне нәтиҗәле куллануны тәэмин итүче җиһазлар куллануга стимуллаштыру өчен аларны кредитлау методикасын һәм системасын эшләргә кирәк.

Энергияне сак тоту өлкәсендә нәтиҗәле бизнеска булышу һәм аны стимуллаштыру дәүләт сәясәтенең мөһим коралы булып тора. Республикада әлегә киң үсеш алмаган бизнесның шушы төренә карата дәүләт протекционизмы җитештерүнең һәм куллануның энергияне күп сарыф итүен киметүгә юнәлдерелгән

аеручa оптималь фәнни, проект-технологик, җитештерү чишелешләрен тәкъдим итүче һәм тормышка ашыручы икътисадый агентларны фомалаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

Энергияне сак тотучы бизнеска булышуны, дәүләт тарафыннан ташламалы шартларда турыдан-туры финас ярдәменнән китеп, тиешле тармакта нәтиҗәле бизнес-проектларны тормышка ашыру, коммерция куркынычларын һәм коммерциягә карамаган куркынычларны иминләштерү системасын формалаштыруны сыйфатлы яңа дәрәҗәгә чыгару зарур.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә энергияне сак тотуны үстерү өчен энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеге өлкәсендә энергияне нәтиҗәле куллануны тәэмин итүче комплекслы проектлар һәм программа чараларын тормышка ашыруда стимуллаштыру һәм дәүләт ярдәме системасын, шул исәптән бу өлкәдә иң әйбәт муниципаль программаларны тормышка ашыруга субсидияләр (грантлар) бирү юлы белән эшләргә кирәк.

Регионнарда энергияне сак тотуны үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Россия Федерациясе дәүләт программаларында Татарстан Республикасының катнашуы буенча эшне, шул исәптән бюджеттан тыш финанс оешмаларының максималь катнашуы белән дәвам итәргә кирәк.

### 4.4. Альтернатив, традицион булмаган һәм торгызыла торган энергия чыганакларын куллану

Торгызыла торган энергия чыганаклары нигезендә энергетиканы үстерү Россия Федерациясенең энергетика сәясәтенең бер өлеше булып тора. Әгәр традицион энергетика запаслары чикләнгән табыла торган ягулык куллануга нигезләнсә һәм энергия китерү зурлыгы белән базар конъюнктурасына бәйле булса, торгызылучы энергетика төрле табигый ресурсларга нигезләнә, бу торгызылмый торган ресурсларны икътисадның башка өлкәләрендә нәтиҗәлерәк кулланырга мөмкинлек бирәчәк. Моннан тыш, торгызыла торган энергия чыганакларын (алга таба — ТЭЧ) кулланганда табыла торган ягулыкны чыгаруга, эшкәртүгә һәм транспортлауга бәйле экологик чыгымнар булмый.

Торгызылучы энергетика технологияләрендә күп фәнни юнәлешләрнең һәм тармакларның — метеорология, аэродинамика, электр энергетикасы, җылылык энергетикасы, электроника, нанотехнологияләр, материалларны өйрәнү һәм башка тармакларның өр-яңа казанышлары тормышка ашырыла. Фәнни нигезләнгән технологияләрне үстерү энергетиканың фәнни, җитештерү һәм экплуатацияләү инфраструктурасын саклау һәм



киңәйтү, шулай ук фәнни нигезләнгән җайланмалар экспорты хисабына өстәмә эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирә.

Россия Федерациясендә торгызылучы энергетиканы нигездә эре гидроэлектростанцияләр тәэмин итә, алар илдә җитештерелүче электр энергиясенең 19 процентын тәшкил итә. ТЭЧның башка төрләре Россиядә әлегә аз, монда җирле энергия системаларында мөһим әһәмияткә ия булган кайбер төбәкләр (Камчатка һәм Куриль утраулары) исәпкә алынмый. Россия Федерациясе энергетика министрлыгы мәгълүматлары буенча, кече гидроэлектростанцияләренең кушма куәте якынча 250 МВт, геотермаль электр станцияләренең — якынча 80 МВт. Җил энергетикасы гомуми куәте 13 МВт булган берничә пилот проектта карала. Кояш энергетикасы энергия системасына тоташтырылмаган һәм шәхси затлар һәм зур булмаган оешмалар тарафыннан кулланыла торган кечкенә автоном энергия белән тәэмин итү җайланмалары рәвешендә гамәлдә.

2020 елга кадәр чорда ТЭЧ куллану нигезендә электр энергиясен үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре һәм максатчан күрсәткечләр 2009 елның гыйнварында кабул ителгән (2013 елның маенда төзәтмәләр кертелгән) Россия Федерациясе күрсәтмәсендә билгеләнгәннәр. Төрле төрдәге ТЭЧ нигезендә Россия Федерациясендә электр энергиясен җитештерүнең максатчан күрсәткечләре 16.1 — 16.3 нче таблицаларда китерелде.

16.1 нче таблица

Куәтләре 25 МВт тан ким булган, су энергиясендә эшләүче генерирлау объектлары тарафыннан электр энергиясен җитештерүнең максатчан күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме / еллар | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Билгеләнгән куәтне гамәлгә кертү күләмнәре, МВт | 26 | 124 | 124 | 141 | 159 | 159 |
| Электр энергиясен җитештерү күләмнәре, ГВт·сәг. | 69,6 | 324,6 | 324,6 | 371 | 417,4 | 417,4 |
| Генерирлау объектының 1 кВт билгеләнгән куәтен кертүгә капитал чыгымнарының чик зурлыклары, мең сум/кВт | 146, 0 | 146, 0 | 146, 0 | 146, 0 | 146, 0 | 146, 0 |
| Җиһазлар җитештерүне локальләштерү дәрәҗәсе, процент | 20 | 45 | 45 | 65 | 65 | 65 |

16.2 нче таблица

Җил энергиясендә эшләүче генерирлау объектлары тарафыннан электр энергиясен җитештерүнең максатчан күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме / еллар | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Билгеләнгән куәтне гамәлгә кертү күләмнәре, МВт | 250 | 250 | 500 | 750 | 1 000 | 3 600 |
| Электр энергиясен җитештерү күләмнәре, ГВт·сәг. | 547,5 | 547,5 | 1 095 | 1 642,5 | 1 642,5 | 7 884 |
| Генерирлау объектының 1 кВт билгеләнгән куәтен кертүгә капитал чыгымнарының чик зурлыклары, сум/кВт | 65, 69 | 65, 63 | 65, 56 | 65, 49 | 65, 43 | 65, 37 |
| Җиһазлар җитештерүне локальләштерү дәрәҗәсе, процент | 55 | 65 | 65 | 65 | 65 | 65 |

16.3 нче таблица

Кояш энергиясендә эшләүче генерирлау объектлары тарафыннан электр энергиясен җитештерүнең максатчан күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме / еллар | 2015 | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Билгеләнгән куәтне гамәлгә кертү күләмнәре, МВт | 140 | 200 | 250 | 270 | 270 | 270 |
| Электр энергиясен җитештерү күләмнәре, ГВт·сәг. | 159,4 | 227,8 | 284,7 | 307,5 | 307,5 | 307,5 |
| Генерирлау объектының 1 кВт билгеләнгән куәтен кертүгә капитал чыгымнарының чик зурлыклары, сум/кВт | 114,12 | 111, 84 | 109,60 | 107,41 | 105,26 | 103,16 |
| Җиһазлар җитештерүне локальләштерү дәрәҗәсе, процент | 50 | 70 | 70 | 70 | 70 | 70 |

Татарстан Республикасында торгызыла торган энергия чыганакларын үстерүнең һәм куллануның төп юнәлешләре «Торгызыла торган энергия чыганакларында Татарстан Республикасы кече энергетикасын үстерү» максатчан программасының концепциясендә билгеләнгән, алар алга таба текстагы бүлекчәләрдә китерелә.

4.4.1. Кече гидроэнергетика

Хәзерге вакытта Россия Федерациясендә гомуми куәте 1300 мең кВт булган 300 дән артык кече ГЭС эшли. Әлеге ГЭСлар конструктив чишелешләренә һәм техник дәрәҗәләренә карап аерыла – кулдан идарә ителә торганнардан алып кизүдә торучы персоналсыз эшләүче тулысынча автоматлаштырылганнарына кадәр.

Кече ГЭСлар энергия системасыннан аерылган аерым кулланучыларны энергия белән тәэмин итәләр, әмма аларның күп өлеше җирле энергия системаларына тоташтырылган.



Кече ГЭСлар классына икътисадый яктан караганда куәте 50 – 100 кВт алып (микро-ГЭС) 5000 кВт кадәр (кече ГЭС) булган ГЭСлар кертелергә тиеш.

Мондый куәтләрне төзү өчен эрерәк ГЭСлар өчен эшләнгән гадәтиләреннән принципиаль аерылып торучы техник чишелешләр кирәк, шул исәптән:

буасыз су коймалары төзү;

су астында калуы максималь ташу биеклегеннән артып китми торган сусаклагычлар төзү;

гидроэлектростанцияләр биналарын елга юлыннан читтә урнаштыру;

су агымының табигый төшү энергиясен файдалану.

Әлеге нигезләмәләр Татарстан Республикасы территориясендә кече ГЭСларны урнаштыруның принципиаль схемасын төзегәндә кулланма булдылар.

Татарстан Республикасындагы кече су агымнарының техник потенциалы тулаем алганда урта куәт буенча 144,3 МВт, электр энергиясен еллык эшләп чыгару буенча 1,264 млрд. кВт·сәг. итеп бәяләнә.

Минзәлә (58375 кВт·сәг/кв.км), Дала Зәе (50098 кВт·сәг/кв.км), Чишмә (45712 кВт·сәг/кв.км), Кичү (43755 кВт·сәг/кв.км), Зәй (43683 кВт·сәг/кв.км), Кече Мишә (32547 кВт·сәг/кв.км), Зичә (32322 кВт·сәг/кв.км) елгалары иң зур энергетик куәткә ия.

Шулай ук мелиорация өчен билгеләнгән сусаклагычлар да каралды. Аларның файдалы күләме нигездә май аеннан алып августка кадәр кулланыла. Мәллә, Иганә, Бидәңге елгаларындагы, Бурла инешендәге сусаклагычлар энергетик яктан куллану өчен иң перспективалы булып тора.

Бәяләүләрнең нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Татарстан Республикасы территориясендә елына 68 млн. кВт·сәг. күләмдә электр энергиясе җитештерә алучы 27 МВт билгеләнгән куәтле 67 кече ГЭС төзелергә мөмкин, шул исәптән республиканың нефть табыла торган районнарында 39,1 млн. кВт·сәг. электр энергиясен эшләп чыгаруны тәэмин итәчәк 12,1 МВт билгеләнгән куәтле 32 кече ГЭС төзелә ала.

Беренчел нәүбәттәге кече ГЭСларның энергетик бәя күрсәткечләре билгеләнде. Нәтиҗәләр 9,2 МВт гомуми билгеләнгән куәтле 14 беренчел нәүбәттәге кече ГЭСтан 31,2 млн. кВт·сәг электр энергиясе алып булуын һәм 10,8 мең ш.я.т. экономияләп булуын күрсәтте.

Кече ГЭСларның икътисадый күрсәткечләрен билгеләү хәзерге вакытта гидроагрегатның төгәл бәясенең бары тик төзелеш мәйданы сайлап алынганнан соң гына билгеләнә алуы белән кы-

енлаша, чөнки җиһазның конструкциясе һәм составы ГЭСның эшләү режимына һәм электр кулланучыларның үзенчәлекләренә нык бәйле. Шулай итеп, Татарстан Республикасында кече ГЭСлар төзүнең беренче этабын гамәлгә ашыруга якынча чыгымнар 4 млрд.сумны тәшкил итә (2005 елгы бәяләрдә).

Татарстан Республикасында кече ГЭСларны төзү якынча 2017 елдан башланырга мөмкин. 17 нче таблицада кече ГЭСларны төзүнең якынча программасы күрсәтелде.

17 нче таблица

Татарстан Республикасында кече ГЭСларны төзү программасы

| | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 – 2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| Гамәлгә кертелә торган куәтләр, МВт | Төзелеш башлану | 2 | 2 | 3 | 7 |

Тулаем алганда Татарстан Республикасы буенча, эре гидроэлектростанцияләрне исәпкә алмаганда (25 МВт тан артык билгеләнгән куәт белән), беренчел энергия ресурсларын куллануның гомуми күләмендә ТЭЧ өлешенә 0,4 проценттан кимрәк өлеш туры килә, 2030 елга аның өлеше берничә тапкыр артырга тиеш.

4.4.2. Җил энергетикасы

Татарстан Республикасы территориясендә 722,4 МВт куәтле 600 кВт һәм 1275,2 млн. кВт·сәг электр энергиясе эшләп чыгара торган җил җайланмалары кулланылган 359 җил энергетикасы станцияләрен (ҖЭС) урнаштыруның техник мөмкинлекләре бар.




**24 нче рәсем. 50 метр биеклектә уртача еллык җил тизлекләре**



Җилнең энергетик кыйммәтен билгели торган иң мөһим үзенчәлеге – аның уртача еллык тизлеге. Уртача еллык җил тизлегенең метеостанция шартларында республика территориясендә сизелерлек үзгәрүе билгеләнде һәм ул секундына 3,3 – 3,5 метр тәшкил итә.

Иң уңайлы җил шартлары Идел елгасының уң як ярында, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының яр буйларында, Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының көнчыгыш өлешендә бар.

Әлмәт (73,8 млн. кВт·сәг.), Бөгелмә (59,4 млн. кВт·сәг.), Зеленодольск (59,1 млн. кВт·сәг.), Тәтеш (57,0 млн. кВт·сәг.), Югары Ослан (50,4 млн. кВт·сәг.) районнары иң зур җил потенциалына ия, һәм 2017 елдан башлап әлеге районнарда җил энергетикасы электростанцияләре төзүнең максатка ярашлы булу-булмау мәсьәләсен карарга мөмкин (18 нче таблица).

18 нче таблица

Татарстан Республикасында кече ҖЭС төзү программасы

| Район исеме / еллар | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 – 2030 |
|---|---|---|---|---|---|
| Әлмәт | төзелеш башлана | 2 | 2 | 3 | 7 |
| Бөгелмә | төзелеш башлана | 1 | 1 | 2 | 5 |
| Зеленодольск | төзелеш башлана | 1 | 1 | 2 | 5 |
| Тәтеш | төзелеш башлана | 1 | 1 | 2 | 6 |
| Югары Ослан | төзелеш башлана | 1 | 1 | 1 | 5 |

4.4.3 Урман ресурслары

Татарстан Республикасында ел саен 64 мең тоннага якын агач калдыклары барлыкка килә (пычкы чүбе, йомычка, кыртыш, кисем, агач төзелеш калдыклары), җыелган һәм файдаланыла торган агач калдыклары күләме якынча 760 тонна (1,2 процент) тәшкил итә.

Республиканың урман кисү фонды ел саен 1800 мең куб метр тәшкил итә һәм аның бары тик 25 – 30 проценты гына файдаланыла, чөнки коммерция ягыннан ул кызыклы түгел (йомшак яфраклы токымнар һәм коры имән). Шулай итеп, республикада агач материалы нигезендә ТЭЧны үстерү өчен ресурс базасы бар.

Бионергетика өлкәсендә агач ягулыгы нигезендәге проектларны тормышка ашыру кысаларында «Энерголеспром» ҖЧҖ инновацион компаниясе һәм «Укыту-тәҗрибә Шәһәр яны урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе базасында «Казан милли тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет югары һөнәри белем бирү учреждениесе галимнәре белән берлектә товарлыгы түбән булган агачны сыек биоягулыкка һәм агач күмеренә термохимик яңадан эшкәртү технологиясен эшләү буенча инновацион проект тормышка ашырыла.

«Энерголеспром» ҖЧҖ кече инновация компаниясе «Сколково» инновация үзәгенең резиденты булып тора һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы ярдәме белән товарлыгы түбән булган агачны, урман кисү калдыкларын эшкәртү өчен 50 кг/сәг (КПД – 80 – 85 процент) җитештерүчәнлекле тәҗрибә-эксперименталь җайланмалар эшләде һәм аларны Столбище участок урмынчылыгында сыный. Капитал чыгымнары һәм агымдагы чыгымнар күләме – 4 млн. сум, эшкәртүнең энергетик нәтиҗәлелеге 65 – 70 процент тәшкил итә. Калдыкларны юк итү һәм товар продукцияне эчке куллану һәм торак-коммуналь тармак өчен сату уңай экологик нәтиҗә булып тора.

Хәзерге вакытта компания тарафыннан товарлыгы түбән булган агачны һәм урман кисү калдыкларын эшкәртү өчен 500 – 1000 кг/сәг. (сәгатенә 3,3 – 6,6 куб метр йомычка) җитештерүчәнлекле күчмә җитештерү комплекслары эшләнә.

4.4.4. Биогаз куллану

Татарстан Республикасында биогаз куллану чимал базасының потенциаль мөмкинлекләре, булган терлек һәм кош санын исәпкә алып, 19 нчы таблицада китерелде.

19 нчы таблица

Татарстан Республикасында биогаз куллануның чимал базасының потенциаль мөмкинлекләре

| Терлек һәм кош саны, мең баш | | Тәүлегенә чыккан тирес, тонна | Эшләп чыгарыла торган биогаз күләме, мең куб метр | Энергия эквиваленты | | Тәүлегенә ашлама чыгу, тонна |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | җылылык, Гкал | электр, кВт·сәг | |
| Мөгезле эре терлек | 1 055,1 | 17 938 | 1 794 | 8 478,4 | 9 860 | 17 938 |
| Дуңгызлар | 525,7 | 2 098 | 210 | 1 461,6 | 1 699,8 | 2 098 |
| Кошлар | 14 198,8 | 1 774 | 177 | 513,5 | 597,2 | 1 774 |
| Сарыклар һәм кәҗәләр | 404,3 | 1 207 | 1 207 | 107,5 | 125 | 1 207 |
| Барлыгы | | 23 017 | 3 388 | 10 561 | 12 282,4 | 23 017 |

Татарстан Республикасының терлекчелек үскән муниципаль районнары территориясендә биогаз һәм биоашлама җитештерү белән тирес һәм кош тизәген эшкәртергә кирәк.

Мондый проектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә күрсәтелгән комплексларда ел саен 53 млн. куб метр биогаз (27 –



37 млн. куб метр метан), 416 мең тонна каты һәм 303 мең куб метр сыек биоашлама эшләп чыгарылачак.

Тиресне һәм тизәкне эшкәртү аны складка урнаштыру мәсьәләсен хәл итә, туфракны пычрату куркынычын киметә, агросәнәгать комплексының кайбер предприятиеләрен газ белән тәэмин итәргә һәм җирле хуҗалыклар сатып ала алырлак югары сыйфатлы биоашлама җитештерергә мөмкинлек бирә.

4.4.5. Җылылык насослары

Каты, сыек ягулыкта һәм электр энергиясендә эшли торган автоном пар казаннары биналары урынына җылылык насослары кертү – альтернатив энергетиканың бер юнәлеше. Җир асты суы, тыштагы һава, җир җылысы, түбән потенциаллы икенчел энергия ресурслары җылылык насослары өчен түбән потенциаллы җылылык чыганагы булып тора.

Татарстан Республикасында түбән потенциаллы җылылык ресурсларының шактый булуын исәпкә алып, икътисад тармакларында җылылык насосларын кертү – перспектив юнәлеш. Шулай да бүгенге көндә Россиядә җылылык насослары аз кулланыла, барлык җылылык насослары җайланмаларының гомуми җылылык куәте 100 МВт тәшкил итә, ә аларның саны 150 үрнәктән артып китми.

Җылылык насослары техникасын кертү юлында төп каршылыклар түбәндәгеләр:

Россия Федерациясендә җылылык электр станцияләренең киң таралган булуы, аларның ягулык нәтиҗәлелеге электр энергиясен эшләп чыгарганда электр приводлы җылылык насосларын югары нәтиҗәле эксплутацияләүне тормышка ашырырга мөмкинлек бирми;

базарда механик приводлы җылылык насосларының, мәсәлән, газ ягулыгында эшли торган насосларның булмавы;

җылылык насослары бәясенең шактый югары булуы аның үзкыйммәтен аклауның озакка сузылуына сәбәп була.

Җылылык насосларын кертү дәүләт тарафыннан тарифларны җайга салу һәм төбәк энергосистемалары тарафыннан җылылык насосларында кулланылган электр энергиясе өчен дифференциацияләнгән түләү кертелгәндә генә мөмкин, бу җылылык насослары техникасына җылылык җитештерү җиһазлары базарында электр һәм ташкүмер казаннары урынын биләргә ярдәм итәчәк.

Бүгенге көндә җылылык насосларын Татарстан Республикасы өчен альтернатив энергия чыганаклары сыйфатында куллану иң перспектив юнәлеш булып тора.

4.4.6. Турбодетандер җайланмалар

Электр энергиясен җитештерүдә энергияне сак тоту күзлегеннән караганда, бүгенге көндә газ турбиналы двигательләрдән чыккан газларның җылылыгын утильләштерү генә түгел, газүткәргеч буйлап эре предприятиеләрнең, компрессор станцияләренең, ТЭЦларның газ бүлү станциясенә яки газ бүлү пунктларына җибәрелә торган табигый газ басымының артык энергиясен файдалану да гаять перспективалы.

«Теплоэлектропроект институты» ААҖнең Түбән Новгород филиалы тарафыннан ДГА-5000 тибындагы детандер-генератор җайланмасын ТЭСның газ бүлү пунктына кадәр урнаштыруның икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү буенча эш башкарылган. Табигый газның 12 кгс/кв.см тигез номиналь басымы ГБПга кадәр булганда исәпләп чыгарганда газның 4 алып 8 кгс/кв.см кадәр факттагы күрсәткечләре алынган. «Теплоэлектропроект институты» ААҖнең Түбән Новгород филиалы белгечләре исәпләве буенча, газның 12 кгс/кв.см. номиналь басымы вакытында экономия бер елга 14000 – 18000 т.у.т. тәшкил итәчәк, җайланманың үз хакын аклау срогы – 6,5 – 7,5 ел.

Шулай итеп, бу өлкәдә тикшеренүләр күрсәткәнчә, кече энергетика технологияләрен үстерү һәм торак пунктларда һәм төрле сәнәгать объектларында 0,5 тән 10 мВт кадәр куәтле югары нәтиҗәле турбодетандер җайланмалар базасында үз автоном энергетика системаларын төзү икътисадый яктан нигезле һәм нәтиҗәле булып тора.




**25 нче рәсем. Туры кояш радиациясен кояш төшә торган өслекләргә бүлү (елына).**



Татарстанда кояш энергетикасы үсешендәге тоткарлыкның берничә сәбәбе бар:

кояш электр станцияләре электр энергиясен көндез генерирлый, шул ук вакытта электрга иң зур ихтыяҗ кичке сәгатьләрдә килеп чыга. Димәк, аккумуляторсыз кояш электр станцияләренең нәтиҗәле булмавы аңлашыла;

дөньякүләм тәҗрибә күрсәткәнчә, дәүләт ярдәменнән, законнарда билгеләнгән икътисадый стимуллардан башка кояш энергетикасы үсеш ала алмый;

кояш электр станцияләре электр энергиясен җитештерүдә кулланыла торган технологияләрнең иң кыйммәтлеләреннән берсе булып тора.

Татарстанда кояш яктыртуының уртача еллык сәгатьләре кв.метрга 2,8 – 3,3 кВт•сәг. диапазонында тора. Шул ук вакытта кояш яктылыгының уртача сәгать саны Мәскәү янында 2,3 тәшкил итә (20 нче таблица).

20 нче таблица

Кояш яктылыгының уртача сәгать саны, кв.метрга кВт•сәг

| Шәһәр исеме | Гыйнвар | Февраль | Март | Апрель | Май | Июнь | Июль | Август | Сентябрь | Октябрь | Ноябрь | Декабрь | Ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Санкт-Петербург | 0,35 | 1,08 | 2,36 | 3,98 | 5,46 | 5,78 | 5,61 | 4,31 | 2,60 | 1,23 | 0,50 | 0,20 | 2,80 |
| Мәскәү | 0,50 | 0,94 | 2,63 | 3,07 | 4,69 | 5,44 | 5,51 | 4,26 | 2,34 | 1,08 | 0,56 | 0,36 | 2,63 |
| Казан | 0,68 | 1,44 | 2,82 | 4,29 | 5,52 | 5,93 | 5,72 | 4,49 | 2,86 | 1,51 | 0,83 | 0,54 | 3,06 |
| Түбән Новгород | 0,64 | 1,45 | 2,75 | 3,95 | 5,34 | 5,60 | 5,50 | 4,27 | 2,69 | 1,45 | 0,75 | 0,45 | 2,91 |
| Екатеринбург | 0,64 | 1,05 | 2,94 | 4,11 | 5,11 | 5,72 | 5,22 | 4,06 | 2,56 | 1,36 | 0,72 | 0,44 | 2,87 |

Эшләп чыгарыла тоган энергиянең бәясе кимегән саен, кояш энергетикасы конкурентлыкка сәләтле булачак һәм Татарстан Республикасында алга таба үсеш алачак. Гелиоҗайланмаларның техник-икътисадый күрсәткечләрен яхшыртуның мөмкин булган ысулларының берсе булып аларны җил җайланмалары белән бергә куллану тора.

2013 елда Россиядә торгызыла торган энергия чыганаклары нигезендә электр энергиясен җитештерүне киңәйтүгә юнәлдерелгән беренче чын адымнар башланды. Электр энергиясен һәм куәтне күпләп сату базарында дәүләт стимуллаштыруы – ТЭЧтагы энергия чыганаклары өчен куәтләр китерүгә шартнамәләр механизмы – хисабына проектларны тормышка ашыру бушланды. Электр энергиясен ваклап сату базарларында ТЭЧ проектларын үстерү әлегә системалы башкарылмый. Шулай да әлеге базарларда ТЭЧны үстерүне стимуллаштыруга юнәлдерелгән чараларны һәм гомумән алганда ТЭЧ нигезендә энергетиканы үстерүне стимуллаштыручы федераль дәрәҗәдәге

зарур норматив һәм хокукый базаны эшләгәннән соң мондый проектлар Татарстан Республикасында тормышка ашырылачак, моның өчен барлык кирәкле башлангычлар бар.

## V. Көтелә торган нәтиҗәләр һәм Стратегияне тормышка ашыру ысулы

Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексы тармакларын үстерүнең максатчан индикаторларын эшләгәндә Россия Федерациясе һәм шулай ук Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә стратегик өстенлекләр исәпкә алынды:

республика икътисады һәм халкының энергия ресурсларына һәм углеводород чималына ихтыяҗын Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексы белән тәэмин итү;

углеводород чималын тирәнтен эшкәртү, чыгару һәм транспортлауның заманча технологияләрен кертү;

ягулык-энергетика комплексының иң эре предприятиеләре базасында сәнәгатьнең кластерлы үсешен тәэмин итү;

озак вакытлы перспективада Татарстан Республикасының Россия Федерациясенең төп нефть чыгаручы төбәкләренең берсе сыйфатында урынын саклау.

Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексының тармак аспектында үсешенең максатчан индикаторлары әлеге Стратегиянең тиешле бүлекләрендә аеруча тулы күрсәтелде.

Әлеге Стратегияне тормышка ашырудан көтелә торган төп нәтиҗәләр түбәндә китерелә.



<table>
<tr>
<td>Стратегияне гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр</td>
<td>
1. Татарстан Республикасында нефть чыгару
<table>
<tr><th>Күрсәткеч исеме</th><th>2020</th><th>2025</th><th>2030</th></tr>
<tr><td>АЮҮН белән нефть чыгару, елына мең тонна</td><td>33 500</td><td>33 500</td><td>33 057</td></tr>
<tr><td>Эксплуатация бораулавы, елына мең м</td><td>887</td><td>703</td><td>701</td></tr>
<tr><td>Эзләү-тикшерү бораулавы, елына мең м</td><td>55</td><td>55</td><td>55</td></tr>
</table>
2. Нефть эшкәртү<br>
Татарстан Республикасы буенча нефть эшкәртү тирәнлеген 2020 елда 95 процентка җиткерү;<br>
Татарстан Республикасында эшкәртелә торган нефть күләмен 2020 елга 21,4 млн.тоннага кадәр арттыру.<br>
3. Электр энергетикасы<br>
2014 ел белән чагыштырганда 2030 елга электр энергиясен җитештерү 61,6 процентка үсәчәк:<br>
2020 елда – 30 500 млн.кВт·сәг,<br>
2025 елда – 32 529 млн.кВт·сәг,<br>
2030 елда – 34 744 млн.кВт·сәг.<br>
4. Җылылык энергиясен җитештерү<br>
2014 ел белән чагыштырганда 2030 елга җылылык энергиясен җитештерү 2,8 процентка үсәчәк:<br>
2020 елда – 48,08 млн.Гкал,<br>
2025 елда – 48,192 млн.Гкал,<br>
2030 елда – 48,304 млн.Гкал.<br>
5. Энергия нәтиҗәлелеге<br>
2007 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда ТТП энергия сыйдырышлылыгы кимиячәк:<br>
2020 елга – 40 процентка,<br>
2030 елга – 58 процентка.
</td>
</tr>
</table>

Әлеге Стратегия 2015 – 2016 елларда Татарстан Республикасының ягулык-энергетика комплексы предприятиеләре тарафыннан 2030 елга кадәр корпоратив стратегияләрне эшләү һәм раслау өчен нигез булып тора.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 523. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 9 августындагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014 № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең дәүләт тарафыннан яклануы гарантияләрен көчәйтү, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм урындагы затлар тарафыннан аларның үтәлүенә һәм хөрмәт ителүенә булышлык күрсәтү» сүзләрен «кеше һәм граждан хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең дәүләт тарафыннан яклануына өстәмә гарантияләрне тәэмин итү, шулай ук аны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда «бәйсез була һәм нинди дә булса дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм урындагы затларга хисап бирми» сүзләрен «нинди дә булса дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга бәйсез була» сүзләренә алмаштырырга;

3) II бүлекнең исемендә «һәм аны урыннан азат итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны карар алдыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аны Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештерә.»;

5) 6 статьяда «35 яшьтән яшьрәк булмаган» сүзләрен «30 яшьтән яшьрәк булмаган, репутациясенә тап төшмәгән» сүзләренә алмаштырырга;

6) 7 статьяның 1 өлешендә «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга;

7) 8 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Вәкаләте срогы беткән Вәкаләтле вәкил үз йөкләмәләрен яңа сайлап куелган Вәкаләтле вәкил вазыйфага кергәнче үтәүне дәвам итә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Бер үк зат Вәкаләтле вәкил вазыйфасына рәттән ике сроктан артыкка сайлап куела алмый.»;

8) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Вәкаләтле вәкилгә карата таләпләр, чикләүләр һәм тыюлар**

1. Вәкаләтле вәкилнең чит дәүләт гражданлыгы йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булырга тиеш түгел.

2. Вәкаләтле вәкил бер үк вакытта Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутаты була алмый, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының башка дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын били алмый, укыту, фәнни һәм бүтән төр иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле яисә түләүсез эш белән шөгыльләнә алмый. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм бүтән төр иҗади эшчәнлек өчен түләү, әгәр башкасы Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчаларына финансланырга тиеш түгел.

3. Вәкаләтле вәкил сәяси партия яисә сәяси максатларны күз алдында тотып эшли торган башка иҗтимагый берләшмә әгъзасы булырга хокуксыз.

4. Вәкаләтле вәкил федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә тиеш.

5. Вәкаләтле вәкил үзенең статусы белән бергә башкарыла алмаган эшчәнлекне вазыйфага кергәнче кимендә 14 көн алда туктатырга, шулай ук үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чорына сәяси партиядә әгъза булуын туктатып торырга бурычлы. Вәкаләтле вәкил билгеләнгән таләпләрне күрсәтелгән вакыт дәвамында үтәмәсә, аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

9) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу**

1. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) вафат булса;

2) вәкаләтләрен үз өстеннән төшерү турында язма рәвештә гариза бирсә;

3) медицина бәяләмәсе нигезендә билгеләнгән сәламәтлеге торышы буенча яисә башка сәбәпләр аркасында озак вакыт дәвамында (кимендә дүрт ай) үз бурычларын үти алмаса;

4) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез, хокуктан файдалануга чикле сәләтле, хәбәрсез юкка чыккан дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

5) аңа карата чыгарылган гаепләү хөкеме законлы көченә керсә;

6) Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына китсә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын югалтса;

8) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $13^1$ статьясында каралган очракларда ышанычны югалтса;

9) федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәсә.

2. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән киңәшләшкәннән соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан алынган күпчелек тавыш белән кабул ителә.



3. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Вәкаләтле вәкил аңа кадәрге Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганнан соң ике ай эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан әлеге Законның 4 – 7 статьяларында билгеләнгән тәртиптә сайланып куелырга тиеш.»;

10) 13 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен көчәйтү» сүзләрен «хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең дәүләт тарафыннан якланоуына өстәмә гарантияләрне тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга;

11) 14 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктта «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) хөкем ителгәннәр һәм сак астына ябылган затлар белән икәүдән-икәү сөйләшергә, бу вакытта аларның әңгәмәләре җәза үтәтү учреждениесе яисә органы администрациясе яки тикшерү изоляторы вәкиленә ишетелмәслек, ләкин үзләре күренерлек шартлар тудырылган булырга тиеш.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вәкаләтле вәкил үз эшчәнлегендәге мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, федераль закон белән аерым дәүләт яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән башка органнар һәм оешмалар җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары, шулай ук мәҗбүри тоту урыннары администрацияләре тарафыннан кичектергесез кабул ителү хокукыннан файдалана.»;

12) IV бүлек исемендә «хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен көчәйтү» сүзләрен «хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең

дәүләт тарафыннан яклануын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

13) 16 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кеше һәм гражданның бозылган хокукларын һәм ирекләрен торгызуга ярдәм итү максатларында Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендәге Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан (алга таба – гариза бирүчеләр) федераль башкарма хакимият органнарының эшчәнлеккә җитәкчелекне Россия Федерациясе Хөкүмәте башкара торган территориаль органнарының, шулай ук федераль буйсынудагы оешмаларның, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә карамастан, оешмалар җитәкчеләренең һәм башка вазыйфаи затларның кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен боза торган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата бирелгән шикаятьләрне карый.»;

14) 18 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга;

15) 19 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4[1] өлеш өстәргә:

«4[1]. Эшчәнлекләренә җитәкчелекне Россия Федерациясе Хөкүмәте башкара торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, шулай ук федераль буйсынудагы оешмалар карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләрне караганда Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:

1) күрсәтелгән территориаль органнарга һәм оешмаларга тоткарлыксыз үтеп керергә;

2) алардан шикаятьләрне карау өчен кирәкле белешмәләрне, документларны һәм материалларны соратып алырга;

3) күрсәтелгән территориаль органнарның, оешмаларның вазыйфаи затларыннан һәм дәүләт хезмәткәрләреннән шикаятьләрне карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча аңлатмалар алырга;

4) күрсәтелгән территориаль органнарның, оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының эшчәнлегенә мөстәкыйль рәвештә яисә компетентлы дәүләт органнары, вазыйфаи затлар һәм дәүләт хезмәткәрләре белән берлектә тикшерүләр үткәрергә.»;

16) 29 статьяда «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга;

17) 30 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмаларның,» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

«1[1]. Эшчәнлекләренә җитәкчелекне Россия Федерациясе Хөкүмәте башкара торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, шулай ук федераль буйсынудагы оешмалар, аларның вазыйфаи затлары аларның карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр каралганда федераль законнар нигезендә түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) күрсәтелгән территориаль органнарда һәм оешмаларда булып китү өчен Вәкаләтле вәкилне тоткарлыксыз кертергә;

2) шикаятьләрне карау өчен кирәкле белешмәләрне, документларны һәм материалларны Вәкаләтле вәкил соратып алуы буенча бирергә;

3) Вәкаләтле вәкил соратып алуы буенча, күрсәтелгән территориаль органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларыннан һәм дәүләт хезмәткәрләреннән шикаятьләрне карау барышында ачыкланырга тиешле мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә.»;

18) 31 статьяның 2 өлешендә «мөрәҗәгать итүченең һәм башка затларның шәхси тормышы турында үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә мәгълүм булган белешмәләрен язма ризалыгыннан башка фаш итәргә хокуклы түгел» сүзләрен «шикаятьне карау барышында шикаять биргән затның һәм башка затларның шәхси тормышы турында аңа мәгълүм булган белешмәләрне әлеге затларның язма ризалыгыннан башка фаш итәргә хокуксыз» сүзләренә алмаштырырга;

19) 32 статьяда «хокукларын һәм ирекләрен» сүзләрен «хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы $1^1$ өлеше нигезләмәсе (әлеге Закон редакциясендә) «Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең эшчәнлеген камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр башланган, күрсәтелгән Федераль закон үз көченә кергән көнгә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасын биләп торган зат сайлап куелган срокны исәпкә алмыйча кулланыла.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2015 елның 27 июне
№ 42-ТРЗ